# Казан утлары

5
МАЙ — 1970

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК ТУГЫЗЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

**5**

МАЙ
1970

## БУ САНДА:

### ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯ, ШИГЫРЬЛӘР

Ш. МАННУР. Ник онытылмый... Шигырь . . . 3
Н. АРСЛАНОВ. Шагыйрьгә. Бер мизгелдә... Мамай курган. Аһ орабыз... Кан шикелле... Атлантида. Мин газазил булып баш күтәрдем. Кайгыдан да, шатлыктан да... Шагыйрь җаны. Тәнге шигырь. Йорт казлары. Палубада. Шигырьләр . . . 5
Г. МӨХӘММӘТШИН. Йөрәктәге эзләр. Повесть. 13
З. МАНСУР. Чыклы иртә. Шигъри роман . . . 82
Р. ЗЫЯТДИНОВ. Бер телем икмәк. Хикәя . . . 89
Р. ЗАКИРОВ. Сагынып... Киткәндә... Сәяхәтче карт. Шигырьләр . . . 93
Р. ГАТАУЛЛИН. Мин бәхетнең ни икәнен беләм... Мин бу җирдә икәү кебек... Әллә ни әйтермен кебек... Күктә йолдыз сирәк кенә. Шигырьләр . . . 94

### ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Л. ШАКИРҖАНОВА. Юри генә. Бар әле. Яшел урам. Сине көтәм. Өле яз... Нигә! Шигырьләр . . . 96

### БӨЕК ҖИҢҮГӘ ЕГЕРМЕ БИШ ЕЛ

Маршаллар сүзе . . . 98
М. САДРИ. Ут эчендә очрашулар. Очерк . . . 100
Н. ДӘҮЛИ. Фронттан кайталмасам... Шигырь . . 112
З. НУРИ. Күңел дәфтәреннән Шигырьләр . . . 113
Ә. МАЛИКОВ. Бу гасырның корыч давыллары. Хаклы идең... Шигырьләр . . . 115
М. МАЗУНОВ. Хәтерлим аның зәңгәр күзләрен. Шигырь . . . 115
Генераллар сөйли . . . 116

### БАТЫРЛАР КИТАБЫНА

Н. ШЕВЧЕНКО. Ул — Матросовлар сафында . . . 123
А. АЙНЕТДИНОВ. Хөрмәт белән телгә алабыз . . 128

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ХАТЛАР, ИСТӘЛЕКЛӘР, ЯЗМАЛАР

Г. ӘПСӘЛӘМОВ. Ватан кайда да бер генә. . . 134
Г. БАКИР. Җиңү сәгате сукканда . . . . . . 138
И. ЭРЕНБУРГ. Татарлар. . . . . . . . . . 140
Фронттан хатлар. . . . . . . . . . . . . 142

ДУСЛАР ҖЫРЫ

К. ИВАНОВ. Тимер талкы. Баллада. . . . . . 146

БЕЗНЕҢ ИНТЕРВЬЮ

Б. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН. Республикабызның культура үсеше . . . . . . . . . . . . . . . 151

ХАЛЫК ИҖАТЫ

К. ДӘҮЛӘТШИН. Фольклорда стихияле материализм. . . . . . . . . . . . . . . . 156

АРХЕОГРАФ ЯЗМАЛАРЫ

М. ГОСМАНОВ. Тарихтагы тирән эзләрдән. . . 160

КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. ХӘЙРЕТДИНОВ. Данлы көннәр елъязмасы . 173
Р. МОСТАФИН. Чорның шигъри шәһадәтнамәсе. 175

Кечкенә рецензияләр . . . . . . . . . . . 179

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

Ш. ГАЛИЕВ. Төньяктагы дустыма хат. Чар. Кем белә! Кысла. Акбай белән Аккай. Шигырьләр. 182

А. ШАМОВ. Дустым турында . . . . . . . 185

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. . . . . . 189


Редакциягә килгән
кулъязмалар
кире кайтарылмый


Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.
**Хатлар өчен:** *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*



Баш редактор Зәки Нури.
Редколлегия: Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рафикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.



Производствога бирелде 27/II-1970 ел. Басарга кул куелды 15/IV-1970 ел. ПФ 09039. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 87.746 экз. Заказ С-121. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1970 ел.

## Шәйхи Маннур

### Ник онытылмый...

Чирек гасыр...
Күпме еллар үткән:
Онытыласы хәл бит күптәнге...
Ә ул миңа —
Гүя кичә генә беткән —
Онытылмыйча изә күпләрне.

Онытылмаган туплар гарасаты
Һаман әле колак чыңлата.
Үлем шашып узган юллар чаты:
Гәүдә ята...
Аяк, кул ята...

Һаман әле күргән төшләремдә
Бомбежкада калып уянам.
Уянам да:
Исән икәнемә
Окоптагы төсле куанам.

Аркаларга сеңгән кар суыгы
Эремәгән кебек һаман да.
Күңел тулы нәфрәт-ярсуымны
Ник суытмый икән заман да...

Төнге ике...
Кем соң коридорда
Шыгырданып,— тия йөрәккә?
Беләм:
Күршем шулай төн уздыра —
Юк аягы сызлап йөдәтә...

Чирек гасыр әлек җиңү килде —
Чирек гасыр тыныч яшәлгән.
Нәни уллар-кызлар үсә инде
Сугыштан соң туган яшьләрдән...

Ә тартмалар,
Китап эчләрендә
Кичә генә килгән хатлар бар.
Кичә генә...
Ләкин өсләрендә
Мең яшь тамган янар таплар бар!

Кичә генә киткән сыман итеп
Улын көткән чал чәч ана бар...
Җан сөйгәнен әле һаман көтеп —
Илле яшькә җитеп,
Тол утырган кызның
Күнелендә күпме яра бар!..

Дымсыз үрдә яфракларын койган
Ялгыз каен сыман хатыннар
Егерме биш еллык сагыш җыйган
Күзләр белән кемгә баксыннар...

Егерме биш еллык сагыш тулган
Тавыш әйтә:
— Кызым, әйдәгез
Өйне рәтлик әле...
Ерак юлдан
Кайтып килер, бәлки, эткәгез...

Чирек гасыр:
«Тигр», «фердинанд»лар,
«Мессер», «фокки», тагын «хэнкель»ләр
Үлеп калгач,
Яуда алкыш — антлар,
Кулны кысты безнең күп илләр...

Чирек гасыр...
Тыныч күктә уйный
Яңа исем:
«Локхид», «фантом»нар...
Напалм — җирне корыту көчен сыный,
Ак гөмбәсен җәя атомнар...

Төнге ике...
Кем соң тынгы тапмый,
Югалганны җирдә тәрәге?..
Беләм:
Күршем шулай шак-шок атлый —
Сызлый анын, сызлый йөрәге...

## Нури Арсланов

### Шагыйрьгә

Булса синдә Әфләтунның акылы,
Садәлеге керсез сабыйның,
Дәрвишлеге Хуҗа-Насретдинның,
Исәрлеге Мәшрәп сафиның,
Телгә оста булсаң Чичән кебек,
Уйга — йөгерек, дала атыдай,
Гаделлеккә Нәүширваннан гадел,
Юмартлыкта булсаң Хатымтай...
Анда да син камил түгел, шагыйрь!
Җитми әле Хәйям касәсе,
Һәрдәм тулы шатлык шәрабына,
Бар әле бар күкрәп яшьнәсе! —
Салават күпере салып күңелләргә,
Коясың бар хисләр ләйсәнен.
Кирәк сиңа Мәҗнүн мәхәббәте
Һәм илһамы гүзәл Ләйләнең!..

Син карванбаш нар дөягә охшаш —
Күпме йөкләр сиңа артыла!
Тик истә тот, иң мөкатдәс йөгең —
Тугрылыклы булу халкыңа.

[illegible]

### Бер мизгелдә...

Бер мизгелдә бөтен нәрсәләрнең
Юкка чыга кинәт мәгънәсе,—
Җан бушлыгы туа: кайгы, шатлык,
Сөю, нәфрәт...— буш сүз һәммәсе.

Тормыш шарты булган ыгы-зыгы
Һич кирәкмәс шәйгә әверелә,
Әхлак, вөҗдан — бер ясалма бурыч,—
Кайтам кире вәхши дәверемә...

Мин каһкаһә белән көләм шунда
Мескенлеген күреп кешенең:
Ул табынган потлар — курчаклыгын,
Фанилеген дөнья эшенең...

Ярый әле бу халәтем уза
Керфек кагар вакыт эчендә:
Мин бөтенләй айныйм һәм шатланам,
Котылгандай авыр төшемнән.

1969.

## Мамай курган

Мамай курган дигән һай курганның
Өсләрендә генәй таш сыннар.
Таш сыннарда чынлап корбаннарның
Каргышлары күккә ашсыннар!..
Йолдызларга бәрелеп яңгырасыннар,
Таралсыннар чиксез галәмгә:
«Ник котырдың, диеп, явыз язмыш,
Башкайларны кыеп әрәмгә!..»

Мамай курган кебек курган бармы
Дәһшәтләрне күргән, үткәргән?!
Күкрәгенә басып шул курганның
Ватан-ана кылыч күтәргән.
Ул күтәргән кылыч калсын иде
Шул көенә — чапмый яңадан:
Күпме генә тыныч дисәк тә без —
Сызланулар китми ярадан...

Курган өстен утлы кургаш япкан:
Табаннарны көйдерә басканда...
Монда ята үлмәс каһарманнар,
Сурәтләре мәрмәр ташларда.
Мамай курган дигән һай курганда,
Шул ташларга бәрелеп җил җылый,
Корбаннарны кысып кочагына
Мәрхәмәтле ана — Җир җылый.

1969.

●

Сугыш чукмарларына карата

Аһ орабыз сугышсалар хулиганнар:
Бу тупаслык бетәрме, дип, берәр заман,
Безнең чорда бу, дип, нинди ямьсез, яман,
Нинди кыргый, нинди җаһил, түбән җаннар!

Ә соң: «Дәүләт вә милләт!» дип лаф орсалар —
Бер-берсенә каршы илләр сугышсалар?!
Бу хәлне якласа вәзир, дипломатлар?!
Кайда мантыйк, вәхшилектән нәрсә аклар?

Кичерсә дә тәрәккыйле анча таңнар —
Юк шул җирдә «кеше»дән дә сәер җанвар...

1969.

●

Кан шикелле кызарып таң ата,
Гөнаһлары күпкә, ахрысы:
Кызара ул кичәгесе өчен,
Хәвефләнеп көтә бүгенгесен —
Сугыш башлар тагын кайсысы?!

1969.

## Атлантида

Атлантида булды микән чынлап?
Тынгы бирми сорау һич кенә:
Әллә кайдан, ерак-ераклардан
Һәлакәтле бер моң ишетелә...

Кинәт юкка чыккан бөтен кыйтга,
Тау-дулкыннар күккә ашканнар:
Бер мизгелдә илләр, шәһәрләрне,
Һәйкәлләрне сулар басканнар...

Океан убкан кебек Атлант җирен,
Дәүләтләрне монда җир убкан:
Дәшти-Кыпчак, Болгар, Алтын-Урда...
Бер-берсенең тамырын корыткан.

Ничә тапкыр килгән монда яулар,
Кичергәннәр илне кылычтан...
Калдыгын да көлгә дүндерергә
Миссионерлар күпме тырышкан.

Сәхифәләр тузган, юкка чыккан...
Ә без менә, без бар, булганбыз!
Фал ачабыз ләкин, баш ватабыз:
Әллә кыпчак, әллә болгар без?

Кем булгандыр бабам? Кыпчакмы ул,
Болгармы ул? — Нинди аерма?!
Татар дигән исем йөртәбез без,
Татар каны ага тамырда!

Атлантида! Атлантида баткан!
Эз калмаган бөек халыктан...
Ә без менә, без — бар, эз бар җирдә —
Без батырган саен калыккан.

Атлантида язмышы юк безгә,
Оныкларның ачык бабасы:
— Нәселең кем? — дип сорасалар әгәр,
Әйтерләр: — Без — татар баласы!

Татарстан дигән ватаным бар,
Татар дигән халкым бар минем.
Узганнардан түгел, мин халкыма
Киләчәктән урын барлыймын.

1969.

# Мин газазил булып баш күтәрдем

Замандаш монологы

Җирдә күрелмәгән һәйкәл булып
Менеп бастым ташка,
Кошлар, болытлар да миннән түбән —
Минем аяк аста.

Кулларымны суздым югарыга —
Күккә дәгъва кылам!
Фәләстиннар, Мәккәләрдән ерак,
Биек минем кыйблам!

Хыялларда, дәрттә рухланып мин
Очам кояшларга!
Күтәреләм — аякларым тими
Инде тау-ташларга!

Төшме, өнме? Үрелгәннәр бергә
Акыл, хыял һәм чын...
Я, шартлатсаң шартлат инде, әйдә,
Кайда, Хозыр, камчың?! —

Күкрәсен бер күкләр, атсын яшен —
Газамәтле күренеш.
Мин атланган сәмругларның хәзер
Канатлары көмеш!

Әнә, миңа хайран калып җиһан
Башын ия, чигенә:
Житәрмен мин, шик юк, житәрмен мин
Чиксез галәм «чигенә»!

Җирнең тарту көчен җиңеп чыктым —
Икәү тартышканда!
Шул минуттан Егерменче гасыр
Басты Пьедесталга!

Егерменче гасыр — гасырларның
Иң-иң рәхимсезе:
Бер котыптан бер котыпка ятты
Аның канлы эзе...

Алып китәр җилләр мәңгелеккә
Хиросима көлен,
Табармын мин эзләп планетама
Абелхәят күлен!

Егерменче гасыр баласы мин,
Акылым минем асыл.

Бар тылсымын беләм табигатьнең:
«Сизәм, ачыл! Ачыл!»

Әфсүннәрнең барлык ачкычлары
Хәзер минем кулда:
Океаннарга чумам, күккә ашам!
Әкият бармы монда?!

Мин газазил булып баш күтәрдем,
Гафил булып калма,
Әгәр булсаң, я, сөр даргаһыңнан,
Көчең житсә, алла!

1969.

●

Кайгыдан да, шатлыктан да читтә калмам,
Фани, диеп, бу дөньядан баш тарталмам! —
Тормыш жамын тулысынча күтәрергә
Васыять иткән безгә бөек Гомәр Хәйям

1969.

## Шагыйрь җаны

Тигез түгел шул бу фани дөнья:
Берәү зирәк, берәү томана,
Берәү матур, берәү ямьсез туа...
Уйлый китсәң зиһен чуала.

Берәүгә гел бәхет килеп тора,
Берәү аны эзли, сорана.
Бәхет,— диләр,— бары язмыш кына,
Бәхет,— диләр,— бары шобага.

Димәгәе, әйдә фал ачсыннар!
Син яманга бер дә юрама.
Шобаганны, я тарт, нәрсә чыгар?!
Ни чыкса да ямансулама:

Бер нәрсә дә камил түгел жирдә,
Дип хикмәтле кеше юана.
Ә дивана өмет өзми бер дә,
Килер бәхет өчен куана...

Күңелнең күп иләс-миләс чагы...
Юк, үпкәле түгел мин аңа;
И әйбәт тә соң син, шагыйрь жаны!
Үзең хәким, үзең дивана.

1970.

## Төнге шигырь

«...Төнлә торган бәндәләр солтан икәндер, белмәдем».
*Һ. Салихов.*

Тын, караңгы бүлмә. Тып-тын акыл.
Йөрәк кенә уяу, талпына.
Өзелердәй булып үзәктә кыл
Чамасыннан чыгып тартыла...

Уята ул мена бүген тагын,
Тибә-тибә акыл — көндәшен.
Читлектәге коштай тетрән, кагын,
Тарсын, җаным, күкрәк төрмәсен!

Керфекләргә күпме яшь кунмаган,
Күпме форсат җилгә китмәгән!..
Йөрәктә дәрт һәрдәм артык булган,
Тик акыл гел җитеп бетмәгән...

Син акылны, тынычлыгын җиңеп,
Кыңгыраулар тагып, дугалап,
Житез, асау юрга итеп җигеп,
Айлы юлдан чаптыр — юргалат!

Уңлы-суллы җигелеп шул арбага,
Кафияләр, моңнар биесен,
Ишетелмәгән җырлар тусын яңа,
Соклансын да күңел сөенсен.

Сикереп торсын шагыйрь түшәгеннән,
Яшьлек югалтуын тутырсын:
Әсәрләнеп шул илһамлы төннән,
Шашып шигырь язып утырсын...

Тояк тавышы!.. Гүя йөрәк тавышы
Ераклардан килгән кайтаваз.
Тын түгел төн — уяу шагыйрь сагышы,
Чыңлап тора серле, моңлы саз!

1970.

## Йорт казлары

Кыйгак, кыйгак! —
Каз, каз.
Казның гомере аз, аз:
Бер көз, бер җәй, бер яз...

Кыйгак, кыйгак, кыйгак!
Канатларыбыз да ак,
Сүзләребез дә хак,
Хак, хак, хак.

Күндәм йорт казлары без,
Тиз үтә язларыбыз,
Бик кыска гомеребез:
Бер яз, бер җәй, бер көз...

Суга сугып шап-шап,
Канатларын как, как,
Язмыштан йөз каплап,
Яши бир кыйгаклап.

Өмәләр ясар җиңгәй —
Булыр гадәттәгедәй...
Бик кыска шул гомеркәй:
Бер көз, бер яз, бер җәй...

Кыйгак, кыйгак, кыйгак!
Очалмыйбыз ерак
Кыр казлары сымак:
Алар һәр яз кунак.
Каз, каз, каз!
Тик бер генә безнең яз...

1969.

## Палубада

Тыйнак кына баруын барабыз да
Сизмәгәнгә салышып,
Гаҗәп күпер ускән арабызда,
Иөрәккә юл ачып.

Салават күпере булып күзләр нуры
Күнелләргә үткән,
Балкып тора бәхет безгә туры,
Җирдән, әллә күктән!..

Үпкәләре, назы чагыла көйрәп
Өзелеп каравында:
«Хатын белән йөрү нигә кирәк
Бәхет корабында?!.

Нәрсә булган — булсаң үзең генә?..
Анда икәү бергә
Булыр идек гыйшык сәхнәсендә
Син — Таһир, мин — Зөһрә...»

Төшерә бит вәсвәсәгә шайтан,
Бер сүз әйтми-нитми.
Бер кулымнан хатын тотып алган...
Гүя исе китми.

Хатын-кызның китмиме соң исе! —
Алар сизгер була.
Дәшмәсә дә, «мин бар!» дигән төсле,
Кулдан кысып куя.

И тылсымлы күз карашы тегенең,
Тарта, өнди, аулый.
Күзләр яшьсез җылагандай, күңелем
Тавыш-тынсыз аглый.

Өзгәләнә, тыпырчынып карый,
Ямансулап ала...
Ай, шаярып бармак яный-яный,
Безнең белән бара.

Идел өсте алтын тәнкәләрдән
Җем-җем итә балкып.
Үз хәлемне үзем генә беләм...
Сорашмагыз артык.

1969.

Газиз Мөхәммәтшин

# ЙӨРӘКТӘГЕ ЭЗЛӘР

ПОВЕСТЬ [1]

13

Нурбаклар авылына килеп кергәндә, кич булган иде инде. Кояш зуп-зур, кып-кызыл шар кебек еракта-еракта — крепость стеналары шикелле киртләч урманнар өстендә, баер алдыннан бер минутка гына туктап, җирне күзәтеп тора сыман. Җир өстенә карангылык инеп, кояшның сурән кызыллыгы белән буталган иде.

Пычранып, арып-талып килгән машиналарны вак малайларның, кызларның шат тавышлары каршы алды.

— Әй, карагыз, карагыз, кояшны йота!..

— Кояшны крокодил йота!..

— Авызын киереп ачкан...

— Аю аның кирәген бирә хәзер!.. Ул аның билен сындыра. Кояшны коткара!

Айзат кояшка карады һәм искиткеч матур күренешкә ирексездән сокланып куйды. Бала-чага юкка гына гөр килми икән. Баеп барган түп-түгәрәк, кып-кызыл кояшка, авызын ачкан зур крокодил төсле, кып-кызыл болыт якынлашып килә. Аның киереп ачылган авызында хәтта тешләре бар. Кабарынкы гәүдәсе, бер якка кәкрәйтеп салган озын койрыгы бар. Рәссам гына болай ясарга мөмкин, аның да остасы гына...

— Йот-ты! — дип ухылдады бала-чага.

Кояш чыннан да крокодилның нәкъ тамак турысына килеп керде. Аннан капланды. Кинәт карангыланып китте.

Бер бәләкәй кыз нәни йодрыклары белән күзләрен уып кычкырып елап җибәрде.

Ләкин менә комсыз «аждаһа»ның койрык турында кызыл шәүлә хасил булды. Ул әкренләп җәелде, ачыкланды. Ялтырап кояш килеп чыкты. Авыл урамнарына яңадан моңсу кызыл яктылык җәелде.

---

[1] Дәвамы. Башы 3—4 саннарда.

Балалар кул чабып сикеренделәр, капка башларына менеп киттеләр.

— Ур-ра!.. Ур-ра!..

— Явыз крокодил кояшны жиңә алмады!.. Ур-ра!..

Нурбакның туып-үскән авылы кайсыбер район үзәкләренә торырлык зур булып чыкты. Машиналар кергән урамы да таш җәелгән, читенә канаулар казып агачлар утыртылган киң урам иде. «Парикмахерская», «Фотография», «Ясли» дигән язулар күзгә чалынып калды.

Урам барган саен киңәйде һәм машиналарны сары такта белән тышланган клуб янына китереп чыгарды. Клуб каршындагы бакчада тирәюньне яңгыратып радио сөйли иде:

— Перуакыт пер тауариш пелән пес сунарга цыхтых. Пара-партых, иц нимә оцрамат. Етләрепес көйеп йатты. Цәй ецкәле гәпләштех. Цәй ецкәле чыйынсах, тавыш киләт. Карасах айыу. Аттым, айагына тите. Кан шаулаты, ет парыф ошлат...[1]

Нурбак, Айзатның радионы аңларга тырышып тыңлап баруын күрде дә, татарча:

— Аптырамагыз, бу — безнең Себер татарларының теле була,— диде.— Аучы Фазылҗан бабай сөйли. Карт инде: 85 яшендә.

— Шулаймыни? — диде Айзат та татарча.— Бу нинди телдә сөйли соң — япунчамы, кытайчамы дип чыннан да аптырабрак бара идем. Һәммәгез шушылай сөйләшәсезме?

— Мине аңлыйсызмы соң? Мин дә шушында туып-үстем бит.

— Синдә диалект сизелми. Нәкъ Казан татары.

— Чөнки татарча укыйбыз, татарча язабыз. Дәреслекләрне сез бастырып җибәрәсез. Алтыда белгән ана телең алтмышта да онытылмый. Ана баланы ике кат тудыра бит: бер кат — тән биреп, икенче кат — тел биреп.

— Әйе, «ана мәм биргән, ана тән биргән, ана сөт биргән, ана тел биргән». «Денемнән дунәрмен, телемнән дунмәм», дип яшәгән горур кешеләрне яратам мин, Нурбак.

— Иң татлы тел — туган тел, анам сөйләп торган тел шул, Айзат дус. Тукай белмичә әйтмәгән:

И туган тел, һәрвакытта ярдәмең белән синең,
Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем!

И-их, колакларга шул кадәр ягымлы: ефәк җепкә сәйлән тезәмени! Миңа Фазылҗан бабайның «пес»ләре, «цыхтых»лары моңлы музыка булып ишетелә...

Радио якын-тирә урамнарга:

— ...Айыу паласы агацка менгән ите, атыв-алтых. Паласы еттән олло ите...[2] — дип, күңелле ау турында сөйли калды, машиналар кырыйдагы таррак урамга борылып керделәр дә озынча өй янына туктадылар. Өй эчендә утлар яна иде инде. Челтәр пәрдәләр аркылы томанлы гына булып ак караватлар һәм өстәл тирәсендә ашап-эчеп, укып утырган кешеләр күренә иде.

— Бүген шушында йоклап, иртәгә иртүк кузгалабыз, иптәшләр,— диде шофер.— Бүтән җирдә кунучылар булса, бишкә килеп җитегез.

— Әйдәгез, безгә барабыз. Өй иркен, урын-җир табылыр, дигәндәй, гаеп итмәссез,— диде Нурбак.

Ләкин иптәшләре аның кунакчыллыгыннан файдаланырга кыенсындылар. Шофер, мин үз кешеләребездән аерылмыйм, безгә монда һәр вакыт урын бирәләр, диде. Уйчан кеше белән Аучыга кунак йортында

---

[1] Бер вакытны без бер иптәш белән ауга чыктык. Бардык, бардык, һич нәрсә очрамый. Этләр кайгырып ятты. Чәй эчмәкче булдык. Чәй эчәргә җыенган гына идек, тавыш килә. Карасак — аю. Аттым, аягына тиде. Кан шаулап ага башлады. Эт барып ябышты...

[2] Аю баласы агачка менгән иде, атып алдык. Аю баласы эттән олы иде...

урын табылды. Петр Петрович таныш укытучысына китәргә ниятләде һәм үзе белән Тамараны да чакырды, кордашымның да нәкъ синең шикелле җиткән сылу кызы бар, иркенләп ял итәрсез, диде.

Нурбак берни дә эшли алмады. Юлчылар ана кат-кат рәхмәтләр укыдылар һәм... кояш чыккач күтәрелгән томан шикелле эреп югала тордылар.

Өмете өзелә башлаган Нурбак Айзатның беләгеннән эләктереп алды.

— Син барырсың бит, Айзат?

Айзат Петр Петровичка карады.

— Барыгыз, дускай,— диде мөдир,— рәхәтләнеп ял итәрсез. Ә сез, журналист иптәш, аны иртән уятырга онытмагыз. Соңга кала күрмәсен.

— Есть, иртүк уятырга! — дип кычкырды Нурбак, ялгыз кунак кына булса да кулга төшерүенә шатланып.

Петр Петрович һәм Тамара, Нурбак белән хушлашканнан соң, кунакка чакырып китеп бардылар. Нурбак алар артыннан күзләрен тутырып карап калды.

Чатка җиткәч, Тамара артына борылып:

— Нурбак, фотоларны җибәрергә онытмагыз, мин көтәм,— диде.

Нурбакның авызы ерылды.

— Тамарочка, онытаммы соң! Сездән алда барып җитәр! Үзегез дә мине онытмагыз! — дип кычкырды.

Тамаралар чаттан борылып күздән югалды.

Егетләр шул урам буйлап аска төшеп китте...

Нурбакларның өе авылның читендәрәк булып, суга төшә торган тыкрык башында үзенә күрә нык бер крепостька охшап тора иде: һәр яктан юан нарат бүрәнәдән салынган келәт-каралтылар һәм бүрәнәне икегә генә ярып эшләгән койма белән әйләндерелгән. Койма буйларына таудай каен әрдәнәләр өелгән. Урыс капка. Дүрт кырлы капка баганасына ат бәйләү өчен авыр тимер боҗра кагылган. Бәләкәй капканың да тоткасы шундый ук тимер боҗра.

Чыпчык та очып керерлек түгел бу ихатага.

Урамдагы башка өйләр дә моннан күп калышмыйлар иде. Урам-крепость!

Агач күп шул, агач, җаннары теләгәнне эшлиләр. Кара әле син, нинди юан, шома каеннарны әрдәнәгә турап өйгәннәр.

Нурбак эчкә атлады, аның артыннан кыяр-кыймас кына Айзат керде.

Биек болдырда нәрсәдер эшләп йөрүче тугыз-ун яшьләр тирәсендәге кыз, керүчеләргә карап алды да таныгач, шатланып:

— Әткә [1], цәцәкә [2] кайтты! — дип кычкырды. Берәү дә җавап бирмәгәч:

— Инәкәү [3], инәкәү!..— дип йөгереп сөенче алырга кереп китте.

Өй эчендә нәрсәдер дөбердәп ауды, тәрәзәләрне балкытып ут кабынды. Киереп ишек ачылды һәм болдырда бер ир кеше күренде. Ул, Нурбак янында ят егетне шәйләгәч, бер генә секундка тукталып калды. Ләкин шунда ук үзен кулга алды. Чын күңеле белән куанып:

— А-а, кайттыңмы, улым, кайттыгызмы? А-а, кунак та бар икән. Кунак төшсә, йортка ямь. Кунак — хуҗаның чәчәге!.. Әйдәгез, рәхим итегез! Ә мин әле әзрәк ятып торган идем,— диде.

— Әти, танышыгыз, бу минем юлдашым Айзат. Казан егете. Машинада бергә кайттык,— диде Нурбак.

Хуҗа ипи күрәге шикелле зур учы белән Айзатның кулын кысты.

— Асулы казан, пешүле аш бар. Рәхим итегез! Мин Нурбакның әтисе Туктабай булам. Бүген кайтып җитмәсләрме дип тора идем инде.

---

[1] Әти.
[2] Кече абый.
[3] Әни.

Айзат кулын артына яшереп авырткан бармакларын бөгеп карады. Ике бармагы юк икән, өч белән генә кысты әле, дип уйлады.

Өй бик иркен иде. Ишектән кергәч тә ипи сала торган зур мичле кухня ягы, аны узгач түгәрәк мичле олы як. Анысы такта белән икегә бүленгән. Чиста һәм бай. Зәвык белән җыештырылган.

Туктабай:

— Әле ятып торган идем. Гафу итәрсез! Ацу күрмән [1] — дип, сөйләнә-сөйләнә ишек янындагы диванны җыештырып куйды. Әле бер, әле икенче бүлмәгә кереп мәш килеп йөрде.

Нурбакның атисе цирк көрәшчеләре шикелле зур гәүдәле, зур башлы кеше икән. Йөзе кояшта, җилдә янып кирпеч төсенә кергән, киездәй калын чәчләре җиткән. Колакларын күмә язып, муенына асылынып төшкән. Бу аны, бер карасаң, үзенә ярамаган парик кигән артистка, икенче карасаң, карт стиляга кыяфәтенә кертеп күрсәтә. Кысыграк күзләре күңел серләрен дә, дөнья хәйләләрен дә бик тирән яшергән. Сакал-мыегы озын, ләкин шул кадәр сирәк: аларны хәтта детсад малае да һич ялгышусыз санап чыгар кебек.

Туктабай кала хәлләрен сорашып алды. Казан белән дә кызыксынды, шул арада авылдагы яңалыклар хакында сөйләргә дә, казан астына утын өстәп самовар куярга да өлгерде.

— Бигрәк бәхетле кунаклар булып чыктыгыз. Әниегез әнә мунча ягып йөри, үзем бүген бер цебе пуаслаган [2] идем... Әниегезне әйтәм, белми микәнни әле, бар, кызым, чакыр әниеңне,— диде.

Бәләкәй кыз абыйсының тезеннән төшеп, шоколад кимерә-кимерә чыгып йөгерде.

— Менә шушы инде безнең эти,— диде Нурбак, Туктабай кухня ягына чыккач.

— Бик ачык кеше,— диде Айзат.

Нурбак җилкәләрен җыерып куйды. Гафу үтенгән шикеллерәк тон белән:

— Ләкин кызу канлы. Дулый башласа, ияр күрмәгән айгырдан яман,— диде.

Кыз йөгереп кереп, шоколад чәйни-чәйни:

— Ка-ата,— дип хәбәр бирде.

Кыз артыннан ук:

— Ай әттә! Ай әттәнә [3]! Белмәй торамын гуй,— дип сөйләнә-сөйләнә Нурбакның әнисе кайтып керде. Башта улы белән, аннары кунак егете белән ике куллап күреште. Яулык почмагы белән күзләрен сөртте, әледән-әле улына карап:

— Айыбы күрмәң [4]! — диде.— Айыптан тайып килептеләр пу йакка [5].— диде.

Айзат Нурбактан әкрен генә:

— Шәһәрдә күп тордыңмы әллә? — дип сорады.

— Юк, районнан ычкынып булмый. Редактор бик кырыс адәм. Утыз чакрым җирдән өч ай кайткан юк иде. Бер-ике көн торам әле. Җае чыкканда файдаланып калырга кирәк. Ә редакторга бүген кайттым диярга дә була.

Быгырдап самовар кайнап чыкты.

Өстәл янына утырдылар.

— Син, Айзат дус, оялып утырма, хәзинәдә ни бар — аша-эч. Безнең халык кунак яратса да, кыстый белми,— диде Нурбак.

— Без дә кыстаганны көтмибез.

---

[1] Ачуланмагыз.
[2] Тавык суйган идем.
[3] Үкенүне белдерүче ымлык.
[4] Гаеп итмәгез!
[5] Көтелмәгән кунаклар турында әйтелә.

— Шулай кирәк. Дөрес. Югыйсә тегендә күчтәнәчләрне бүлешеп ашап кына котылдык.

— Әллә ач йөрдегезме, улым? — дип, борчылып сорады әнисе.

Нурбакка ул хәлләрне кыскача гына сөйләп бирергә туры килде.

Әтисе, әйткәннәренә куәт бирергә теләгән шикелле, өч бармаклы йодрыгын өстәлгә бәрде:

— Бездә дә шулай булачак. Бүген түгел икән күр дә тор. Менәрләп килерләр. Завод-фабрикалар салырлар. Бар анда алмаз, коны[1] сазында алмаз булырга тиеш,— дим мин.

Туктабай агайның кысык күзләре ялт-йолт килә башлады, тәлинкә тоткан бармаклары дерелдәп китте. Кәлбикамал апа сүзне икенчегә борырга ашыкты:

— Цосы-боцы[2] сүләшкәнче ашап утырыгыз әле.

Туктабай ага тынычланып, сирәк сакалын бармаклары арасыннан үткәрә-үткәрә:

— Дөрес, Кәлбик. Әйдә, сыйла кунакларны. Чәйдән соң мунча кереп алырсыз, мунчан житкәнме инде, корткайак[3]? — дип сорады.

— Ие, Туктабай.

— Ярый. Мунчадан чыгуларына цебе шулпасы янына тагын ниең бар?

— Шөшвәрә[4] куйсак, Туктабай?

— Бик әйбәт! Шулай итәрбез...

Егетләр өстәл янынnan торып мунчага киттеләр. Мунча агач бакчасының түрендә чишмәгә якынрак урында икән. Нурбак, бакча аркылы үткәндә, ике тармаклы карт шомырт төбендәге агач сәкегә карап уйланып торды, җанлы әйберне сыйпагандай аны сыйпады.

— Синең урынмы? — дип сорады Айзат.

— Минем урын,— диде Нурбак әкрен генә һәм сәке тактасын яңадан сыйпап куйды. Аннан көрсенеп өстәде.— Хәер, минеке генә түгел, икебезнеке бу. Без аның белән шушында утырып таңнар атуын карарга ярата идек...

— Ә хәзер?

— Кияүдә... Кемнең газизе кемгә булмый!..

— Соң... Нишләп... Кайсыгыз дигәндәй?..

— Үзем. Үзем җүнсез булдым. Типографиядәге линотипистка белән шаярргалап кинога-фәләнгә барыштырдым. Ә ул бик горур һәм гарьчел кыз иде... Әһһһ!..

— Да-а!..

— Үткән эшкә үкенмә, гомерең зая үтәр дип әйтәләр дә соң — үкенмичә булмый, малай...

Нурбак үкенечле мәхәббәтенең тарихын сөйләп бирде. Шуннан соң берәүне дә ярата алганым юк, яратырмын дип тә уйламыйм, диде. Исәр башымны алып әллә кайларга олагырга, җир читенә китеп югалырга дигән көннәрем күп, дип көрсенде. Тамара аңа охшаган. Беренче күргәч, чәч төпләрем чымырдап, тәнем эсселе-суыклы булып китте: алдыма үкенечле мәхәббәтем килеп баскан дип торам, дип авыр сулады.

Айзат, үз чиратында, Чәчкә белән танышкан бәхетле май кичennән алып Казан вокзалында саубуллашкан төнгә чаклы хәлләрен бер-ике сүз белән аның үзенә сөйләп чыкты.

— Сез — бәхетле-е! — диде Нурбак.— Бәхетеңне бер яклап калгансың икән, икенче ычкындырма. Аны алтын-көмешкә дә сатып алып булмый. Аның өчен йөрәк каныңны бирергә кирәк.

— Мин дә аз түләмәдем.

[1] Себер бурсыгы — россомаха.
[2] Юк-бар.
[3] Карчык.
[4] Пилмән.

— Ышанам. Барып урнашу белән телеграмма сук. Урал таулары аркылы кош кебек очып килеп җитәр.

— Ник аның канатларын талдырырга? — дип елмайды Азат.— Үзем кире очсам, шәбрәк булмасмыни?

— Үзең кара. Кеше үз тормышына үзе баш. Тормыш юлын үзе билгели. Ләкин ул юл якты булырга һәм бу яктылык, фәкать хуҗасына гына төшмичә, әзрәк башкаларга да төшәргә тиеш... Баш мәкаләме? Газетачы шул мин... Әйдә керик, эти-әниләр зарыкмасын...

Егетләр рәхәтләнеп юындылар. Мунчаның уттай кызган ташларына квас сибеп, хан кызларын терелтә торган хуш исле каен себеркесе белән пошкыра-пошкыра, ухылдый-ухылдый чабындылар. Авыр юллардан соң мунча ләззәте бермә-бер арта икән. Малайларга хәл керде, сөяк-санаклары йомшарды.

Мунча чыккач, Туктабай агай яшьләр тирәсендә киләп сарып йөрде дә, ахыр чиктә түзмәде:

— Мунчадан соң берәр рюмка гына арак [1] эчеп җибәрсәгез ничек булыр икән, егетләр, ә? — дип сорады.— Суворовның да әйткән сүзе бар бит бу турыда.

Суворовның да әйткән сүзе булгач, егетләр баш тартмадылар. Закускалар да менә дигән иде: тозлы гөрҗә, тавык, салат, күкәй тәбәсе, өй казылыгы, юка [2], балыклар һәм башкалар иде. Кәлбикамал апа пешергән баллы-баллы камыр-комыр әйберләре, вареньелар, бу өстәлдә урын җитмәгәнлектән, икенче өстәлгә куелды. Тавык шулпасыннан соң табак белән данлыклы себер пилмәне килде. Мондагы гадәт буенча, башта чәй бирелде. Айзат, чәйләрне аштан соң эчәргә гадәтләнсә дә, бу юлы бик яратып эчте: мунча сусаткан иде.

Өстәл янында озак утырдылар. Туктабай агайның көрән йөзе кызарып чыкты, күзләре ялт-йолт килә башлады. Кул хәрәкәтләре кискенләште. Ул да, Кәлбикамал апа да Казан «нугаен» ашамлыкларның иң тәмлесен, иң олысын өсти-өсти ярышып сыйладылар. Аның авызыннан чыккан сүзен күтәп кенә тордылар, кыскасы, «бер алдына, бер артына төштеләр».

Әти белән әни кеше өч-дүрт айга бер күренеп китә торган сөекле малайларын да исләреннән чыгармадылар. Сый-хөрмәт аңа да Айзаттан ким әләкмәде. Кәлбикамал апа улының сылу йөзеннән мәхәббәтле күзләрен алмады. Бәләкәй кыз абыйсы янында анын беләген тотып, йокы белән көрәшә-көрәшә, озак кына утырса да, ахырында түзмәде. Күзләре йомылды, башын абыйсының киң җилкәсенә салып, тәмле йокыга китте. Әтисе аны үз урынына чыгарып салды.

Туктабай агай, чәшкеләр бушаган саен, Кәлбикамал апага ымлап:

— Кәлбик, цай кой [3]! — дип торды.

Үзе хрусталь рюмкаларга «акны» да коярга онытмады.

Урал таулары артындагы киң тайга кочагында гомер сөрүче, бүгенге кичкә кадәр аның дөньяда яшәвеннән-яшәмәвеннән хәбәре дә булмаган бу чит-ят кешеләрнең үзен сагынып көткән кадерле кунак шикелле каршы алулары һәм ярыша-ярыша сый-хөрмәт итәргә тырышулары Айзатның күнелен нечкәртеп җибәрде. Туктабай ага белән Кәлбикамал апаның, олы башларын кече итеп, аның алдында кырыкка сынарга әзер торуларына оялса да, эченнән рәхмәтләр укып, сөенеп утырды. Кәлбикамал апага караган чакларында бу сөенечле хисләренә, үзенә дә ят һәм кирәкмәс тоелган, кызгану сыманрак икенче тойгылар да килеп кушыла иде.

---

[1] Аракы.
[2] Күзикмәк. Себер татарларының һәр мәҗлестә куела торган яраткан ризыклары.
[3] Чәй яса.

Кәлбикамал апа Туктабай агайның гел киресе иде. Туктабай агай үгез шикелле таза булып, көчен кая куярга белмәгән шикеллерәк тәэсир калдырса, хатыны ялан уртасында көзге җилдән сыгылып-бөгелеп торган нечкә тал кебек иде. Биле нечкә, иелсә өзелеп китәргә тора. Шуның өстенә буе дә бәләкәй булып, иренең җилкәсеннән генә. Ябык ак чырай. Улына сөеп һәм сокланып карап утырганда да, иренә, и Туктабай дип тиз һәм бераз каушаганрак караш ташлаганда да, хәтта мәзәк сүзләрдән куанып көлеп җибәргән чакларында да аның эчкә баткан күзләрендә яшерен сагышы сүнми-сүрелми. Өен кунак өе шикелле җыештырып чиста тоткан, эшләгәндә кулллары-кулга йокмаган бу хатынның күзләрендә шатлык һәм канәгатьлек нурлары бөркеләсе урынга, сагыш билгеләре күру кич буе Айзатның йөрәген чәнчеп, әчеттереп торды.

Айзатның җиңелчә генә башы әйләнә башлагандай тоелды. Ул, чираттагы рюмканы күтәрергә вакыт җиткәч:

— Торсын әле, бу юлы минсез генә эчегез,— диде.

Нурбак та үзенекен читкәрәк этеп куйды.

Туктабай агай кысык күзләрен тагын да кыса төшеп елмайды да:

— Их цебе палалар! [1] — диде һәм, озын мыегын ирен читләренә сыпырып, рюмкасын «йотып» куйды.— Менә ничек эчәдер идек без яшь чакта...

Кәлбикамал апа аның кулын тотарга теләгәндәй омтылыш ясады, ләкин өлгерә алмый калды. Иренә ялынулы караш белән:

— И Туктабай, и Туктабай!..— диде.

Туктабай моңа каршы, чебен куган шикелле итеп, өч бармаклы кулын гына селтәде.

— Кысылма, корткайак!..

Нурбак та нидер уйланып утырганнан соң, читкә карап:

— Бәлки бүгенгә җитәр, эти? Без юл кешеләре. Утырып кына килсәк тә арыткан,— диде.

— Һей,— диде этиләре,— өеңдә кунак утырып та гулять итеп калмагач... Дөньясын әйтим!.. Сөйләрмен әле мин сиңа. Әбиҗәйт итәләр этиеңне... Һей...— Ул тагын салып ялгызы гына эчеп җибәрде.

Кәлбикамал егетләргә пышылдады:

— Сез мунчага киткәч тә эчкән иде. Кодаем...[2]

Ата кеше хатынының пошынып пышылдавын әллә ишетмәде, әллә ишетеп тә колагына элмәде, каты каймакка манчып тозлы гөрҗә кабып җибәрде дә, Нурбак белән Айзатка мөрәҗәгать итеп:

— Әйдә, йыру ерлыйбыз. Йыруның ертыгы юк, ертылса — ямавы юк,— диде.

— Куй-цы, сүләмә-це! Карын төп йоклаган гуй [3],— дип, Кәлбикамал апа аны тыярга тырышты.

— Тик кенә утыр, корткайак,— диде Туктабай агай, аңа карамыйча.— Я, журналист, башла. Таршайып [4] өлгермәгәндерсең бит әле?

Нурбак күзлеген тотып куйды.

— Таршаймадым. Без — юл кешесе, ардык. Ятарга да вакыттыр. Син дә ят, эти, авырайдың.

Туктабай улына җавап бирмәде. Сирәк сакалын бармагына урый-урый уйланып утырды да, тавышы әйбәт кенә булса да, бераз салпышлыгы белән бик каты көчәнүдән «әтәч» очырта-очырта җырлап җибәрде:

Тувыл ла урам, әй, сас кына,
Пасатогон йере мус кына.

---

[1] Чебешләр.
[2] Ходаем.
[3] Китсәнә, сөйләмә! Төпчек йоклаган ич.
[4] Масаеп, борын күтәреп.

Иатсам да төшемтә, торсам да исемдә
Иарым әйткән сүс кенә [1].

Туктады да тамак төбе белән «ык» иткән тавыш чыгарды. Бармагына ураган сакалын кире сүтте һәм икенче җиңелрәк көй башлады:

Иртеш суын салгын, тиләр,
Атларга ецергәле.
Мөкәппәт ул — көлләр түгел
Иатларга куцергәле [2].

Я, кунак, ярыймы Сепер җырлары?

Айзат, йокысы килеп, тизрәк туктаса ярар иде дип утырса да, «кунак булсаң тыйнак бул»ны исенә төшереп, алдашырга мәҗбүр булды:

— Бик әйбәт, Туктабай агай, тагын җырлагыз әле!

— Туктабай, и Туктабай, ятар иден...

— Әкрен, Кәлбик. Касан [3] кунагы сорый бит: кунак алдында тупрак [4] булыйм. «Галияпану»ны йырлаем да... Ыхы-ым...

Түр тәрәзә төпләрентә
Кемгә кийем пецәсен,
Агылын камил, пуйын сифа,
Галия-пану, сылуым-иркәм,
Кем пәхтенә үсәсен?

Көй озын булганга, Туктабай агай бу юлы «әтәч»ләрне күбрәк очырды. Туктагач та сулышын еш-еш алып, тамак кыргалап хәл җыярга мәҗбүр булды. Өстәл читенә таянып, авыр гына урыннан кузгалды.

— Кунакларны арыттык. Я, ятып йокласыннар.

— Урыннар җәелгән, почмак бүлмәдә,— диде Кәлбикамал апа һәм урын-җирне тагын бер кат карап-тикшереп чыккач:

— Шикләнмәгез, чиста җәймәләр яптым, мендәр-юрганнарның да тышларын алмаштырдым,— дип өстәде.

Айзат, ниһаять, күптән көткән бәхетенә ирешүенә шатланып, мамык шикелле йомшак урынга чумды.

— Синең белән сөйләшәсе бар әле — дип, Нурбакны әтисе олы якта алып калды.

Айзат көлтә төягән арба өстендә тирбәлеп барган шикелле рәхәткә тарды һәм озак та үтми тирән йокыга талды...

Ул нинди дер шау-шуга кисәк уянып китте. Якында гына кемнәрдер кычкырып-кычкырып сөйләшәләр иде. Айзат бер тын үзенең кайда булуын, бу тавышның нинди тавыш икәнен аңламый ятты. Аннан кылт итеп кичәге вакыйгаларны да, үзенең кайда икәнен дә исенә төшерде. Такта стенаның теге ягында Туктабай агай белән Нурбак сөйләшәләр. Хәер, бу «сөйләшү» күбрәк әрләшүгә тартым иде. Туктабай агай улын ни өчендер кызып-кызып шелтәли, аның нәрсәгәдер үпкәләгәнлеге сизелеп тора, ә Нурбак аны артык җилкендермәскә тели булса кирәк, әкренрәк тавыш белән җавап бирә бара, тавышны артыкка җибәрмичә бетерергә тырыша.

---

[1] Тувыл ла урамы, әй, саз гына,
Иөргән җире боз гына.
Ятсам төшемдә, торсам исемдә
Ярым әйткән сүз генә.

[2] Иртыш суын салкын, диләр,
Атларга эчерергә.
Мәхәббәт ул — гөлләр түгел,
Ятларга күчерергә.

[3] Казан.

[4] Туфрак.

«Сөйләшсәләр дә, ызгышсалар да үз эткәсе, үз улы, эти белән малае арасында нинди хәл булмас. Кеше сүзен тыңлап яту килешми», дип уйлады Айзат һәм башыннан ук юрганга төренеп ятты. Хәзер генә төшендә Чәчкәне күрә башлаган иде булган иде. Шул кадерле төшен бүлдерүләренә уфтанып, Хуҗа Насретдин шикелле, кабат ялганып китмәсме дип йокларга тырыша башлады.

Ләкин бүген йокларга язмаган икән — йоклатмадылар. Зал ягында тавыш көчәйде. Инде аннан, тыңлап яту килешми дип кенә котылу мөмкин түгел, колагыңа мендәр капласаң да ул барыбер ишетелә иде.

Туктабай агайның каты тавышы:

— Әйт син миңа, сезнең газетамы бу? Сез чыгарган газетамы?

Нурбакның әкрен тавышы:

— Кулында бит. Күреп торасың. Ник сорыйсың?

Туктабай агай, уфтана:

— Почтальон китергәч, ачып карасам, йөрәгем тамак астына килде. Фельетон!.. «Кола сыер хикмәтләре»!.. Ә мин монда мактанып торган булам. Минем малай журналист, редакциядә эшли дим. Ул анда райком секретарьлары белән на «ты» җибәрә димен.

Нурбак:

— Мактанмаска иде.

Әтисе аны тыңламыйча:

— Ишеттем мин монда. Комиссия киткәч, газетага язганнар икән. Туктабайга крышка дип авыл буйлап теш ыржайтып йөрүчеләр табылды. Ышанмадым, язсыннар, мине язсалар да минем малай шунда, ин первый аның кулына барып эләгә, дидем. Шунда ул мәкаләнең үзенә крышка дип өметләндем. Белдеңме син аны, күрдеңме үз күзләрең белән?

Нурбак, бераз тын торганнан соң:

— Күрдем.

— Нимә, нимә?

Нурбак, тыныч әйтергә тырышып:

— Күрдем дә, укыдым да.

Әтисе өстәлгә сукты, ахры, чәшке-тәлинкәләр зыңгылдап куйды.

— Соң?

Нурбак:

— Нәрсә — соң?

Атасы, тавышын тагын да күтәрә төшеп:

— Соң нишләп үзең шунда эшләп атаңа каршы мәкалә бастырып ятасың? Картупка баш![1] Атинә[2] кирәкми башладымыни хәзер? Бишектән төштеңмени? Кола сыерның арт ботын сиңа җибәрдем ласа! Ашаганда тын-тавышың чыкмады, ә? Хәзер атасы карак! Фельетон баса, оятсыз!

Нурбак, үзен тыярга тырышып:

— Хәрам ризык икәнен белмәдем... Иптәшләр алдында миңа да оят булды. Оятка калудан да авыр җәрәхәт юк. Оят үлемнән көчле икән. Ләкин басмыйк диярга телем әйләнмәде. Чөнки... фактлар дөрес. Алар хаклы, әти... Комсомол башым белән намусымны сатарга теләмәдем. Кылыч ярасы китәр, намус ярасы китмәс, диләр... Гафу ит!..

Туктабай, каһкаһә белән көлеп:

— Ха-а, комсомол!.. Менә мин... Нитүкмеште комсомол — заманында секретарь райкома булып торган кеше!.. Ха-а! Икенче Павлик Морозов!.. Атаңны бәлки төрмәгә дә яптырырсың, ә? Пожалысты!.. Улым бар дип торган идем — ялгышканмын.

Нурбак, өзеп-өзеп:

---

[1] Ангыра.
[2] Ата-ана.

— Эти, тыңла әле бер. Тыныч кына... Бүлмәдә кунагыбыз ята... Мин үзем дә синең белән күзгә-күз сөйләшергә җыенып йөри идем.

Этисе, әз генә басылып:

— Сөйләп бак!

Нурбак күңелендә күптәннән бирле йөрткән уйларын әйтеп калырга тели, шул ук вакытта әтисен ачуландырудан, каты бәрелүдән дә курка, сүзләрен сайлап сөйли:

— Эти... Тагын әйтәм, газетага язылган нәрсә — дөрес. Ә дөреслекне, ачы булса да, яшерә алмадым.

Этисе, мыскыл белән:

— Ала-ай, атаң белән янәшә райком тарантасына утырып авылдан-авылга йөрүләреңне яшерә алдың бит! Хәер, хәтереңнән чыккандыр: кечкенә идең...

Улы:

— Әйе. Мин сүзне шуннан башларга телим дә. Ул авыр елларда син секретарь идең. Халыкка икмәк җитмәде. Ә без?.. Юу-ук, без ачыкмадык. Дөрес, синең хезмәт хакың бал-май ашарлык түгел иде. Ләкин колхозларда булды. Тарантасның башы тулы-тулы кайткалый иде. Тик кешеләрнеке иде бит ул, эти!.. Эшләп түгел, кешнәп яраучы куштаннар күчтәнәче... Ә синең дөньяга һәм кешеләргә мөнәсәбәтең үзгәрүе яхшы якка булмаган, эти. Миңа акыл керә башлаганда, син беркем белән дә исәпләшмәүче бер тәкәббер идең. Ай эти, кешеләрне кешеләрдән аера, кешелектән чыгара торган шул сызыкны атлап узмаган булсаң ул чакларда! Кешеләр түбәннән башлый, югарыда тәмамлый. «Без түбәннән күтәрелдек» ди Галимҗан абый Ибраһимов та. Кеше туганда ук хөрмәткә лаек булып тумый, аны яулау җиңел түгел, син аны беләсең, эти... Кешеләр эштә түбәннән күтәреләә, еллар буена, әкренләп. Ә син, эти, югарыдан башладың — түбәндә тәмамлыйсын түгелме икән... эти...

Туктабай ярсып кычкыра:

— Син, көцөгәц[1], атаңны тәмамлаган дисеңме? Миңа үләргә кушасызмы?.. Ю-ук! Кара бу дөньяга! Кемнекеннән ким? Артык!.. Арты-ык!.. Кара миңа, кара бу күкрәк, җилкәләргә! Көцөгән[2] түгелме атаң!.. Көцөгән әле бу!.. Сезнең кебек сыек бавырлы интеллигентларның унысын йомам әле мин менә бу учка!..

Нурбак тавышы:

— Эти, мин тән тазалыгы турында әйтмим, рухи тазалыкны әйтәм.

Атасы тавышы — ачу белән:

— Дошманнарым күп булды ул чак, бәхетемнән, дәрәҗәмнән көнләштеләр. Минем урынга килгән Тувыл малае ни күптарды? Миннән ни уздырды? Барысы да шул көнләшүдән... Бар булсаң, күрәлмиләр, юк булсаң, бирәлмиләр... Ничә тапкыр килеп тикшерделәр Тувыл малаен?.. Ничә тапкыр астын-өскә китереп ташладылар, ә? Комиссия арты комиссия. Берсе килә, берсе китә. Даны олы, дәрманы коры булды малайның. Булдымы мин утырган заманда шундый эш? Халык күрде аның кем икәнен, күрде-е!..

Нурбак, этисенең тын алуыннан файдаланып, әйтеп калырга ашыга:

— Эти, гафу ит, ләкин нигә ике йөзләләнеп маташырга!.. Кемне алдыйсың? Бала-чага түгел бит... Син айгашлап[3] яттың бит суны, син яздың, син китерттең. Көнләштең. Хурлануына чыдый алмадың. Сине, шундый эш кыра торган секретарьны аударып, урынына ят-чит кешене, «ирененнән ана сөте дә кипмәгән бер малайны» утыртып куюларын башыңа һич сыйдыра алмадың. Ләкин кешеләр дөресен сизенделәр. Райфо мөдирлегеннән шул сәбәпле алындың.

---

[1] Эт баласы.
[2] Бөркет.
[3] Болгатып.

Атасы тавышы — ирония белән:

— Әйтеп бетер. Тыңлап багыйм аса-гөсә[1] улымны.

Нурбак тавышы, атасы кәефенә каты кагылмаска, йомшак әйтергә тырыша:

— Кеше күңеле балавыз, эти. Шуннан соң да сине бетереп ташларга куллар күтәрелмәде. Председатель итеп җибәрделәр. Ләкин син сынсан-сынасың, ләкин бөгелми идең. Район белән әрепләшә башладың. Ялгызың — бөтен районга каршы. Уенча, син генә хаклы, ә алар — йөз кеше хаксыз иде. Тормышта алай булмый. Башкаларны үзеңнән җүләррәк дип уйлау үзе...

Туктабай тавышы — кинәт зәһәр кабынып, тәрәзә пыялаларын зыңгылдатып кычкыра:

— Мин җүләрме?!. Атаңны җүләр дисеңме?!. Күземә карап?!. Телең әйләнәме?!. Арсар!..[2]

Нурбак тавышы — хатасын сизеп, гафу үтенгән тавыш төслерәк:

— Мин алай дип әйтергә теләмәгән идем...

Туктабай тавышы — үзалдына мыгырданып:

— Асгырганнар[3] баланы.

Нурбак тавышы — әкрен, үкенгән тон белән:

— Район күзеннән дә ераклашкач, бөтенләй патшага әйләндең. Җыелышларда үзеңә каршы беркемнән бер сүз әйттермәдең. Әйтсәләр, андыйларның якты көннәре караңгыланды.

Туктабай тавышы — мыскыллы:

— Корбан бәрәне булып, бар — сөйрәп кара колхозны!.. Бигрәк тә ул чакта. Җәһәннәм иде бит, җәһәннәм!..

Нурбак тавышы — ныгая төшә:

— Бүтән җитәкчеләр колхозларны авырлыктан чыгару өчен үзләре михнәт чикте. Үзләре теләп, эти.

Атасы тавышы — аны кинәт бүлдереп:

— Ичмаса төшендә күргәнең бармы ул чактагы колхозны? Бигрәк тә мине җибәргәнен? Мине абынып егылсын дип олактырды саз арасына. Давай сөт, ит, май! Американы куа идек... Бирмәсәң, подсуд иде башың. Ә кемнән савыйм мин сөтне?!. Саусам да кая тапшырыйм? Юл сал башта. Туфрак селтеле, икмәк үсми. Якты көн житми. Шулай да бодайны гектардан унар центнер алган чак булды. Ничек җыйганны беләсеңме син икмәкне — йөрәк каны белән, малай актыгы! Чөнки каккраз урак өстендә эрбет чикләвеге житешә. Күпчелек халык шунда шыла. Җый икмәкне шулар белән!.. Хәзер — атаң фәлән, атаң төгән. Туй беткәч, сүз, яу беткәч, батыр күбәя. Чор шундый иде. Хәзерге колхозлар булса-а!.. Кассадагы миллионнар белән нишләргә белер иде атагыз. СССР да беренчегә чыгар идем, герой булыр идем! Биетер идем кайберәүләрне... ых-хы!.. Пеләшләренә төкерер идем биек баскычка менеп... Мин... (Туктабай шарт итеп өстәлгә сукты, ютәлли башлады).

Кәлбикамал тавышы — әле генә сүз катарга батырчылык итте, ахры:

— И Туктабай!.. И, Туктабай!.. И балам!.. Нәмәкәйгә атарынасыз?[4] Пулауцы[5] көлерте үзегездән. Туктагыз!.. Кодаем, ятыгыз!..

Туктабай тавышы — кискен:

— Кысылма, Кәлбик!.. Кереп ят! Катын башы житәрлек сүс түгел.

Нурбак тавышы:

— Әнине кума. Безнең сүзне тыңларга хаклыдыр ич ул? Болай да гомере буе куылган кеше. Сиңа сүз әйтергә дә курка.

Анасы тавышы — ялварулы:

---

[1] Бердәнбер.
[2] Исәр, юләр.
[3] Юлдан яздырганнар.
[4] Пыр тузасыз.
[5] Юлчы (Айзат турында).

— Пала?!. Пала?!. Атана каршы!?.
Туктабай тавышы — шикләнеп һәм мыскыллап:
— Икәү сүз берләштегезме? Былчыракка салып таптагыз. Туктабайның күкрәгенә менеп сикерегез!..
Нурбак тавышы — әкрен:
— Бала булма, әти. Сүз йомгагының җеп очын онытмыйк... Кассада миллионнар булса, дисең. Мин ул чорны яхшы хәтерлим. Күрше колхозлар дәүләт хуҗалыгына әйләндерүләрен сорап дәүләткә мөрәҗәгать иттеләр ич. Аучылык-промысел хуҗалыгына әйләнгәч, алар акчалы булмадылармыни! Директоры үзенә сөйләде. «Ике ай эчендә мең кеш, уникe мең тиен тиресе әзерләдек, илле тонна эрбет чикләвеге җыйдык, өч йөзгә якын болан, пошый һәм кыр кәҗәсе тапшырдык, унбер мең саф табыш алдык, киләсе елда ун мәртәбә артык алачакбыз», диде. Сина да дәүләт хуҗалыгына әйләнергә киңәш бирде, теләмәдең.
Мин узган көзне ул директор турында мәкалә яздым. Миллионер. Ә син колхозның тәмам рәте киткәч, председательлектән «үз теләгең белән» китеп котылдың.
Туктабай тавышы — үпкәләп:
— Рәхмәт! Атагызны зурайттыгыз картаймыш көнендә... Әйе, атагызның бәхете булмады. Ни өчен булмады? Чөнки атагыз гомер буе сезне бәхетле итәр өчен тырышты, билен төкәйтте[1], юлында ни очратса да иелеп алырга иренмәде. Бөтенесен, әрләп шикелле, өенә ташыды. Сезгә! Ач-ялангач итмим, диде, кеше арасында шәп йөрсеннәр, шәп тормышта яшәсеннәр, диде. Йауган аш ашатмады[2]. Бүгенгесе көндә сез дошман күргән атагыз... Ник әлгәре тыныгыз чыкмады, ә?.. Хәзер атагыз искерде, ярамый. Миннән ояласыз. Оялмагыз. Мин оялырлык дөнья көтмәдем моңарчы. Карагыз бу имаратка[3]. Начармы? Элекке байлар да ирешмәде шундый тормышка. Бу өй әле тагын йөз ел торачак. Синең балаларыңның балаларына житә... Ярар, котылырсыз, үләрмен. Бөтенесе сезгә калыр, сезгә. Атай әшәке иде дип кешегә бирерсез микән?!.
Нурбак тавышы:
— Бу имаратка харам мал да кергән, әти.
Туктабай агай, кузгала башлаган җен ачуын соңгы кат тыярга тырышып:
— Тагынниләр әйтәсең калды — әйдә, чыгарып бетер. Аннан соң атаң әйтер.
Нурбак тавышы — ашыгып:
— Әйе, яман мал да кергән бу имаратка. Мәктәптә завхоз булып эшләгәндә буяу, такта, тегесен-монысын кайтармадыгызмы?.. Утсыз төтен чыкмый. Тагын бөтенесе юньсез, син генә акыллы идең. Мең бәла белән чыгардылар. Соңыннан «югалган» әйберләр өчен суд шактый түләтте. Инде бу фельетонга килик. Фермага бозау илт тә сыер алып кайт, ә? Тизрәк егып суй. Ярый әле, кеше сизенгәч, тизрәк түләп котылгансың. Юкса суд булмас идеме? Мин ничек аны йомыйм? Нинди кеше булырмын? Дөнья күзенә ничек багармын? Уйладыңмы шуны, әти! Бу эшләрең миңа оят түгелме? Җылыйм бит мин, җаным әрни. Атаң шулай...
Кәлбикамал апа тавышы, улын туктатырга теләп еламсырап кычкыра:
— Уай! Атаң пелән үртәшмә, асау[4] пала!.. Атаңның кысгыр[5] адәм икәнен белмисеңме әллә?!.

---

[1] Бөкрәйтте.
[2] Кысыр аш.
[3] Ихата, йорт-жир.
[4] Тискәре.
[5] Кызу канлы, тиз кызып китүчән.

— Беләм, әни, тынычлан! Хәзер бетерәм. Бер генә сүзем калды. Мәнә шул, әти, редакциягә синең турыда фельетон кергәч һәм аны укып чыккач, мин ике ут арасында калдым. Бер якта син — мине ашаткан-эчерткән, тәрбияләп үстергән, ниһаять, кеше иткән туган атам, икенче якта — мин үзем һәм минем намусым. Мин икенчесен сайладым, әти, гафу ит!.. Син гомереңне ялгыш яшәдең, әти. Кешеләр үсте, син — төштең. Әкрен-әкрен гел түбән тәгәрәдең. Я, син, әйт, мактана аласыңмы хәзерге көнең белән? Юк әти, син үзең дә хәзерге хәлеңнән ояласың, шуңа да кешеләргә, тормышка усал син. Ятма болай, әти, кер эшкә. Күрсәт үзеңне. Син машиналарны әйбәт беләсең бит. Шаккатыр тирә-юньне. Шатландыр безне, синең белән горурланыйк. Моннан түбән урын юк... Мин сиңа менә шуларны әйтергә теләгән идем. Бик күптән. Ачуланма!..

Туктабай тавышы — ярсып, өзеп-өзеп:

— Ачуланма дисеңме? Атаңның күзенә бер лакан шакшы су сип тә... атаң ачуланмасынмы? Миңа хәзер бүтән барыр урын да юк, ә? Әйт, шулаймы, апхана [1] сакчысы?.. Атаң башына алагарга [2] булып каргылдарга кайтып килдеңме?..

Кәлбикамал апа тавышы — жылап җибәрер төсле:

— И Туктабай, и Туктабай!.. Палам, ир йөткән пала бит син, нимәкәйгә атаңны арсытасың? [3] Тукта!..

— Ялынма, корткайак. Ул инде туктамас. Кабышмак [4] эткә әйләнгән. Ул... чагында... менә бу ризыклар харам икән... харам дип сөйлисез икән... ул чагында син үзең миңа... харам... харам... Яшәдек әле моңарчы... Синнән ипи сорап бармадык. Моннан соң да яшәрбез, бармабыз...

Кәлбикамал апа тавышы, әкрен генә жылап:

— И Туктабай!? И Туктабай!?.

Туктабай типте бугай: дөбердәп урындык ауган тавыш ишетелде.

— Син хәзер песгә ашагы [5] пала...

Урында болай тик ятып булмый иде инде. Айзат аңлады: Нурбакка да һәм ана да бу өйдә артык калу мөмкин түгел. Өйдә давыл. Ул давыл ике егетне карангы төнгә очыртып чыгарачак. Ата һәм ул дуслыгының бүген кич бер кырые кителде. Үпкәсен һәм рәнҗүен ничә еллар буена күнеленә җыеп тешен кыса-кыса түзәргә тырышып килгән баланың сабыр капчыгы бүген кич чишелде. Атасы алдына күңел капчыгын чыгарып селекте егет. Бу авыр сөйләшү иртәме-соңмы барыбер булыр иде. Айзат шулай аңлады. Ул әле Нурбакны да, аның этисен дә якламый, дөресрәге, бу кандашлар бәрелешүеннән әле нәтиҗә ясарга өлгермәгән иде. Бер яктан, бала хак булса, икенче яктан, ата хакы да зур. Ата хакы — тәңре хакы. Әти-әнисен тирән хөрмәт итүче авыл малаеи соңгысы да тәшвишкә төшерә...

Айзат, жылы урыныннан торып, урындык аркасыннан чалбар-күлмәкләрен алып киде.

Давыл үзенең иң югары ноктасына күтәрелгән иде инде.

Туктабай тәмам чыгырыннан чыккан, күңелендә булган үпкә һәм зәһәрен кычкырып калырга тырыша.

— Бар, бар, кит! Чыгып кит минем өемнән!.. Икенче кайтып ишек шакыйсы булма ләкин. Шакысаң да кертмәм. Уйлама!.. Минем канны беләсең. Канымның нинди икәнен беләсең...

Кәлбикамал апа тавышы, күкрәгеннән өзелеп чыга:

— Соң... ул да синең үз палаң бит! Аның да каны синеке шикелле. Кандашлар бит сез!..

---

[1] Бәдрәф.
[2] Козгын.
[3] Котыртасың.
[4] Тешләшә торган.
[5] Чит-ят.

Туктабай тавышы — усал, лэкин бәйләнешсез, өзек-өзек:
— Катын, син тыгылма! Ирләр сөйләшә... Әйе, кандашлар. Миндә кеше каны өч литр... Менә бу ике бармагымны немец минасы өзеп китте... Э-э-э... Нинди гармунчы идем мин, нинди гармунчы!.. Минем бер калак сөягем юк. Мин җеннәнсәм, бер нәстә дә эшләтә алмыйлар... э-э-э... Кандаш. Үз малаем!.. Минем бер калак сөяге, минем ике бармаккаем!.. Немец... Фашист ашады башымны. Э-э-э...
Кәлбикамал апа тавышы, борчулы, куркулы:
— Атасы, атасы!.. Тынычлан, сиңа әйтәм... Барысы да бик әйбәт... Улым! Улым!.. Атасы!..
Нурбак тавышы, ашыгып һәм борчылып:
— Әти, әти! Бетте, әти. Мин болай гына... Кызып кителде. Ялгышлык миндә, әти. Гафу ит мине, әти!.. Менә су эч, әти, ят, әти, ял ит, әти!..
Туктабай тавышы — тотлыгып һәм әкренәеп:
— Сез бу дөньяны ничек төзерсез икән. Үзегезчә... Минем бер кабыргам юк. Миңа өч литр кеше каны җибәрделәр. Үз каным юк минем. Э-э-э, синең дә каның юк, ю-ук!.. Чыгып кит! Урын юк сиңа монда, беләсеңме?!. Бар! Югыйсә яндырам, кырам, чукындырам!.. Мине тынлый иде халык. Берәүләре мүкәләп тә йөрделәр. Ә хәзер мин... Дөрес... Нишләп терәлеп каттың? Кит! Минем калак сөягемне кисеп алдылар. Мине фашист тәреләре... Ояласыңмы миннән?.. Оялмаслык итеп сез төзеп карагыз дөньяны... Чыгып кит!.. Кайтма мәңгегә!..
Кәлбикамал апа, җылап:
— И Туктабай!.. И Туктабай!.. Кереп кенә ятсана!.. И улым!..
Айзатның күкрәгендә кинәт кенә нәрсәдер кузгалгандай булды. Сәетбатталлар нәселенең горур каны уйнау идеме бу, әллә Нурбак өчен пошыну идеме — ул аны белмәде. Торып басты. «Болар нишләп минем алда күптәнге исәп-хисапларын өзәләр әле? Кунакларын нишләп әз генә дә хөрмәт итмиләр? Мин аларга бер малаймы әллә, бер чүпрәкме?!. Ю-ук, шайтан алгыры, мин — кеше!» — дип уйлады Айзат һәм тиз-тиз атлап олы якка чыкты.
— Рәхмәт хөрмәтегезгә! Мин киттем! — диде.
Кәлбикамал апа ябык иңсәсенә шакмаклы шәл ябынып караватбашында утыра иде. Гомер буе эштән бушамыйча каралып һәм ярылып беткән бәләкәй кулындагы чүпрәк кисәге белән күз яшьләрен сөртә, «и Туктабай, и Туктабай» дип сөйләнә иде. Айзат чыккач, сагыш һәм яшь тулы күзләрен күтәреп аңа карап алды. Сүз әйтмәде.
Табигать тарафыннан юаш хатынының нәкъ киресе итеп яратылган зур гәүдәле, зур башлы Туктабай, көрәк хәтле учы белән өстәл читенә таянып, кысык күзләре белән улына зәһәр текәлгән иде. Ул Айзатка борылып карамады, сүз кушмады, гафу үтенмәде, кунарга калыгыз, димәде. Аны бөтенләй күрмәгән шикелле, алдында торган стаканга яртылаш аракы салды да готгылдатып эчеп җибәрде.
— Я, ник терәлеп каттың?.. Югал, иблис баласы! — диде.
— Тынычлан, әти. Ят, ял ит!.. Мин киттем. Мина нәрсә! Син төн уртасында Казан кунагын да куып чыгардың, әти. Минем дустымны. Ояты гомер буена җуелмас, йөзебездә йөрер,— диде Нурбак һәм, ишеккә барган җиреннән кире борылып, әнисенә карады. Аны кызганып авыр сулады. Аннан нык тавыш белән:
— Әти, кара аны, әнине кыерсытасы булма. Мин җир читенә китмим, ишетеп торырмын,— диде.
— Вон! — дип кычкырды Туктабай, сирәк сакалын йолыккалап.
Кәлбикамал апа сыгылып төште.
— И балалар! И балалар!.. Шушындый төндә!.. И Туктабай!..
— Сау бул, әни. Җылап үз-үзеңне бетермә! Бик кыен була башласа, үз яныма алдырырмын... Әйдә, Айзат дус!.. Хуш, әни!..

Нурбак тиз-тиз чыгып китте.
Айзат аның артыннан иярде...
Авылда, бөтен якны яңгыратып, таң әтәчләре кычкыра иде.
Нурбак капка төбендә уйланып торды. Айзат ана комачауламас өчен дәшмәде, көтте. Ниһаять, Нурбак озын итеп көрсенде дә кулын селтәп:
— Киттек,— диде.
Айзат тагын бер ни сорашмыйча аның артыннан иярде. Нурбак унунбиш адым атлагач, борылып туган-үскән өенең яп-якты тәрәзәләренә карады. Тагын көрсенде, тагын кулын селтәде, тагын:
— Киттек! — диде.
— Кайгырма, Нурбак дус, бүгенге эшләренә үкенер дә иртәгә үк янына килеп житәр әле.
— Юк, безнеке алай түгел. Әйткәнен эшләми торган адәм. Бер нәрсә башына керсә — чүкеп тә чыгара алмыйсың.
— Ничек? Ачуы да басылмас, үкенмәс тә дип әйтергә телисеңме әллә?
— Ачуы да басылыр. Үкенер дә. Ләкин өйгә кертмәс. Кире беткән кеше ул.
— Ничек була инде бу? Аңламыйм.
— Әти исән чакта мин өйгә аяк баса алмаячакмын — шул.
— Нурбак, ул нитмәсә... Син үзең...
— Мин дә аның баласы шул, аның каны. Кандашлар.
— Карале, Нурбак...
— Житте, Айзат. Бу хакта бүтән сөйләшмик.
— Без кая барабыз?
— Әнинең апаларына — чибәрттәйләргә. Шунда кунып чыгарбыз.
— Йөзеңнән сизәр. Сөйләтми калмас. Ә сиңа сөйләве авыр булыр. Әллә...
— Юк, сизмәс. Ә ишетүен ишетер. Иртән көтү чыкканда ук минем куылган малай булуым бөтен халыкка ишетеләчәк. Яман хәбәр төнлә дә йокламый, килеп житә, яхшы хәбәр көндез дә кичегә. Авыл халкын беләсең, чыбыксыз телефон. Ләкин нихәл итәсең: ил авызын тыгарга илле ыштан кирәк диләр бит.
Шул чагында егетләр бара торган якта караңгы күкне ярып, йөрәкләрне сискәндереп, ингерәүле һәм газаплы ачы тавыш — хатын-кыз тавышы яңгырап китте.
— А-а-а-а-ах!!!
Әтәчләр, команда биргәндәй, берьюлы шым булдылар. Котлары очкан егетләр баскан урыннарында катып калды. Моңа кадәр караңгыда шәйләнми торган өйләрнең тәрәзәләрендә утлар кабынды. Әле анда, әле монда капкалар ачылды. Мыдыр-мыдыр сөйләшкән, дөп-дөп баскан аяк тавышлары ишетелде.
Нурбак белән Айзат та шулар артыннан чапты. Ун-унбиш кеше жыелып торган бер капка төбенә житкәч, алар аптырап калды. Жылы түшәкләреннән сикереп торып, бәхетсезлеккә очраган билгесез хатынга ярдәмгә йөгергән кешеләр эчләрен уа-уа тыела алмый көләләр иде.
— Берәр суккин сыннның башын сугып ярыйм дип торып чапсам — лесник хатыны тышка чыккан жирендә бала тапкан икән,— диде зур гәүдәле берәү, кулындагы ломын селкә-селкә һәм кешнәп көлә-көлә.
Ләкин ул мескенкәйнең үз хәле дә көлке иде: өстендә майкадан бүтән киеме юк иде. Бу турыда шыпырт кына үзенә әйткәч, ул иелеп карады да жан жирен учы белән тиз генә каплап куйды һәм «мать честная, срам какой!» дип күздән югалды.
Капкадан ак халатлы хатыннар кереп китте.
Авыл уянды.
Егетләр үз юллары белән китеп бардылар.

Иртәнге сәгать биштә, егетләр гостиница янына килгәндә, юлчылар җыелып беткән, автомашиналар колоннасы үзенең авыр юлын дәвам итәргә әзер иде.

Петр Петрович, янына калын портфелен куеп, утыргычта утыра. Соңга калмагае дип борчылган, ахры, егетләрне күргәч, йөзе яктырып китте.

— Исәнмесез, Петр Петрович!

— Хәерле иртә, кадерле Петр Петрович!

— Исәнмесез, дуслар! Кичләр, төннәр һәм таннар тыныч үттеме?

— Менә дигән. Сез ничек? Аякларыгыз интектермәдеме?

— Артык борчымады. Шушыннан аязып китәр шикелле.

Чыннан да күктә болыт әсәре калмаган иде. Кояш агачлар биеклеге генә күтәрелсә дә, нурлары җир өстен сизелерлек җылыта башлаган иде.

Капкадан Тамара килеп чыкты. Йоклап, ял итеп алгач, йөзе һәм күзләре тагын да сафланып, чибәрләнеп киткән. Ул егетләр белән шатланып исәнләште.

Төркем-төркем булып юлчылар машиналарга менә башлады.

Тамара Нурбакка кулын сузды:

— Я, хушыгыз! Таңнан торып шулай озатырга килүегез өчен рәхмәт!

— Рыцарь, чын рыцарь ул безнең Нурбак! — дип көлде Петр Петрович.

Нурбак, Тамараның кулын озак кына кысып торды да, елмаеп:

— Менә, алдадым. Бер — ноль — безнең файдага. Мин бит озатырга төшмәдем, районга кадәр сезнең белән барам,— диде.

Тамара гаҗәпләнеп һәм ачуланып:

— Шайта-ан,— диде.— Монда калмагач, ник кулымны кысасың? Үзенең кулы кул булса иде тагы — тимер шикелле. Бармакларым шытыр-шытыр итте.

Нурбак авыз ерып ук елмайды:

— Тотма, тотсаң каты тот! диләр бездә. Җае чыкканда кысып калмасаң! Кызлар кулы диләр аны, иптәш, кызлар кулы.

Машина янына атлый-атлый, Петр Петрович сүзгә кушылды:

— Сез бер-ике көн әти-әни янында кунак булам дигән идегез бит, дускай. Кире уйладыгызмыни?

Нурбакның чырае кинәт караңгыланды.

— Ашыгыч эш килеп чыкты, Петр Петрович, бүген китмичә булмый,— диде ул, әкрен генә.

Аларның машиналары бүген дә, кичәге шикелле үк, колоннаның алдыннан китте.

Юлчылар да кичәгечә үк таныш кешеләр булып, үзләренең кичәге урыннарында утыралар иде. Аучы аларны елмаеп һәм шакмаклы кепкасын селкеп каршы алды:

— Сәлам, сәлам яшьләргә һәм картларга! Мин сезне, юлдашны юл аера, калалар инде болар, йокы чүлмәкләре дип куркып көткән идем. Ярый әле,— шикләрем бушка булды. Югыйсә сездән башка күңелсез.

Уйчан Кеше:

— Исәнмесез! Хәерле иртә! — диде дә үзенең очсыз-кырыйсыз уйларына чумды. Айзат аңа карагач кыенсынып куйды. Уйчан Кеше бүген тагын да уйчанланган булыбрак күренә. Бөтенләй йокламаган, ял итмәгән кебек. Күз төпләре тагын да шешенгәнрәк, борыны очлая төшкән, бугаз төене дә олайган сымак.

«Нишләп авыз ачып сүз әйтми бу кеше, нишләп башкалар кебек уйнашып-көлешеп бармый, нинди авыр кайгысы бар, нинди сагыш белән мае сызыла монын, кем соң бу, кая бара, нишләп йөри?» дип

уйлады Айзат. Ләкин, сиздермәскә тырышып, аның йөзенә карап-карап алса да, бу сорауларына җавап таба алмады. Ул, гомумән, бер карау белән кешеләрнең йөзләрен, кием-салымнарын, кыяфәтләрен хәтерендә калдыра ала, ләкин начар психолог иде, кешеләрнең хәеф-ләрен, уй-хисләрен юрый белми иде.

Нурбак та, эчендәген сиздермәскә теләп, кичәге шикелле уйнап-көлеп, беркатлыланып барырга тырышса да, вакыты-вакыты белән кая барганын һәм кайда, кемнәр белән утырганын онытып уйга тала иде. Айзат дустын аңлады һәм кызганып куйды: Нурбак та аның кебек бик яшь, тормыш тәҗрибәсе аз, уй-хисләрен чит-ят күзләрдән яшереп сакларга көче җитми. Гаре булса — күзендә, каһәре булса — йөзендә. Ләкин ул бүген кичәге беркатлы шаян малай түгел иде инде.

Айзат моңа куанды. Әйе, дустының кайгырып, борчылып утыруына куанмый булдыра алмады. Димәк, аның яңа дусты ата-ана кадерен белә. Әгәр ул бүген кичә кич белән өйләрендә булган хәлләрне онытып, Тамара белән кичәге шикелле шаяра башласа, уен-көлке сөйләп барса, Айзатка бу бик гаҗәп тоелыр иде һәм ул Нурбакка нәфрәтләнер иде, аны онытырга, киләчәктә исемен дә телгә алмаска тырышыр иде.

Атадан һәм анадан кадерле кем бар дөньяда безнең өчен.

Күктә ай белән кояш — бер.

Җирдә ата белән ана — бер.

Дөньяда алардан башка бары да табыла.

Алар безгә тормыш биргән, авырсак — баш очыбыздан китмәгән, ашның иң тәмлесен безгә каптырган, тунсак — күкрәгенә кысып җылыткан, егылсак — күтәреп торгызган, еласак — күз яшебезне сөрткән, кайгырсак — кайгырган, шатлансак — шатланган, без янсак — янган, без көйсәк — көйгән.

Алар безгә туган телебезне өйрәткән.

Беренче каләмне һәм дәфтәрне безгә алар сатып алган.

Көзнең бер якты иртәсендә шулар безне җитәкләп мәктәпкә илткән.

Әнкәң ничек кенә булмасын, ул сиңа — әнкә!

Әткәң ничек кенә булмасын, ул сиңа — әткә!

Ата аркасы — кала аркасы. Җәйләүгә тугай яхшы, яхшыдан ата яхшы!

Ата-анасына хыянәт иткән зат Туган иленә хыянәт кылмас дисеңме!?.

Ян, Нурбак, ян, кайгыр, сызлан!..

Син бүген гәрчә хакыйкать әйтсәң дә, атаңны үпкәләттең.

Сызлан, Нурбак!..

Авылны чыккач, машиналар, уңга борылып, саклана-саклана, кызыл ярдан түпергә төштеләр.

Тагын бераздан колонна яшь каен урманына килеп керде. Каеннар төз, яңа гына акбур белән буяп чыккандай ап-аклар. Һавада, агач ботакларына бәрелә-бәрелә, тын гына сары яфраклар оча, алар, менә ычкынам, менә ычкынып китәм дигән шикелле, каен ботакларында да дерелдәп торалар. Шул сары төс арасыннан һавага ак сөңге булып сузылган ак каеннар! Матур да, сагышлы да. Күңелле дә, күңелсез дә. Яз тагын үтте, җәй дә үтте. Менә тагын көз килде. Ак юрганын ябынып кыш җитәр. Шулай еллар үтә торыр. Кешеләр үзләре дә сизмичә олыгая, картая торыр. Һәм бер көн килер дә ул исе китеп үзенә карар. Гаҗәпләнер, аптырар. Әле генә яшь егет идем ләбаса, әле генә томырып торган чибәр кыз идем ләбаса, нишләдем соң әле мин, ничек булды соң әле бу, дияр. Һай, тиз үтә дә соң бу гомер дигәнең, һай, тиз дә үтә лә дип авыр сулар.

Машинадагыларның да күңелләрендә шундый ук хисләр иде, ахры, юлның як-ягыннан сузылып киткән шушы көзге матурлыктан күзләрен алмыйча, тын гына карап бардылар.

Ике-өч чакрымнан соң ак каеннар артта калды. Юл унике чыбык эленгән (Айзат аны санап чыкты) телефон баганаларының әле бер, әле икенче ягына чыгып, уйнаклап барды-барды да, кинәт алардан аерылып, уң якка кереп китте. Вак таллар үскән юеш болынны артта калдырып, үргә күтәрелә башлады. Юл корыды. Торфлы балчыкны соры ком, вак таш алыштырды. Озак та үтмәде, колонна, шатлыклы гүли-гүли, куе нарат урманына чумды. Үпкәләргә хуш исле сагыз һәм ылыс исе бәреп керде. Сулавы җиңеләйде, күңелләр күтәрелде. Колач җитмәс юан, күз җитмәс биек нарат ботаклары кай урыннарда юлның ике ягыннан да сузылып бергә кушылганнар, һәм машиналар андый төшләрдә караңгы тоннель эченнән баргандай булалар иде.

Юл бөтенләй корыды, әйтерсең лә атна буе яңгыр яумаган иде. Инде менә тузаннар да оча башлады. Аның дөньяда барлыгын инде исләреннән чыгара язган кешеләр тәгәрмәчләр астыннан пырхылдап күтәрелгән тузанга ят әкәмәткә караган шикелле гаҗәпләнеберәк карап-карап алдылар. Төчкерә, төкерә башладылар. Күзләрдән яшь, кесәләрдән кулъяулыклар чыкты.

Чокыр-чакырлар күбәйде. Машина тартмасында шалтыр-шолтыр килеп тимерләр сикерде, кешеләр, чемоданнар сикерде. Кинәт машина туктады. Кабина ишеге ачылып аннан шоферның башы күренде.

— Ну, ничек анда? Әле сынган сөякләр юкмы?

— Әлегә юк, ләкин озакламый сынар дип өмет итәбез,— дип җавап бирделәр аңа.

— Юл түгел бу — җәһәннәм! — диде шофер тагын да күңеллерәк итеп.— Ләкин гел шушындый юл булса, алласына җиде шәм куяр идем. Түзегез инде, тегендә азапланганнарның үчен алып калырга кирәк. Без бу юлны сагынып көтеп алабыз.

Ул шуннан соң машинасын тагын да кызурак алып китте. Башка машиналар да, куышлы уйнаган шикелле, аның артыннан күңелле генә чаптылар. Менә сөзәк тау башына килеп менделәр. Наратлар, куе стена булып, тау итәгендә калды. Моңа кадәр юл читендәге агачлардан башканы күрми барган кешеләрнең күз алдында дистәләрчә километрларга сузылган гаҗәеп күренеш ачылып китте.

Аста — бөтен якта — зәңгәрсу-яшькелт иксез-чиксез нарат урманнары иде. Әле анда, әле монда, уч төбедәй генә булып, каен, я бүтән төрле яфраклы агачлар төркеме күренеп кала. Алар кайбер урыннарына сары буяу тигезгән яшькелт паласны хәтергә төшерәләр. Агачлар арасыннан, шулай ук әле анда, әле монда, нефть вышкалары күккә сузылган. Тау итәгеннән тимер баганалы электр линиясе уза. Агачлар артында сирәкмирәк авыллар барлыгын сизеп була. Кайбер урыннарда тар гына сөрелгән җирләр каралып күренә. Алпамша кесәсеннән коелып калган көмеш тәңкәләр шикелле якты күлләр күренә.

Боларның барысы өстеннән дә моннан ун-унбиш чакрым ераклыгындагы бер зур төзелеш хакимлек итеп торган шикелле тоела. Ул урында җиргә кадалган кызгылт таяклардай бик күп завод трубалары күренә. Алардан һавага кап-кара, сап-сары, чия-кызыл төтен күтәрелә. Алар, торбалар өстендә бергә кушылып, рәссам да ясый алмаган гаҗәеп бер төс тәшкил итәләр. Ул сихри төс талгын елга булып урманнар өстеннән әллә кая кадәр сузылган. Торбалар тирәсендә ак шикәр шакмагыдай өйләр, корылмалар, тимер челтәрләр, краннар күренә, кара коңгыз кебек бәләкәй паровозлар йөри. Аларның кычкырткан тавышлары, тимер чаңнары, тайга уртасында калкып килә торган зур төзелеш сулышы ташлы тауга кадәр ишетелә кебек.

Шоферлар, тау түбәсенә менеп җиткәч, үзләре үк машиналарын туктаттылар һәм «биш минутка перекур» диделәр.

Севастопольдән Ялтага барган чакта Байдар капкалары янында туктап, аста шаулаган диңгезне тыңлап һәм тауларга сокланып карап китү

Кырым шоферларының гадәте икәнен Айзатның ишеткәне бар иде. Себердә дә бу язылмаган закон бар икән: болар шушы тау өстендә туктап, астагы матурлыкка карап торалар.

— Нәрсә бу, Петр Петрович? Нинди завод? — дип сорады Айзат Петр Петровичтан.

— Могҗиза бу, дускай. Нефть табылганнан соң ике ел эчендә тигез урында калкып чыккан могҗиза! — диде Петр Петрович, бу төтеннәрне берничә кат күрсә дә һаман сокланып.

— Ул әйберләрне, машиналарны ничек алып килгәннәр? — дип гаҗәпләнде Айзат.

— Кирәк булгач, алып киләләр, дустым, безнең кешеләр эшли алмаган эш юк,— диде Петр Петрович.— Мин ышанам: күп тә үтмәс, безнең Аю-ятарның аюлары да калмас, төзелеш шавыннан куркып качып бетәр. Тагын да төньяккарак, ешкын җирләргә качарлар. Казаннан ким булмас бездә дә — күр дә тор...

Петр Петровичның соңгы сүзләре Айзатка, монда да зур тормыш булачак, син юкка китәсең дип шелтәләгәндәй тоелды. Айзат дәшмәде. Күз карашын читкә борды...

Петр Петрович «аюлар төзелеш шавыннан куркып качып бетәрләр» дигән иде, ләкин тайга хуҗалары бик үк куркак түгел икән. Ун-унбиш чакрымдагы төзелеш шавыннан түгел, хәтта өсләренә ыжгырып килгән машиналардан да куркып тормыйлар икән. Алай гынамы әле! Машиналар белән күкрәккә күкрәк килеп сугышалар да.

Очраса да бик сирәк очрый торган, әйтеп кеше ышанмаслык бу вакыйга машиналар тау түбәсеннән кузгалып киткәч булды.

Колонна, юлның тигезсез урыннарында сикерә-сикерә, шәп кенә алга бара. Ике якта да куе нарат урманы, юл коры һәм тузанлы иде. Шулай әйбәт кенә барган чакта, машина капыл туктап калды. Нәрсәгә туктады икән бу, ни әйтергә тели икән, дип кабина ачылуын көттеләр. Ләкин ишек ачылмады, шофер чыкмады. Бу хәлгә аптырап аякларына бассалар, исләре китте: машинадан биш метр гына алдарак, юл уртасында, аю баласы утырып тора иде.

— Аю! Чын аю! — дип кычкырды Тамара, бала кебек куанып.

Башкалар да аңа кушылып җанланып сөйләшә, бу кызык хәл турында фикер алыша башладылар.

Аю баласы машина күреп өйрәнмәгән, бу урыннарга күптән түгел генә килеп чыккан булды, ахры. Машиналардан да, кешеләрдән дә курыкмады. Карасагыз карагыз инде, минем сезгә һич тә исем китми, йокым да туймады дигәндәй, авызын кызык кына ачып иснәп куйды. Иснәгән чакта, әдәпле кеше шикелле, авызын тәпие белән каплап торды. Аннан соң шул тәпиен кызыл теле белән ялап, чистартып алды. Күзләрен төймәләндереп тагын кешеләргә карап тора башлады.

Арттагылар бу әкәмәтне күрмиләр иде. Берьюлы биш-алты машина кычкырта башлады. Шоферлар үзләре дә кычкырырга тотындылар:

— Ник туктадык?

— Аю бар,— дип кычкырды Аучы.

— Юл уртасына утырган — җибәрми,— диде шофер.

— Торалар вакытны әрәм итеп,— дип, арттагы машиналарның шоферлары да, юлчылары да кило башлады. Алданрак килүчеләре:

— Кара син, әй, чыннан да аю бит! — дип гаҗәпләнгәч, арттагылар, кәмит күрми калмыйк дигәндәй, йөгерешергә үк тотындылар.

Бәләкәй аю баласы үзенә кызыксынып карап торган халык төркеме алдында калды. Сез әнә ничә кеше карыйсыз, ник мина да сезне карап калмаска дигәндәй, башын бора-бора кешеләргә текәлеп торды. Тик бу ике аяклыларда игътибарын тартырлык кызык тапмады, ахры, бөтен дөньясын онытып, ләззәтләнеп колак артын кашырга тотынды. Бу «тәмле» эшне тәмам иткәч, канәгатьләнеп төчкереп куйды һәм ачу белән баш

очындагы чебен-черкине куарга итте. Арт аякларына басып, алгыларын бик гайрәтләнеп баш очында болгаса да, унышка ирешә алмады: ачуланып, зур аюларга охшатырга тырышып үкергәндәй итте. Аннары тәпие белән һавага тузан чөеп алды. Шуңа кызыксынып карап торды. Тагын сипте, тагын карап торды. Күрәсезме, кешеләр, мин нинди батыр дигәндәй, дөпелдәтеп күкрәгенә сукты. Әмма үз хәлен белмичә артыграк мактанып җибәрде бугай. Авыртуга чыдый алмыйча, шул ук тәпие белән суккан җирен ышкый-ышкый, башын чайкый-чайкый ыңгырашып куйды.

Кешеләр аның бу кыланышларына карап шырык-шырык көлештеләр. Көч биреп, котыртып тагын беpаз тордылар да кайсылары әкрен-әкрен генә, кайберләре йөгерә-йөгерә машиналарына таралыштылар һәм менеп тә беттеләр.

Әйтергә кирәк, бик вакытлы менеп беттеләр.

Айзатларның машинасы кузгалды һәм юл бир, юл бир дип кычкыртакычкырта шаян аю баласына якынлаша башлады. Шул чагында сул яктагы яшь чыршылар каты давыл бәргән шикелле кинәт чайкалып китте. Һаваны һәм колакларны ярыперткыч үкерүе яңгырады. Чыршылар артыннан сыер кадәр зур, йөнтәс аю дүрт аякланып сикерә-сикерә чабып чыкты да баласына ярдәмгә ташланды.

Юлчылар кайдадыр шушы тирәдә ана аю барлыгын белсәләр дә, болай ук булыр дип башларына китермәгәннәр иде. Куркырга да өлгерә алмый калдылар — баласына куркыныч яный дип ярсыган, күзенә ак-кара күренми башлаган нәрсәкәй юл уртасына атылып чыгып, тынлаусыз малаен әз-мәз «акылга утыртып» алды: янак төбенә берне кундырып, аны читкә атып бәрде. Аннан соң арт аякларына басты да ыжгырып машинага килә башлады. Шофер, тизрәк алга сыптырасы урынга, каушап тормозга басты һәм машина, җинелеп әсир төшкән шикелле, ерткыч җанвар алдында туктап калды. Аю бәләкәй күзләрен зәһәр уйнатып, сары тешләрен ыржайтып үкерде дә машинаның сул фарасына китереп тондырды. Тирә-якка пыяла ватыклары сибелде. Кешеләр бөтенесе берьюлы:

— Ах! — дип куйдылар.

...Колак төбендә күк күкрәгәндәй булып мылтык тавышы яңгырагач, карт аю, гаҗәпләнеп һәм куркып, һуштан язды, юл тузанына тәгәрәде. Ләкин каты курку авыртуын оныттырды булса кирәк: күз ачып йомганчы сикереп торды да арт санын бик мәзәк сикертә-сикертә чыршылар арасына кереп сызды. Артыннан тагын мылтык шартлады.

— Маша, хуш! Михаил Петровичка сәлам әйт! — дип кычкырды Аучы, көлеп. Мылтыгын янадан чехолына тыгып куйды. Шул секундта машина кузгалды, чокыр-чакырларны бар дип тә белмичә аюдан да катырак чабып китте.

Ә калкулыктан төшеп киң болынга кергәч, ул кинәт туктады. Кабинадан шофер чыкты. Кулларын як-якка җәеп үлән өстенә сузылып ятты.

— Иптәшләр, һич чамам юк. Бераз искә килим,— диде.

Башкалар да шаулаша-шаулаша яланга сибелделәр һәм әле генә булган гаҗәеп хәл турында иркенләп сөйләшә, фикер алыша башладылар.

Тамара Аучы янынннан китмәде.

— Менә бу абый булмаса, ул безне берәм-берәм тотып ашаган булыр иде,— диде.

— Чыннан да салкын канлы икәнсез,— диде Петр Петрович, Аучының кулын кысып.— Югалып калмадыгыз. Кай арада мылтыгыгызны алып өлгергәнсездер — белмим. Мин бөтенләй күрмәдем.

Халык та Аучыны урап алды.

Күп сөйләргә яратучы мескен Аучы, үзенә мондый игътибарны күргәч, тумыштан килгән гадәтен онытып, телдән калды. Ык-мык итте, шакмаклы кепкасы белән коры маңгаен ышкыды, очлы башлы туфлие белән кырмыска оясына төрткәләде.

— Бәй... шулай булмыйча... Мин инде аю баласын күргәч үк мылтыкны корып куйган идем... Саклык кирәк... Дошман безне искәрмәстән каптырырга тиеш түгел...— дип мыгырданды.

Берәү:

— Ике мәртәбә атып та тидерә алмадыгызмы? — дип сорау биргәч, аның беркатлылыгына аптырап:

— Нишлә-әәп?.. Нишләп мин ана атыйм!.. Шундый матур ерткычка!..— диде.

Машиналар янәдән кузгалды. Сүз бетмәде. Берәүнен дә тик утырасы, аз сөйләп, күп тынлыйсы килмәде. Җәнлек-җанварлар, үзләре күргән-белгән хәлләр турында сөйләшеп бардылар.

Берәү генә сөйләшмәде: Нурбак. Аю вакыйгасы да аны кузгатып җибәрә алмады. Тамара, баштарак сүз кузгаткалап караса да, аның бүген кичәге Нурбак түгеллеген күреп, авыр сулады һәм сүздән туктады.

Ләкин бара-бара калганнарның да, эссе салмаган мунча шикелле, кызулары басылды. Юл арытты, оетты. Урман-агачлар да ялыктырды. Юлаучылар йокымсырабрак бара башладылар...

Көндезге сәгать уннар тирәсендә машиналар юлның бик хәтәр җиренә — Кара сазга килеп керделәр. Аны шоферлар ике көн буе сөйлиләр иде инде, кунарга туры килмәсә ярар иде дип борчылалар иде. Дөрестән дә, борчылырлык булган икән шул. Кара саз исеме җисеменә туры килеп торган кара һәм шомлы саз булып чыкты. Машиналар батып яткан эзләр, чокырлар күренә башлады. Юл читендә хәтта авып төшкән бер «Беларусь» тракторы күренде. Километр саен пычракка ташланган тимер торбалар, төрле ящиклар, машина кисәкләре очрый башлады.

«Тагын урман кисеп юл салырга туры килә икән», дип уйлап алды Айзат.

Менә аларның машинасы куе зирекләрне узып унга борылды. Агачлар артындагы ачык урынга бүрәнә һәм чыбык-чабык түшәп ындыр табагы шикеллерәк тигез урын эшләнгән. «Ындыр табагының» бер читендә, күзгә юеш куккә зәңгәр төтен бөркеп, кечерәк кенә такта будка тора. Будка янында өр-яңа трактор һәм бер транспортер.

Моны күргәч Айзатлар шоферы машинасын туктатып, кабинасыннан сикереп чыкты.

— Ниһаять, кузгалганнар икән, җәй үткәч булса да. Шулай да рәхмәт! — дип кычкырды.

Будкадан өстенә кыска тун кигән берәү чыкты. Папиросын сүндереп аяк астындагы суга ташлады, биялэен кия-кия:

— Кайдан? — диде.

Шофер әйтте.

— Нинчә машина?

Шофер әйтте.

— Кая?

Шофер аныеын да әйтте.

— Ярый,— диде тунлы кеше,— минем арттан гына барыгыз. Җеп белән тагып куйган кебек. Бер сантиметр читкә чыкмыйсыз. Аңлашылдымы?

— Аңлашылды? — диде шофер.

Будкадан шундый ук тун кигән икенче кеше чыкты. Ул да тәмәкесен сүндереп суга ташлады. Беренче тунлы транспортерга, икенче тунлы тракторга менеп утырды. Ике машинаның да моторы тырылдап эшли башлады.

— Әйдә!

Транспортер болганчык суны ерып алдан китте. Аның артыннан машиналар, ә иң арттан, бабкаларен саклап барган ата каз кебек, трактор кузгалды.

Ике көн буе шоферларның котын алып килгән өч чакрымлы Кара

сазны үтү авыр булмады. Транспортер алдан юл ярып, куәтле трактор арттан аларны саклап барды. Колонна уртасындагы машиналар икеөч мәртәбә батты батуын. Ләкин шунда ук алар янына транспортер, трактор килеп җитте. Машиналарны әһ дигәнче чыгарып та куйдылар.

Кара сазга, кара авызын ырҗайтып, кара йодрыгын селкеп калудан башка чара юк иде.

Сазның икенче ягында егермеләп машина аларның чыгуын көтә иде. Тунлы кешеләр моторларын да сүндермичә, ашык-пошык папирос тартып алдылар да, теге машиналарны алып, тагын Кара сазга кереп киттеләр.

Шуннан соң ком һәм вак таш түшәлгән коры юл башланды. Юлны быел да төзәтәләр икән. Чит-читләрендә өем-өем комнар, түшәү өчен әзерләнгән ак ташлар тора, кай урыннар, үтәргә тар гына юл калдырып, казылып, актарылып беткән. Шулай да бу урыннар моңа кадәр үткән юллар белән чагыштырганда әйбәтнең дә әйбәте. Алар арасында җир белән күк аермасы бар иде.

Юлаучылар тагын сөйләшә, көлешә башладылар.

Петр Петрович авырткан аякларын әкрен генә ышкып утыра иде.

Айзат аннан:

— Петр Петрович, Аю-Ятарга хәтле шушындый юлмы әллә хәзер? Сазлыклар беттеме әллә? — дип сорады.

— Безгә бик ерак әле, дускай,— дип җавап бирде Петр Петрович:— Бу шоссе Коштабанга гына бара.

— Ә аннан соң?

— Аннан соң гадәттәге тайга юлы.

— Ник юл салмыйлар икән соң?

— Көч күп кирәк. Анысын алай, монысын болай итәсе бар. Себерне бит әле үзләштерә генә башладык. Без — юл ярып баручылар, пионерлар. Мин ышанам: киләчәктә Себер белән Үзәк Европа арасында бер аерма да калмас, Себер хәтта яшәү өчен уңайлырак итеп, яңача төзелгән булыр.

— Шул көннәрне без дә күрсәк иде, Петр Петрович!

— Без күрмәсәк, балалар, аларның балалары күрер.

Коштабанга якынлашкан саен, Уйчан кеше тик утыра алмый башлады. Эшләпәсен бер салды, бер киде. Иске ак күлмәгенең якасын ычкындырып җибәрде. Бугаз төене әле аска төште, әле өскә менде. Юл буена тәмәке тартмаган иде, Айзат аны тәмәке тартмаучылар исәбенә керткән һәм моның сарае буш түгел дип, акыллы адәмгә чутлап куйган иде. Менә шул «акыллы» адәм кинәт кенә Аучыдан папирос сорады. Анысын тартып бетергәч, минут тормый икенчесен алды һәм тирән итеп суыра-суыра анысын да тартып бетерде.

Моңа гаҗәпләнделәр, әлбәттә. Ләкин кыюланып сәбәбен сорашучы табылмады. Кеше күңеле — төпсез океан. Диңгез төбен үлчәп була, кеше күңелен — юк. Кеше күңелендә ни булмас дисең!..

## 15

Менә еракта Коштабанның тау өстеннән калкып торган чиркәү манаралары күренде. Уйчан кеше торып басты. Кабина түбәсенә таянып шул манараларга карап бара башлады. Бүтән утырмады.

Коштабан шәһәр белән авыл арасындагы зур район үзәге икән. Ул тирән һәм киң елга яры буйлап чакрымнарга сузылып киткән, калку җиргә урнашканга урамнары да коры, икешәр, хәтта өчәр катлы таш өйләр күп булып, җәмәгать һәм дәүләт учреждениеләренең барысы дип әйтерлек таштан салынган иде.

Колонна авыл уртасындагы тигез мәйданга туктады.

Айзат тирә-якка күз йөртеп чыкты. Бу мәйданны дүрт ягыннан да

таш корылмалар ураткан иде. Каршы якта борынгы чиркәү. Ул ак кирпеч койма белән әйләндерелгән. Эчендә ниндидер автоколоннамы, ремонт мастерскойларымы урнашкан, күрәсең: шар ачык тимер капкасыннан машиналар керәп-чыгып тора. Уң кулда ике катлы райком, райисполком биналары, редакция һәм пекарня. Сул якта кибетләр рәте: аяк киеме, яшелчә, китап, азык-төлек, кием-салым, һәм башкалар, һәм башкалар. Ә бу якта зур ашханә, азык биналары һәм болан мөгезеннән сувенирлар ясый торган мастерской...

Мәйданның дүрт ягыннан да киң урамнар сузылып киткән. Капка төпләрендә тавыклар тырманып йөри, ак мамык мендәрләр шикелле йомарланып оя-оя казлар утыра, солдатлары каршындагы генерал шикелле, түшен киереп, озын ботлы күркә басып тора, үрдәкләр бакылдый, симез чучка пычрак эзләп ялкау гына йөренә...

Шоферлар юлчыларга «команда» бирде:

— Ашап чыгабыз. Тик минут та артык юанмаска. Бер сәгать!

Унлап кеше ашарга-эчәргә кермәде. Алар кайтып җиткәннәр иде инде. Саубуллашып өйләренә таралдылар.

Уйчан кеше дә ашханәгә керүдән баш тартты.

— Рәхмәт! Минем ашыйсым килми,— диде. Шоферга акча түләде. Кешеләр белән ашыгып кына исәнләште.

Айзат ашханә баскычына менгәч борылып артына карады. Ике көн буе бергә-бергә юл кыскартып килгән бу гаҗәп кеше белән менә шулай көтмәгәндә аерылышу аңа кинәт кыен тоелды. Гомер юлларында бәлки тагын очрашырлар, бәлки мәңге күрешмәсләр. Кызык бу тормыш!.. Ә ул Айзатны күрмичә, юл капчыгын уң җилкәсенә кия-кия, түземсезлек белән як-ягына карана иде. Баскан урынында таптана, әле таш шикелле катып кала, тротуардагы кешеләрнең һәр берсен танырга теләгәндәй җентекләп карый. Әйе, ул кемнедер көтә иде.

Айзат «көткән кешең килсә ярар иде» дип ашханәгә керергә теләгән иде, бер машина янындагы халыкның шырык-шырык көлүен ишеткәч кызыксынып кире төште. Алты көпчәкле зур машинага таудай итеп зәңгәр тышлы мамык юрганнар төялгән, һәм шул йомшак таучык өстенә, зур шәлгә төйнәлгән бөктәрен кочаклап, чуклы шәлгә төренгән, бәләкәй битле бәләкәй карчык утыра иде. Ләкин кызыгы бу түгел, бөтенләй башка нәрсә булды. Дөньядагы һәр эшне җиренә җиткереп эшләүче, кешеләр өчен тәмле телле, җирнең бар шатлыклары һәм бар кайгылары сыеп бетәрлек иркен күңелле, үз балалары өчен генә түгел, оныклары өчен дә җылы куенлы, күп эшләсә дә күзгә артык чагылмаска тырышучы безнең шушы, мыскалы сиксән сумлык бәләкәй һәм кадерле әбекәйләребездән теле барып кем көлә алсын! Юк андый адәмнәр! Булсалар да салкын, таш күңелле булыр...

Машинаны урап алган кешеләрне икенче берәү — Буденныйныкы шикелле купшы мыеклы, әйбәт яндырылган кирпеч шикелле кызгылтсоры йөзле, алыптай зур гәүдәле карт көлдерә иде. Ул бүреген салып кулына тоткан, яшел кожан итәкләрен ачып җибәргән, икенче кулы белән бортка тотынган да карчыкның күзләренә карарга тырыша.

— Китәсеңмени инде, Якут? — ди.— Бәлкем әле кире уйларсың? — ди.

Әби аңа күтәрелеп тә карамый.

Карт авыр сулый. Резин итекләре белән пычракта таптана.

— Якут дим! Китер төенчегеңне. Аннан үзеңне күтәреп төшерермен? Әби кымшанмый.

Бабай бүреге белән шыпылдатып тезләренә суга. Тагын авыр сулый.

— Якут, карале, моннан бер кая да китмибез инде. Менә күрерсең. Шушы җүләр әйткән не диярсең... Якут!? Эһһ, шулай инде, картайгач карчыгың да сөйми.

Әби керфеген дә селкетми.

— Өй салам. Сиңа бер бүлмә, миңа бер бүлмә. Кухнясы белән. Кер юу машинасы алам, билләһи. Бәдрәфне дә җылы ясыйм... Якут?!

Таш та таш, әби дә таш.

Бабай тагын да ныграк ялына башлый:

— Мәҗлүмбәгеннен тагын бер үзен ташлап китәсеңмени инде? Якут?!. Үләрмен инде мин, картайдым да... Карт кеше торган кадәр тормас... Уй җир читендә йөрсә дә, үлем җилкә өстендә йөри... Я, бәхил бул инде, Якут, алайсаң. Бик җылама. Балалар да җылашмасын... Вакыт җиткәндер инде, күңелем сизә... Бүген иртән колак та чыңлады. Якут, дим, китмә инде, кал инде, ә?!.

Әби кымшанмый.

Әби бу ялваруларга да эреп төшмәгәч, бабай әзрәк уйланып тора, тактикасын кисәк йөз дә сиксән градуска борып әбине куркыта башлый.

— Ярар, кит ул чагында! Кит, зинһар! Ә мин бүген үк эчә башлыйм. Иренне генә тидереп куймыйм, төбенә хәтле чөмерәм, менә күр дә тор. Мәҗлүмбәкне беләсең... Яшь чакларда... Син киткәч ниләр кыланып куя идем, ә? Менә хәзер дә шулай итәм. Хәзер үк керәм дә эчәргә тотынам. Мин бер ычкынып китсәм, үзең беләсең... Башта акчамны эчеп бетерәм, аннан — акылымны. Ә бит миңа эчәргә дә ярамый әле: бөерем авырта. Хәзер барыбер, үлсәм үләрмен. Син киткәнгә ачу итеп... Якут?!.

Әби дәшми.

Бабай, янау-куркытулардан да рәт чыкмагач, үзе уенча, әбине секунд эчендә юрганнар өстеннән очыртып төшерерлек сүзләр әйтә:

— Кеше исерек баштан ни кыланмас — бәлки әле кызлар янына да барып чыгарга туры килер!..

Әбиебез борын очын да селкетми.

Тирә-яктагы ачык авызлар көлүләрен беләләр. Пырлап мотор кабына. Машина дерелдәп әкрен генә кузгала башлый. Бабай эһ дип кул селти дә әбигә соңгы киңәшләрен кычкыра:

— Якут, төренеп утыр, җил тимәсен... Юрган күп... Бишмәт кесәнне кара, мин анда акча салып куйдым... Мин сине шушы төштә нәкъ утыз өч көннән соң каршы алырмын... Бүгеннән чутлый башла: утыз өч көн, утыз өч... Балаларга сәлам әйт!.. Хуш, ху-уш, Яку-ут!.. Яку-у-ут!..

Машина кызулый. Әби бабайга җавап та бирми, күтәрелеп тә карамый. Урынында таш сын шикелле хәрәкәтсез утырган килеш, урам чатында күздән югала...

Бабай шул якка күзләрен талдырып карап торды да, бүреген басып киеп, кожан төймәләрен каптырды. «Эһ» диде, «эһ... эһ!..»

Шунда берәү тәмәкесен пыскыта-пыскыта башкаларга күз кысып алды:

— Картлач, корткаң тәртәдән чыккан бит. Сиңа бер сүзем җәлли. Катырак тотарга кирәк иде аны, йодрыкка катырак йомарларга кирәк иде. Карамаганның хатыны, бакмаганның малы китә. Синеке китте. Карамагансың, димәк. Минем шундый хатын булса-а...

Бабай аңа кырт борылды.

— Нинди?

Теге куркып китте.

— Шундый...

Бабай аңа мәсхәрәле караш ташлап әйтте:

— Ә син аның кем икәнен белеп тор, энекәем,— диде.— Минем Якутым — безнең унбер балабызга ана. Ул акыллы, җыйнак, тыйнак. Аның урыны: җирдә — түрдә, гүрдә — оҗмахта. Ә менә мин, җилкуар, илле ел торып аңа җитәрлек хөрмәт-кадер күрсәтмәдем. Гомер буе ат тоягы яссы, ир тезгене озын, дигән булып чегән шикелле дөньяны гизеп йөрдем. Бакының Биби-әйбәтендәге[1] бораулаучы егет идем, өйләнгән

[1] Биби-әйбәт — Бакуның нефть промыселлары урнашкан бер районы.

чакта. Тик кеше төсле бер жиргә төпләнеп, йорт корып, мал-туар үрчетер әмәлем булмады. Берәр жирдә нефть чыга дисәләр, жаным уйный башлый. Ашым үтми, йокым кача. Жыенып шунда китмәсәм, үләрмен кебек. Менә илле ел күченеп йөрим инде. Баку — Грозный — Пермь — Салават — Шөгер — Әлмәт — Сахалин — Ерак Көнчыгыш — тагын Пермь — Төмән, тагын әллә кай жирләр. Ә ул — минем Якутым — жүләр ире артыннан әнә шулай илле ел йөри, белдегезме? Әйбәтме ана — түгел, жинелме ана — түгел. Бер урында, газлы, сулы фатирда гына яшисе килмиме аның — килә. Ә йөри, миннән калмый. Ярата. Мин жүнсезне ярата. Гомерен минем белән палаткаларда, баракларда үткәрде. Без — гомер буе ике энә бер жептә, ике иман бер төптә. Тагын күчәм дисән, үпкәләп, гел шулай Бакыга, малайлар янына китә. Тик нәкъ утызынчы көнне кире кайтып житә. Гомер буе шулай... Менә тагын төньяккарак керергә исәп. Күрдегез бит: унга борсаң сулга йөгерүче син жүләр артыннан гомерем буе инреп ялыктым инде, тик тора белмәсән, ялгыз башың ят, картлач, дип китеп барды. Әмма ләкин тагын утыз өч көннән кайтып житәчәк ул. Минсез тормыш — тормыш түгел анар. Монда юл арырак, шунлыктан өч көн артык куйдым. Ә мин аны барыбер биш-алты көн алданрак чыгып китәргә тотынам.

Менә нинди кортка ул Якут түтәң, беләсенме, энекәш?..

Бабай эре-эре адымнар белән төркем уртасыннан чыгып барганда, кемдер бераү, әллә шаяртырга итеп, әллә чынлап:

— Мәжлүмбәк бабай, бәлкем теге... ни... янган йөрәкне басарга керәп чыгарбыз, мин сыйлыйм,— диде.

Мәжлүмбәк ана борылып та карамады.

— Лениногорскидан бирле чәй генә эчәм,— диде дә урам уртасыннан китеп барды.

Халык аның артыннан уйланып карап калды. Алар арасында да әллә кайлардан килгән кешеләр бардыр. Алар да хәзер кин илебезнен төрле жирләрендә үзләрен көтүче, я яннарына килергә жыенып ятучы хатыннары, бала-чагалары, сөйгән кызлары хакында сагынып уйлый торгандыр.

Аерым яшәү — дәла жиле. Сагыну учагың көчсез булса — өреп сүндерә, көчле янса — тагын да ныграк дөрләтеп жибәрә.

Мәхәббәт учакларыгыз сүнмәсен — катырак дөрләсен, кешеләр!..

Айзат Чәчкәне күз алдына китерде. Үзе елмайса да, күзләре моксу иде: ул да сагына, сагына, сагына!..

Аннары көрсенде дә баскычтан менеп китте. «Ашханә»дә халык күп иде. Өстәлләрдә буш урын күренми. Кухня тәрәзәсенә чират. Юк, сәгать эчендә генә ашап чыгарлык түгел моннан. Айзат залга күзләрен йөртеп аптырап калды: аның иптәшләреннән монда бер кеше дә юк иде, ишектән керәп китканнәрен Айзат үз күзләре белән күргән булса да — суга төшкән шикелле юкка чыкканнар иде.

Ләкин, бәхетенә, шул чакта каршы ишектән Нурбак килеп чыкты.

— Кайда йөрисең син? Безнекеләр аш алырга да өлгерде инде,— дип, аны үзе белән бүлмәгә алып керде. Нурбак, ялгызак булганлыктан, еш кына монда ашый, аның өстенә, редакция кешесе дә булгач, аны бик яхшы беләләр икән. Ул иптәшләрен эчке бүлмәгә керткән, һәм кухня кызлары ашларны йөгертеп чыгарырга да өлгергәннәр иде.

— Дускай, син кайда йөрисең? Менә ашың,— дип эндәште ана Петр Петрович.

Айзат аның янына барып утырды. Симез итле кып-кызыл борщ кайнар һәм гажәп тәмле булып чыкты. Яхшы ашка кыстау кирәкми: тәлинкә төбенең ялт итүен сизми дә калды. Аннан соң бәрәңге боткасы белән колбаса ашадылар. Өченчегә алма компоты эчтеләр. Бер сәгать тә үтмәгәнлер, канәгать чырай белән машиналарына урнаша да башладылар.

Нурбак Айзатны читкә чакырып алды да адресын тоттырды.
— Менә, кайтканда кер, күтәрмен,— диде.
Айзат вәгъдә бирде.
Нурбак, тагын ни әйтәсем калды икән дигәндәй, озын аяклары белән таптана-таптана уйланып торды да уңайсызланып кына елмайды:
— Син, Айзат дус, төнге хәлләрне тегеләргә сөйләмә. Бигрәк тә Тамарага,— диде.— Безнең арада булган хәлләрне кешеләрнең белеп торуы нигә кирәк...
Айзат аны тынычландырды:
— Бәй, теләсә нәрсәне сөйләп йөрергә — җилсез тартучы буш тегермәнме әллә мин!
— Рәхмәт!
— Ничек уйлыйсың соң? Кайтуны әйтәм.
Нурбак читкә карап авыр сулады.
— Үзем кайтуны уйламыйм да мин... Үзе, исенә төшеп, килеп чыкса гына... Кайтсам... ул мине барыбер кертмәячәк... Шундый ул...
Айзат дустын тынычландырырлык сүз таба алмады.
— Я,— диде Нурбак,— хуш! Сезнең белән бергә килү бик күңелле булган иде. Нишлисең, калырга, аерылырга туры килә... Хәзер редакциягә керәм...
Каты итеп кул кысыштылар.
Нурбак бар кеше белән дә саубуллашып чыкты. Читкәрәк китеп машиналарның кузгалуын көтә башлады.
— Син минем карточкаларны җибәрерсең бит инде, Нурбак? — дип дәште Тамара.
— А-а, Тамарочка, әйттем бит инде, карточкалар сез барып җиткәнче анда булыр,— диде Нурбак, эре ак тешләрен ялтырата-ялтырата елмаеп.— Мин аларны бүген үк эшләячәкмен, бүген үк.
Соңгы минутта елмаеп әйбәт итте Нурбак — Айзатның хәтеренә ул шулай елмайган килеш кереп калды...
— Я, ничек? Барыгыз да утырып беттеме? Хәзер кузгалабыз,— диде шофер.
— Беттек! — дип җавап бирделәр.
Айзат кинәт исенә төшереп мәйдан уртасына — Уйчан кеше торган урынга карады. Уйчан кеше һаман шунда иде. Ул, яшәүдән һәм бөтенбөтен дөньядан өметен өзгән бер кыяфәт белән башын иеп, инде бер кая да карамый басып тора иде.
«Килмәгән, көткән кешесе килмәгән, бөтенләй каршы алучы булмаган», дип уйлады Айзат. «Аһ, хәерсезләр, хәерсезләр!» Моторлар эшли башлады. Уйчан кеше сискәнеп китте. Болар ягына карады. Авыр мәсьәләне чишә алмаган сыман аптырап торды. Аннары биштәрен җирдән алып йөгерә-атлап болар янына килде.
Шофердан:
— Мин кире уйладым. Монда калмыйм. Сезнең белән ары китәм. Кире утырырга мөмкинме? — дип сорады.
Шоферның тавышы ни сәбәптәндер коры чыкты:
— Утыр. Урын җитәрлек.
Уйчан кеше тавыш-тынсыз гына үзенең элекке урынына менеп утырды. Биштәрен аяк очына ташлады. Иске ак күлмәгенең изүен ычкындырды. Күзләрен бер ноктага текәп уйга чумды.
Сүз әйтүче булмады.
Айзат аның бер күтәрелеп, бер төшеп торган бугаз төененә, йөзенә карады: Уйчан кешенең күз төпләре тагын да шешенебрәк, күгәребрәк киткән, ул шушы бер сәгать эчендә сизелерлек ябыккан иде.
Кайгысы бар бу кешенең. Ник икән, ни икән? Белсәң иде, ярдәм итеп булса иде!..
Айзат борчылып авыр сулады...

Машиналар ял иткән аттай җәһәт кузгалып, тагын очсыз-кырыйсыз тайгага кереп югалдылар...

Бүген юлчылар авызларына су капкандай тын гына утыралар иде. Моңа, мөгаен, ике көн килүнең ару-талулары сиздерә башлаган булса, икенче һәм өченче сәбәпләр дә юк түгел иде. Икенче сәбәп шул: уйнап-көлеп кешеләрнең күңелләрен таба белә торган егет — Нурбак юк. Өченчесе — яннарында Уйчан кеше бара. Һәркем аның яшерен борчуы барын белеп тора.

Кешеләр үз уйларына бирелеп, йокымсырабрак та бара башладылар. Тайга да, юл да кичәге, өченче көнге тайга иде. Искә алырлык вакыйгалар, мажаралар булмады.

Бәләкәй каеннар үскән болын сымак җиргә килеп чыктылар. Анда болан көтүе утлап йөри иде. Айзат та, башкалар да аларга исләре китеп карадылар (һәрхәлдә, егеткә шулай тоелды). Айзатның моңа чаклы бу кадәр боланны берьюлы күргәне юк иде әле. Кайда күрсен ди: Татарстанда аучылардан качып йөрүче бөртек-бөртек пошыйларны чутка тыкмаганда, көтү-көтү нинди болан булсын ди!

Шул чакта боланнарга әллә ни булды. Алар нидәндер курыккан шикелле кинәт кузгалдылар да, тигез җирдәге аккан су кебек, юлга таба чаба башладылар. Юл киселде. Машиналар көтүнең чыгып бетүен көтте. Кызык та, матур да, куркыныч та иде бу. Меңләгән болан өстендә мөгезләр урманы чайкалды, боланнар астында торфлы сазлык сыгылып дер-дер калтырады.

Көтү юл аркылы «агып» бетте дә киң болынның икенче башында агачлар артына күмелеп күздән югалды.

Айзат болан көтүен этләр белән көтүчеләр саклап йөртүен китаплардан, кино-картиналардан белә иде. Шуна күрә кайда соң алар дип тирә-якка карады. Ләкин этләр дә, озын корык тоткан болан сакчылары да күренмәде...

## 16

...Кояш баеп эңгер-меңгер төшкәч, колонна олы юлдан борылып ярты километр чамасы керде дә өч ягыннан кара урман әйләндереп алган түп-түгәрәк аланга килеп туктады. Аланның дүртенче ягында чит-читенә таллар һәм камышлар үскән зур күл җәелеп ята иде. Бу алан шоферларның ял итеп, кайчакларда кунып та китә торган күптәнге таныш урыннары иде, ахры. Аның берничә урынына аш пешерү, чәй кайнату өчен бастырык юанлыгы агачтан таганнар ясалган. Учак тирәләрендә печән һәм салам өемнәре ята, бер урында хәтта ун-унбиш кеше сыярлык куыш та калкып тора иде.

Машиналар, парадка җыенгандай, аланның бер читенә тезелеп туктадылар.

— Отбо-ой! — диделәр шоферлар.— Шушында кунабыз.

Түгәрәк алан җанланды, сабан туйларындагы шикелле шаулый-гөрли башлады. Айзатлар урманнан кочак-кочак чыбык-чабык җыеп чыктылар. Ике машинадагы юлчылар берләшеп, бер таганны үзләренә алдылар да учак кабызып җибәрделәр. Тагын дүрт-биш урында якты учаклар кабынды. Кичке караңгылык артка чигенеп, урман ешкынлыгына посты.

Юлда нужа калачы ашап йөри-йөри, җылы өендә генә утыручы, кояш баю белән мамык түшәгенә ятып йоклаучы адәмнәрнең исенә-осына да кермәгән төрле мажараларга, бәла-казаларга юлыга-юлыга, эт тә күрмәгән авырлыкларны башыннан кичерә-кичерә үзе дә эт каешына әйләнеп бетә икән бу шофер халкы: бер нәрсәгә дә исе китмичә, алдагысын кем үлмәгән шул күрер дип йөри башлый икән. Айзатларның шоферы да кабинасының әллә кай төшеннән генә бер чиләк су керешле борынгы җиз чәйнек чыгарды. Күлдән чумырып су алып килде, карлыган яфрак-

лары салды. Чәйнекне ялкынланып, чыртлый-чыртлый янган учак өстенә элеп куйды. Кулларын уа-уа елмайды:

— Кайгырмагыз, егетләр! Менә хәзер изүләрне ычкындырып, тирләп-пешеп чәй эчәрбез. Җылынырбыз. Мондый чәйне беренче разрядлы ресторларнардан да таба алмыйсың, хәтта җылап эзләсәң дә,— диде.

— Ур-ра-а! — дип кычкырды Тамара.

Икенче шоферны әллә матур кызның шушы шатлыклы «ура!» сы дәртләндереп җибәрде, әллә инде ул чәенә дә сөенеп утыручы юлчыларның тагын да ныграк исләрен алыйм диде: ул да кабинасына кереп югалды. Аннан солдат котелогы һәм азык-төлек сумкасын алып килде. Сумкасыннан бер шешә сөт алды, аны котелокка салып җиз чәйнек янына элде. Янә ике-өч кәгазь төргәк чыгарып үлән өстенә куйды.

— Ботка да пешерик,— диде,— солы боткасы юлчылар өчен иң әйбәт азык. Мин гел солы лачавы йөртәм. Менә, «Геркулес», овсяные хлопья диелгән. Унбиш-егерме минут эчендә пешә.

Шоферның сүзе дөрес булды. Чәй кайнап чыкканда тирә-якка тәмле ис таратып, бытырдап ботка да өлгерде. Үлән өстенә кемнеңдер кожанын, кожан өстенә газеталар җәйделәр. Һәркем чемодан, сумка, бөктәрләрен актарды, уртак табынга хәзинәсендә ни бар — шуны куйды. Бер авызлары пешкәч, әле күптән түгел генә юл өстендәге урман хуҗалыгының азык-төлек кибетен «басып» чыкканнар иде, шунлыктан «хәзинә» дигәнебез байлар ашына әйләнде: чәйдән, солы боткасыннан тыш бу табында ике-өч төрле күмәч, шикәр, конфет һәм шоколадише тәм-томнар, төрле-төрле казылыклар, кыздырылган һәм пешерелгән балык, йомырка, ит, консервалар, тавык, бер өем креветка [1], тагын әллә нинди ризыклар, хәтта бер кипкән балык та бар иде. Ул да булмады (Айзат кем куйганны абайламыйча да калды), шушы мул нигъмәтләр уртасына, сез — нәрсә, табын күрке — менә без ул дигәндәй кукраеп, өч шешә «Мәскәүски» килеп утырды.

Шоферлар тамак кырып куйдылар.

— Без мескеннәрнең «аракы — шоферлар чәе» дип яманаты чыккан,— диде Айзатларның шоферы, кружкасын кулына алып.— Ләкин күрдегез бит — ике көнгә берәр каптыммы? Юк. Руль тотканда ярамавын бик беләбез. Ә хәзер, минемчә, ярый торгандыр? Бик арытты да. Дуслар гафу итәр.

Табын җанланып, шаулашып куйды:

— Ниткән гаеп ди ул!..

— Күреп торабыз бит ничек интеккәнегезне...

— Әйдә, тотыгыз да куегыз — исәнлеккә-саулыкка!..

Шоферлар чәкешеп эчеп җибәрделәр. Ашый башладылар. Икенче шофер нишләптер үзенең яраткан солы боткасын хәтереннән чыгарды, гел авызына керергә чамалап торган мыек чылгайларын әледән-әле сыпыра-сыпыра тавык һәм казылык умыра башлады.

Кружкалар түгәрәк буйлап китте.

— Кызганыч, хатын-кызларга да кызылын-мызылын аласы калган,— диде Айзатлар шоферы.

— И аптырамагыз ла... Хәзер ире дә, хатыны да бер тигез инде,— дип, таза гына бер ханым шаяртып куйды.

— Ә-ә, шулаймыни? — диде ирләр.— Бик дөрес әйттең. Мә әле алайсаң, тот әле шушы нәмәрсәне.— Һәм аңа аракы салып бирделәр.

— Кая, бирегез, бир, дару өчен генә безгә дә хәрам түгел,— диде ханым, көлеп.

Петр Петрович та, мин бу нәрсә белән дус түгел дә, ләкин хатыннардан калышу килешмәс дип, шаярткалап бераз эчеп куйды. Чират Айзатка житте. Аның мона кадәр дусмы, дус түгелме, дип икеләнеп

[1] Креветка — диңгез кысласы.

торганы юк, әлеккәндә «арслан тотып менәрлек кенә» җибәргәли иде. Хәзер ул Петр Петровичка астыртын гына күзләрен төшерде. Уңайлы булырмы аның алдында? Ул, ни дисән дә, районо мөдире бит.

Петр Петрович — хәйләкәр төлке (ни әйтсәң дә педагог, психолог шул!) аның нәрсә уйлап утыруын сизеп, эчке бер җылы тавыш белән ягымлы гына дәште:

— Айзат дускай, чын күңел белән биргән сыйдан баш тарту килешмәс. Без беребез дә абстинентлар [1] түгел. Арылды. Төн дә салкын. Әгәр организмыгыз кабул итсә, икеләнмәгез,— диде.

Айзат җиңеләеп кружканы кулына алды...

Аштан һәм чәйдән соң таралмыйча, әңгәмә башлап җибәрделәр.

Агачлар артыннан әкрен генә җиз тас төбе төсле түгәрәк ай калыкты. Күл өстенә терекөмештәй якты эз сузылды. Нарат башларына тияртимәс кенә җемелдәп торган йодрык-йодрык якты йолдызлар тоныкланып өскәрәк күтәрелде. Җидегән йолдыз, чумырып су алырга теләгәндәй, күлнең аргы башына төшә башлады. Якындагы агачларда дөрләп янган учакларның кызгылт-сары шәүләләре биеп торды.

Петр Петрович әңгәмәгә катнашмыйча башкаларның сүзен тын гына тыңлап утырды да, торып, күл ягына юнәлде. Озакламый унгарак каерылып, таллар эченә кереп күмелде.

Сәгатькә якын вакыт үтте. Хатын-кызлар йоклар өчен шалашка кереп киттеләр. Ирләрне дә йокы баса башлады. Әңгәмә сүрелде. Учакның ялкыны кимеде. Мөдир чыкмады. Айзат, борчылып, адаштымы әллә дип уйлады һәм аны эзләргә китте.

Күл ярлары биек кенә иде. Яр өсләре — тигез ялан. Яланда төркем-төркем карт өянкеләр үсә. Тоныкай яктысында ялтырап, алардан бөтерелә-бөтерелә яфраклар коела. Төнге тайганың тирән һәм серле тынлыгын бозып, аяк астында коры яфрак кыштырдый.

Кызык бу тормыш! Әллә кайда — Урал таулары артындагы кара тайга уртасында кара төндә ялгыз башы йөри түгелме соң Айзат! Дерсу Узала кебек, Соңгы могикан кебек. Институтта бәхәсләшкән, авыз суларын корыткан романтика белән мажара дигән нәмәкәе җир читендә түгел икән ич бу фани дөньяның! Хәзер каршыга үкерә-үкерә аю, я бүре көтүе чыкса? Индә мылтык, билдә пычак юк. Эһ тә итмиләр, тоталар да, монысы кемгә дип, бүлешеп ашыйлар инде. Бисмилла иррахман иррахим дип, коры яфрак өстенә егып...

Айзат үз-үзеннән көлеп куйды. И бала, бала шул әле син һаман, диде, мыек чыккан, хатын алган булгансың, ә үзенә акыл теше чыкмаган. Петр Петровичны табарга кирәк. Бик озакка китсә, ярдәмгә кешеләр чакырырга кирәк. Үен түгел...

Тагын берәз баргач, ялан киңәеп, матурланып китте. Тар гына инеш борыла-сырыла агып күлгә кушылган урында ике рәт булып карт өянкеләр үсә иде. Шулар төбендәге эскәмиядә бөкрәеп Петр Петрович утыра. Айзат туктап аңа карап торды. Әмма Петр Петрович, һич кымшанмыйча, гел бер урынга карап, агач сын кебек катып утыруында булды. Айзат тагын бер-ике адым атлап, әкрен генә йөткереп куйды. Аны күргәч, Петр Петрович гаҗәпләнмәде.

— Ә-ә, Айзат. Монда килегез,— диде.

— Петр Петрович... бик озак тордыгыз... Юк та юк. Әллә нигә тап булуың бар... я адашып-нитеп китәр, мин әйтәм.

— Мин адашаммы соң, дускай,— диде Петр Петрович, ничектер әкрен һәм сәер тавыш белән.— Бу урыннар миңа бик таныш һәм бик кадерле, истәлекле урыннар.— Ул ымлап каршысындагы зур-зур ташлар аунап яткан, инде үлән каплап бетерә язган чокырлы-чакырлы урыннарны күрсәтте.— Минә монда өй иде, хәзер аның урынына кычыт-

[1] Абстинент — аракыны бөтенләй тыюны таләп итүче.

кан, әрекмән үскән, нигез ташлары гына аунап ята. Әнә тегендә сарай иде, арырак абзарлар, яр буенда мунча. Бу инешнең теге төшендәрәк такта басма иде, күлнең бу урынында көймә. Монда чия бакчасы. Язларын ап-ак чәчәккә күмелә иде. Чеховның «Чия бакчасы»ннан ким күрми идек без аны...

Петр Петровичның тавышы калтырап куйды. Ул кинәт туктап, бер башы җиргә иңә башлаган иске эскәмияне сыйпады:

— Бу эскәмия карт инде, бик карт. Безнең монда утырып ал таңнарны каршылаган чакларыбыз булды... Көз көннәрендә ай да күлнең нәкъ әнә шул урыныннан, бүген калыккан урыныннан калка иде... Ә бу инешнең исеме — Ширбәт. Суы бик чиста, салкын һәм ширбәт шикелле тәмле. Аңа без шундый исем куштык. Бүтәннәр белми, үзебез генә белә идек...

Петр Петрович тынып калды. Айзат дәшергә кыймады. Баш очында көмеш ай, тирә-якта серле тын тайга иде. Менә кинәт, бар дөньяны сискәндереп, күл аръягында илерә-илерә кемдер кычкырып җибәрде.

— Болан баласы җылый. Бүре-мазар тоткандыр,— диде Петр Петрович.

Озак та үтмәде, капма-каршы яктан бала көлүенә дә, җылавына да охшаган икенче шомлы тавыш ишетелде.

— Тагын эләктердеме?

— Монысы мәче башлы ябалак...

Ай янында, артыннан якты койрык сузып, йолдыз атылды. Аннан икенчесе, өченчесе...

— Йолдызлар атыла-а. Нишләптер бик еш.

Петр Петрович авыр сулады.

— Көз көне, агач яфраклары коелган кебек, йолдызлар да еш атыла. Көз — сулу, саргаю һәм үлү чоры. Табигатьтә үсү бөтенләй дип әйтерлек тукталa. Җәнлекләр дә кыш көне, җылы җәйне көтеп, җан саклау өчен генә яшиләр. Көз көне кеше башына күңелсез уйлар килә. Кеше үз гомеренең дә кайдадыр көзе булуын уйлый, аның бер вакыт килеп җитәчәген күз алдына китерә. Көзге көнне, кияүләр көне дип мактасалар да, яратмыйм.

Ярар, дускай, фәлсәфә сатып утырудан файда юк. Төне бик матур, төрле хыяллар кузгата торган төн булса да, кайтып ятыйк.

Алар кайтып киттеләр.

Артларыннан мәче башлы ябалак кычкырып көлеп калды...

Түгәрәк аландагы учаклар төнге аксыл күккә сыек төтен баганалары сузып әле дә янып яталар иде.

Аучы Петр Петрович белән Айзатка, читкәрәк күчеп, үз яныннан урын бирде.

— Озакладыгыз.

— Күл буйларын әйләндек, төн матур.

Учак тирәсендәгеләр болар килгәч өзелгән әңгәмәләрен кабат ялгап җибәрделәр.

— ...Ә мин элек тә әйтеп килдем, хәзер дә әйтәм һәм үлгәнче әйтермен — тимер кулсыз ярамый, тезгенне каты тотмыйча булмый,— дип, күн бүрек кигән берәү кулларын бутый-бутый кызып сөйли башлады.— Әнә күршемнең, үзе囗 эштә вакытта, бар әйберен җыеп чыкканнар. Шкафта онытылып чалбары гына калган. Үзе милициягә йөгергән икән — балта урлаган — сабын да урлый дигән шикелле, икенче мәртәбә кереп, теге чалбарны да чәлдереп киткәннәр... Ачкыч ятканнар... Ә ни белән бетте? Ярты әйберләрен таптылар, яртысын юк. Тегеләрне бары тик куркыттылар гына — шуның белән шул: яше җитми... Ха!..

«Элек тә булган иде бу сүз,— дип уйлады Айзат.— Тагын шуңа тотынганнар. Халыкның теңкәсенә бик нык тия микәнни соң бу?»

— Тамаклары тук, өсләре бөтен, ни ашасалар, ни кисәләр, шул бар.

Туеп сикерәләр, азыналар,— дип, калын тавышлы бер ир кун бүрекнең сүзен куәтләде.— Чыбык кирәк аларга — менә шул. Чыбык ашап караганнары юк. Шуна курыкмый башладылар.

Петр Петрович тамагын кырып алды:

— Әйтергә кирәк, «педагог» дигән сүз «таяклы кеше» дигәнне аңлата. Борынгы Грециядә килеп чыккан. «Пед» — таяк, «педагог» — таяклы кеше. Грециядә ул вакытта коллар укыткан. Бер колның да ирекле грекка сугарга хакы булмаган. Ә менә педагоглар суккан. Аларга шундый өстенлек бирелгән.

— Менә-менә! Әйтәм бит: ике сөйләшмәгән элекке халык, каты куллы булган.

— Ләкин бу үсеш чорының кирәкле бер этабы гына булган,— дип, тегене ишетмәгәндәй, Петр Петрович сүзен дәвам итте.— Без балаларны кыйнап, аларга гомерлек авыр эз ясарга теләмибез. Ул тормыш законнарын тәне белән түгел, акылы белән аңларга тиеш. Гуманизм...

Күн бүрекле кеше гарьләнеп тәмәке төпчеген учакка ташлады.

— Һә-ә-әй!.. Гуманизм, гуманизм!.. Бер сволочь йөз рәтле кешенең тенкәсен корта да, шуна, без гуманистлар дип, акыл өйрәтеп яталар. Син, җан кисәгем, зинһар өчен урлашма, чәнчемә инде дип ялыналар. Мин ул үтерүчеләрне минут тотмый, судсыз-нисез, үзем атар идем... Җинаятьнең атасы — кеше үтерү, анасы — аракы. Адәм каны атлатмасын сволочьларны. Канга кан белән җавап бирергә — һәм бетте-китте!..

## 17

Шул чагында Уйчан кеше әкрен генә килде дә, аякларын бөкләп, ничектер бөкрәеп һәм кечерәеп учак янына утырды. Учакның сүрән шәүләләре сүрән күләгәләр булып аның йөзендә дерелди башлады.

— Ул чагында... Менә мине атыгыз... Чөнки... мин... үтерүче,— диде Уйчан кеше.

Ишетүчеләр катып калды. Арттa кемдер пышылдап һәм куркынып: «Нәрсә ди? Ни әйтә?» — дип сорады.

— Дөресрәге, үтерүче үк түгел, әмма үтермәкче булган адәм,— дип ачыклады Уйчан кеше.

Юлчылар, әле генә күргәндәй, текәлеп аңа карадылар.

— Үлмәдеме... ул? — дип сорады Аучы.

— Исән.

— Аныс ярый икән.

Уйчан кеше ямансу гына елмайды:

— Белеп торам: бу хәтәр эш сезне кызыксындыра. Сорарга гына кыймыйсыз. Йокы кала димәсәгез, сөйләргә була.

Учак тирәсе кыймылдашып куйды.

— Гел йоклый торган йокы ла ул. Аны җәлләп торырга!

— Әгәр үзегезгә авыр булмаса, сөйләгез.

Уйчан кеше көлмәк изүен ычкындырды, уч төбе белән иягеннән ышкып куйды. Күзләрен көлләнә башлаган учакка текәп, кайбер урыннарда туктала-туктала, үз башыннан үткән фаҗигане сөйләргә тотынды.

— Сүземне соңгы вакыттан гына башласам, аңламассыз дип куркам. Шуның өчен ерактанрак башларга исәп, гаеп итмәссез... 1944 елның февраль урталарында мин фронттан кайтып төштем. Аякларым солдат походларына чыдарлык иде әле, кулларым да автомат тотарлык иде. Шулай да кайтарып җибәрделәр. Моряклар әйтмешли, ярга чыгардылар. Үпкәләрем беткән иде. Төрле госпитальләрдә ята-ята ярты ел үткәрдем. Үлемне көтмә, үзе килер диләр дә — ләкин минеке бик озакланды. Кайчан килә, кайчан җанымны алып китә соң инде бу нәрсә, ник соңгара дип юксына башлаган идем.

Бер карасаң, кызык та һәм гаҗәп тә. Дүрт елга якын пуля астында

йөргән солдат кеннәрдән бер көнне пуля тиеп түгел, тылдагы гап-гади кеше кебек караватка ята да гап-гади итеп үлә дә китә, ә?!.

Ярты ел яттың, житәр, башкаларга да урын кирәк, монда үлмә — кайтып үл дигәннәрдер инде, чыгарып жибәрделәр. Урал тауларын кичеп Себергә — туган шәһәремә кайтып төштем. Әнинең ике ел элек вафат булуын язганнар иде. Мин аның бердәнбер малае. Бүтән туганмазар юк. Вокзалдан ук зиратка киттем. Ул кышны үлем-житемнәр күп иде, ахрысы. Зират юллары шактый тапталган, күмеп йөрүчеләр дә, яңа казылган каберләр дә аз түгел иде. Агач араларында көрт ярып күпме әйләнсәм дә, әни карчыкның каберен тапмадым. Хәлем бетте. Гыжылдап бер ташка утырдым.

Үзем утырам, үзем уйланам. Һай, мин әйтәм, жүләр Иван икәнсең, иптәш. Аның кайгысы булганмы кешеләрдә. Ятим карчыкка кем таш куйсын, кем исемен язсын. Үзе исән чакта гына сәет бит кеше, үлгәч — мәет. Исемсез кабердә ята ул бичаракай. Ай буе эзләсәң дә таба алмассың син аны. табутынны хәстәрләп йөрүче сырхау солдат!..

Зираттан чыктым да үзем туып-үскән, шуннан сугышка алынган, шунда әнием үлгән баракка киттем. Кар өстенә сузылып яктысы төшкән сынар тәрәзәбездән күзләремне алмыйча бик озак басып тордым. Бозлы тайгак сукмактан ишегалдына кердем. Анда бер-берсенә терәтеп искемоскы такталардан корыштырган утын сарайлары юк иде инде. Безнең сарай да, түбәсендәге күгәрчен оялары да юк — барысын да жимергәннәр, ягып бетергәннәр иде.

Баракның озын коридорын ишек өстендәге тузанлы лампочка тоныкына яктыртып тора. Салкын. Идәнгә түгелгән сулар шакыраеп каткан. Ике яктан тезелеп киткән ишек түбәләреннән пар чыгып зыкыга әйләнгән.

Коридорда берәү дә юк иде. Мине күрүче булмады. Үзебезнең ишек янына килеп бастым да, йөрәгемнең тар читлек эчендәге кош кебек бәргәләнүен тыярга теләп, хәл жыеп тордым. Кара чүпрәк белән тышланган таныш ишек! Тишек-мошыкларыннан асылынып торган сүс кисәкләренә кадәр жанга якын. Малай чакларны уйлата, күңелдә әллә никадәр истәлекләр уята, давыллы хисләр кузгата. Әнә, алачыкта эткәй үзе чүкеп ясаган тимер тотка! Агарып беткән, ялтырап тора. Мин аны ничә йөз һәм ничә мең мәртәбәләр тотып ишегебезне ачканмын бит!..

Менә күрше ишекне шырр итеп ачып, икесенә бер олы бишмәт бөркәнгән ике бәләкәй малай атылып чыкты да, ялан аяклары белән бозлы идәнгә тып-тып баса-баса, коридор башындагы бәдрәфкә чапты. Мин ишек шакыдым.

— Керегез! — диделәр эчтән.

Бүлмә якты һәм жылы. Анда суган, чын май белән кыздырылган тәмле бәрәңге исе таралган иде. Табада кадерләп кенә кыздырылган өй бәрәңгесе! Минем мондый тәмле исне күптә-ән иснәп караганым юк иде инде.

Өстәл янында әле үзе дә кыз бала кебек кенә яшь хатын бала имезеп утыра иде. Ят кешене күргәч, күкрәген каплап яны белән борылды.

Өстәлгә чуклы ашъяулык жәелгән. Ашъяулык өстендә газета-журналлар, китаплар ята, безнең аяклы пыяла лампабыз янып тора. Мин шушы өстәлдә, шушы лампа яктысында дәрес әзерли идем, лобзик белән фанерадан самолетлар, танклар кисә идем. Ишек төбендә таныш галанка. Әни, минем буем житмәсен дип, шырпы капларын аның өске сырына тезеп куя торган иде. Галанка алдында стенага эленгән өч шүрлекле шкаф. Аны әти үзе ясап какты, һәм мин урындыкка басып аның өске шүрлегеннән әни яшергән конфет-прянникләрне эзли идем. Түрдә тимер караваты. Шул — безнең карават. Чукмар башлы, зәңгәр. Әни белән әти иртүк эшкә чыгып киткәндә, сандык өстеннән күтәреп алып, мине шунда яткыралар һәм өстемә безнең бик кадерле әйбәт әйберебез-

не — хәтфә тышлы җылы юрганыбызны ябалар иде. Юрган күренми, тузгандыр инде. Тәрәзә төбендәге гөлләр дә ничектер ят шикелле. Бәлки әни утырткан гөл түгелдер, аларны шушы яшь хатын утырткандыр...

Хатын, ишек төбендә каккан казык шикелле торучы яшь солдатка карап, бигрәк тә аның бер әйбердән икенчесенә күчкән утлы карашын күреп, әллә ни уйлады, ахры, баласын бишеккә илтеп салды да, аны тирбәтә-тирбәтә:

— Ялгышып кердегезме әллә, иптәш? — дип, борчылып сорады.

— Гафу итегез, сеңелем! — дидем мин исемә килеп.— Шикләнмәгез. Мин адашып кермәдем. Бу минем туып-үскән өем,— дип үземнең кем икәнлегемне дә, нишләп йөрүемне дә әйттем.

Хатынның йөзе ачылды. Миңа чишенергә кушты, утыртты, кайнар чәй ясады. Өстәлгә мин кызыккан суганлы бәрәңге дә килде.

Ул үзе әле яңа гына эштән кайткан, ә ире төнге сменага киткән. Алар шулай берсе кайтып, икенчесе китеп, алмаш-тилмәш бәләкәй кызларын карыйлар икән.

Яшь хатын миңа әни турында, бигрәк тә мәрхүмкәйнең соңгы көннәре турында җентекләп сөйләп бирде. Әни аларны фатирга керткән. Әнине тәрбияләп торганнар. Әни карчык алардан бик риза булып, үлгән чакта хәер-фатихасын биреп үлгән.

Без озак сөйләшеп утырдык. Ул миннән бу өйдә үткән бала чакларым, солдат елларым турында кызыксынып сорашты. Ләкин шулай дусларча сөйләшеп утырганда да аның күзләрендә ниндидер куенсыну һәм шикләнү бетмәде. Ул кинәт нәрсәдер сорарга яки әйтергә омтылып та, кыймыйча икеләнеп кала иде. Түзмәдем, шаяртkan булып әйтеп куйдым:

— Сез бик серле ханымга охшыйсыз,— дидем.

— Нишләп алай икән? Кешеләрдән яшерен бер серем дә юк, эчемдәге — тышымда,— дип көлде.

— Тел очыгызда торган сүзне кычкырып сорарга кыюлыгыгыз җитми.

— Дөрес,— диде,— безнең өчен бик әһәмиятле бер мәсьәлә бар, шуны беләсем килә. Тик... сорасам, ачуланмассызмы икән?

— Юк, рәхим итегез!

— Сез, әлбәттә, үз бүлмәгездә калырсыз инде, безгә чыгарга туры килер. Тик кыш өстеннән җиңел эш түгел бу. Язга хәтле торырга рөхсәт итсәгез иде? Курыкмагыз: кызыбыз бер дә җылак түгел, сезгә комачауламас. Ә без ирем белән рәтләп өйдә дә тормыйбыз.

Мин аны тынычландырырга ашыктым:

— Һа-ай, юк нәрсәгә борчылып утыргансыз икән. Чатлама суыкта яшь балагыз белән фатирдан куарга мине кем дип беләсез! Мин — солдат. Кешеләрне суыкка куу өчен түгел — җылы өйләргә кертү өчен дүрт ел сугышып йөрдем. Дүртебез дә бик рәхәтләнеп торырбыз, күңелләребез киң булсын,— дидем.

Хатын миңа рәхмәтләр укыды, күбәләктәй җиңеләеп, шатланып китте. Ә үзе шулай да ышангач-ышангач тәмам ышану өчен:

— Сөйгән кызыгыз сагынып torгандыр? Өйләнерсез менә, туй ясарсыз. Шулай бит? — дип сорады.

— Кызганычка каршы, андый кешем юк шул. Туйлар ясау өчен башта кыз табарга кирәк,— дидем.

Аерылганда вәгъдәләр бирешеп, сугышка киткәч хат алышып торган кызым чыннан да юк иде. Безне бик яшьләй алдылар. Безгә кызлар исе керә генә башлаган иде әле. Ә сөюнең тәмле газабын татырга бөтенләй өлгермәгән идек. Ләкин бу безнең җебегәнлектән түгел, минем һәм минем шикелле мең-мең малайларның гаебе түгел иде. Менә безнең иң беренче, иң самими хисләребезне тартып алган каһәр төшкән сугыш гаепле иде.

Шуна күрә мин моны яшь ханымга һич тә яшерми, оялмый әйттем.

Ә монда уларга — туып-үскән туфрагыма күмелергә дип кайтуымны, бәлки беренче яшел чирәмнәргә кадәр дә тарта алмаячагымны, язның апрель ташулары белән агып китәчәгемне әйтмәдем. Шатлыклы хәбәр түгел ич. Сугыш, кырылыш, ачлык. Халыкның кайгысы болай да түбәсеннән ашкан...

Мин бу төнне, ханым үз караватында рәхәтләнеп иркенләп бер йокла дип бик кыстаса да, кунарга калмадым, төрле юк-бар гайбәтләргә тел озынайтырга ирек бирмәс өчен, күрше бүлмәгә — әнинең дус карчыгына кереп йокладым...

Икенче көнне иртән аның үзе шикелле яшь кенә ире, бер заводның смена мастеры, эштән кайтты һәм мине әнинең каберен күрсәтү өчен зиратка алып китте. Әнине зиратның иң читенә, койма янына, җирләгәннәр иде. Мин сизелер-сизелмәс кенә калкып торган ак кар таучыгына бик озак карап тордым. Күңелем тулып җылап та алдым. Туңа башлагач, солдат итекләрем белән шыгыр-шыгыр килеп зират юллары буйлап йөрдем. Йөрдем дә тагын әйләнеп килдем. Башларым чатнаганчы уйладым. Үткәнне, киләчәкне. Үткәннәр — үткән. Аларны искә төшерү авыр түгел. Ә менә киләчәк билгесез, киләчәк — томан, куе томан.

Мин киләчәккә күп төрле планнар корып карадым. Ләкин аларның барысы да өч-дүрт айдан бер үк ноктага килеп терәлде. Үлемгә. Дөньясы шулай корылган: берәүләр көлә, берәүләр үлә. Мин үземнең яздан да калмаячагымны белә идем һәм аннан курыкмый да башлаган идем. Сугышта гел кан күреп һәм үлем арасында йөреп күнеккән идем инде.

Ярый, язга кадәр дүртәүләшеп яшәдек, ди. Яз көне җир эрегәч, мине әнкәй янына китереп куйдылар, ди. Паспортымны ЗАГСның үлемнәрне теркәү бүлегенә, хәрби билетымны комиссариатка, орден белән медальләремне кызларына уйнарга бирерләр. Ләкин аларның яшь йөрәкләрендә бер үлем шәүләсе уелып калыр. Гомерләренә дә җуелмас. Үлем истәлеге — кара һәм кайгылы истәлек. Ә ник мин аларның йөрәкләренә тиктомалдан кара истәлек салып калдырырга тиеш? Нинди хакым бар? Мин кем аларга? Чит-ят бер авыру солдат.

Дөрес, мин соңгы көнемә хәтле кеше кулына калмаска, аяктан егылмаска тырышачакмын. Күкрәк авырулы көлеп үләр дип әйтәләр. Ләкин дөнья бит ул! Дөнья хәлен кем белә! Бәлки миңа да соңгы атналарымда кеше күзенә карап түшәктә ятарга, кеше тәрбиясенә мохтаҗ булырга туры килер. Ә минем ул кешеләрне мәшәкатьләргә хакым юк.

Кыскасы, әйтәм бит, нык уйландым, нык. Минем эшкә яраклы җирем калмаган иде инде. Тезләнеп ялынсам да, бер кая да кабул итәчәк түгелләр иде. Ә бер шөгыльсез, үз авыруың белән икәүдән икәү генә, аның белән булышып кына көннәрне үткәрүе авыр булачак. Мин шуңа күрә, савыкмас авыруның тизрәк үлгәне яхшы, әллә ул каһәр суккан соңгы сәгать дигән нәрсәне тизләтергәме дип тә уйлап карадым. Мәсәлән, тирләгән килеш салкында йөрисең, бөркү бүлмәдә атналар үткәрәсең, тәүлек буе каты махорка тартасың, эчкечелеккә салынасың... Мондый сыналган чаралар белән аны тизләтеп була. Ләкин кабер казучылар искә төшкәч, бу уемнан да кире кайттым. Җир тун, таш кебек каткан. Сукраныр лар, әрләрләр... Мин язгы сулар китеп, җир эреп, беренче үләннәр борын төрткәнче ничек тә җан сакларга карар бирдем.

Тагын бераздан минем башка монысыннан да шәбрәк фикер килде. Ә ник монда уларга? Бу шәһәрдән китәргә кирәк. Кая да булса еракка олагырга. Мондагы танышлар, бергә уйнап үскән дус-ишләр, белгән кешеләр мине бер чакта да үлгәнгә исәпләмәсеннәр. Ул фәләненче елны үлде дип сөйләмәсеннәр. Мин аларның күңелендә исән булып калыйм.

Китәргә!.. Югалырга!..

Кич белән яшь ханымга шул карарымны әйткәч, ул аптырады.

— Әллә безне яратмадыгызмы, абый? Әллә бергә торыйк дигән сүз ошамадымы? — дип сорады.

Мин аны юатырга тотындым.

— Юк, юк!.. Мәскәүдә минем бергә хезмәт иткән полкташ дустым бар, шул чакыра,— дидем.

— Кичә калам дигән төслерәк әйткән идегез бит?

— Шулай иде дә... Тик мин һич тә бер төрле генә була алмыйм. Кичәге планым бүгенгә ярамый.

— И абый, бергә-бергә күңелле булыр иде. Сыяр идек әле. Көннәр матурайгач китәр идегез.

— Монда йөрәк мәсьәләсе дә бар шул, сеңелкәш,— дип алдарга мәҗбүр булдым.— Кайт дип калды. Алдагы көннәргә планнар бик зур.

— И, шулаймыни, абы-ый? — диде хуҗа хатын, ачылып китеп.— Өйләнешәсездер инде, әйеме?

— Шундыйрак уй бар барын. Тик кайчанрак булыр. Анысы хәл ителмәгән. Дөресрәге, хәл ителеп үк бетмәгән.

— Парлашып кайтыгыз, абый. Бөтенләйгә димәсәгез, кунакка булса да.

— Юк, сеңелкәш, көтмәгез. Кунакка да кайтып булмас. Якын юл түгел. Борчылмагыз, мин бу бүлмәне бөтенләйгә сезгә калдырам. Мин кайтыр дип курыкмагыз. Кайтып булмас... Кайтып булмас... Юллар бик ерак... Анда... бер киткәч... кайтып йөрмиләр...

Шуннан соң, бүген булса да кунып, җылы өйдә йоклап китегез, төнгә каршы кая барасыз, дип ялына-ялына кыставына да карамастан, яшь ханым белән саубуллаштым. Чыгып китә башлагач сандыктан алып, ул миңа бер кечкенә генә төенчек бирде.

— Күңеле тулыр, авыр уйлар уйлар, кайтып кергәч тә хәсрәтләнмәсен дип, кичә тапшырмаган идем. Гафу итегез! Әнкәгезнең сезгә бирергә кушып калдырган соңгы әманәте,— диде.

Төенчекне кулыма алуга йөрәгем дерт итеп китте: кара чүпрәк, әнинең әлек кешелеккә генә бәйли торган чигүле кара яулыгының бер кисәге иде бу. Ашыга-ашыга төенчекне чишеп җибәрдем. Төенчек эченнән әти-әни һәм мин өчәүләп төшкән фотокарточка, бер кисәк җиләк сабыны, минем фронттан язган хатларым һәм унөч сум акча килеп чыкты.

Бүлмәдә кинәт әниемнең: «Улым! Улым!..» дигән тавышы яңгырап киткәндәй булды.

Мин ихтыярсыз тәгәри башлаган күз яшьләремне яшь киленгә күрсәтмәс өчен ашыгып кына саубуллаштым да кара төенчекне күкрәгемә кысып чыгып йөгердем...

Уйчан кеше сүзеннән туктады, башын иеп уйга калды.

Учак янында алар үзләре генә түгел иде инде — болар нишләп тын утыра, нинди сүз сөйлиләр монда дип, башка учак яннарыннан да кешеләр килгән иде. Кай арада куыштан чыккандыр, Тамара да Уйчан кеше каршысында, аның авызына карап, дулкынланып, ах-ух килеп утыра. Тынлык озакка сузылгач, ул авыр сулады да, урыныннан торып, учакка чыбык-чабыклар илтеп салды. Кисәү башларын уртагарак этте. Учак яңа көч белән күтәрелеп яңа башлады. Аучы әкрен тавыш белән, әмма ашыгып:

— Тамара, толымнарың утка керә күрмәсен! — дип кисәтте.

Тамара толымнарын җилкәсенә чөеп, урынына барып утырды.

Күл ягында җылап-җылап бер төн кошы кычкырды.

Түгәрәк аланның аргы башындагы янәшә куе учакның икесе дә бербер артлы сүнде.

Каралҗым күктән, биектән, бик биектән талгын гына гүли-гүли төнге самолетлар үтте.

Уйчан кеше бу гөрелтегә айнып киткәндәй булды. Кымшанып куйды, нияген ышкыды да сүзен ялгап китте:

— Төнне вокзалда үткәрдем. Таң атканда поезд килде. Шыгрым тулы вагоннарның берсенә этелә-төртелә кердем дә Урал таулары аша кире Европага китеп бардым. Ләкин, бәхетемә каршы димме, бәхетсезлеккә каршы димме, Урал тауларын кичәргә насыйп итмәде: бер шәһәрдә поездан төшеп калырга һәм егерме ел буе яшәргә туры килде...

Калуымның сәбәбен сорасагыз, болай булды. Станцага килеп туктагач, кайнаган су алмакчы булып, вагоннан төштем. Поезд озак тора дигәч, бераз һава сулау нияте белән вокзал каршысындагы бакчага киттем.

Күрәләгән сукмаклары буйлап бер үттем, сукмак читендә басып торган орчык буе гына бер бәләкәй малай миңа күзләрен тутырып карап калды. Икенче тапкыр урап килдем, малай һаман шул төштә, мина һаман йотылып карап тора. Мин инде бу юлы игътибар итмичә кала алмадым, адымнарымны әкренәйтеп ныклабрак карадым.

Ул бик бәләкәй иде әле, бары дүрт-биш яшьләр тирәсендә генә булгандыр. Аягында үкчәсенә күн теккән олтанлы ак киез итек. Үзенә таман гына. Өстендә билен каеш белән буган, озын итәкләрен күтәртеп шул каешка кыстырган искерәк кара телогрейка, җиңнәрен дә, озын булганга, кайтарып куйган. Куян мамыгыннан бәйләгән ак башлык. Аның да колакчаларын төшереп ияк астыннан каптырган. Кечерәк йөзе бик ябык һәм агарып сулган булса да — матур. Ә күзләре кап-кара. Чигәннеке төсле янып тора. Шул зур кара күзләре белән мина караган да каткан. Мин кая борылсам, шунда борыла, кая барсам, шул якка карый. Нидер әйтергә тели, нидер сорарга омтыла, тик кыюлыгы гына җитми, нәрсәгәдер базмый, шүрли төсле.

Өченче мәртәбә бакчаны урап килеп, үзенә карый-карый янынннан үтә башлагач, ул сабый тартынуын җиңде. Җәлт кенә урыныннан кузгалды. Йөгереп килде дә нәни куллары белән тезләремнән кысып кочаклап алды.

Шатланып һәм куркып:

— Әти!..— дип кычкырды.

Жылый-жылый:

— Әти!.. Әтием!.. Кайттыңмы?!. Әти!.. Әтием кайтты!.. Әтием!.. Әтием кайтты!..— дип сөйләнде.

Яныбызга халык җыела башлады.

— Әтисе кайткан!..

— Безнеке кайларда йөри торгандыр?!

— Сабыйның бәхете бар икән,— диештеләр хатын-кызлар һәм күнелләре тулып күз яшьләрен сөртеп алдылар.

Бер тимер юлчы килеп сүзгә кушылды:

— Бүген генә түгел. Әти кайта дип, җәйдән бирле килә инде ул монда. Көн дә дип әйтерлек. Бүген кайтмады әле, иртәгә кайта дип, кич кенә китә. Әнисе дә килеп алгалады, без дә куып карадык — тыңламады. Күнеле сизгән икән баланың, төшенә кергән икән. Тәки сүзен сүз итте. Егет чыгар моннан, молодец!..

Шунда хатыннарның берсе миңа киңәш бирде:

— Я, күтәреп ал инде, газиз баланны! Исең китеп торма. Күкрәгеңә кыс, сөй газиз балакаеңны... Куанып күрешергә язган булгач... И бәхет, бәхет!..

Мин баланы күтәреп алдым. Ул минем муенымнан кысып кочаклады, кечкенә битен күкрәгемә яшерде. Мин аның шул сулган битләреннән бик үбәргә теләсәм дә, үземнең ни хәлдә икәнемне уйлап, тыелып калдым. Халык арасыннан әкрен генә чыктым һәм, үземнең кая баруымны да абайлап тормыйча, бер урамга кереп киттем...

Әллә ничә өйне узгач кына, мин аңыма килгәндәй булдым. Малайны җиргә бастырып:

— Кем син? Исемең ничек синең? — дип сорадым.

— Сережа,— диде.
— Ярый, Сережа, өегез еракмы? Кайда торасыз?
— Тегендә-ә.

Ул кулын сузып күрсәтте.

Мин кесәләремне актарып карадым. Ләкин йолдызлы солдат төймәсеннән бүтән әйбер тапмадым. Аны Сережага бирдем.

— Бар, Сережа... Сергей, кайт инде. Өегезгә кайт. Тунарсың, бүген көн бик суык,— дидем һәм аның аркасыннан сөйдем дә борылып китә башладым.

Шунда минем бәләкәй танышым артымнан йөгереп килеп, шинель итәгемә ябышты да кычкырып җылап җибәрде.

— Китмә-ә! Әти, китмә-ә!.. Мин сине ярата-ам... Әни дә ярата-а... Китмә-ә!..

Аптырап калдым. Туктадым да аны яңадан күтәреп алдым. Шайтан алгыры, ничек була соң инде бу? Нишләргә соң миңа? Әнә, чытырдатып муенымнан кочаклады да тагын тынып калды. Аның җылысы шинель аркылы миңа да күчә кебек. Сулышы авыру күкрәгемә шифа булып керә сыман. Әнидән башка минем күкрәгемә кемнең шулай сыенганы бар? Мине кем кочаклады? Менә шушылай! Чын күңеле белән яратып, ышанып. Миңа ышанып һәм чын күңеле белән яратып!..

Нишләргә соң? Әйдә, булмаса булган икән — илтеп куйыйм. Әниенә әйтермен, көн дә чыгарып йөртмә баланны, суык, тунар, диярмен. Ә поезд? Поезд китеп барыр бит. Билеты кесәсендә дип көтеп тормас. Әйдә, китә бирсен. Миңа барыбер. Поездда ни, монда ни! Азиядә ни, Европада ни! Әйе. Соңгысы түгел. Поездлар йөреп тора. Поездлар тагын килер... Әйдә, Сережа! Күттек, Сергей! Үзең әйткәндәй, тегендә-ә-ә... Сине шушындый салкынга чыгарып җибәргән әниең янына...

Без киттек. Сережаны күтәреп, тегендә-тегендә дип атлый торгач, шактый җир үттек. Шәһәр читенә җитеп, кар сырындылары басып киткән урамга борылгач, Сережа бер өйне күрсәтте:

— Менә! — диде.

Аның «менә» дигәне асты кызыл кирпечтән, икенче каты агачтан салынган һәм түбә кыегында өченче кат дип чутланырга хакы булырдай күгәрчен оясы шикелле кечкенә чарлаклы, элекке урта кул сәүдәгәрдән калган бер йорт иде.

Без парадный ишекләрне, утын сарайларын һәм бер таш мунчаны үтеп, өй артына чыктык. Сережа шундагы ишекне күрсәтеп:

— Менә! — диде.

Ишекне ачтым. Аска төшеп киткән текә бер баскыч, аның янәшәсендә өскә менеп киткән икенче баскыч күренде.

Сережа, өскә менеп киткәненә күрсәтеп, янә:

— Менә! — диде.

Без килеп кергән чардак җиде-сигез квадрат метрлы гына бәләкәй бүлмә иде. Сул почмакта плитә, түрдә карават, өстәл, тумбочка һәм ике иске урындык. Озынрак кешенең башы тиярлек тәбәнәк түшәм, ике кечкенә тәрәзә. Һәм тагын шуны әйтергә кирәк: чардак бик салкын иде, ишек тупсасы белән түр почмакларга боз каткан иде.

Әйе-е, әтисен юкка гына тилмереп көтми икән бу балакай, ана да, әнисенә дә әтиләре кирәк, бик кирәк һәм бик тиз кирәк, юкса боларның хәлләре мөшкел, дип уйлап куйдым. Калырга да, чыгып китәргә дә белми шулай аптырап торган чакта, баскычта аяк тавышлары ишетелде. Ишек ачылды һәм бер ханым керде. Ул, көтмәгәндә ят кунак күргәч, аптырабрак китте, ләкин елмаеп исәнләште.

— Сезне ул, мөгаен, вокзалдан алып кайткандыр? Әти дигәндер? Шулаймы?

— Дөрес,— дидем.

— И бала, бала! — диде ул, минем янда куанып торган малаен шелтәләп.— Бу гадәтеңне кайчан ташлыйсың инде? Җүләр булып тудыңмы әллә син? — Аннан миңа карап гафу үтенгән тон белән:— Минә, бер ни эшләтә алмыйм. Тыңламый, чыга да китә. Ике солдат китереп куйды инде аны. Сез — өченче. Әтием солдат, әтием кайта дип башына сендергән — тыяр хәл юк, аптыраш. Кешеләрдән, мина сездән оят.

— Зарар юк,— дидем мин.— Бер прогулка гына булды... Ә аның үз әтисе чыннан да солдаттыр бит? Озакламый кайтыр. Җиңү көннәренә күп калмады инде.

Хатын соравымны ишетмәде бугай — җавап бирмәде. «Ай, өебез боз кебек салкын. Ягып җибәрим әле, чәй дә куйыйм»,— дип плитә өстеннән утын агачы алды һәм тиз-тиз чыра теләргә тотынды.

Мин үземне тыярга теләсәм дә, тыела алмыйча аның йомры беләкләренә, түгәрәк балтырларына карап-карап алдым. Ул өстенә зәңгәр борчаклы ак ситсы күлмәк кигән иде. Бөдрә кара чәче иелгән саен маңгаена төшеп тора. Тутырып карасa, үзәкләреңне өзеп һуштан яздыра торган утлы кара күзләр, тулырак кына алсу иреннәр, чигән кызыныкы төсле кара тут йөз, ситсы күлмәген матур гына кабартып торган түгәрәк, калку күкрәкләр. Биеп кенә йөрүче нечкә билле зифа сын. Менә шулай иде ул чакта Надя... Надежда!..

Кыскасы, ул мине — авыру солдатны — сихерләде.

Без ул көнне чәйне өчәүләп эчтек. Алар мине вокзалга кадәр озата бардылар. Поездлар булмагач, кире кайтып киттек. Сережа үрле-кырлы сикереп шатланды: әйтергә генә ансат, гомерендә беренче мәртәбә әтисе белән йокласын әле!..

Әллә ни булды шунда — миңа кирәк поезд икенче көнне дә килмәде. Өченче кичне дә...

Ә дүртенчесендә без инде вокзалга барып та йөрмәдек.

Надя кумады.

Сережа, әти дә әти дип, сарылды да торды.

Мин үзем дә текә баскычлы бу чормадан төшеп китәргә бик ашыкмадым...

Көннәр үтте. Өчебез бер гаилә булып яши башладык. Шулай итеп, һич уйламаганда хатынлы да, малайлы да булдым.

Язмыш юк, ихтыяр көче генә бар дибез дә, ләкин, туганда ук маңгайларга язылмаса да, дөньяда кеше гомерен кинәт борып җибәрә һәм аның халәтен дә күз ачып йомганчы үзгәртә торган сәбәпләр дә чыгып куя икән. Хәер, баш әйләндергеч сикерешләре, шарламалары очрамаса, сай сулы елга шикелле талгын гына агып ятса, мәзәге белән рәхәте дә булмас иде тормышның. Йөрәкләр мүкләнеп бетәр иде.

Менә минем белән дә шулай кыланды язмыш. Үләргә китеп баручы боек күңелле солдатның гомер елгасын бөтенләй икенче якка борып җибәрде.

Яшермим, мин бу агымга үземне ихтыяри рәвештә баш-аягым белән рәхәтләнеп тапшырдым һәм көлә-көлә, җырлый-җырлый агып киттем. Минем өчен Себернең салкын феврале үтте, җылы җәй килде, күгемә якты кояш чыкты.

Тик вакыт-вакыт якты кояшымны кара болыт томалый, күңелем төшә, башымны кая куярга белми ачы хәсрәткә бата идем. Хәсрәтем — минем авыруым иде. Инде ай буе торуыбызга карамастан, Надяга мин үземнең авыру икәнлегемне һәм киләчәгемнең шәп түгеллеген һаман әйтмәгән идем.

Минем авыр уйлар уйлый башлавымны, күңелем боегуын Надежда да сизде. Тик ул аннан үзенчә — хатын-кызларча нәтиҗә чыгарды. Бер төнне башларны бер мендәргә куеп янәшә ятканда ул миңа:

— Ваня, сине соңгы көннәрдә нииндидер сагыш басты. Белеп түгел, болай гына әйтәм: берәр җирдә күңелеңә якын кызың калган булса, әйт

тә бир, яшермә. Мин аңлармын. Һәм мин сине тотмам. Мине калдыр да кит. Аны тап. Аңлашыгыз, кушылыгыз, бәхетле булырга тырышыгыз. Безне бөтенләй оныт. Миңа синең мәхәббәтең кирәк. Мәхәббәтең сүнгәч, коры шәүләң белән нишлим? Газапланма, Ваня, хәл итәсе нәрсәңне тартып-сузып йөртмичә шунда ук хәл ит, син ир бит, Ваня! — диде.

— Рәхмәт, Надюша! — дидем мин, дулкынланып.— Хәзер мин сиңа үземне борчыган нәрсә турында сөйлим. Шуннан ары соңгы сүзне син әйтерсең, ничек дисәң — шулай булыр...

Һәм аңа үземнең хәлемне сөйләп бирдем.

Надя мине бүлдерми-нитми тыңлады, сөйләп бетергәч тә, түшәмгә карап бераз сүзсез ятты. Шуннан соң кинәт калкынды да кысып кочаклап алды. Коры ирennәремне яндырып, суырып үпте.

— Мин синең авыруыңа менә шушылай карыйм, минем соңгы сүзем менә шундый, җуләрем... Ванюша! — диде.

Шуннан соң Надюша, укымышлы кешеләр әйткәндәй, баш-аягы белән минем гомерем өчен көрәшкә ташланды. Әнисе авылда яши икән. Ни әйтсәң дә, анда сөт-май табыла инде. Аңа хат язып, кирәк азык-төлеген соратып алды. Мине дуңгыз, аю, бурсык майлары, әллә ниләр кушып кайнаткан сөт белән сыйлый башлады. Кырыкмаса-кырык төрле үлән тамырлары кайнатып эчерде, дарулар эзләп тапты. Тимердәй каты режимга утыртты. Үпкәне өрдерергә дә үзе йөртте. Гомумән мин бик иркә һәм кадерле сырхау бала хәлендә калдым.

Ләкин ул үземә дә бик нык кисәтеп әйтте: «Әгәр үзеңә үзең булышмасаң, барыбер үләсе дип ябь коеп йөрсәң, бу эшләрдән бер тиенлек тә мәнфәгать чыкмаячак, син үзеңнең терелүеңә җир белән күккә ышангандай ышанырга тиеш!» — диде.

Билгеле, Надя минем гомерем өчен утка-суга төшеп сугышып йөргәндә мин язмыш иркенә буйсынып тик ятсам, оят булыр иде. Минем йөрәгемдә дә Чулпан йолдызы булып якты өмет кабынды.

— Мин яшим, мин яшәргә тиеш, ишетәсеңме син, үлем, мин әле яшим, сиңа үч итеп яшим, яшим, яшим!..— дидем.

Һәм мин җирдә яшәп калдым!

Кеше ихтыяры алдында үлем үзе җиңелеп үлде!

Бер меӊ тугыз йөз кырык алтынчы елның май аенда диспансерда мине соңгы кат җентекләп карадылар да әйттеләр:

— Котлыйбыз! Сез хәзер өч яшьлек үгез шикелле тап-таза! — диделәр.

Без шуннан соң, Сережа һәм Надя белән өчәүләп, көн буе һәм төн буе, җуләрләр шикелле көлә-көлә, шәһәр буйлап йөрдек, бакчаларда, су буйларында сандугачлар сайраганын тыңлап утырдык. Кояш чыккач, базарга киттек. Надяның биек үкчәле ак туфлиен сатулашмыйнитми генә «озатып» җибәрдек һәм шунда ук, базар читендәге яшел чирәм өстенә утырып, көлешә-көлешә туйганчы бер ашадык.

Ләкин бәхет бер кайчан да түгәрәк булмый, бик ялтыраса чатный икән — аның бер чите китек була икән.

Мин терелдем — каты авырып Сережа егылды.

Сәбәпчесе — мин.

Ул чакта инде аның җиде яше тулган иде. Салкын февраль көнендә мине вокзалдан «тотып» алып кайтканнан соң бик дуслашкан идек. Ул миңа шул хәтле ияләнде, шул хәтле яратты — гаҗәп инде! Үзенең чын әтисен дә шулай нык яратмас бала-чага. Хәер, мин аның өчен чыннан да үз әтие идем. Без Надюша белән аңа бер чакта да минем кем икәнлегемне әйтмәскә, йөрәгенә җәрәхәт ясамаска дип сөйләшкән идек. Ул мине чын күңеле белән ярата. Мин аны яратам. Әти дә әти дип өзелеп тора, алдан төшми, арттан калмый, дөнья түгәрәк — ни кирәк? Әйбәт, бик әйбәт! Куанып яшисе дә яшисе генә!..

Сережа, урамнарга чыксак, башка малайлар алдында бик горурла-

нып йөри иде. Минут саен — эти дә эти, минутына йөз сорау. Үзе бер секундка да миннән аерылмый, кулга чытырдатып ябышкан.

Ул уенчыкларны, бигрәк тә машиналарны нык ярата иде. Тик үзенчә. Алып кайту белән әз генә йөртә дә сүтәргә тотына, эчен карарга тырыша. Магазин уенчыкларыннан туйгач, мин ана чыра белән кәтүк жебеннән «выж-выж», буш кәтүкнең башына сабын һәм резина белән бармак озынлыгы таяк беркетеп, кәтүк «тәгәрмәчләрен» киертеп, үзйөрешле «трактор» ясап бирә идем. Резинасын борасың-борасың да «трактор»ны идәнгә куясың. Ә ул сабан сөйрәп барган шикелле әкрен генә китеп бара. Малайның куанычы эченә сыймый. Сикерә, кул чаба. Көннәр буе тыны юк, уйный. Иртән күзен ачуга: «Эти, тракторым кайда?» — дип сорый. Аны урамга алып чыгып иптәшләренә күрсәтә. Тегеләре тракторны тотып карарга чират торалар...

Ә аның сораулары! Сүзләре! Ул сорауларга профессор да жавап таба алмас! Кызык сүзләреннән көлеп эчебез ката иде. Мәсәлән, поездга карап тора да:

— Эти, поездның бензине сумы? — дип сорый.

— Нишләп алай дисең, улым? — дим.

— Поезд бармый башлагач, су кирәк диделәр дә, су салдылар да — поезд китте,— ди...

Бер вакытны шулай Сережа балык ашап утыра. Мин китап укыйм, әнисе плитә янында кашык-аяк юа. Сережа мина иелеп пышылдап кына әйтә:

— Эти, әйдә, бу балыкны икәүләп тиз генә ашап бетерик әле,— ди.

— Ник? — дим.

— Әни, «ашап бетермәсәң, урамга чыгармыйм» дип әйтте,— ди.

Яки:

— ...Шуннан соң ведмедь (медведь) килеп чыга. Тегене кытыклый башлый: кети-кети, кети-кети! — дип безгә әкият сөйли иде...

Минем өчен иң кадерлесе шул булды — мина жаны-тәне белән бирелгән иде малай, ярата һәм ышана иде. Аның өчен миннән дә булдыклы, эшчән, көчле, батыр һәм матур, кылны кырыкка яручы унган эти жир йөзендә бүтән юк иде кебек.

Менә шул кешене мин рәнжеттем.

Белоруссиядә һәлак ителгән разведчик дустымнын истәлеге булып уч төбе хәтле генә бәләкәй көзге калган иде. Җәй көне, гадәттәгечә, шуны алып өстәлгә куйдым да кырынырга сабын күбеге ясый башладым. Шул чагында Сережа йөгереп килеп тә керде, көзгене идәнгә бәреп тә төшерде. Көзге чәлпәрәмә килде.

Мин,— ул чагында да анламадым, хәзер дә анламыйм,— нишләптер женләнеп сикереп тордым да каеш белән тегенәр ике-өч тапкыр сыптырдым.

— Җүнсез малай! Харап иттең бит! — дидем.

Сережа таш кебек катып калды. Аннан кинәт көл шикелле агарынды. Күзләре түгәрәкләнде. Бөтен гәүдәсе яман дерелди башлады. Иреннәрен кыймылдатып әйтәсе сүзен әйтә алмый тотлыгып торды да сабый, ахырында ачыргаланып:

— Эти!.. Эти, кыйнама!.. Эти, сукма!.. Кыйнама, эти!.. Этием, сукма!.. Авырта!! — дип кычкырды. Миннән күзләрен алмыйча әкрен-әкрен артына чигенде. Ишек төбенә житкәч, кырт борылып чыгып йөгерде, ләкин дүрт-биш адым гына атларга өлгерде. Кинәт чайкалып өй алды идәненә егылды.

Без Надюша белән ана ташландык. Күтәреп караватка салдык. Сережа саташа башлады, бәйләнешсез сүзләр кычкырды, аяклары белән нәрсәнедер типкәләде, тәне кызышып шыбыр тиргә батты, торып йөгерергә, качарга омтылды.

Мин коелып төштем. Йөрәгем сикерергә тотынды. Үзем дә, улыбыз

сыман, менә егылам, менә егылам дип кенә утырдым. Ничек кирәк алай аякка басып врач чакырдык. Ул килде. Карады да:

— Нервное потрясение, рухи борчылу...— диде.

Озак авырды. Балаң авыру үзең авырудан авыррак икән. Алай гынамы — бер баланың авыруы ун өлкәннекенә тора. Аны карый-карый, аның өчен янып-көеп үзебез авыруга сабышып беттек. Бигрәк тә мина кыен булды. Дөрес, Надюша рәнҗеп бер сүз дә әйтмәде. Һич ни белән дә үпкә белдермәде. Түзде. Ләкин бит ул: «Ник суктың? Ник ашадың малайның башын? Кеше баласында ни дәхелең бар синең?» дип әйтергә хаклы иде. Менә бу минем йөрәгемне барсыннан да ныграк талады, өзгәләде. Әйтсен, әрләсен иде. Түзәр идем. Ә менә болай, сүзсез генә яшьле күзләрен тутырып карап торуы! Үтерә!.. А-а, ниләр генә юк иде ул күзләрдә! Баладан да газиз нәрсә юк шул. Бигрәк тә ана өчен. Күктән төшмәгән — эчтән төшкән бит ул...

Булган эш булган, үкенүдән узган диләр дә бит — ничек үкенмисең! Нишләгәнмендер! Гомерем буена кешегә түгел, терлек-туарга да чиртканем юк иде...

Надюшаның да үз хәле хәл. Атналар буе керфек какмыйча Сережаның баш очында утырып чыга. Ә үзе шулай булса да мине юаткан була, тынычландырырга тырыша. Терелер, элеккедән дә тазарак булыр, үзүзеңне бетермә, Ваня, дигән була.

Бик шулай да, тик Сережа йөрәккә хәсрәт утын ягып кына тора. Кайвакыт күзләрен ача. Аңга килгән шикелле итә. Әнисенә көлгәндәй итә. Ә мин якын килә башласам, урыныннан сикереп торып качарга омтыла.

— Әти!.. Әти... Тимә, сукма, әтием!.. Авырта бит, әтием!.. Кыйнама, әти, кыйнама!..— дип жылый-жылый ялынырга тотына. Агарып ката. Коты оча. Мин ыңгырашмас өчен тешләремне шытырдатып кысам да тизрәк чыгып китәм.

Өйдә булган бөтен каешларны чокырга чыгарып аттым. Күзенә күренеп борчымас өчен астагы күршеләрдә йоклый башладым.

Шулай бер төнне, гадәтемчә, күршеләрдә ята идем, тыны бетеп Надюша йөгереп төште. Корт чаккандай сикереп тордым.

— Я?!. Ни булды? Тизрәк әйт!?,— дим.

— Курыкма! — ди Надюша, үзе көлә, үзе жылый.— Аныңа килде. Әзрәк сөйләшә... Ярты стакан сөт эчте. Әйдә! — ди.

Баскычтан очып кына мендем. Карыйм, чыннан да күзләре акыллы төсле. Мине күргәч, көлеп куйды. Беләсезме, аңлыйсызмы, иптәшләр, авырып егылганнан соң беренче мәртәбә курыкмады, качмады, кыйнама, әтием, дип кычкырмады — тыныч кына, матур гына итеп көлде.

— Улым!.. Хәлең ничек, улым? — димен, үзем тамак төбенә тыгылган яшьләремне әкрен генә йота торам.

Тагын елмайды.

— Ә мин сине беләм,— ди.

— Беләсең, улым, беләсең, алтыным,— дибез.

— Син Кыш бабай бит,— ди.— Син былтыр да елкага килгән идең. Ә кайда соң капчыгың? Миңа күчтәначләр бирмисеңмени? — ди.

Надюша коты очып: «Ай!.. Ай аллам!» дип пышылдады да, үкереп жылап жибәрмәс өчен, куллары белән авызын каплады.

Йөрәгемә гүя хәнҗәр тыгып әйкадылар, күзләремнән дөнья яктысы качты. Ишек яңакларына тотына-тотына чыгып, өй алды идәненә аудым...

Хәллар болайга әйләнгәч, Сережаны больницага салудан башка чара калмады.

Ул анда кырык көн ятты. Без алмаш-тилмаш аның янында булдык, кунмаганда көн саен барып хәлен белеп тордык.

Тәмам сәламәтләнеп житкәч, кырык беренче көнне, без аны өйгә алып кайттык.

Улыбыз, тәнгә ябык булса да, буйга үсеп киткән иде. Безнең өчен иң куанычлысы — ул инде тәмам терелгән, үз акылына һәм фигыленә кайткан иде.

Икенче елны, врачлар кушуы буенча, путевка табып, мин аны Кавказга алып киттем. Ул елларның нинди икәнен беләсез инде, аякка баса гына башлаган идек. Аны-моны, минем солдат шинелен сатарга туры килде. Кисловодскида санаторий врачлары Сережаны үз балалары шикелле карадылар, дәваладылар. Ә мин үзем якыннан гына фатир алып яшәдем. Кич кенә аерыла идек. Малай матураеп, тазарып китте. Нервысы ныгыды. Без Кавказдан күтәренке күңел белән кайттык.

Авыру җиңелде.

Сережа теге хәлләрне онытты. Мәхәббәте миңа тагын да артты. Әтием дип өзелеп тора башлады.

Безнең чардагыбызга янә якты кояш керде.

Бәхет керде!

...Еллар үтте. Сугыш хәрабәләре бетә, югала торды. Дөнья елдан-ел рәтләнде. Без дә чардактан төштек. Кирпеч йортның өченче катыннан ике бүлмәле, балконлы, җылы, якты квартира бирделәр. Надюша, бухгалтерлар курсын тәмамлап, заводта бухгалтер булып эшли башлады.

Шул чагында нур өстенә нур булып, кызыбыз Светлана туды. Кыз тугач, мәшәкать артты. Надяның әнисе — Анна әби авылдан безгә күчеп килде. Уйнап-көлеп бишәүләп яши башладык.

Без тормыштан бәйрәмнәр көтеп тормадык, тормышның үзен бәйрәмгә әйләндердек. Сережаны пионерга, комсомолга алалар — өйдә бәйрәм тантанасы, шатлык. Светлана укырга керә, музыка мәктәбенә йөри башлый — тантана. Бишәүләп куанабыз. Өстәлнең түрендә — балалар. Уку елын «5» легә һәм «4» легә тәмамлап чыгалар — тагын сөенеч...

Шатлык яшәртә, без яшәрдек!..

Үзем ТЭЦта слесарьлар бригадиры. Исемем телдә, урыным президиумда. «Мактау кәгазьләре», акчалата бүләкләр алам. Беренче Май хөрмәтенә портретымны ясап, Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенә куйдылар. Өйгә кайтмыйча икешәр смена эшләгән чаклар еш була иде.

Сережа үсте, Сергейга әйләнде. Урта мәктәпне тәмамлап кичке институтка керде. Ә эшкә минем бригадага, үземнең кул астына килде. Бергә эшли башладык. Светлана да мәктәп бетерде. Тагын укып, химзаводта аппаратчица булды.

Иртән торабыз да дүртебез бергә тезелешеп эшкә китәбез, тезелешеп дүртәү кайтып керәбез.

Бер кайгыбыз, борчуыбыз да юк иде.

Жылаган чакларыбыз булмас, тормыш юлын гел шулай җырлап кына үтәрбез дип уйлаган идек.

Ләкин ялгышканбыз. Киләчәкләре булса, күрәчәкләре дә бар икән.

Моннан дүрт ел элек, җылы апрель кичендә, сыерчыклар очына-очына сайраганда, челтер-челтер язгы ташулар аккан чакта безнең бәхет агачыбызны кинәт яшен сукты. Яшеннән янып кара көйгән шул агачны кара гарасат кубып, тамырлары белән йолкып читкә атты.

Соңгы вакытларда сабыр холыклы, һәр вакыт саф күңелле, көлеп кенә йөрүче Надюша алмаштырып куйгандай кинәт үзгәргән иде. Юк нәрсәләргә дә кәефе кырыла башлады, ызгыш-талаш, җәнҗал күтәрергә бик остарып китте. Я ду килеп гауга куптара, я көннәр буе авызын ачмый, кара коелып йөри. Тегесе охшамый, монысы аныңча түгел, анысын ата, монысын бәрә. Гомумән җәннәтебез җәһәннәмгә әйләнеп бара.

Өйдә бәрәкәт бетте — һәлакәт керде.

Без моңа дуртәүләшеп аһ итәбез, ут йотабыз. Сәбәбен белергә тырышабыз, тәпченәбез. Төрлечә уйлап карыйбыз — юк, әйтми.

Ирләр холыксызланса, ярты өй яна, хатыннар холыксызланса — бөтен өй. Безнеке дә бөтенләй яна башлады.

Бу фаҗигане мин бик авыр кичердем. Тамактан һәм йокыдан калдым. Кулымнан эш төшә башлады. Ахырында, менә ничә ел инде рәтләп ял иткән юк, кеше төсле Кавказ, Кырымнарга, санаторийларга да барганыбыз юк, быел отпусканы Кара дингездә үткәрергә кирәк. Надя рәхәтләнеп дөнья күрер, дингездә су коеныр, туйганчы Кырым кояшында кызыныр, тынычланыр, яңадан элекке сөйкемле һәм акыллы Надюшага әйләнер дип, ныклы карарга килеп куйдым.

Бу теләгем дә матур теләк кенә булып калды. Икенче май көнне бөтен халык бәйрәм иткән чакта, без дежур торабыз дип, Надя эшкә китте. Мин, парын югалткан ялгыз каз шикелле, көн буе урамнарда каңгырып йөрдем дә, юл уңаеннан Надяны да алып чыгыйм, бергә кайтырбыз дип, аның янына кердем. «Бүген ул ял итә»,— диделәр.

Һич нәрсә аңламыйча, бу эшне алай да юрап, болай да юрарга тырышып, өйгә кайтып киттем. Надяның күңеленә әллә ни булган иде. Ул элекке хатын түгел иде инде. Анысы — факт. Әмма нәрсә, ни булган? Монысын белә алмадым. Аның күңеле бер көн килеп кабат урынына утырачак, ул үзе үк бу көннәр турында көлеп һәм гафу үтенеп сөйләячәк иде әле. Мин моның шулай буласына чын-чынлап ышана идем, иманым камил иде.

Надя караңгы төшкәндә кайтып керде.

— Кайда йөрдең? — дип сорадым.

— Ялгышканмын. Миңа бүген ял биргәннәр икән. Кайтып тормадым инде, дус хатыным белән йөрдек шунда,— диде.

Мин аны-моны әйтмәдем... Аерым ятып йокладык. Егерме ел торганнан соң беренче мәртәбә. Үзебез теләп...

Шулай ут йотып, ялкын сулап йөргән көннәрдә элекке күршебез очрады. Бакчага кереп утырдык.

— Ябыгып киткәнсең. Чигә чәчләрең дә бик нык чаларган. Әллә авырыйсыңмы? — дип сорый.

— Юк, авыруның ни икәнен дә белмим,— дим.

— Үпкә ничек?

— Шикәр кебек.

— Йөрәк авыруың юкмы? Берәр зур шатлык, я, мин әйтәм, кайгы ишетсәң, кинәт тота торган гадәте юктыр бит?

— Йөрәгем йөз ат көчле машина моторы кебек. Карале, ник тәпченәсең әле син? Докторлыкка укырга кердеңме әллә карт көнеңдә? Практика үтәсеңме?

Шуннан соң ул ык-мык итеп торды да авыр сулады, иелеп чалбар балагындагы юк тузанны кага башлады.

— Син, Ванюша, миңа ачуланма. Дус булганга әйтәм... Бер синнән генә калмаган... ни... туган... Хатының синең өстән... йөри бит,— диде.— Үзләрендәге баш бухгалтер белән... Ул аңа җылы ботинка белән күлмәк тә алып биргән... Син генә сизмисең... Ванюша...

Мин башта бер ни дә аңламадым. Лыгырда инде, лыгырда, дип җүләр кеше сыман авыз ерып утырдым. Сүзләренең мәгънәсе башыма барып җиткәч, йөрәгем туктады, кымырҗый-кымырҗый чәчләрем үрә торды.

Мин, я нервысы какшап, я миңа ачу итәм дип, я бүтән сәбәпләр аркасында Надюша әллә ниләр кыланырга мөмкин, хәтта кирәкмәгән, ярамый торган эшләр дә эшләп ташларга мөмкин, дип борчыла идем. Ләкин, ант итеп әйтәм, хыянәтне башыма китермәгән идем. Бөртек тә, тырнак очы кадәр дә! Гомумән, Надюша өчен ул сүз дөньяда юк төсле

иде. Инде эш үткәч үз-үземне ирләргә генә калды: никадәр беркатлы булганмын икән!..

Теге кешегә җавап бирерлек, Надяның гөнаһсызлыгын исбат итәрлек хәлем юк иде. Көчәнеп урынымнан тордым да ангы-мингә килеп кайтып киттем. Күз алдым карангыланды, минем өчен кояш сүнде, көн бетте.

Мин инде монысына түзә алмам дигән идем. Тик бу әле кара язмышның беренче шаяруы гына булган икән. Аның тагын да рәхимсезрәге мине өйдә көтеп торган икән.

Өй эче үлек чыккандай шомлы. Малай, кыз, әби — өчесе өч җирдә тавыш-тынсыз утыралар. Минем аптыраулы карашымны күргәч, өстәл янына ымладылар. Анда Надяның безгә калдырган язуы ята иде. Мин аны бер кат укыдым. Ике, өч — аның ни өчен язылуын, нәрсә язылуын һаман аңламадым. Язуның мәгънәсе авырлык белән генә башыма барып җитте һәм йөрәгемне чәнчеп алды. «Кичер мине, кызым,— дигән иде ул анда.— Мин сезнең яннан китәм. Мине эзләмәгез, эшемә барып йөрмәгез... Без читкә чыгып китәргә җыенабыз... Барып урнашу белән мин сине үз яныма алырмын. Болар янында калдырмам, курыкма... Гафу ит мине сездән аерылганым өчен!..»

Язуның күп өлеше шулай Светланага атап язылган иде. Иң соңыннан минем турыда да: «Ә монысы сиңа, атасы, мин синең теләгенне үтәдем», дип куйган иде.

Мин аны аңламадым. Нинди теләк? Минем нинди теләгемне үтәде икән ул? Аның үзе һәм балалар белән, әби белән бергә эшләп, бергә гөрләшеп яшәү иде бит минем теләк. Нәрсәгә алай дип куйды икән? Нинди сер икән бу сүзләрдә?..

Әйе, алдан ук уйланган сере булган икән. Мин аны судта гына белдем.

Үзем генә җитмәгән, балаларның хәсрәтенә чыдый алмадым. Хатын — ир табар, ир — хатын табар, бала гына — ата-ана тапмас дип, оят булса да, әбине җибәрдем — кайтмады. Кыз барып карады — кызына да күнеле эремәде...

Кыскасы, аллага табынгандай табынып йөргән, минем өчен иң чибәр, иң акыллы, иң гүзәл һәм иң кадерле булган, җанымнан якын күргән сөекле кешем шуны эшләгәч, егерме ел корган җәннәтем күз ачып йомганчы җил-давыл булып очкач, зиһеннәрем таралып, башым уйламас булды. Көндез кешеләр арасында. Анысын алай итәсен, монысын болай итәсен, хәсрәтең әз-мәз онытылып та тора. Эш белән әкренләп көн үтә. Эштән бушагач, шыксыз өйгә кайтып керүе авыр...

Ярый-ый. Шулай ни тере, ни үле яшәп ятканда, бер ял көнне Надюша кайтып керде. Әби оекмы, шәлме — нидер бәйли, Светлана пианино уйный, Сергей китап укый, мин өстәл янында отвертка белән боргалап утюгмы, трансформатормы төзәтеп утыра идем.

Дүртебез дә исебезгә килә алмыйча шаккатып калдык.

— Исәнмесез! — дип мыгырданды Надя, елмаерга тырышып.— Ни хәлләрегез бар?.. Нишләп ятасыз?..

Света «Әни!» дип аның муенына ташланды.

Надя, кечкенә чагындагы шикелле итеп, аның чәчләреннән сыйпады.

— Я, кызым, я, җитәр!.. Син зур бит инде!

— Әни, әнием!.. Син нишләден?.. Нишләп болай?!.

— Я, кызым, я! Бөтенесе дә көйләнер, әйбәт булыр. Мин сине алырга дип кайттым. Кием-салымнарыбызны гына җыябыз да китәбез... Я, тынычлан!..

Сергей урыныннан торды.

— Син бөтенләйгә кайтмадыңмыни?

— Юк, улым.

— Китәсеңме?.. Аның янынамы?

— Әйе. Шулай туры килде инде. Гаепләмә, улым. Дөнья бу!..

— Син... үзеңне яраткан кешеләрне ник уйламадың, ә?!. Кара этигә! Кара аның чәчләренә!.. Ун көн эчендә син аны ун елга картайттың!..

— Нишләп ул кадәр кайгыртасың аны?.. Үз этиең булса ярар иде!..

Сергей кинәт китереп суккандай чайкалды. Күзләрен зур итеп ачып туп-туры анасына карап торды. Аннан соң тотлыга-тотлыга:

— Нишләп... үз этием... булмасын!.. Син ни... сөйлисең?.. Шаштыңмы... әллә син?..— дип, көч-хәл белән сорый алды.

Надюша чынлап та шашкан хатындай кабынып китте. Ямьсезләнеп, Сергейга таба кулларын сузып кычкырып җибәрде:

— Ха-ха-ха!.. Кайдан килеп эти булсын ул сиңа!.. Дивана!.. Син биштә идең инде... Вокзалдан тотып алып кайттың син аны... Дивана-а!.. Ха-ха-ха-ха!..

Сергейның бөтен гәүдәсе, куллары дерелдәргә тотынды. Йөзе күгәрде. Башын артка ташлап нидер әйтергә азапланды, ләкин әйтә алмады, каны качкан иреннәрен генә кыймылдатып тора башлады, тавышы чыкмады...

«...Приступ... әлекке шикелле... тагын кабатлана» дигән уй башымнан үтеп китте, күз алдым томаланды. Ни эшләгәнемне белмәдем — кулымдагы отвертка белән хахылдап көлеп торган Надяга китереп кададым...

Район прокуратурасы следователе, юстиция кече советнигы Рахман эшемне тикшергәндә изоляторда тоттылар. Минем бу каһәрле эшемне үтерергә теләү дип бәяләсәләр дә, иптәшләрнең дә, өйдәгеләрнең дә җылы сүзләре, мөгаен, минем файдага булгандыр.

ТЭЦның кадрлар бүлеге башлыгы, дөресен әйтеп, бик яхшы характеристика җибәргән иде. Директор, партбюро секретаре һәм завком председателе — өчәү кул куеп миңа җинелчәрәк җәза бирүне сорадылар, судка бик белемле җәмәгать яклаучысы сайлап җибәрделәр. Аның өстенә әби дә, Сергей да, Светлана да Рахман иптәшкә биргән аңлатмаларында гел мине яклап язганнар. Мәсәлән, әби үз кызы дип кызганып тормыйча, дөресен әйтеп, намусы ни кушса, шуны язган:

«...Ул минем кызым иде. Хәзер инде мин аны телем барып кызым дип әйтә алмыйм. Миннән качып киткәч, нинди кыз булсын ди инде ул миңа?! Аның бу эшенә аклану юк, үтерсә дә сүз әйтмәс идем, ярый әле, бәхете бар икән: больницстә генә ятып чыкты...

Мин кияүемне җәзага тартмавыгызны үтенәм!..»

Улым болай дигән иде:

«...Эти гомере буе безнең өчен тырышты. Икешәр смена эшли иде. Ул мине үз этиемнән дә яхшырак тәрбияләде...

Бу хәлләргә бары тик әни генә гаепле. Шундый тату, дус яши идек бит. Шуңа риза булмыйча, әниеңне, иреңне, улыңны һәм кызыңны ташла да, дөрт хатын аерган ниндидер адәмгә кит, имеш! Бу — түбәнлек. Кеше үз намусын бөтенләй югалткан дигән сүз... Югарыда язылганнардан чыгып, минем этиемә җәзаның иң җинелен генә бирүегезне үтенәм...»

Хәтта «минем этием» дигән сүзләрнең астына сызып куйган...

Светлана кызым да төп гаеп әнидә, этине аклавыгызны сорыйм дип язган иде...

Болар миңа ул көннәрдә тереклек суы шикелле булды...

Суд залы шыгрым тулды. РСФСР җинаять кодексының 15-103 статьясе нигезендә дүрт ел бирделәр...

Уйчан кеше, сүзен бетереп, кисәү башларын учак уртасына этәрә башлады. Ай баткан, түгәрәк аланны кара төн баскан, йолдызлар эреләнеп һәм яктырып, агач башларына кунаклаган шикелле якын күренә иде.

Ирләрнең «ө-өф» итеп тәмәке төтенен өрүләре һәм арттарак кемнеңдер мыш-мыш сулавы ишетелде. Агач башларын шаулатып ашыга-ашыга ниндидер саташкан җил үтте.

Берәү тамагын кыргалап:

— Менә, иптәш... Минем сезгә соравым...— дип сүз башлаган иде, Уйчан кеше көлемсерәп аны бүлдерде:

— Нинди сорау бирәсегезне беләм. Улым, гаиләм. Шулмы?

Надяны баш бухгалтер бутаган. Ялган документлар ясап өстенә бик күп акча чыгарган. Әйберләрегезне саттырам, өегезне туздырам, дип куркыткан. Безне хурлыкка төшермәс өчен Надя шул кабахәт белән китәргә мәҗбүр булган. Дүрт ай үтүгә кире кайткан. Хәзер өчесе яшиләр икән. Светлана кечке институтны тәмамлаган. Шул ук заводта инженер-химик. Сергей — геолог. Шушы тирәләрдә нефть эзли... Тел очыгызда тагын бер сорау тора инде, анысына да җавап бирәм. Әйе, мин бүген Сергейны көттем, улымны. Ул мине каршыларга тиеш иде.

— Килмәде бит...

— Килмәде. Миңа хәзер җаным-тәнем белән эшкә чумарга кирәк. Мин тормыштан төгәл дүрт елга арттарак калдым. Ләкин мин аны куып җитәргә тиеш. Хәзер һәр көнем хисапта, һәр сәгатем кадерле. Менә шуның өчен улымны көтеп ятарга теләмичә сезнең белән киттем.

Мин семья җылысына кабат кайта алмыйм инде. Ә Сережа белән без кайчан да булса, һичшиксез, очрашырга тиеш. Мин моңа ышанам...

Ашыгуымның бүтән сәбәбе дә бар. Мин элек бераз рәсем сәнгатенең серләрен өйрәндем. Бик зур хыяллар, бик зур планнар белән җенләнеп йөргән чакларым бар иде. Третьяков галереясында, Эрмитажда, башка музейларда булдым. Рус музеенда Карл Павлович Брюлловның «Помпейның соңгы көне» дигән картинасы каршысында ярты көн утырдым. Әкият, могҗиза! Ә ничек эшләгәннәр! Репинны алыгыз. Кулы корыгач пумаласын кулына бәйләп куйган. Рембрандның безгә билгеле 650 ләп картинасы, 2 000 рәсеме, 300 ләп офорты бар. Гомерләрен сәнгатькә багышлаган чын художниклар хәзер дә шулай иҗат итә.

Әдәпсез, тыйнаксыз дип гаепләргә ашыкмагыз, зинһар. Үзен чагыштырырлык художниклар тапкан дип тә көлмәгез. Чагыштырыр өчен әйтмәдем. Мин укуны уйлыйм. Укырга беркайчан да соң түгел. Гомер буе укыйлар. Өйрәнергә телим. Кешеләрнең бөек хезмәтләре турында үз гомеремдә ичмасам бер генә картина эшләү турында хыялланам. Менә мин хәзер шул картинама төшәчәк иптәшләрем арасына — көчле рухлы, таза тәнле, тимер мускуллы кешеләр янына китеп барам. Тундра буйлап болан көтеп йөрерменме, урман кисәрменме, юллар салырмынмы, нефть чыгарырмынмы — әлегә белмим. Ләкин эзләгән кешеләремне табачакмын. Әнә, буяулар, киндерләр алдым.

— Юлыгыз уңасына ышанам,— диде кемдер.

— Сез эзләгән кешеләр Себердә генә түгел — бөтен җирдә.

— Әйе. Ни өчен Себерне сайладыгыз?

— Әйттең сүз! Үзе сибиряк ич ул.

— Ул чагында, әйдәгез, минем белән! Әшебез уен түгел, кешеләребез дә.

— Ә ни өчен сезгә? Безне ким дип уйлыйсызмы әллә? Башкаларны җырлап акча ала дип беләсезме?

— Дөрес! Безнең газчылар да иптәшне сөенә-сөенә үз бригадаларына кабул итәчәкләр.

Иван тамагын кырып алды. Эчке куаныч сизелеп торган ягымлы тавыш белән:

— Рәхмәт, иптәшләр! — диде.— Мин әле тагын да арырак керергә дигән идем. Салехард тирәләренә үк. Бәлки, уйласам, Ямалга [1] да барып чыгармын. Новый Порткамы шунда, Сёяхагамы...

---

[1] Карск диңгезендәге ярым утрау.

## 18

Шул чагында машиналар кергән юлда чопыр-чопыр басып килгән ат аягы тавышлары ишетелде. Учак янындагылар башларын шул якка борып тын калды. Озак та үтмәде, алан читенә бер карамчык чыкты. Дөрләп янган учакларны күргәч, «на-а!» дип атын куалады һәм юртып болар янына килеп туктады. Пычракка һәм шыбыр тиргә баткан ялгыз ак аргамак еш-еш сулыш ала башлады. Киерелгән борын тишекләреннән бөркелеп пар чыкты, шар күзләрендә, әле кабынып, әле сүнеп, учак шәүләсе уйнады. Сакаллы җайдак үзе дә атыннан ким армаган иде. Бүреге агач ботакларына эләгеп, кайдадыр төшеп калган бугай: ялан баш. Озын чәчләренә сары яфраклар эләгеп калган. Кара телогрейкасының уң җилкәсе ертылган — тавык күкәе зурлыгы мамык чыгып тора.

Ул, исәнлек-саулык алышкач, иң әүвәл тәмәке сорады. Кабызып бирделәр. Дәшмәделәр. Җайдак рәхәтләнеп папирос суырды. Хәл алгач кына эштән сүзгә күчте, төнлә урман тарап йөрүенең максатын әйтте:

— Кай тарафларга юл тотасыз, иптәшләр? Шәһәргә баруыгызмы, әллә кайтасызмы инде? — дип сорады.

— Шәһәрдән, шәһәрдән.

— Ай, бик яхшы булды. Белмисезме, сезнең колоннада Аю-Ятардан... э-э-э...— Җайдак куен кесәсеннән бер кәгазь алды да учакның тонык яктысында аны укырга тырышып күзләренә якын ук китерде,— э-э-э... сезнең белән Аю-Ятардан Петр Петров дигән кеше кайтмыймы? Э-э-э... Петрович!..

— Мин булам,— диде Петр Петрович, сәерсенебрәк һәм авырткан аякларын авыр гына язып, урыныннан күтәрелә башлады.

— Сезме?.. Чыннан да сез Петр Петрович Петров үземе? Районо мөдиреме?

— Әйе, әйе. Ни бар? Ни булды? Сез кем?

— Мин сез үтеп киткән авылның почта бүлеге мөдире. Әзли-әзли җаным чыкты. Ялга яткан өч колонна янында булдым, икесен юлда туктаттым... Ниһаять... Сезнең исемгә, иптәш, облонодан телефонограмма бирелде. Линия буйлап барлык почталарга...— Җайдак кулындагы кәгазен Петр Петровичка сузды һәм тавышын әкренәйтеп,— әниегез авырыбрак тора икән,— дип өстәде.

Петр Петрович ул кәгазьне, мөлдерәмә тулы аш тәлинкәсен тоткан шикелле, саклык белән тотып, учакка килде. Ләкин учак яктысының кирәге булмады: ике-өч яктан кесә фонаре кабызып җибәрделәр.

Петр Петрович телефонограмманы ашыкмый гына укып чыкты да күзләрен учак күмерләренә текәп уйга калды. Бүтәннәрнең дә бу тынлыкны бозарга йөрәкләре җитмәде. Ак ат, авызлыгын шалтыратып башын чайкады, тирә-якны яңгыратып рәттән ике тапкыр пошкырды. Җайдак тамагын кырғалап:

— Ярый, мин китим, төш авышкач ук ат менгән идем,— диде.

Петр Петрович, аякларының авыру икәнен онытып, тиз генә торды. Җайдакның кулын кысты.

— Рәхмәт, иптәш! Мәшәкать булды инде, гафу итегез!.. Бик зур рәхмәт!

Ак атның ялыннан сыйпады.

— Сиңа да рәхмәт, дускай!

Аргамак аңа җавап итеп пошкырды, өске иренен алга сузып Петр Петровичның җилкәсенә тидерде.

— Безнең эшебез шул,— диде җайдак.— Әниегезнең тизрәк сәламәтләнүен телим.

— Рәхмәт!..

— Хушыгыз!.. Сау булыгыз, иптәшләр!.. На-а-а!..

Ак ат юыртып урман юлына кереп күмелде.

Петр Петрович урынына килеп утырды. Бер кожанлы кеше, аның янына чүгәләп, учактан тәмәке кабызды. Чыбыгын учакка ташлап:

— Бик каты авырыймы? — дип сорады.

Кемдер әкрен генә:

— Җиңел булса, линиянең буеннан-буена шалтыратмаслар иде,— дип куйды.

— Әйе, әнинең хәле яхшыдан түгел,— диде Петр Петрович.— Мөмкин кадәр тизрәк кайтып җитүемне үтенәләр. Соңга калуың бар, диләр.

— Мөмкин кадәр тизрәк... тизрәк...— дип мыгырданды кожанлы кеше.— Әйтерсең, Мәскәүнең кольцевой юлын әзерләп куйганнар...

— Мин аңлыйм, иптәш, чара юк икәнен беләм. Шуңа күрә дәшмим...

— Дәшми, имеш! Дәшергә кирәк! — Кожанлы кеше аягүрә басып учак тирәсендәгеләргә карады. Үзенең властен яхшы тоеп, сизеп торган командир шикелле калын тавыш белән кычкырды.— Егетләр, хәзер полный ял! Ике сәгатьтән подъем!

— Булыр микән?.. Арылган... Яктырылып та җитми,— диде кемдер кыймыйчарак.

— Фараларың нигә?.. Ике сәгатьтән!.. Бетте!.. Таралыгыз!.. Сез дә ятыгыз, иптәшләр...

Кожанлы кеше эре-эре атлап үз урынына китте. Аңа шоферлар һәм юлаучылар иярде. Тамара да, хәерле төн теләп, шалашка кереп китте. Сүнеп баручы ут янында Петр Петрович, Аучы, Иван һәм Айзат дүртәү калдылар.

Учак күмерләре аксылланып көлләнә башлады. Алан читенә бер пошый чыкты. Һаваны сагаеп иснм-исни болар ягына карап торды. Нәрсәдәндер куркып кире сикерде һәм агач ботакларын сындыра-сындыра урманга чабып кереп китте.

Күл ягында сузып-сузып кош кычкырды.

Корыган үлән сабакларын чыштырдатып җил исте.

Учактагы көлләр тузгып куйды.

Лепелдәп сары яфраклар килеп төште.

Юлчылар пальто, плащ итәкләрен тарткалап, ботаклар һәм үләннәр өстенә тезелешеп яттылар...

Айзат Петр Петрович белән янәшә ята иде. Ул аңа берәр җылы сүз әйтергә, күңелен күтәрергә, кайгысын әз булса да уртаклашырга теләде. Ләкин теленә рәтле сүз, башына юньле уй килмәде. Шуңа газапланып ятты. Ахырында Петр Петровичның җилкәсенә сак кына кагылып пышылдады:

— Петр Петрович!..

Петр Петрович аның дәшүен көтеп яткан шикелле шунда ук җавап кайтарды:

— Аңлыйм. Рәхмәт, Айзат!.. Йокла, йокла!..

Юк, йоклый алмады, черем дә итә алмады Айзат бу ике сәгать эчендә.

Йокысы качкан, күзенә йокы керерлек түгел иде.

Әллә нинди көн булды бүген. Гади кеше ел яшәп күрмәгәнне күрсәтте, ишетмәгәнне ишеттерде.

Уйчан кешене — Иванны кара! Аһ дисә, авызыннан ялкын чыгарлык көннәр кичергән. Ничек чыдаган йодрык кадәр йөрәге, хәзер ничек чыдый?!

Петр Петрович ята менә. Ыңгырашмады, еламады, дәшмәде. Чын ир-егет! Хәзер яшен әчендә йота торгандыр. Әнисе түшәктә соңгы сулуларын сулый. Бәлки инде дөнья белән мәңгегә бәхилләшеп тынгандыр да. Рәхимсез син, тормыш! Бөтен ягың килгән, бөтен ягың түгәрәк — ләкин җиһанга ник кайгы-хәсрәт, авыру һәм үлем яраттың соң син!? Аңсыз гына булмый идемени?!

Айзатның кыска гына гомерендә дә хәсрәте дә булды, кайгысы да.

Үзган елны башын кая барып орырга белми аптырап йөргәндә, ул дөньяда үзеннән дә бәхетсез кеше юк дип, аның хәсрәтеннән дә ачы хәсрәтне монарчы бер адәм дә кичермәгән дип уйлый иде. Күзенә ак-кара күренми йөргән ул көннәрнен сәбәпчесе аның көләч Чәчкәсе иде.

Әйе, йөрәгендәге мәхәббәт утыннан кайгы сөреме чыгарган кеше — кура җиләге шикелле шул кыз иде.

## 18

Чәчкә ул кичне Кремль тукталышына килмәгәч, Айзат борчулы уйларга күмелде. Язгы нурлы кич, чакырылмаган кунакларга ишек ачкан хуҗа йөзе шикелле, караңгыланып китте. Айзат таш баскычтан өскә күтәрелде. Кремль стеналары буйлап китте, һәм Ленин күпере ягына чыгып, Казанкага карап утырды. Икенче башта кочаклашып утырган бәхетле пар, «өченче-артык» дигәнне искә төшерде, күрәсең, теләр-теләмәс кенә кузгалды, җитәкләшеп аска төшеп китте. Бүтәннәр дә төн уртасы житкәндә әзләрен суыттылар.

Кремль буенда Айзат үзе генә калды. Троллейбуслар, трамвайлар да ялга туктый башлады, бөтенләй буш дип әйтерлек дежур машиналар гына берән-сәрән күренгәләп торды. Хәер, алай дип әйтсәк ялгышырбыз, Айзат аларны күрмәде, ишетмәде. Ул хәлсез кулларын тезләренә куйган килеш, күзләрен еракка — Ослан таулары ягына текәп, бөкрәеп утыра бирде. Башы эшләмәде. Аның өчен әллә бар иде дөнья, әллә юк иде.

Кремль курантлары чыңлатып берне сукты.

Күпер ягыннан ашыга-ашыга ике солдат күтәрелде. Алар, Айзатка ун-унбиш адым калгач, туктап ни турындадыр киңәшеп алдылар. Кул селтәп, янына килделәр.

— Сәлам, төн патрулена! — диде сарысы.

— Кайгырма, дус. Бер кыз ташлаганнан дөнья бетәме! — диде карасы.— Насыйбың бер чыгар әле. Икенчене табарсың. Бар кайт, җүләрләнеп утырма. Шундый егетне яратмаган кыз синең калган йокыңа да тормый.

Алар Кремль коймасының төзәтелә торган җирендәге ак ташларга баса-баса өскә күтәрелделәр дә теге якка сикерделәр.

Язгы төннең карыны бер генә колач. Бераз эңгер-меңгер булып торды да яктыра да башлады. Аккош урманнары артындагы химзавод өстендә төн буе уйнаган шомлы кызыл шәүлә тоныкланды. Әле ул, әле бу төштә сөңге шикелле булып күккә сузылган торбалардан чыккан көлле сары төтеннәр ачыграк күренә башлады.

Каршыдагы мәһабәт циркның каплап куйган көмеш тәлинкә кебек ялтыр гөмбәзенә таң нурлары ятып, андагы чык тамчыларын яларга керешге.

Зур шәһәр уянды. Һич тә ялга ятып тормагандай, үзенең шау-шулы һәм эшлекле гадәти тормышы белән яши башлады.

Айзат каршысындагы өрәңге ботагына бәләкәй сары кошчык кунды. Башын кыек салып аңа карап торды. Койрыгын селкетте, нечкә тавыш белән «пип-пип» дип дәште, аннан «ычч» дип сызгырды да җилпенә-җилпенә стадион ягына очты. Һәм Айзат та, яңа йокысыннан уянган кешедәй, як-ягына каранды. Их, дип шыпылдатып тез башына сукты һәм акрын гына кайтып китте.

Тулай торак иртәнге гөрелте белән пыр килеп гөжләп тора иде. Кемнәр юына, кемнәр кырына, кемнәр ашый, кемнәр киенә. Ишекләр шап та шоп, коридорларда тыз да быз.

Айзатка ишек төбендә Нариман очрады. Ул сөлгесен җилкәсенә салып, сабын-щеткасын алып юынырга менеп бара иде.

— Ну-у, мать честная, төнлә дә аерыла алмыйсыз, гашыйк күзенә йокы керми дигәч тә.

Айзат күңелсез генә елмайды.

— Төнлә белән көндезен генә түгел — мәңгелеккә аерылдык, ахры.

— Ничек?

— Шулай.

— Ничек «шулай»? Син кешечә аңлатып бирә алмыйсыңмы?

— Килмәде.

— Килмәде? Кайда кундың соң?

— Кремль буенда утырдым.

— Кит әле!.. Ну-у, энекәш, син чыннан да йончыгансың. Күзләрең кызарып беткән. Еламагансыңдыр бит? Анысы булмас та. Борчылма, бар кер. Мин кичтән, ачыгып кайтыр дип, тумбочкаңа колбаса куйган идем. Кер, аша. Мин юынып төшим. Син борчылма, берәр нәрсә килеп чыккандыр. Шуңа күрә килә алмагандыр. Андый хәлләр еш була. Менә институтта күрер дә сөйләп бирер. Борчылма, бар кер, аша.

Айзат бүлмәгә керде. Ашыга-ашыга лекциягә җыенып ятучы егетләр аны уен-көлке белән шаулашып каршы алдылар:

— Безнең кияү төнгә дә кала башлады хәзер, ә?

— Комендантка әйтергә кирәк, тиздән бер койка бушар кебек, икенче кеше кертсен.

— Җитәр сезгә, сакаллы сабыйлар,— диде Айзат ачуланмый гына.

Рухы гадәттән тыш тетрәнгән чакта, әйтик, артык шатланганда, я, киресенчә, нык кайгырган чакта, кеше тамактан яза дигән сүзләрне Айзатның ишеткәне бар иде. Менә хәзер ул аны үзе сынады, дөрес икән, бөртек тә ашыйсы килми, тамагыннан валчык үтмәс шикелле. Ләкин Айзат киресен эшләде, «үкереп еларлык кайгым да, «әпипә»гә биерлек шатлыгым да юк, бу минутта мин нормальный студент, шулай булгач, мин нишләп тамактан калырга тиеш», диде дә зур гына колбаса кисәген көчли-көчли ашап бетерде.

— Я! — диде Нариман, кереп киенә-киенә.— Ни булды? Сөйлә!

Айзат хәл-әхвәлен ике-өч сүз белән әйтеп бирде.

Нариман аны тагын юатырга кереште:

— Син борчылма. Хәзер бар, Чәчкәне күр — и бел! Аһ орырлык нәрсә юк. Әгәр күрә алмасаң, мин кайткач киномшербез, берәр нәрсә уйларбыз. Ах, мать честная, бүген соңрак кайтам икән. Ну, шулай да көт, китмә.

— Җыелыш-мазармы?

— Әйе. Син барасыңмы? Әйдә!

Алар икәүләп институтка чыгып киттеләр.

Айзат Чәчкә булачак аудиториягә әллә ничә кереп чыкты, инфак коридорларында чуалып йөрде, урамда көтеп торды. Звонок булды, ләкин Чәчкә килмәде. Айзат беренче лекциядә көч-хәл белән утырды да тагын йөгереп аска төшеп китте. Чәчкә юк иде. Айзат икенче лекциягә кереп тормады (керсә дә утырып торыр хәле булмас иде), урамга чыкты да Болак буйлап Кабан күленә таба китте.

Кабан күле янындагы бакчага җиткәч, «Ветерок»ка кереп портвейн эчим микән әллә, йөрәк янганчы вино янсын дип тә уйлаган иде дә, кулын селтәп кире китте — кәефне аракы белән күтәрергә калгач булмый инде ул. Кая баруын үзе дә белми атлый торгач, мәчет каршысына килеп чыкты. Я алла, әгәр булсаң, ник газаплыйсың бу кадәр, минем нинди зур гөнаһым бар соң синең алдыңда дип, аны үтеп китте һәм «Тукай» кинотеатрына җиткәч, кинәт телефонга ташланды. Кабаланып номер җыя башлады, калтыранган бармакларын номер тишегенә туры китерә алмыйча аптырап бетте. Ниһаять, трубканы алдылар, ләкин Чәчкә түгел, әнисе алды.

— Ләбибә апа, бу мин әле — Айзат. Чәчкә нишләп укырга килмәде икән? Шуны белим дигән идем,— диде Айзат, артыннан куган шикелле тиз-тиз.

— Башта исәнләшергә кирәктер бәлкем,— диде Ләбибә апасы, тыныч кына.
— Ай, гафу итегез, Ләбибә апа, исәнмесез!
— Исәнмесез! Минә хәзер ярый. Чәчкә бара алмады шул: авырыбрак тора.
— Ну-у, бик ныкмы?
— Куркыныч түгел. Ләкин температурасы бар.
— Бер генә минутка телефонга килмәс микән, Ләбибә апа, ә, Ләбибә апа? Бик кирәк иде.
— Хәзер. Әйтеп карыйм.
Бераздан шул ук тып-тыныч тавыш белән:
— Әй, карагыз әле, кем... Айзат иптәш, ул поликлиникагамы, аптекагамы чыгып киткән икән, күрми дә калганмын,— диде.
— Ә-ә, шулаймыни? — диде Айзат, ни әйтергә белмичә.— Ярый. Гафу итегез, Ләбибә апа!
— Зарар юк.
— Хушыгыз!
— Хуш!
Айзат трубканы элде. Шуннан соң гына, и дивана баш, иртәгә килерме, дип сорамадым, барып хәлен белешергә мөмкинме дип әйтә белмәдем, терелүен теләргә онытттым, и сантый-сантый дип, үзенә үзе ачуланды. Тагын урам-бакчалар буйлап китте. Чәчкә яшәгән Воровский урамына барып чыкты. Ике-өч мәртәбә керергә талпынса да, йөрәге житмәде. Ленин исемендәге культура сараена кинога кереп ярты сеанстан ташлап чыгып китте. Арып-талып, ачыгып һәм ябыгып кичке караңгы төшкәч монастырьга кайтып ауды.
Нариман аны шелтәләп каршы алды:
— Аю егарлык егет! Ник бала-чага шикелле борын салындырып йөрисең? Дөнья бетмәгәндер бит? Җәй бар, кыш бар, ашыгып ни эш бар дигәндәй, бүген булмаса, иртәгесе көн бар. Терелсә иртәгә килер, терелеп житмәсә — берсекөнгә күрешерсез. Озаккарак тартылса, янына бар. Айзат та ташлады дип моңаеп ятмасын...
Айзат төшендә Америка очучыларының Хиросима шәһәренә көләкөлә атом бомбасы ташлауларын күрде. Бөтен жир тоташ ялкын һәм ут булып, күктә кан төсле кызыл шәүләләр уйный, суларга һава житми, өскә ишелеп һәлакәт һәм үлем килә, йөзәрләп-йөзәрләп бер гөнаһсыз халык кырыла, кычкыра-кычкыра аналар һәм балалар яна иде.
Айзат шыбыр тиргә батып куркып уянды. Йөрәге атылып тибә, авызында нинди дер күгәргән тимер тәме иде...
Иртән Исмәгыйлдән бер шакмак шикәр алып, аны кайнар суда эретеп эчте дә институтка ашыкты. Күнеленә бүген Чәчкәне күрер кебек тоела иде. Чыннан да, егетнең чиксез-чамасыз бәхетенә каршы, звонок булыр алдыннан гына Болак күперендә Чәчкә күренде. Айзат кыз каршысына ыргылды.
— Чәчкә!.. Терелдеңме, Чәчкә?!.
Чәчкә курыккандай кинәт туктады. Әкрен генә:
— Айзат!.. Синме?.. Килдем менә,— диде.
Аның йөзе агарган, йончыган, күз кабаклары шешенебрәк киткән иде. Айзат аны кызганып куйды. Ул үпкәләп торган була, ә Чәчкә мескенкәй нинди ябыккан. Шушы матур көннәрдә таш бүлмәдә авырып яту жиңелме әллә!
— Нык авырдыңмы, Чәчкә?
— Нык.
— Башың авырттымы?
— Башым да авыртты.
— Мин сиңа шалтыраткан идем. Әниең белән сөйләштем. Син өйдә юк идең.

— Әйе шул.

— И Чәчкә!..

Алар институтка кергәндә звонок бирәләр генә иде — өлгерделәр. Кызык та инде бу яшьлек, билләһи, гаҗәп кызык. Бер дә даими хәле юк. Кичәге уе бүгенгә ярамый, бүгенгесе иртәгәгә. Бер карыйсың — ал да гөл, икенче карыйсың — агай, үзең бел. Әле болыт, әле кояш. Айзат та бүген иртән генә үзен бөтен Европада һәм Азиядә иң-иң бәхетсез кеше дип уйлап сыкранып йөри иде, үзенә хәтта инде бер кайчан да көлә-шатлана алмас кебек тоелган иде. Их, яшьлек! Сөйгән яр! Яр бер бакса көлдерә, бер бакмыйча көйдерә шул. Назлы була, чукынган! Хәзер ни булды? Чәчкәсен күреп сөйләшүгә, авызы ерылды куйды. Лекцияләрдә урындыгында очлы энә бар шикелле гел кыбырсып, күршеләренең тенкәсенә тиеп, пыш-пыш сөйләшеп, укытучыларга урынлы-урынсыз сораулар биреп, пүчтәк нәрсәләрдән дә көлеп утырды.

Соңыннан алар «Татарстан» да бергәләп кино карадылар. Картина начар иде. Әйбәт кенә ирләр, бу минем малаймы, әллә синең малаймы дип, бик пошаманга төшеп, эш юктан эш табып, юк кайгыларын бар итеп ах-ух килеп йөргән булдылар. Чәчкә дә көлмәде. Вакыт-вакыт авыр сулап тирән уйларга чумып утырды. Ут сүнгәч тә кулын тоттырмады, тамагым авырта дип, мороженое алдырмады.

Кинодан чыккач, Айзат аннан йөз кабат сорады:

— Ни булды? Ни булды сиңа, Чәчкә? — дип өзгәләнде. Чәчкә, елмаерга тырышып:

— Бер ни дә юк. Кара инде, нишләп сиңа шулай тоела торгандыр,— дип кенә җавап бирде.

Айзат аны, гадәттәге кебек, трамвайга кадәр озатырга теләгән иде, кыз каршы килде.

— Озатып йөрмә, мин ашыгам,— дип, Матбугат йорты янында троллейбуска утырды.

Айзатның, дулкынланып:

— Кайчан күрешәбез соң тагын? — дигәненә каршы бөтенләй икенче нәрсәләр турында уйлый-уйлый:

— Белмим... Иртәгәдер,— дип китеп барды...

Айзат кайтты да чишенми-нитми караватына сузылып ятты. Ул аңлады: Чәчкә авырмаган, ана нәрсәдер булган, шул «нәрсәдер» аны борчуга төшергән. Ләкин ни, нәрсә? Анысы хәзергә билгесез. Айзатны яратамы, яратмыймы? Әллә аннан әйбәтрәк ярны сөяме?

Сөясе килә икән, сөйсен. Мине генә сөй дип ялынып булмый. Ул барыбер үзенчә кылана. Кылансын! Айзатка нәрсә! Кыланып калсыннар. Ул аларга комачаулап йөрмәс...

Бер кочак китап күтәреп Равил кайтып керде.

— Менә шулай инде ул безнең кияү, менә шулай инде ул галим кияве: кызы янынннан кайта да «ух» дип сузыла да ята, ботинка салырлык та хәле калмый,— дип тыкылдый-тыкылдый Айзат янына килде. Я, ничек? Ике бәлеш, бер пәрәмәч кияүләрнең азыгы, ди минем туксан тугыз яшьлек әбием. Шәп сыйладылармы әбекәй-бабакайлар? Урынның түрен, бәлешнең төбен бирделәрме? Кияү-кияүкәй дип, бер алдына, биш артына төшеп биеп йөрделәрме? Бабакаең сине дә профессор кисәге итәм, диме? Ә? Син дә сынатмагансыңдыр инде: озын-озын, йомры-йомры сүзләрне җиффәреп кенә утыргансыңдыр, ә? Әйт инде, кияү балакай?

Айзат ачуланып аңа йодрыгын күрсәтте.

— Тагын бер генә сүз әйт — бәреп үтерәм, тере саескан!

— Бә-әй, ни булган моңа? Ни булган бу кешегә? И-и, мина димәгәен. Әйттем исә кайттым, бетте, бетте. Аллам сакласын. Янына якын бара күрмәгез. Тфү, тфү, тфү,— дип сөйләнде дә Равил юкка чыкты.

Нариман кайтмады: Иркәсе белән берәр җиргә киттеләр, ахры.

Айзат шул ягуыннан тормады. Төшендә тагын Хиросимага атом бомбасы ташлауларын күрде. Нәкъ кичәге төшне кабаттан икенче тапкыр, нәкъ кичәге төсле куркыныч һәм шомлы итеп күрде...

Авыргандыр, кәефе булмагандыр, үтәр, Чәчкә тагын алсу чәчкә шикелле нурланып дип үзен юатса да — өмете акланмады. Чәчкә икенче очрашуга да аптыраган кыяфәттә, таркау зиһен белән килде. Айзатның сүзен әллә тыңлады, әллә юк. Кирәкмәс урыннарда да «әйе», «түгел» дигәнрәк сүзләр әйтеп утырды. «Нишләп болай?» дигәнгә — тагын туры җавап бирмәде. «Мин элекке төсле инде. Белмим, нишләп сиңа алай күренгәндер», диде. Әледән-әле сәгатенә карады, ашыкты.

Салкын гына аерылыштылар.

Айзат мәхәббәтнең метеор тизлеге белән һәлакәткә якынлашуын һәм аның тиздән янып юкка чыгачагын аңлады. Сукырга, үлеме җиткәнче, һаман күзе ачылыр кебек тоела. Шуның шикелле аның күңеленең кай төшендәдер көл астында көйрәгән күмер шикелле кечкенә очкын яши иде әле. Ятып калганчы атып кал дип, Айзат Чәчкә белән өченче тапкыр сөйләшергә уйлады. Моңысы соңгы көрешүләре. Я пан, я пропал. Бүтән свидание теләнеп йөрмәячәк. Кайгы-сагышын эченә йотачак. Егет кеше әле ул, егет кеше! Үзен үзе тыя ала, кеше арасына сыя ала. Мәхәббәт романнары укып йөрган астында яшь сыгып ята торган нәзберек кыз түгел!..

Өченче мәртәбә көрешүгә Нариман каршы килде.

— Төкер! — диде.— Колхозчы малаеның данын сатма. Үз ишләреннән салам сыйраклар кирәк, димәк, ул туташка. Кызларның тамыры Бохарда түгел — табылыр. Башың әле яшь. Шаша-шаша сөяргә дә, сөелергә дә өлгерерсең. Һәр кем ише белән яралган. Яратмый икән, ялынма, кирәкми. Төкер, барып йөрмә.

— Барам, Нариман, соңгы мәртәбә. Булмый икән... Йөрәгем яна. Аңламыйсың хәлләремне, Нариман!..

Айзат кызны бер атнадан гына күрә алды. Алар кичкырын Соцгородта очраштылар, аннары паркка керделәр. Аларның монда килгәннәре бар иде. Чәчкә үзәк аллея буйлап ике яктагы бюстларга язылган сүзләрне укып бара торган иде.

Аннан соң алар, гадәттә, Ленин һәйкәле каршында тын гына басып торалар, күнелләреннән юлбашчы белән сөйләшәләр.

Һәйкәлне үткәч, уңга борылып, өч кенә эскәмияле тыныч аллеяга юнәләләр. Эскәмияләрнең берсенә, пәке белән чокып, «Коля Киселев» һәм «Сарычева В.» дип язылган.

— Әйдә, үзебезнең «Коля Киселев» эскәмиясендә әзрәк утырыйк,— ди Чәчкә.

— Үзебезнең «Сарычева В.» эскәмиясендә,— дип өсти Айзат, шатлыктан елмаеп.

Агачлар арасында балалар уйнап йөри, якында гына бәләкәй фонтан һавага салам нечкәлеге салкын су сиптереп тора. Айзат белән Чәчкә балаларга карыйлар, иреннәре белән су агымын тотып шаяра-шаяра су эчеп килләр. Карашып күзләре талмый, сөйләшеп сүзләре бетми. Куллары кулда. Аларга — ике мәҗнүн гашыйкка — көн дә яз, төн дә яз, көз дә яз, яз да яз!..

Бүген боларның берсе дә булмады. Паркка керү белән Чәчкә:

— Ардым, утырыйк шушында,— диде. Утырдылар. Айзат, сиздермәскә тырышып, аңа күз салды. Аның ак түгәрәк йөзе суырылып киткән, нәге очлая төшкән, күзләрендә моң һәм аптыраш иде.

— Чәчкә! — диде Айзат, аны кызганып.— Нишлибез без?

— Нигә чакырдың? Я сөйлә, тыңлыйм,— диде Чәчкә, илтифатсыз гына.

— Ни булды, Чәчкә? Нишләп кинәт...

— Һаман шул сүз. Бер ни дә булганы юк миңа, нигә аптыратасың?

— Миңа кыен, Чәчкә.
— Миңа да рәхәт түгел, Айзат.
— Мин сине сөям, Чәчкә!
Чәчкә йөзен ике кулы белән дә каплады. Иелеп бик озак утырды. Елады бугай: кулларын алганда күзләре кызарып юешләнгән иде.
— Айзат! — диде ул, ә үзе Айзатның күзләренә карамаска тырыша иде.— Әллә миңа җиңел дип беләсеңме!.. Син әйбәт егет. Минем берәү белән дә йөргәнем юк иде. Син акыллы... Тик ачуланма... Мин сиңа аңлата алмыйм. Булмый. Очрашырга ярамый безгә. Бу очрашуыбыз — аерылышуыбызның башы... Мин дә ут эчендә. Син акыллы бит... Аңларсың. Киләчәк күрсәтер. Көннәр үтсен... Бәлки әле... Гафу ит, Айзат! Очрашмаска тырышыйк, Айзат... Әгәр... булдыра алсам, көчем җитсә... мин үзем килермен... Батыр бул!.. Кайгырма... Ачуланма... Хуш, Айзат!.. Үп мине... соңгы кабат!..
Егет тораташ шикелле иде. Кыймылдый да алмады.
— Хуш, Айзат!.. Миңа үпкәләмә!..
Чәчкә башын иеп тиз-тиз китеп барды. Бакчаның ул киткән ягында шаулап-гөрләп, җирне дерелдәтеп товарный поезд үтте.
Айзат трамвай тукталышына атлады.
Шуннан соң аның өчен көннәр каралды. Кояшы айга, язы көзгә әйләнде. Нариман, тора-тора, әле Чәчкәне, әле Айзатның үзен сүкте:
— Төкер! Син — аңа ярәм! — диде.
— Яле! Мунчасы янган кеше шикелле йөрисең. Атаң үлмәгәндер бит, нинди кайгың бар? Ник саргаясың юк өчен? Кызлар беткәнме әллә дөньяда — сызгыр гына,— диде.
Группа кызлары арасында бу мәсьәләгә карата төрле фикер йөрде. Берәүләр Чәчкәне гаепләделәр.
— Бигрәк инде, кыланган була. Инфаклар үзләрен әллә кемгә чутлап йөргән булалар, хөрәсәннәр. «Зер гут», «Плиз» дип кенә без дә әйтә беләбез, харап. Безнең Айзат шикелле асыл егетне җылый-җылый эзләр әле. Исенә бик төшә-әр, ләкин соң булыр,— диделәр.
— Айзат үзе дә инде... Тапкан. Агачның биегенә асылынырга уйлаган... Профессор кызы кирәк булган. Профессор кызлары шулай шома ул, шамбы кебек шуып кына китә,— дип, Айзатка төрттерүчеләр дә булды.
Ә китек тешле Нурия шаярып Айзатны юатты:
— Кайгырма, парень. Китсен академик кызлары. Ул әле бәрәңге дә әрчи белмидер. Гомер буе интегер идең. Котылуыңа шөкерана кыл. Ул булмаса — без бар. Группада бер башыңа егерме биш кыз. Егет очратсак, күзебездән ут күренә торган чагыбыз. Теләсәң, мене үземне сөяргә можешь. Мин дә сине назлап йоклатырмын, үбеп уятырмын... Һи-һи-һи... Нигә?.. Дөрес түгелме әллә, кызлар? — дип көлде.
— Теңкәмә тимә әле, пожалуйста, тукта. Тешеңне кайсы җан кисәгең киткәндер бит әле,— диде Айзат...
Имтиханнар беткәнче, ул Чәчкәне очратмады. Дөресрәге, очратырга теләмәде. Болай да кыен, күрсә йөрәк җәрәхәте артыр гына иде. Урамнарга сирәк чыкты. Укыды да уйланды, укыды да уйланды, уйлана-уйлана йокыга китә иде. Консультацияләргә, имтиханнарга гына барып кайта да тагын караватына менеп ята иде. Кино-театрларга эзе суынды.
Кыскасы, Айзат бу язны кулга алынып өендә яшәргә хөкем ителгән тоткын кебек үткәрде. Ничек кирәк алай имтиханнарын биреп бетерде. Уку дәверендә беренче мәртәбә ике «яхшы» алды. Ләкин борчылмады. Чөнки аңа барыбер иде...
Иртәгә авылга очасы дигән көнне кич белән тагын Ленин районына китте. Җәяү барды. Чәчкә яшәгән йортка, аларның якты тәрәзәләренә урам почмагыннан озак карап торды. Чәчкә күренмәде. Айзат авыр су-

лады да, хуш, Чәчкә, көзгә тикле күрә алмам инде, дип кире кайтып китте.

Икенче көнне иртән самолетка утырганда да Чәчкәне көтте. Килмәсен белсә дә, һич өмете булмаса да, үзен-үзе алдый-алдый көтте.

Әнисе аны күргәч елады.

— Сынау дигәнең бик авыр булдымыни соң, балакай? Тәмам беткәнсең бит. Тәнеңдә җаның гына калган,— диде.

— Борчылма, әни. Бераз ардым, шул гына.

— Әллә ашарыңа булмадымы, балакай? Ник акчаны күбрәк җибәрегез димәдең? Табылыр иде.

Моңа кадәр өстәл янында тын гына утырган әтисе сүзгә кушылды:

— Вәт нәрсә, анасы, улыңны тазартасың килсә, сыенны алдыннан өзеп торма. Аңа хәзер күбрәк ит, май кирәк. Хәзер симез тавыгыңны тот. Тавык шулпасы йөрәккә ята торган аш. Иртәгә малай кайтуына дип калдырган кысыр сарыкны көтүгә чыгармабыз. Вәт шул. Монысы бетсә, абзарда тагын сарыклар бар. Итсез тормабыз. Ял итәр. Балык тотар. Күрәер. Анасы, кая әле, пычакны тап та тавыгыңны тотып кер...

Ничек кирәк алай атна үтте. Айзат кичне житкерә алмыйча тәмам интегеп бетә иде. Өчтә-дүрттә кояш чыга, унынчыда бата. Мунча ташы кебек кызган яланнарда һәм урамнарда сузылып йөреп кенә үткәрүе җиңел түгел шул җәйге көннәрне. Куян койрыгы хәтле кыска төндә дә керфегенә йокы элми. Арып-талып тынгысыз йокыга талса да, төшенә шундук Чәчкә керә. Гаҗәп төшләр! Айзат бергә чакларын, өндә ничек булса, төшендә дә нәкъ шулай икенче мәртәбә кабаттан күрә. Сүзләре, хәрәкәтләре белән. Уяна да төрле уйларга чумып ята...

Күңелсез, авыр. Ашыйсы да, эчәсе дә килми. Туган-тумачалары тавык суеп, аракы алып кунакка чакыра. Бармый. Гаҗәпләнәләр, әрлиләр, үгетлиләр, үпкәлиләр. Эреләнгәнсең, апай, туган итмисең, диләр. Ләкин Айзатның моңа исе китми. Әйтмәгәйләре! Аның гомумән бер нәрсәгә дә исе китми. Көннәрне тизрәк үткәрәсе, тизрәк Казанга китәсе килә. Иртән торуга календарь битен ерта. Тагын бер көн үтте, дип, исәр кеше шикелле куана...

Бер көнне кич белән ашап утырганда әнисе аңа текәлеп карап торды да:

— Нигә ашамыйсың, улым? Әллә яратмыйсыңмы? Тәмсезме? Тозы җиңелрәкме? Кая, салыйм. Суынганмы әллә? Кая, кайнарын өстәп китерим,— диде.

— Борчылма, әни, бик тәмле. Әллә нигә ашыйсым килми.

— Тамагыңнан аш үтми, улым. Эчеңдә чирең була күрмәсен берүк. Дуктырга күренеп карарга иде, балакай.

— Күрендем, әни, чир тапмадылар. Сабанга җигәрлек, диләр.

— Кая инде, сабанга җигәрлек җирең калмаган, улым. Ашамыйсың, эчмисең. Хәсрәте бар кеше шикелле уйланасың-моңланасың да утырасың. Атаң да әйтә, кайтса туйганчы бер сөйләшербез дип сөенеп көтеп тора иде, юкка гына сөенгәнмен — утырып ике авыз сүз дә сөйләшкәнебез юк малай белән, ә дисәң, җә дип әйтә дә, бүтән сүзе юк, ди. Аптырап йөри.

— Сөйләшәбез бит инде, тагын ни кирәк!

— Түтән дә, апайларың [1] да әйтә, абыкай әллә нишләп кайткан, диләр.

— Һе... Күп сөйләгән кешедә өмет юк, дип үзегез әйтәсез бит.

— Кич чыгып йөрмисең. Клубларга бармыйсың. Кичә кино булган, тагын чоланга кердең дә яттың. Кунагы кунак инде, аракы эчмим дигәч, көчләп эчерүче юк. Анысына үзебез дә риза. Аракы авызга черки булып керә, аждаһа булып чыга. Өйрәнми торуың әйбәт. Ашау өчен йөрергә дә

[1] Энеләрен-сеңелләрен мәгънәсендә

элекке мулла түгел. Ә менә, мин әйтәм, бергә үскән, укыган дус-ишләрен белән шаярып, сөйләшеп бергә-бергә йөрергә кирәк ие.

— Иртәгә чыгам, әни.

— Кая, балакай?

— Элекке сымак грузчик булып икмәк ташырга.

Әнисе бераз уйланып утырды. Аннан риза булды.

— Анысы ярый. Монда читлек эчендәге кош шикелле ябылып ятканчы, кеше арасында күңел ачып йөрерсең.

Айзат икенче көнне таң сызылуга сикереп торды да, әнисе ни кыстап караса да, ашамыйча-эчмичә эшкә чыгып китте.

Амбар алды, иртә булуга карамастан, гөрләп тора иде инде. Ике-өч җирдә зернопультлар үкерә, катлаулы җилгәргечләр текелди, машина моторлары шаулый. Кая карасаң, тау-тау ашлык, кая карасаң, хатын-кызлар, егетләр, ирләр кайнаша. Бер апа (каравылчы булса кирәк) кулына чыбык тотып:

— Кәҗә-ә, мөртәт, чукынгыры нәрсәкәй! — дип, кәҗә куып йөри.

Күп кешеләр эшләреннән аерылып, Айзат белән күрештеләр.

— Нихәл, апаем! Исән-сау гына кайттыңмы?

Бригадир кеше — Кашсыз Сәгыйт (сугышта бер кашын мина кыйпылчыгы пәке белән кискәндәй кыеп кына алып киткән) абыйсы да килеп күреште.

— Бәй, апай, Айзат кайткан дисәләр дә һич барып күрешергә җай юк. Вакыт табып булмый. Самай каты чак... Нихәл, апай, сау-сәламәт кенә кайттыңмы? Сынауларыңны әйбәт бирдеңме?

— Дөрес әйтәсең, Сәгыйт абый, тыгыз чак, иртәрәк уяна торган чак,— диде Айзат.— Миңа да берәр эш калгандыр бит?

Бригадирның йөзе балкып китте. Үзе шулай да әдәп саклап:

— И апай, әзрәк ял итәр идең әле,— дигән булды.

— Грузчик кирәктер инде сиңа? Эш өсте житсә, шуңа зарланасың. Кайсы машинага төйик?

— Менә монысына, апай. Моңа хәтле йөргән кыз кичә авыр күтәреп эчен кузгаткан. Гел аптыраш иде пәрәмә...

Шуннан башлап Айзат, һәр җәйдәге шикелле, автомашинага йөкче булып йөри башлады. Аның көчле куркрәгенә авыр физик эш, уйлы һәм моңлы күңеленә кешеләр арасында булу, онытылып тору кирәк иде. Эш белән, уен-көлке белән көн үткәне сизелми. Сагыну һәм сагышларга вакыт әзәйде.

Әле таң атып кына килә, ә алар амбар алдында була инде. Икмәк төяп Табагач пристанена чыгып чабалар. Әллә ни ерак түгел түгелен — утыз биш чакрым гына. Әмма юлы бик хөрти. Икмәкне бушаткач, хәл җыеп тир катыргач, Камада су керәләр. Аннан кире кайтып китәләр. Тагын төйиләр, тагын илтеп бушаталар, тагын керәләр. Чиялегә күктә якты йолдызлар калкып, авыл йоклап беткәч кенә кайталар. Айзат өйгә плащын беләгенә салып, иелә төшеп атлый-атлый, арып-талып кайта.

Ләкин аны эш куплеге һич тә куркытмый. Болай ул Чәчкәне онытып тора. Әмма ашлык бушатып кире кайткан чакларда шул имансыз кыз барыбер искә төшә бит. Кабинада бөркү, бензин исе. Айзат кузовта чыбылдык эченә кереп бөркәнеп утыра да Казан белән Чәчкәсен уйларга керешә. Озак уйлый. Эче сызылып, авыз эченнән җырлый башлый:

> Җыйдым җиләк, җыйдым җиләк,
> Җыйдым да кабалмадым;
> Синә ошаган алсу чәчкә
> Эзләдем, табалмадым...

«Бүтән җырлар белмим, ахры, бәлки белгәннәрен дә онытып бетергәнмендер — бу башта җыр кайгысымы соң!» — дип уйлый...

Йөрәген учына йомарлап шулай йөрде-йөрде дә бер көнне иртән амбарлар алдына үзенең чип-чиста киемнәрен киеп килде. Сәгыйть абыйсының күзләрен тутырып карап торуын сизгәч, кул селтәп:

— Чәчен үрә тормасын, иптәш бригадир, мина житәр. Бүген Табагачка грузчик булып түгел — пассажир булып кына барам,— диде.

Сәгыйть юк кашын сыпырды.

— Ни, апай... Что син... пажалысты. Ярдәм иттен, рәхмәт... Кәчләп кушкан юк...

Айзат Табагачта озак кына «арка кыздырды». Казан — Уфа пароходы төш узгач кына килде.

Өрсән очып китәр төсле жинел, аккоштай ак пароход Кама буйлап югары менде дә унга борылып гүзәл Агыйделгә керде. Анын көмеш төсле суына, яр читендәге бөдрә талларына: «Саумысыз-ы-ыз! Менә, мин тагын әйләнеп кайттым әле-е-е!» — дип, күнелле кычкырып сәлам бирде. Таллар анын ак башлы дулкыннарында чайкалып, кул болгап калдылар.

Айзат каютага бөтенләй кермәде. Жырларда мактап жырлана торган бу мәһабәт елганын борылыш саен янача ачыла барган кабатланмас матурлыгына сокланып, палубада утырды. Кич житеп жиләсләнгәч, Агыйдел өстендә аллы-гөлле маяклар кабынгач, барасы жиренә житеп, бер пристаньда төшеп калды.

## 20

Нариман көн буе печән чабып әле генә Агыйдел аръягындагы болыннан кайткан иде. Айзатны күргәч, ул үз күзләренә үзе ышанмады. «Мать честная!» — дип кочаклап алды да аркасыннан дөп-дөп кагып торды. Айзат та старшинаны сагынган иде, ул да дустының аркасын нык кына дөмбәсләп алды...

Нариманның йокы урыны өй алдындагы агач бакчасында — карт алмагачның чатырдай тармаклары астында икән. Ашап-эчкәч, шунда чыгып марля чыбылдык эченә кереп яттылар. Иң аска такта тезелгән, ана калын итеп мәтрүшкәле вак печән түшәлгән, иң өскә мамык юрган жәелгән иде. Шәп иде Нариманның урыны! Ул бакчаның Агыйдел ярында ук булуын, аннан алма, чия исләренә кушылып жиләс жил исүен, сирәк-мирәк пароход һәм буксирларның моңсу тавышлары ишетелеп торуын да искә алсаң — бөтенләй ожмах иде!

Моны әйткәч, Нариманның исе китмәде.

— Һәй, ялгыз баш булгач күзгә әйбер күренәме, арка — йомшакны, күкрәк — рәхәтне тоямы! Иркә булса, мин как жирдә дә ятарга риза,— диде.

Әлеге дә баягы — башына кисәү таягы дигән шикелле, сүз бик тиз кызлар тирәсендә әйләнә башлады. Гаеплән тә булмый: жәйге матур төндә Агыйдел ярындагы алма бакчасында өйләнмәгән сау-таза ике егет кыз-кыркын хакында сөйләшмичә дегет чиләге турында гәпләшеп ятмас инде!

— Мин дә теләсә нәрсәгә, теләсә нинди катр эшләренә шатлана-шатлана риза булыр идем, тик Чәчкә менә...— диде Айзат.

— Онытмадыңмы?

— Юк.

— Онытып булмыймы? Тырышып карадыңмы?

— Карамадым: онытылмаслыгымны сизәм.

— Килеп кергәч тә нишләп йөрүенне белдем. Башыңны кая куярга урын, йөрәгенә ял таба алмый интегеп йөрисен. Канаты каерылган тургай кебек, атылып-бәрелеп йөрмә, оныт, йолкып ат йөрәгеңнән шул билчәнне!

— Билчән дисеңме?

— Соң!

— Синең өчен бәлки билчәндер. Тик минем өчен барыбер чәчкә у. Мәк чәчкәсе.

— Мәк чәчкәсе күрер күзгә матур да...

— Әйтеп бетер!

— Әнә шул күрер күзгә матур мәктән әфиюн ясыйлар.

Айзат авыр сулады.

— Үпкәләмә. Үзеңне кызганам, бетәсең.

Айзат кабынып китте:

— Кызганма!.. Иди ты... беләсеңме кая?..

— Син үзең иди... тегеләйрәк. Юкса төртеп төшерәсен.

Бераз тын яттылар...

Агыйдел өстендә, бик еракта, елый-елый әллә адашкан, әллә юл ки леп арыган пароход кычкыртты...

— Горькийга рәхәт булган, җанына ял табылмаса, аркасына кап чык аскан да босяк булып киткән. Мин дә китәр идем. Күрмәгән-белмә гән, чит-ят җирләргә китәр идем! Аркада капчык, кулда таяк. Алдынд очсыз-кырыйсыз озын юл. Атла да атла, бар да бар!.. Туйдым! Һәр көн не, һәр елны бер үк нәрсә. Таң ата да кич була, шимбәдән соң якшәмбе, җәйдән соң көз. Ичмасам бераз булса да үзгәрсен иде бу дөнья. Бер ү төс,— күңелсез сары төс туйдырды. Сары төс — сулу, үлү төсе...

Нариман, бәләкәй баланы юаткан шикелле, дустының кулын кысы куйды.

— Вакытлы гына бу синен. Үтәр, борчылма. Минем дә шулай күңе сызланган чаклар була. Башымны алып олагасым килә. Барлык кеше ләрдә дә була торгандыр мондый авыр минутлар. Кайгырмаска, моңай маска тырыш. Син егет кеше бит.

— Тапканнар бер сүз: егет кеше! Торалар да син алай итмә, болай булма, син егет кеше, диләр. Әйтерсең, егет кешенең җаны юк! Шул ук ата баласы ла ул. Аерым материалдан ясалмаган. Сыер дуласа, аттан яман, диләр. Аны киресенчә дә әйтеп була. Егет еласа, нык елый.

— Айзат, беләсеңме нәрсә, ял йортына кит син. Миндә путевка бар

— Ни сөйлисең? Ничек инде мин?.. Кеше путевкасы белән...

— Анысын, баргач, үзең рәтләрсең. Баш ярылып күз чыгарлык эш түгел.

— Ә үзең?

— Бара алмыйм.

— Ник?

— Ник тә ник! — диде Нариман, үртәлеп.— Әнине күрдеңме — кар тайган. Көчкә йөри. Бала-чаганы күрдең бит? Апанықылар. Без апа белән икәү генә идек. Хәзер дүрт ел инде үзем генә. Аларны Нариман абыкайлары карамыйча, хозыргаләйһиссәләм карар дисеңмени?

— Стипендияң синең үзеңә дә...

— Юк сүз. Мине Агыйделнең ак суларында коенып ята дип беләсең ме әллә? Юк, туган. Җәй буе печән чабып кибән куям. Киткәндә сатып, балаларга кышлык азык, әз-мәз акча калдырам. Кием-салымнарын рәтләгәндәй итәм, китап-дәфтәрен дигәндәй. Икенче елга мин кайтканчы җиткерергә тырышалар... Быел, местком биргәч, әллә дөнья күреп, ял итеп кайтырмынмы дип путевкасын алган идем дә, тагын бия тартэгэ типте. Элек чапкан аланга колхоз көтү керткән. Язгы ташу да бәләкәй рәк булган, печән юк. Тал төпләре, түмгәк башлары чокыштырып йөрим шунда. Күп кирә-эк... Сызламаган буыным калмый... Укып чыксам, үз яныма алыр идем инде җыенысын. Иркә каршы килми.

— Мин боларны бөтенләй белми идем, Нариман. Ник миңа әйтмә гән идең, ә?

— Күп сөйләргә яратмыйм. Без синең ише лыгырдавык филологлар түгел, бездә — формула!

— Без бит — дуслар!

— Бер дус икенчесен кызганса, ул инде дуслык булмый. Аннан соң, мать честная, минем хәл кызганырлыкмыни! Подумаешь, печән чаба бер егет! Үтми аның чалгысы, анда кызлар кайгысы, ә? Юк, чалгым да үтә, кызлар кайгысы да юк. Бу болай гына, вакытлыча. Сагынып сөйләргә кала. Укытучыларның хезмәт хакын күтәрделәр, житәр әле, яшәрбез. Гөрләтеп, матур итеп, җырлар җырлап!

— Мин кызганам димәдем. Ярдәм иткән булыр идем.

— Гафу, мин чит кешеләрдән һич кайчан да ярдәм сорамадым.

— Син минем сүзне дөрес аңламадың. Печән чабышырга килер идем. Икәү күңеллерәк булыр иде. Әй товарищ старшина...

— Мин, нинди булсам да — старшина. Ә син — рядовой солдат, необученный, запас второй категории. Тфу! Иртәгә подпускаларны карап кайтабыз да — шартлаганчы балык ашыйсың. Аннары путевканы кесәгә саласың да — Актанышка китәсең дә, самолетка менеп утырасың да, Казанда төшәсең дә, елга портында «ОМ»га кабат утырасың да, Идел буйлап өскә китәсең дә, мин унөч көн рәхәтләнеп ятасы ял йортына китәсең дә, дөньяда алтын дустың булуына шөкерана итеп минем исәнлеккә хәер-дога кыласың. Менә шул, солдат иптәш! Моны старшина боерыгы дип кабул ит.

— Тыңлыйм һәм буйсынам, галиҗәнап хәзрәтләре. Ләкин командагызга печтик төзәтмә кертергә мөмкин түгелме?

— Түгел! Түбән чинның олы чин командасына төзәтмә кертергә хакы юк. Алар аны фәкать йөгерә-йөгерә үти генә алалар.

— Ну, дус итеп кенә, фельдмаршал?

— Ну, дус итеп кенә кайчакларда рөхсәт ителә.

— Рәхмәт! «...Казанда төшәсең дә...» дигәннән соң «Воровский урамына борылып кайтасың да» дигән сүзләр өстәргә ярыймы?

— Әйдә, бездән булсын изгелек — өстәп куй.

— Ходай сезгә озын гомерләр бирсен, тәкъсир. Хатыныгызга тәүфикъ, бала-чагаларыгызга акыл бирсен. Амин!

— Әллә йоклыйбызмы? Мин чыннан да ардым.

— Рәхмәт, Нариман. Син әйбәт дус.

Ләкин аларның йокларга вакытлары калмаган иде инде. Баш очларында, алмагач ботагына кунып, нниндидер кошчык сайрап җибәрде. Агыйдел аръягындагы тигез болыннар өстеннән кунак кызыдай кызарынып таң сызылды. Таңгы җил шул яктан чәчәк һәм печән исе алып килде. Агыйдел өсте яктырып көзге шикелле ялтырый башлады. Ишекләр, капкалар ачылып-ябылды, сыерлар мөгрәде, сарыклар бәәлдәде. Авыл уянды. Нурлы һәм җылы яңа көн туды.

Айзатлар кармакларын карарга төшеп киттеләр. Агыйделнең бу урыны көянтә шикелле борылмаланып, авыл шул «Көянтә»нең эчендә утыра иде. Яр читенә саллар туктаган. Шул сал өстеннән елганың яртысына кадәр кердeләр дә бәләкәй көймә белән түбәнгәрәк төшеп киттеләр. Нариман койрыкка утырды. Үзе кармаклар тезелгән озын капрон җепне әкрен генә су төбеннән тартып көймә төбенә тәгәрмәчләп җыярга кереште. Бәхетләренә каршы, кармакларның өчесенә өч зур гына корбан эләккән иде. Алар чапор-чопыр су төбеннән килеп чыккач, икесенең дә йөрәкләре атылып тибәргә тотынды.

— Балыкның үзеннән бигрәк чупырдавы кыйбат, әйеме?.. Ризыгың артыннан иярәп йөри икән,— диде Нариман, шатланып,— юкса әнкәй белән икебезгә гел икәү эләгә иде. Кылчыгыннан куркып, балалар ашамый.

Алар көймәләрен тагын бүрәнәгә бәйләп, сал өстеннән ярга чыктылар. Элеватор янында торучы тимер баржага кереп чишенделәр дә, Агыйдел акчарлаклары кебек канат җәеп, бөтерелеп аккан яшькелт суга ташландылар. Куыштылар, батырыштылар, чумыштылар, пошкырдылар, көлеш-

теләр. Агыйделнең алкын суы, шифалы дару шикелле, тәннәрен арулады, күңелләрендәге шөбһәләрен юды.

Бик әйбәтләп балык белән сыйлагач, Нариман, балык ашаган тук булып, тез буыны юк булыр дисәләр дә Казанга хәтле түзәрсең әле дип көлә-көлә, Айзатны Актанышка озатып куйды.

— Син килүнең файдасы тиде, үземә бер көн ял бирдем. Югыйсә, хәйләсен тапмый йөри идем,— диде.

Айзат, дусты белән хушлашып, Казанга очты. Казанда, елга портына киткәнче, Ленин районына кагылып чыгарга булды. Чәчкәләрнең өе каршысында, йөрәгенә бик тә якын тәрәзәләргә өмет һәм сагыш тулы күзләре белән томырылып карап озак торды. Ләкин Чәчкә күренмәде. «Китәм бит инде, китәм бит, ник чыкмыйсың, нишләп чыкмыйсың? Күреп калсам да йөрәгемә ял алыр идем, чык инде, үт инде!» дип теләде. Телефон-автоматка керде. Трубканы кире элде: шалтыратырга көче җитмәде. Шуннан соң әрле-бирле йөреп торды да кинәт кыюланып, ни күрсәм дә күрермен, шалтыраткан өчен милициягә тотып бирмәсләр әле дип, баскычтан менеп китте. Менә өченче кат. Кадерле ишек. Күз кебек звонок төймәсе. Басаргамы? Беткән баш беткән — басарга!

Басты. Тагын басты. Тагын, тагын!.. Сонга таба бармагын алмыйча өзлексез чыңлатып тора башлады.

Эчтән тавыш ишетелмәде. Ишек ачылмады. Дөресрәге, аңа кирәк ишек түгел — күрше ишек ачылды. Бер бәләкәй малай аңа шикләнеп карап торды да:

— Ала-а Кы-ымга киттелә-ә,— диде.

— Кырымга дисенме?

— Кы-ымга.

— Кайчан?

— Вто-оныкта.

Айзат кайсы сишәмбедә дип төпченеп маташмады, башын иеп аска төшеп китте.

Ял йортында иң куркыныч нәрсә, ял итүчеләрнең иң әшәке дошманы эч пошу диләр. Шушы дошман Айзатны да ял йортына аяк басуга әсир төшерде. Айзатның күршесе сүзләрен тешсез карт шикелле әвәләп сөйләшүче, арыш умачыдай кап-кара йөзле егет аңа иптәш була алмады. Эчен генә пошырды. Икенче көнне халык җыйнаулашып уйный-көлә Казанга экскурсиягә китте. Айзатка моның кирәге юк иде. Көнен журналлар укып уздырды. Кичен культмассовик Идел ярындагы яшел чирәмдә «мероприятие» оештырды. Аларны түгәрәккә тезеп үзе уртага керде дә:

— Хлопнем раз! Хлопнем два! Хлопнем еще, еще раз! — дип кул чаптыра башлады.

Айзат барысына да кул селтәп соңгы электроход белән Казанга кайтып китте. Шул ук көнне Уфа пароходына утырды...

Нариман аны күргәч бер дә аптырамады. Көтеп торган кешесе шикелле гади генә итеп:

— Шәп чалгы бар, сәнәк-тырма ише нәрсәләр дә җитәрлек. Икәү булгач, кунып эшләү яхшырак. Кайтып йөреп вакыт әрәм итмәбез,— диде.

Айзат күңелендә гомер буе исенә төшереп сагынып-сагынып сөйләргә калган матур көннәр һәм төннәр башланды.

Әйе, Агыйдел тугайларында көчле беләкләрен уйнатып каерылып-каерылып печән чапкан көннәрен, бер төрле матур, моңлы көй кебек иртәдән кичкә кадәр колакларын иркәләгән чалгы чыжылдауларын, кин болынны яңгыратып чалгы янауларын, мендәр шикелле күпереп калган тигез покосларны, чалгы астына коелган күгәрчен башыдай эре-эре жир җиләкләрен, аларның хуш исен, балдай татлы тәмен,

карт тал ышыгындагы иркен куышны, андагы татлы йокыны, куыш янындагы салкын чишмәнең челтер-челтер иркәләп йоклатуларын, озын-

лыгы бер генә саплам җәйге төннәрне, шул йолдызлы төннәрдә күккә күңелле чаткылар сибеп дөрләп янган учакларны, төнге кошларның чыр-чуын, тынгысыз бытбылдык, тар-тар тавышларын, камышлыкта куркып уянган карт үрдәкнең, балалары өчен борчылып үз алдына сукранып сөйләнүләрен;

арыш ипиенең, чишмә суының, балык шулпасының тәмен;

тын кичләрдә чәй эчкәндә дусты белән серләшүләрен, рәхәт әңгәмәләрен;

Агыйдел маякларын, ак пароходларның мәһабәтлеген, Агыйдел дулкыннарының йомшаклыгын, Агыйдел акчарлакларының бер карасаң әллә кайларга өндәгән дәртле, икенче карасаң онытылган сагышларны искә төшерә торган моңлы җырларын — берсен дә, берсен дә гомер буена оныта алмас инде Айзат! Алар мәңге аның күз алдында булыр, колакларында матур җыр шикелле мәңге яңгырап торыр!..

Август урталары җитте, болыннарда чабылмаган печән калмады, курпы калыккан болыннарга кабат көтүләр керде. Агыйделгә дә «шайтан бармагын тыкты», яңгырлар ешайды. Нариман әле бер елны да печәнне болай күп чаба алмаган идек, быел әнкәй белән малайларга пошынырга сәбәп юк дип, шатланып чираттагы «ялга чыкты». «Эш беткәч уйнарга ярый» дип, Айзатны шәп кенә кунак итте.

Бу авылның егет-кызлары кысан клубта кысылып ятмыйча, һәр көнне кич бер үк сәгатьтә Уфа пароходын каршыларга җыелалар иде. Кызлар, яр өстендәге эскәмияләрдә тезелешеп бер-берсенә «соңгы хәбәрләр» тапшырган арада, егетләр пароход буфетына кереп сыра эчеп чыга. Пароходны озаткач, гармунчылар гармуннарын сыздырып җибәрә, яшел чирәмлектә уен-җыр, биюләр башлана. Парлылар парлары белән кавыша, ялгызлар мәхәббәтләрен эзләп йөри.

Нинди генә уеннар булмый монда! «Куыш» та, «Парыңны тап» та, «Әйлән-бәйлән» дә, такмаклы биюләр дә, «Каеш ташлау»лар да, хәтта сугыш вакытыннан калган мирас — «Ялтыр-йолтыр йолтырыйдыр»лар да, ялгыз һәм парлы биюләр дә, элекке һәм өр-яңа танцалар да. Уң түгел, йөз төрле! Самими, гүзәл, гаүдәгә һәм җанга рәхәт авыл уеннары!

Нариман белән Айзат пароход каршыларга ике кич төштеләр. Яшьләрнең уеннарын сокланып карап тордылар. Гармун чыңнары, егет-кызларның кичке Агыйдел өстен яңгыратып, көчле күкрәк тавышы белән:

Агыйделдән пароход килә,
Эче яшел, тышы күк;
Сагынмаган көннәремнән
Сагынган көннәрем күп.

Уфаларга барыйм әле,
Уфа юлы ачылгач,
Уф йөрәгем димәм әле,
Янулары басылгач,—

дип өздереп җырлаулары, уйламаганда-нитмәгәндә искә төшеп сагындырырга, егетләрнең хәтеренә кереп калды...

## 21

Айзат үз авылына кайтып китте. Чаллы пристаненда, алдан сөйләшү буенча, Нариман килгән пароходка утырды. Алар икесе дә бер каютада бардылар. Пароходта, көз көне очар кошлар төркемнәргә җыелган шикелле, Казанның төрле уку йортларына җыелучы студент халкы бик күп иде. Уен-көлке, җыр, гармун, гитара тавышлары тынмады. Җәй буе саф һавада, иркен кырларда, урман-болыннарда күкрәгенә һәм беләгенә көч җыйган, ял иткән, керәйгән һәм кояшка каралып беткән тик

тормас яшьлек кабат очрашу шатлыгын кичерде. Эч пошарга урын юк иде. Яшьлек барда куңелсез буламени!..

Нариман белән Айзат, иптәшләренең күбесе кебек үк, соңгы төнне бөтенләй йокламадылар, Палубада уткәрделәр. Кама тамагын уткәч тә, күзләрен талдырып, Казан ягына карый башладылар. Пароход Казанга таң алдыннан килеп җитте. Башта бер борылмадан үтүгә, бик еракта горизонттан горизонтка җәелеп, таң шәүләсе шикелле аксыл шәүлә күренде. Вакыт үткән саен якынайды, зурайды, биегәйде. Инде җир өсте генә түгел, күктә балкып яктырды. Җирдәге сихри нурлар сиздерми генә күктәге таң яктысы белән кушыла башлады.

Егетләр бу гүзәллектән күзләрен алмады. Йөрәкләр дулкынланып типте, күп иреннәр даһи Тукайга кушылып пышылдады:

Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан:
И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!

Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.

Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур;
Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур...

Айзатның йөрәге сызлап кысылды. Менә шушы нурларга күмелеп, нурлар ябынып йоклап һәм эшләп яткан моңлы Казанның бер урынында хәзер аның нечкә биле дә йоклый бит. Йоклый, Айзатның өзелеп-өзелеп үзенә карап торуын, минут саен якынаюын сизми һәм белми... Бәлки белергә дә теләмидер. Бәлки йокламыйдыр. Бәлки берәрсе белән таң атуын көтәдер...

Айзатның йөрәге тагын сызылып китте. Дөнья, дөнья! Бер шатлыгың булса, мең хәсрәтең бар. Адәм баласына бер рәхәт бирсәң, ник аңа өстәп мең михнәт бирәсең соң син?.. Айзат башын иде...

Чәчкә Казанда юк иде. Ул, бер айга укудан азат ителеп, Кавказда дәвалана, диделәр.

Октябрь ае керде. Айзат бер кичне соң гына кайтты. Урынына сузылып ятты. Нариман аның янына килде. Каты гына итеп:

— Тагынмы? — дип сорады.

— Тагын,— диде Айзат, аңа карамыйча.

— Нәрсә?

— Ром.

— Ром эчеп РОМ[1] га эләгәсең киләмени, ә?

— Аракы — дару, Нариман дус. Кайчагында ул дарудан да шәп. Аракыны эчмәгән ике генә кеше булган — аның да берсе үлгән, икенчесе тумаган.

— Мин уйнап сөйләшмим, кара аны! Колак төбеңә шундый кундырырмын, көзге бозга суккан шикелле яңгырар. Килгәннән бирле ничәнче мәртәбә шулай кайтасың, беләсеңме?..

— Нишлим соң? Башта шешәсе була, шешәсен башлагач эчәсе була. Ыхх-быхх!..

— Учти, әгәр тагын бу хәл бер кабатланса, үтерәм мин сине, парин. Белеп тор.

— Үтерерсең.

— Айзат, бу хәтле булырга ярамый! Син егет кеше бит. Уян. Ташла шул Чәчкәңне, оныт!

— Мина бәхетсез мәхәббәтемнең газабы да рәхәтлек бирә. Сез аңламыйсыз, аңлый алмыйсыз андый рәхәтне... Кызганам мин сезне.

— Нишләп бәхетсез булсын! Бәлки... күрешерсез әле...

---

[1] РОМ — сүз уйнату. Районное отделение милиции.

— Күрде-ем!..
— Күрдең? Кайчан?
— Күрдем, Нарима-ан, күрде-ем! Бүген.
— Соң? Я, я?
— Дөрес, старшина, соң икән инде. Өстенә джерси пәлтә кигән, кулына бозау хәтле портфель тоткан фән корты белән трамвайда бара иде.
— Чынлапмы?
— Чынлап.
— Һа! Трамвайда кеше күп булыр.
— Юатма. «Вузовец» киносына кереп киттеләр. Чәчкәне култыклап, иелә-иелә колагына нидер сөйләп бара иде... Киңәш бир, Нариман, инде нишләргә? Минем баш баш түгел хәзер — кабак. Уйлый алмый... Аны очрата алмыйм мин хәзер. Нишлим икән? Укуны ташлап китим микән? Әллә теге мужикның авызын җимеримме?
Кулларын артка куеп, Нариман Айзат яныннан китеп барды. Уйланып тәрәзәдән карап торды. Аннары аяк очына килеп утырды.
— Син минем апаның балаларын күрдең бит?
— Күрдем.
— Апа җизнине яшь вакытында бик нык яраткан. Җизни Сахалинга киткәч, аның артыннан эзләп барган. Аңлыйсыңмы? Сахалинга! Мин кыз кеше, килешми, гаеп итәрләр, фәлән-төгән дип тормаган. Җизни ник тагылып йөрисең дип әйтер дип тә курыкмаган. Мәхәббәте шундый көчле булган — җир читенә хәтле эзләп барган, тапкан, кавышкан. Үзенең яраткан кешесен берәүгә дә бирмәгән. Җизни апаны бәхетем дип кутәреп кенә йөрткән. Бөтен Сахалинда алардан тату, алардан матур, алардан шат һәм бәхетле семья булмагандыр. Алар үлгәндә дә бер үк көнне, бер үк сәгатьтә кочаклашып үлгәннәр. Бураннан соң кар астыннан казып чыгарганда, бер-берсен җылытырга теләп, кочаклашып яткан булганнар. Шул килеш күмделәр. Алар хәзер дә каберләрендә кочаклашып яталар.
Айзат торды.
— Нариман, син моны миңа сөйләмәгән идең.
— Җае чыкмагандыр. Их, Айзат, кешедә сөйләнми торган сүзләр азмыни!
— Мин синең батыр апаң алдында башымны иям. Көнләшәм. Мин аның алдында чүп. Җебегән, сволочь мин, Нариман, шулаймы? Сез мине разведкага алмас идегез, әйеме?
— Разведкагамы?.. Белмим.— Нариман Айзатның җилкәсенә кулын куйды.— Син үпкәләмә, без аңа разведка ясадык. Ул егет галим булырга җыена. Хәзер кече фәнни сотрудник.
— Ә?!.
— Әйе, без. Иптәшләрең синең өчен борчылмый дисеңме әллә? Джерси пәлтә Чәчкәләргә барып йөри. Өйләренә. Анысын да ачыкларга туры килде.
— Үзләре сизмәдеме? Хурлыгы ни тора!
— Кайгырма. Чын разведчиклар эшләде. Солдаттан кайткан малайлар.
— Ниндидер чит ил журналында кызыклы рәсемнәр күргән идем. «Көнләшү эволюциясе» дип атала. Беренче рәсем — феодализм чоры. Ире хатынын чит ир белән тоткан да икесен дә чәнчеп үтергән. Икенче рәсем — капитализм чоры. Ире хатынының сөяркәсен генә атып үтергән, хатынын калдырган. Өченче рәсем — империализм вакыты. Ире, тегеләрне тотканнан соң, көндәшенең яңагына кундырган, хатын көлеп тора. Дүртенче рәсем — хәзерге көннәр. Хатын сөяркәсе белән кочаклашкан, ә ире «ничек оялмыйсыз?» дип бер читтә зарый-зарый елап тора.
— Әкәм-төкәм камышка үрмәләп менде дә, ди, түбәнгә карап бик каты гаҗәпләнде, ди. «Һи-и, нинди киң икән бу дөнья, нинди зур икән

бу жир шары!» дип әйтте ди. Шунын кебек син дә бөтен нәрсәне үз биз-мәненә генә салып үлчәмә. Ул бүген генә сиңа шулай тоела. Кәефең яхшыргач фикерең үзгәрер.

— Минем кәеф бер вакытта да яхшырмас кебек, Нариман!

— Ә син егет бул. Күңеленне чебенгә талатма. Онытма: минем апа хатын-кыз, син — егет! Син минемападан да көчлерәк бул!

— Ә Чәчкә мине ялына-ялвара дип уйласа?

— Зыян юк.

— Гарьлек!

— Бәхетне машинага утырып түгел — тезләнеп куалар.

— Анладым, старшина. Рәхмәт!.. Иртәгә!..

— Иртәгә!..

## 22

Икенче көнне, бер кыек килсә гел кыек дигәндәй, Чәчкәләр группасы бистәдәге мәктәпкә практикага китте. Айзат кичкә кадәр аудиториядән аудиториягә кереп селкенеп йөрде. Инде кайтып китим дип җыенгач кына, китапханәдән чыгып килгән Чәчкәне күреп, нишләргә белми шып тукталды. Чәчкәнен түгәрәк йөзе ябыккан, күз төпләре суырылып кергән иде. Кинәт каршысына баскан Айзатны күргәч, аптырап калды. Тук-тады. Бер сүз дә әйтә алмыйча, башын иеп тик торды. Айзат та телдән язган иде.

Көч-хәл белән исән җыеп.

— Исәнме... Чәчкә! — дип әйтә алды.

— Исәнме, Айзат! — диде Чәчкә.

— Чәчкә, синең белән сөйләшәсе сүз бар.

— Яз көне сөйләшеп бетердек инде, Айзат. Иске яраларны кузгат-мыйк.

— Безнең иске әйберебез юк, Чәчкә. Атлыгып Казанга килсәм — син һаман кайтмагансын. Менә кайттың. Ләкин ни файда!

— Мин дә файдасы булмас дип уйлыйм, Айзат... Әйттем инде... Ярый, ашыгам...

— Кая? А...ның янынамы?..

— Ничек? Кем янына?

— Кече фәнни сотрудникгын. Булачак академигын янына сон!

— Ни сөйли торгансыңдыр, аңламыйм.

— Белеп сөйлим, белеп, Чәчкә. Әллә мине бер нәрсә дә күрми дип уйлыйсыңмы?.. И-и-их, Чәчкә-ә!..

— Белсәң белерсең инде, Айзат. Мин нишлим!.. Кешедән яшереп эшли торган эшләрем юк... Ярый, Айзат, үпкәләмә. Хуш, юл бир!

Айзатның йөрәге күкрәк читлеген ватып чыгарга теләгән шикелле ярсып тибәргә тотынды, котырып каны кайный башлады. Гәүдәсе турай-ды, кысык кара күзләре киерелеп ялкын бөркеде. Җәй буе, көз буе аһ-зар түгеп яшәвен искә төшерү, «теге нәрсә»дән көнләшү ачысы, бердән-бер кадерле мәхәббәтен югалтып ялгыз калу куркынычы аны кинәт көч-куәтләндереп җибәрде. Тау ашырлык кыюлык, дингез кичәрлек гайрәт бирде. Ә бу гайрәт аны тәвәккәл адәмгә әйләндерде.

Айзат шул минутта, сизмәстән, гомерендә беренче батырлыгын эш-ләде: егетнең болай кинәт үзгәрүен күреп шүрләбрәк калган Чәчкәне ку-лыннан тимер кыскыч белән кыскандай эләктереп алды да, ай-ваена карамыйча, буш бүлмәгә алып кереп китте. Керүгә үк комсызланып кочаклап алды. Чәчкә башта аптырап тик торды, исенә килгәч тартыша башлады, учларын Айзатның иягенә терәп аның башын артка этте, ычкы-нырга тырышты. Ләкин бу минутта тимер мускуллы куллардан, кыз түгел, арслан үзе дә ычкына алмаган булыр иде.

— Җибәр!.. Кычкырам!..— диде Чәчкә.

— Кычкыр!.. Кычкыр!.. Керсеннәр, күрсеннәр,— диде Айзат, ярсып һәм кайнарланып. Үзе Чәчкәне һаман ныграк кыса барды.— Күрсеннәр. Мин курыкмыйм... Сине ничек сөюемне белсеннәр. Бөтен дөнья белсен! Мин сине сөям! Шашып-шашып сөям. Ник мине акылдан яздырасын син?.. Нинди кичерелмәс гөнаһым булды?.. Сөю гөнаһмы?.. Син сөйләшми башлагач, минем көннәрем җәһәннәмгә әйләнде. Күз сал бу йөрәгемә, ул бит синең утында көеп кара күмергә әйләнде. Ә нинди күнелле иде! Дөньяда бездән бәхетле кеше юк иде. Мин гел шулай булыр диган идем... Нишләдең син, Чәчкә?! Аһ, нишләдең?!. Тукта, тукта, зинһар, бүлдермә!.. Әйтеп бетерим, күңелемдә калмасын... Бәлки... Юк, бәлки түгел... Ә җәй көне мин нинди газапландым, ничек сагындым!.. Башымны кая куярга урын тапмадым. Әллә кайларга алып олагасым килде... Монда килсәм, тагын син юк... Кайткач та гел качып йөрдең... Син уйлама, башыңа да китермә!.. Бирмим мин сине, бирмим мин сине ятларга!.. Мин сине беркемгә дә бирмим!.. Мин сине сөям! Сөям! Сөям!.. Син дә мине сөясең. Мин аны беләм бит, Чәчкә! Мин аны белеп торам бит. Шулай булгач, ник безгә газапланырга?! Ник рәтле генә, сөенә-сөенә рәхәтләнеп йөрмәскә!.. Шулай бит, Чәчкә, әйеме, шулай бит?..

Айзат, сабан туенда чапкан ат шикелле, сулуы кабып калтырый-калтырый кинәт тынып калды.

— Мин менә шуннан... курыккан идем дә инде,— диде чәчкә, өзек-өзек пышылдап.— Качып та йөргән идем... Йөрәгемә ялкын ягар диган идем... Безнең күңелләргә... бер очкын гына кирәк... Гөлт итеп кабына да китә... Мәхәббәт уты... Менә шуннан курыккан идем мин... Сүндерергә теләүчеләрем файдасыз булыр... Әгәр очратсам, аны... йөрәк ялкынын тагын да ныграк дөрләтеп җибәрер диган идем... Мин сине көттем... Килмәсән... үзем килә идем... Ничек түзәсен...

Чәчкә сак кына Айзат кочагыннан чыкты. Аның ике кайнар яңагын ике кайнар учы белән кысып, мәңге хәтерендә калдырырга теләгән сыман текәлеп йөзенә, күзләренә карап торды.

— Җан кисәгем!.. Нинди каралгансың, ябыккансың... Күзләрең генә утырып калган, мескенем!..— диде дә Айзатны кочаклап алды һәм, аның киң күкрәгенә башын салып, җылап җибәрде...

— Айзат!.. Ә... ә... Рем турында...

— Юк, юк!.. Сөйләмә!.. Кирәкми!..

— Тик син... белергә тиеш. Мин бәләкәй чакта безнең өйдә пожар булган. Рем шунда, ут эченә йөгереп кереп, мине күтәреп алып чыккан... Сул беләгем шунда янган иде. Болай... әйбәт төзәлгән үзе. Җөе дә сизелер-сизелмәс кенә тора. Шулай бит? Игътибар белән ныклап карамасаң, бөтенләй күренми бит, әйеме? Беленми бит?..

— Беленми, бөтенләй сизелми,— диде Айзат, аны тынычландырып.— Мескенкәем!..

— Рем Ленинградтан аспирантура бетереп кайтты да... безгә килеп тора башлады... Әтинең шәкерте ул... Мин... Мин... Син...

— Чәчкә! Дәшмә, бүтән дәшмә! Кирәкми!.. Ниләр эшләмәс идем мин синең өчен! Мине күкләргә күтәрдең бүген! Чынлап сөюемә ышандың. Син дә чынлап сөясеңме мине, Чәчкә?

— Әйттем бит...

— Ә син исеме белән әйт, сөям диген!

— Сөям!

— Сөюеңне исбат та итә аласыңмы?

— Ничек, Айзат?

— Әгәр сөюең чын булса, минә кияүгә чык! Бүген үк! Хәзер үк!

— Җүләр, җүлә-әр, Айзат!..

— Мәхәббәт җүләрлегенә акыллылар көнләшә. Мин чынлап әйтәм: бер ычкынаяздың, икенче ычкындырмам. Иртәгә үк язылышабыз!.. Кил әле кил, кер кочагыма, кер!..

— Айзат... кеше күрер...

Алар, куаныч һәм бәхетләреннән исереп, аудиториядә озак утырдылар. Буш залларны соңгы кат күздән кичереп, утларны сүндереп йөрүче дежур апа чыгарга кушкач, кулга-кул тотынышып, өзлексез көлә-көлә тын урамнарның уртасыннан киттеләр.

Айзат тулай торакка җырлый-җырлый кайтып керде. Нариман, аңа карап-карап торды да, шатланып елмайды.

— Я, хәерлеме? — дип сорады.

— Хәерле! — диде Айзат.

Нариман баш бармагын тырпайтып өскә күтәрде:

— Во?

— Во!

## 23

Шушы кичтән соң Айзатның көннәре һәм төннәре тоташ бәйрәмгә әйләнде. Ул моңарчы авыру иде. Авыру батманлап керә, мыскаллап чыга. Ләкин Айзатныкы гадәттәгечә булырга теләмәде: чыгуы да батманлап булды. Бер бәхетле кичтә кисәк кенә морҗадан күтәрелгән төтен шикелле эреде дә бетте. Менә күпме гомер эленке-салынкы йөргән малайның җилкәсе турайды. Кара күзләре тирә-якка тагын текәлеп карый башлады. Тумбочка өстендә китаплар, группа журналында «отл.»лар бик тиз үрчеде. Группа бу үзгәрешне күреп куанды, ниһаять, иркен сулап куйды.

Алар Чәчкә белән һәр көнне диярлек очрашып тордылар. Көндез институтта, анда булмаса лекцияләрдән соң. Инде көз җитеп, кичләрен шактый гына салкын төшүенә дә карамастан, бульварларда, бакчаларда йөрделәр. Көн бозылып яңгыр тамчылый башласа, тын һәм яшел Лядов урамы буйлап Челюскин урамына китәләр иде дә, чаттагы алтынчы китап кибетенә кереп, сәгатьләр буенча рәхәтләнә-рәхәтләнә китап актаралар иде. Кайчакта алар күңелләренә ошаган китапларны да сатып алып чыгалар.

— Үзебезнең китапханә өчен,— ди Айзат, «үзебезнең» сүзенә басым ясап һәм елмаеп кызның күзләренә карый.

— Ай-һай! — ди Чәчкә.— Син бик иртә «үзебезнекели» башладың түгелме әле, егетем? Исеңнән чыгармаска киңәш итәм: без әле сезнең белән... дуслашып йөргән кыз белән егет кенә. Бер пар, бер мәхәббәт кенә. Соңыннан ни булыр бит — алдагысын алла белә диләрме әле?..

— Әллә кайдагы — җиде кат күк өстендәге картаеп беткән алла моны кайдан белсен. Аны мин беләм, сеңелкәш. Менә мондагы — җирдәге абзаң. Саф мәхәббәтнең соңы, әлбәттә — ЗАГС! Бер даһи математик әйткән ди бит:

— Өйләнү — кушу,
Үлү — кимету,
Гыйшык — тапкырлау,
Калган малны бүлү — бөлү!..

Шуның шикелле, без әлегә гыйшык — тапкырлаулар булсак та, якын көннәрдә өйләнү — кушу булмабызмыни? Кушылгач бар нәрсә дә «үзебезнеке» була инде, парень. Аннан соң «ат алсаң, арба кирәк, хатын алсаң, бар да кирәк» дигән сүзләрне дә онытмыйк әле без синең белән. Китабы да кирәк, хәтта иң кирәк әйбер...

Бу фани дөньяның, әлбәттә, сәер генә законнары бар. Хыяллар бер нәрсә булса, чынбарлык дигән икенче аяусызрак нәрсә аңа һич тәкәллефләнеп-нитеп тормыйча, итагатьсезлеккә дә санамыйча, үзенең төзәтмәләрен кертә тора. Тукта, иптәш, сина язганны башка берәү күрмәс, маңгаеңа язылган язмышны тир белән сыпырып төшереп булмый, менә, минемчә, чак кына болайрак итеп карыйк әле, ничек булыр икән ди. Ә бу «ничек булыр икән?» гадәттә, ике генә төрле була: яхшы хыялларың яманга әйләнә, яманың — яхшыга. Әмма Айзат бәхетлеләр исәбенә эләкте.

Бу болай булды. Бер көнне кич арып-талып комсомол җыелышыннан кайткан чакта аңа Равил очрады. Күзләк пыялаларын сөртә-сөртә, авызын ерып:

— Ай-һай-һай, министр булгандыр бу, ә! Министрдыр бу, югыйсә кунагын шул тикле көттермәс иде,— диде.

— Кем көтә?

— Кем белгән аны. Яшь кенә егет. Минем шикелле күзлекле, минем шикелле солидный вә чибәр.

— Тукта әле, «ученый». Сүзең сүзгә ошамый, авызың сүздән бушамый. Лыгыр-лыгыр, лыгыр-лыгыр. Кайчаннан бирле көтә? Кайдан килгән?

Равил үпкәләде.

— Һә-әй, миңа димәгәе, Казаннан түгел, Мәскәвеннән килсен шунда! Миңа килгән кешеме, минем ни эшем бар! — диде дә лыштыр-лыштыр китеп барды.

Кем булыр икән дип аптырап кайтып кергәндә, сигезенче бүлмә каршысында калын портфелен тоткан, соңгы мода белән киенгән зур күзлекле бер ят егет арлы-бирле йөреп тора иде. Ул озын буйлы, бик чиста йөзле. Айзат белән бер яшьләр тирәсендәге конгырт чәчле кеше иде.

— Исәнмесез! — диде Айзат.— Сез мине көтмисездер бит?

Егет аңа туп-туры карап берничә секунд сүзсез торгач:

— Сез Сәетбатталов Айзатмы? — дип сорады.

— Әйе. Нәкъ үзе.

— Мин бик шат! Ул чагында танышыйк: мин Рем булам, фамилиям Абдулов.

— Әйдәгез, бүлмәгә рәхим итегез, Рем иптәш!

Бүлмәгә керделәр. Анда, бәхетләренә каршы, берәү дә юк иде. «Менә син нинди икәнсең, туган, дип уйлады Айзат, төшеп калганнарга охшамагансың. Хәер, Чәчкә андыйлар белән сөйләшеп тә тормас иде».

Рем да аңа сөзеп-сөзеп карап алды. Аннары:

— Белмәгән-күрмәгән кеше янына кинәт кенә килеп чыгуым сезгә гаҗәп тоеламы? — дип сорады.

— Гаҗәп түгел,— диде Айзат.— Мин сезне ишетеп белә идем. Чәчкә сөйләде.

— Әйе. Чәчкә миңа да сөйләде... сезнең хакта,— диде Рем, маңгаен ышкый-ышкый һәм кинәт Айзатның күзләренә туп-туры карап, калтыравыклы тавыш белән сорады:

— Сез аны яратасызмы?

— Мин сөйгән кызымны яратуым-яратмавым хакында теләсә кемгә сөйләп йөрергә гадәтләнмәгән.

— Институтны тәмамлагач сезне кая җибәрәләр, билгелеме?

— Билгесез. Кая җибәрсәләр, шунда китәчәкмен.

— Ә Чәчкәне уйладыгызмы? Яшь хатынга,— ул сезнең хатыныгыз булырга ризалыгын биргән очракта дип әйтәм,— коры мәхәббәт кенә җитми бит, аңа яшәргә дә кирәк. Ә Чәчкә — шәһәр кызы, интеллигент кызы. Ул Казаннан башка тормышны күз алдына да китерә алмый. Аның хәзерге романтикасы вакытлы гына, ул бетәчәк.

— Дөрес, Казан иле — гөлбостан. Әмма Советлар Союзы Казан белән генә бетми. Миңа аның һәрбер урыны Казаным шикелле кадерле түгелмени?

— Зинһар, дөрес аңлагыз, мин туган ил кадерләме-түгелме дип бәхәсләшмим. Ләкин Чәчкә музыка сөя. Авыл җирендә ул музыкадан мәхрүм булмасмы? Шуны уйлагыз. Яраткан кешеңне кадерле әйберләреннән аеру — эгоистлык. Мин шулай аңлыйм.

— Карагыз әле, иптәш Абдулов, сез миңа лекция укырга килдегезме әллә? Алай булса, юкка тырышасыз, миңа аны биш ел буе көн саен укыйлар. Бүген дә өчне укыдылар. Мин ардым, бәлки бүгенгә җитәр?

— Кичерегез! Әйтергә теләгәннәремне дә әйтә алмас булып калдым.

— Ник килдегез?

— Чәчкә Казанда калырга тиеш!

— Анысын Чәчкә үзе хәл итәр. Сезгә үзе әйтер. Бәлки әйткәндер дә инде.

— Беләсезме... Ул... кызга мин дә тыныч карый алмыйм.

— Ышанам.

— Сез аннан баш тартырга тиеш!

— Ә ни өчен — мин? Ник, мәсәлән, сез түгел?

— Без Чәчкә белән бер фикер кешеләре. Тормышка мөнәсәбәтебез дә бер. Уртак тел таба алабыз.

— Без аны таптык инде. Бу сөйләшү чыннан да туйдырды. Бәлки ул кызны акча чөеп кенә бүләрбез, ә?

— Шаяртмагыз. Мин көрәшәчәкмен. Ник көләсез?

— Бер дустымның батыр йөрәкле апасы исемә төште. Ул мәхәббәте өчен Сахалинга кадәр барган. Аңлыйсызмы — ул бит хатын-кыз. Ә мин — ир кеше. Шуңа куанып көләм. Мин мәхәббәтем өчен җәһәннәмнең иң түренә кадәр барып җитә алам.

— Карап карарбыз. Уңышлар телим.

— Ә мин сезнең моннан тизрәк чыгып сызуыгызны телим, иптәш академик. Кул да кычыта башлады: күптән бер кемне дә кыйнаган юк.

— Иа алла! Мондыйлар белән ничек сөйләшеп йөри ала ул!

— Ха!.. Бәхетегез әле: бу бүлмәдәге иң культуралы малайга эләктегез... Бүтән егетләр булса... Ишекне ныклабрак ябыгыз!

— Безнең юллар кисешәчәк әле!

— Мин аларның кисешү түгел — очрашуларын да теләмим!

— Сакланыгыз — мин перчатканы ташладым!

— Ташласагыз, икесен дә ташлавыгызны үтенәм: бияләем юк.

Рем белән батыр кыланып, ирәеп сөйләшсә дә, ул чыгып киткәч, Айзат уйга калды. Пошамагга төште. Рем Абдулов җибәргән егетләргә охшамый. Көрәш җиңел булмас. Чәчкәне янгыннан алып чыгуы турында ләм-мим әйтмәве Айзатка ошады. Бер төрле бәндә шуны төп сылтау итеп алыр һәм Чәчкәгә күбрәк хаклы икәнлеген дәлилләргә омтылыр иде. Юк, алай итмәде. Чәчкәне сөюе дә хактыр. Сөймәсә болай йөрмәс. Һәрхәлдә, сак булырга кирәк. Нидер уйларга, Нариман белән киңәшергә. Уен түгел бу, түгел! Җаның уртак булса да, ярың уртак булмасын!..

Нариман кайтты. Айзат аңа хәлләрне сөйләп бирде. Нишләргә инде хәзер? дип сорады.

— Күңелле эш түгел,— диде Нариман.

— Күңелле эш булса, киңәшеп тә тормас идем.

— Менә монысын хак әйттең, молодец! Киңәш иткән — ким булмый. Ләкин хәзер мин сиңа бер нәрсә дә әйтмим. Үзең нишләр идең? Уйла. Ярты сәгать вакыт бирәм. Шуннан сөйләшербез.

Ярты сәгать үткәч, ул Нариман янына килде.

— Ну? Нәфис башыгызда нинди планнар туды?

— Мин өйләнәм, Нариман.

— Вакыты җиткәч, барыбыз да өйләнәбез. Кайчан?

— Чәчкә риза булса, быел ук, хәзер ук. Нигә уку беткәнне көтәргә?

Күп кешеләр шулай итәләр ич. Кичә дә әнә физмат малае белән географ кызы дөбердәтеп туй итеп яталар иде.

— Үзен бакыр булсаң да, акылың алтын икән. Тагын бер кат молодец! Мин дә моны хуплыйм. Икегез дә өлгергәнсез, пешеп җиткәнсез. Риза икәнсез, бер-берегезне яратасыз икән — ник сузарга? Эшкә җибәргәндә дә әйбәт — аеры-чаеры китермиләр.

— Ай-һай, Нариман! Бик зур эш бит бу уйлаган. Гомер юлым үзгәрү дигән сүз!

— Синеке генә түгел — Чәчкәнеке дә. Икенче якны да онытма: Чәчкә кайда йөри икән хәзер, теге нәрсә белән түгел микән дип аптырап ятмыйсың — Чәчкә үз кочагыңда була.

— Ай, анысы да бар икән әле. Өйләнәм, өйләнәм!

— Ха-ха-ха! Аннан соң да Чәчкә янында пәйда булса, эшләре херт теге портфельнең.

Айзатның күзенә йокы кермәде. Мең төрле уйларының яхшылары да, яманнары да бар иде. Өйләнү кадәр олы эш юк. Өйләнү дигән зур эш — җаныңа мәхәббәт, башыңа бурыч. Әйе, зур бурычлар алырга тора башыңа Айзат, зур бурычлар! Гомерлеккә, мәңгегә! Ярый ла бәхетле булсалар, уңсалар? Ә уңмасалар? Бер айлык шатлык, гомерлек кайгы булса?.. Чәчкәне яхшы беләме соң ул? Өйләнер булсаң, күзеңә ышанма, колагыңа ышан, диләр бит. Белә кебек инде. Чәчкә — тыйнак, акыллы кыз. Ул да өлгергән. Энә өстендә биегән чагы. Риза булырга тиеш. Яратса, билгеле. Ярата кебек. Үзе әйтеп тора. Яратмаса, тегенең белән һаман очрашып йөрер иде... Хәер, кызлар күңеле — караңгы төн, томанлы көн... Их, шайтан. Баш ватмыйча булмый шул. «Ярап торыр»га гына алмыйлар шул кәләшне — гомер итәр өчен алалар.

Ә Чәчкәнең әнисе-әтисе ни әйтер? Айзатның үз әти-әнисе? Фатиха бирерләрме? Ашыкма, кабаланма, берәр ел укыт, өс-башыңны бөтәйт димәсләрме?

*Ахыры бар.*

## Зыя Мансур

# ЧЫКЛЫ ИРТӘ

*Шигъри роман... шагыйрьдән зур осталык, күп еллык тәҗрибә сорый торган гаять авыр жанр. Татар совет поэзиясендә, шигъри романда кайбер шагыйрьләр көч сынап карадылар. Заманында каләмдәшебез шагыйрь Зыя Мансур да «Чыклы иртә» исемле романын язды. Әсәрнең беренче вариантын ул шагыйрьләр секциясенә тикшерүгә куйды. Зыя Мансур зур күләмле бу әсәрен төзәтте, яңадан эшләде. Әмма ул аны матбугатка бирмәде. Иҗатына таләпчән караган Зыя Мансур үз романыннан канәгать түгел иде.*

*Шигъри романда Зыя Мансур Бөек Ватан сугышы чорындагы яшьләрнең батырлыгын, утта-яуда сыналган дуслыгын, мәхәббәтен җырлауны максат итеп куйган. Әгәр дә шагыйрь исән булса, әлбәттә, иҗат планын ахырына кадәр җиткергән булыр иде. Түбәндә шул әсәрдән өзекләр тәкъдим ителә.*

### Өч почмаклы хат килде

Өч почмаклы хат килде,
Ерак җирдән язылган.
«Сәлам сиңа, кадерлем,—
Дигән башлап Галимҗан,—

Язам, дигән, урманда,
Язар сүзем күп,— дигән,
Яза алмыйм барын да,
Көтә белеп көт»,— дигән.

Азакта күп нокталар,
Димәк, сүзләр бетмәгән.
Димәк, шушы җылы хат
Ашык-пошык бикләнгән.

Үзе кыска булса да,
Мәгънәсе бик зур аның.
Аннан, уйлап карагыз
Нинди юллар узганын.

Салынган ул Казанга
Ерак Киев ягыннан.
Ә Казанда аңарга
Яңа адрес язылган.

Узган, узган юлда хат
Этапларны тагын да.
Алды аны Гөлзада
Бүген Орел янында.

Туган якның кырлары
Уздылар күз алдыннан,
Аларны да язган шул
Үз хатында Галимҗан.

Әй, туган җир, туган җир,
Сулыш биргән җирем син,
Тирбәлдергән бишегем,
Тормыш корган җирем син.

Телем ачылган урын,
Әткәм, әнкәм үскән җир.
Бәхет булып кешегә
Алмаларың пешкән җир.

Снарядлар ярылганда
Тирә-якта гөрселдәп,
Яра бәйли Гөлзада
Үзәннәрнең берсендә.

Аның йомшак куллары
Кагылганда солдатка
Кирәк түгел шикелле
Санчасте дә, санбат та.

Ни өчендер югала
Сызлаулары яраның.
Гашыйк булма син, егет,
Сөйгән яры бар аның.

## Әй, туган җир, туган җир!

Партизаннар янына
Килде бүген артистлар.
«Ватан турында җыр»ны
Тыңлый безнең шат дуслар.

Кем утырган, кем баскан,
Кем агачка сөялгән.
Һәркемнең күз карашы
Җырчы кызга төбәлгән.

Җырлый чибәр җырчы кыз,
Башкаладан килгән ул.
Тар билле, киң итәкле,
Ак күлмәген кигән ул.

Киң итәге күлмәкнең
Тигән яшел чирәмгә.
Кемнәр, ниләр уйламый
Бүген аны күргәндә!

Тыңлый безнең Галечка,
Җыр тибрәтә хисләрне.
Уйлый илен Галечка,
Тыныч көнне, кичләрне.

Кичә урман шаулаган
Тын гына бер урында —
Бүген шәһәр балкыган
Могжизалар жире син;

Айкап котып бозларын,
Зур «Челюскин» узганда
Ак аюлар аптырап
Карап торган жирем син;

Мәңгелек яз тугачтан
Чын бәхетле көн күргән,
Гомерлеккә дуслашкан
Шат халыклар жире син;

Әйе, туган жир, туган жир,
Тормыш корган жирем син,
Дөньяда һич нәрсәгә
Алмаштырмас жирем син;

Синең тинсез яменне
Тели дошман бозарга,
Сулышыннын кинлеген
Хыяллана буарга.

Әй, туган жир, туган жир,
Хур булырлык жирме син,
Җиңәрлек көч кая ул
Синең халкың сөңгесен!..»

Ак сакаллы партизан
Яшел имән янында.
Туган жир шул, туган жир
Күңелендә аның да.

«Әй, туган жир, кояш та,
Йолдызлар да бар иде,
Чиләкләр аскан кызлы
Тулган ай да бар иде.

Һәр нәрсәне күрерлек
Күзебез дә бар иде,
Рәхәтләнеп сөйләрлек
Телебез дә бар иде.

Ләкин аннан ни файда,
Эчендә ут уйнагач,
Рәхәтләнеп суларлык
Азатлыгың булмагач.

Чиновниклар, түрәләр
Төрле яктан кыстылар.
Төрмәләргә яптылар,
Авыз ачсаң — астылар.

Әй, туган жир, ул чакны
Онытырга мөмкинме,
Безгә кабат килүен
Теләр дошман шул көннен.

Әй, туган жир, туган жир,
Хур булырлык жирме син!
Жиңәрлек көч кая ул
Синең халкың сөңгесен!»

## Кеше көлә үлемнән

Үлем белән кешенең
Көрәшүе турында
Әкият йөри, күчә ул
Буыннардан буынга.

Халык аны һәркайда
Сөйли үзе белгәнчә.
Үзгәртә дә, яңарта
Үзе кирәк дигәнчә.

Горькийның да жыры бар:
«Үлем һәм кыз» диелгән.
Кайда гына карама,
Кеше көлә үлемнән.

Нинди әкият булса да,
Нинди жырда булса да,
Горурланып, масаеп
Башта үлем сүз ала.

Оялу юк аңарда:
«Мин — синен үлем,— ди ул,—
Вакыт житте, әзерлән,
Алырга килдем»,— ди ул.

Ә кешеләр гадәттә
Күрсәтәләр каршылык,
Беркемнең дә китәсе
Килми жирдән ашыгып.

Әле: «Бу эш бар»,— диләр,
Әле: «Теге эш»,— диләр.
Кулына ач үлемнең
Жиңел генә төшмиләр.

Тагын вакыт сорыйлар
Үлемнән аз булса да.
Киләп сарып кылый күз,
Өй артында юл сала.

Килә һаман куркусыз,
Ничә тапкыр килсә дә,
Салкын кулы белән ул
Кешеләргә кизәнә.

Тыңла хәзер, укучым,
Бүген сугыш кырында
Каһәрләнгән үлемнең
Ни күрүе турында:

Яшь бер солдат алдына
Килеп баса карт үлем.
— Вакыт житте, әзерлән,
Сине алырга килдем.

Житәр инде, күп көлдең.
Курка-нитә белмисең,
Ахры, мине бөтенләй
Хур итәргә телисең.

Менә хәзер нинди зур
Эш алгансың өстеңә.
— Теләп алдым! — ди егет,
Һәм курыкмыйм һич кенә!

— Әйт алайса,— ди үлем,—
Миннән нәрсә телисең?
— Юк, теләмим, ал мине,
Син бит ике килмисең!

Күз алдына китерә
Егет туган якларын,
Шаулы ВУЗда, шәһәрдә
Укып йөргән чакларын.

Күз алдына бастылар
Туган жирнең таулары,
Дулкынланды киң кырлар,
Зур урманнар шаулады.

Сөйгән кызын, сеңелесен,
Тыныч, якты өйләрне
Кыска гына сүзендә
Егет зурлап сөйләде.

— Шулар өчен китәм мин,
Әгәр килгәнсең икән.
Каһәрлим сине, ләкин
Һич тә шикләнми китәм!

Өченче көн кич кенә
Алган партбилетын да
Бармак битләре белән
Барлады егет шунда.

Гранатасын капшады,
Һәм тамак кырды егет.
Серле карады үлем:
«Бу нишли?» — дигән кебек.

Чигенеп куйды аннан,
Карады ян-тирәсен.
Уйлады ул эченнән:
«Ул-бу»,— була күрмәсен...

— Мин әзер! — диде егет,
Гранатасын алды да
Бәрде аны күтәреп
Үлем һәм үз алдына.

Яндырып үтте ялкын
Кыю егет кукрәген.
Ишетте җир шул вакыт
Көчле «ура» кукрәвен.

Йөгерделәр секундлар,
Минутлар узды талгын.
Маңгаенда жылы кул
Сизде егет шул чагын.

Ачты коңгырт күзләрен;
Үлемнең юк эзе дә.
Яшь, чибәр кыз елмая
Карап егет күзенә.

Бәйли дусның ярасын
Тончыккан ДОТ янында.
Үлем тончыккан, димәк,
Батыр егет алдында.

— Мин... исән...— диде егет.
— Син исән, Вася, исән!
Куркыныч түгел яраң,
Сафка басарсың тиздән.

Рәхмәт, Вася, куркуның
Ни икәнен белмәдең.
Күрсәттең син эш белән
Коммунистлык үрнәген!

## Даның үлмәс, батырым

Ямьле Идел буйлары
Ямьледер бик һаман да,
Тиздән, тиздән кайтыр кыз
Туган-үскән Казанга.

Каршы алыр әнисе,
Каршы алыр дуслары,
Каршы алыр олылап
Аны иптәш кызлары.

Кыз йөзендә кушылган
Елмаю да житдилек.
Кайгысы да бар аның,
Кечкенәдән түгел бик.

Син юк бүген, Галимҗан,
Бөек җиңү көнендә,
Шуның өчен кайгы бар
Гөлзаданың күнелендә.

Син дәшмисең, Галимҗан,
Тыныч йокла, кадерлем,
Гөлләр белән бизәлсен
Гади солдат каберең.

Бар көчеңне, дәртеңне,
Омтылышын җаныңның,
Хәтта соңгы тамчысын
Ташып торган каныңның,

Туган илнең намусы,
Даны өчен бирдең син,
Тынды авыр көрәштә
Кайнар йөрәк тибешең.

Һәлак булдың ил өчен,
Даның үлмәс, батырым,
Илнең кулы күмсә дә,
Күңеле күммәс, батырым.

Тыныч көннәр агылыр,
Айлар, еллар үтәрләр,
Гөлләр белән бизәлер
Бакчаларда түтәлләр.

Алмагачлар сыгылыр
Алмалары пешкәндә,
Кара-комда пальмалар
Шаулар җилләр искәндә.

Мең йолдызын кабызып,
ГЭСлар балкый суларда.
Авыллар да шәһәрләр
Шаулар тыныч елларда!

Ә Гөлзада нишләр соң?
Бер генәсе иде бит,
Хыялында, уенда
Гел син генә идең бит.

Һаман да гел син генә
Хыялында, уенда.
Әле дә бит ул сине
Уйлый Эльба буенда.

Рәшит Зыятдинов

# БЕР ТЕЛЕМ ИКМӘК

хикәя

Мин тәрәзәдән ишек алдына карап торам. Кинәт абзар почмагында, кычыткanлыкта посып яткан җил йөгереп чыкты да ишек алды уртасында бөтерелергә тотынды. Салам-солам, чүп-чарларны, ишек алдында яткан бөтендөнья картасы ертыкларын ияртеп күтәрелде, үсте, аннан әкрен генә авышып күздән югалды.

— Әти, карале, әти, кара, пәри туе!

— Пәри туе шул әле, улым, дөнья да бер дә аннан ким түгел,— әти тәрәзәгә карамый, ул чабатасы астына тире почкагы тегеп маташа.

Әти, чыгып китәр алдыннан, ишек тоткасына тотынган килеш тукталып кала. Кашларын җыерып идәнгә төбәлеп тора да әйтеп сала:

— Анасы, ишетәсеңме, син хәтерлерәк, тор әле, җәме.

Әни кече яктан башын тыгып сүзсез генә аңа төбәлә.

— Ни дип әйтүем, сәхәриең-мазарың...

— Әллә хәбәр-хәтәр бармы? — ди әни, сагаеп.

— Әлегә юк югын, булыр инде ул, анасы.

— Юкны сөйләмә, Мисбах, олыгаеп беткәч...

— Олыгаеп дип... Чүтеки мин әйткәннәрне хәтерлә, ярыймы? Әнә сәвиттә Мәхмүтнең язуы ята, ди. Әлегә семьясына әйтмәгәннәр.

— Ярабби! Биш баласы... Ярабби.

Карт солдатның сизгер күңеле ялгышмаган икән: әтигә дә сугышка китәргә повестка биреп киттеләр.

Бәйрәм кичләрдәгечә өйдә куыклы ике лампа яна, өй тутырып шулпа исе, май исе, тагы әллә нинди борынны кытыклый торган исләр чыккан. Бер карагандa, әти гел дә иртәгә фронтка китәсе кеше кебек түгел. Лампа турысынарак утырып китап укый ул. Кәефле янсә тантаналы минутларда гына ала ул шушы китабын.

— Сиңайтәм, карале, анасы, тучны язган бит Фурманов абзагыз. Менә без нәкъ шушында окруженниедән чыккан идек, тучны! — дип бармагы белән китап битенә төртеп күрсәтә.

Әни, әлбәттә, мең тапкыр ишеткәндер инде бу турыда, алай да ул, эшен ташлап кече яктан чыга да, эти янына килеп утыра, тәүге мәртәбә ишеткәндәй итеп:

— Алаймы, кара син, әй,— дигән була.

— Ай, гайрәтле кеше дә иде Чапаев, гайрәтле иде... Бу китапны мин кайтканчы саклыйсы булыгыз, ишеттеңме шар баш,— ди миңа эти.

Икенче көнне, мин уянганда, эти белән әни әллә кайчан торганнар, юл хәстәрләрен әзерләп, төйнәп куйганнар, уңайсыз киеренкелектән бушану өчен генә булса кирәк, юк эшне бар итеп мәшәкать табып йөриләр. Туган-тумача, таныш-белеш саубуллашырга кереп-чыгып йөри. Өстәл өстендә утырган чиректе шешәдән яртышар стакан салып алалар да:

— Я, ярый, юлың уң булсын, Мисбах, җиңеп кайтыгыз, исән кайтыгыз,— дип, гади генә сүзгә җитдилек белән олы мәгънә салып саубуллашалар.

Капка янына ат килеп туктады.

— Җә, анасы, хәвефсез яшәгез, ә син, шар баш, мин кайтканчы гармун уйнарга өйрәнеп куй,— бусы миңа әйтелгәне. Мин, әлбәттә, сүз дәшәрдәй дәрәҗәдән узган, кипшенеп киткән авыздагы юк төкерекне йотып, этинең күзләренә мөлдерәп карыйм да башымны гына кагам.

Әле мичтән генә чыгарган кайнар бодай күмәченнән әни каерып бер зур телем кисеп алды да, тастымалга төреп, шүрлеккә куйды, калган икмәкне этинең капчыгына тыкты.

— Үзең чәчеп үстергән ризык тартыр, иншалла, әйләнеп кайтырсың, Мисбах.

— Әбәзәтелни кайтабыз! Таза яшәгез. Киттек.

Киттеләр. Яшьләр кебек гармуннар уйнап җырлашу да, һава ярып сызгырып җибәрүләр дә булмады. Басуга гына кузгалгандай, ипле, эшлекле генә сөйләшә-сөйләшә китеп бардылар. Әни яулык очы белән күзләрен сөртә-сөртә пышылдап калды.

— Ярабби, кайтырга гына язсын инде...

Әни миңа сәер генә карап торды да, күңелсез генә елмаеп, башымны сыйпагандай итте:

— Менә егет булып килә инде минем улым да, түлке никтер бетеренеп, өшәнеп киттең әле бераз, улым, әллә берәр тавыкны Хәйрулла бабаңнан суйдырып чыгыйммы?

Өшәнерсең дә шул. Эти киткәннән бирле ни кадәр гомер үтте. Ә сугыш һаман туктар кебек түгел әле. Этидән калган икмәк-мазар әллә кайчан бетте. Үләнгә, черек бәрәңге кәлҗемәсенә килеп терәлдек. Өзелеп ашыйсы килгән чакларда тастымалга төргән шүрлектәге икмәк кисәген сүтеп карыйм. Ул, билгеле, сөхәринең сөхәриенә әверелгән. Җипжиңел. Эх, кырыеннан чеметем генә кетердәтеп бер тешләп аласы иде. Аласы иде дә бит... Әни әйтүенчә, шул икмәк кисәге этине кайтарырга тиеш. Ашасаң, ризыгы өзелә, имеш. Киредән төреп куям. Һич югында, күрше малае Мәлик белән учак көленә суган, я бәрәңге күмеп ашыйбыз. Ифрат шәп чыга үзе. Мәликләр тагын да авыррак яшиләр шул. Аларның гаиләсе зур, җитмәсә барысы да вак, җылак, кап-корсак халык Мәликләрдә.

Бөкре Хәйрулла бабай хат китерә. «Исән-сау сугышабыз»,— дип яза эти. Гарәп хәрефләре белән язганга, хатны әни генә укый. Укыйукый да, кәгазьгә карамыйча минем өчен укый:

— Улым үскәндер инде, әнисенә ярдәм итә торгандыр, сүзен тыңлыйдыр, өс-башын саклап кия булыр, малларны карашадыр...

Әлбәттә, мин «эти наказларын» үтәргә тырышам, мал асларын тазартып чыгарам, салам түшәгәч, үзем ятып тәгәрәп карыйм — катыкоты оершалар булса, шундук сизәсең. Мәлик уйлап тапты инде бу

хәйләне. Үзләренең мал-туары булмагач, миңа булыша торган иде ул, мал ярата иде Мәлик.

Әни табакка бәрәңге тутырып бирә дә, «кеше ишетмәсен» дигәндәй, шыпырт кына:

— Бар, улым, Мәликләргә кертеп бир,— ди.

— Бәй, аның өстен ник чүпрәк белән каплап торырга, пешмәгән бәрәңге ич бу,— дип тарткалашам.

— Бар, бар, улым, кеше-кара күрмәсен, кимсеткән кебек булмасын, «кирәкми» дисәләр, мал карашкан өчен әни үзе бирде диярсең.

Әйе, Мәликләрнең эше хөрти иде шул. Энгер-менгер вакыты житеп, әз генә караңгы иңә башлауга, Мәлик күзен бәйләгән шикелле берни шәйли алмый, бөтенләй сукырга әйләнә. Тавык күзе була, имеш, ашау житмәүдән, витамин юклыктан була, имеш, ул каһәр тавык күзе.

Без урамда «чабата базары» уйный идек. Үтеп барышлый Хәйрулла бабай мине бармагы белән генә чакырып китерде дә:

— Улым, әйдәле минем белән, бәк ручный йомышым бар,— диде. Уенны ташлап китүе, әлбәттә, күңелле эш түгел түгелен, инде Хәйрулла бабай булып Хәйрулла бабай дәшкәч, хәтта борынны чөебрәк ияреп киттем. Башта бу миңа бер ярка пүлән хәтле сары нәрсә тоттырды:

— Ашарга ярый ул, улым — шул килештән дә, пешерсәң дә була. Соя түбе ул, маен чыгаргач шунысы кала инде.

Мин җәлт борылып «чабата базарына» сыптырырга дип кузгалуга, ул минем җиңнән чеметеп туктатты да, көрсенеп, уфылдап куйды:

— Туктале, улым, утыр әле. Син хәзер егет инде, өегездә бердәнбер ир кеше, менә шундый хәтәр хәбәр бар бит... Ул тагы беравык дәшми торды, мин, суярга еккан яшь малдай, тетрәнеп куйдым.

— Әниеңә әлегә әйтми торыйк әле, улым. Бу язуны әйбәтләп кенә җыеп куй, бер кирәге чыгар аның. Бәлки ялгыш кына... Сугыш бит, ниндәен хәлләр генә булмый сугышта. Дүрткә бөкләгән язуны укып карарга хәлем дә, кыюлыгым да җитмәде, тишек кесәдән бишмәт чабуына төшереп җибәрдем. Капканы чыгып барганда Хәйрулла бабай дәшеп туктатты да онытылып калган әлеге сары түпне култык астыма кыстырып җибәрде.

— Әниеңә әйтми тор әле, улым, бәлки... Янә хәбәре килеп куймасмы.

Әзмәвердәй гәүдәле, турыга керсә ишеккә сыймас киң җилкәле әти урынына чабуда дүрткә бөкләнгән кәгазь кисәге. Белмим, ни өчендер, мин җылый алмадым. Мунча артына чыгып утырдым. Бөтен галәм шул ук та кебек, түгел дә кебек миңа: каршыда соры әтәч тибенеп йөри. Фәйзерахман абзый малайлары бәрәңге китмәнли.

Әнинең: «Кайда югалдың, Илгиз, бар, казан астына ягарлык чатыр алып кайт әрәмәдән»,— дигән тавышын ишеткәнче исәнгерәп утырдым.

Шулай көннәр үтә торды. Әни хат килмәгәнгә борчыла. Китап ачтырып, фал салдырып карый, минем белән киңәшә:

— Плингә-мазарга эләкте микән инде, бичара,— ди. «Үлгәндер» дип, бер генә мәртәбә дә шикләнеп юраганын ишетмәдем мин әнинең.

— Кәгазе юктыр, хат язарга вакыт эләкмидер, бер дә туктап тормыйча, гел сугышып кына йөриләрдер,— дигән булам. Башкача ышандырырлык, юатырлык берни дә уйлап чыгара алмыйм.

— Ят инде, улым, иртә торасың бар.

Түн астына кереп җылынырга да өлгермәдем, Мәлик әнисе килеп керде. Ул яшьләрен дә сөртмичә, тавышсыз гына җылый. Мичкә килеп сөялде дә үз алдына гына караган килеш әнигә дәште:

— Оят инде, бик оят та бит, Миңжамал, ни хәлләр итмәк кирәк. Олы малаем чирләп егылды. Саташып ята, наным. Берәр стакан сөтең булмасмы дип кергән идем.

Икенче көнне дә әни Мәликкә бер стакан сөт кертергә кушып китте. Сөтле чынаякны тоткан килеш, үзем дә аңыштырмыйча, никтер мин бераз тукталып тордым. Аннан чүпрәккә төрелгән икмәк телемен тиз-тиз куеныма яшердем дә Мәликләргә юнәлдем.

Мәлик мине күрүгә елмайгандай итте.

— Баш әйләнә бит әле, малай, балыкка да төшеп булмады инде.

— Әй, балыгы булса икән, бармак буе җылан балыгы өчен пычранып йөрисе юк,— дип юаткан булдым.— Менә сөт эчеп җибәр әле, малай, бусын сөткә манып аша,— дип, куеннан олы ап-ак телемне сөйрәп чыгардым. Мәлик читкә карый. Кул аркасы белән кинәт җебеп, юешләнеп киткән борынын сөртә:

— Анысы кирәкми, әтиең кайтмас, кирәкми анысы.

— Юкны сөйләшмә, карчыклар юравына ышанмыйм мин,— дим.

Әни мескен ачулана да алмый. Ул югалган, әрнегән бер кыяфәттә, икмәк телемен төргән тастымалны тотып миңа текәлгән:

— Әй, улым, улым! Кешеләр түзгәнне түзгән булыр идек әле. Әтиеннең өлешен...

Ни әйтергә дә белмим мин. Әллә кайдан, бик тирәннән дулкын-дулкын булып нидер күтәрелә, күзләремне томалый, күпме вакыт бәгыремдә җыелып килгән хәсрәтем күз яше булып актарылып ташып чыга. Мин чабуымнан кәгазь битен алып әнигә сузам да ирләр авазы белән үкереп үк җылап җибәрәм. Минем тавыш та түгел бу, ят бер кеше тавышы кебек, әмма минем тавыш та ул...

## Рифгать Закиров

### Сагынып...

Бер сагыш тоямын да,
Бар эшне куямын да,
Үткәннәргә кире кайтып
Йөримен... хыялымда.

Һәм шуны күрәм ачык:
Син һаман вак-вак басып,
Ак чәчәкләр арасыннан
Барасың еракташып.

Әгәр бер киткән юлдан
Кайтмасын белгән булсам,
Сине мәңге саклар идем,
Җибәрмәс идем кулдан!

Тик ул чак үткән инде...
Акыл да бүтән инде;
Шулай да сине сагынып
Гомерем үтәр инде...

### Көткәндә

Вокзал алды. Көтәм. Тик бер үзем
Гүя бу дөньяда...
Тын перронга фәкать шыбыр-шыбыр
Янгыр гына ява.

Томан аша кайчак күренеп куя
Еракта гы утлар.
Ә бит шунда минем күңелемне
Җылытучы ут бар!

Бер шуларга карыйм, бер юлларга —
Күзем камашканчы.
Тик хәзергә рельс буйлап йөгерә
Бер-бер артлы тамчы...

### Сәяхәтче карт

Аһ, бу картлык?!.
Нинди сәер вакыт:
Тыштан тыныч,
Эчтән... карт, чыда!
Төннәр буе
Юллар йомгак сыман
Бөтерелә һаман каршыда.

Өстәвенә
Поезд гудоклары
Тәрәзәгә килеп сарыла...
Юк, ул гына түгел,
Юл да, ахры,
Аны шулай өзелеп сагына...

## Рәшит Гатауллин

●

Мин бәхетнең ни икәнен беләм,—
Җитәкләшеп бергә юллар үттек.
Мин сагышның ни икәнен беләм,—
Юл чатында бергә озак көттек.
Мәхәббәтнең ни икәнен беләм,—
Бергәләшеп озак очып йөрдек.
Мин нәфрәтнең ни икәнен беләм,—
Икәү бергә янган утка кердек...
Бәхет белән икәү булганда да
Күзләрендә сары сагыш күрәм.
Мәхәббәтем, синең гөлләреңне
Кайчак нәфрәтемә кушып үрәм.
Бишенче хис тагын бардыр бит ул,
Болар гына миңа җитми, беләм.
Нәрсә эзлим? Бәхет, нәфрәт аша,
Сөю аша, авыр сагыш аша
Шушы җиргә якынрак киләм.

●

«...Менә мин дә бүген ике мин...»
Һ. ТАКТАШ

Мин бу җирдә икәү кебек,
Ике кеше, ике йөрәк;
Берсе аның гел акыллы,
Берсе бераз юләррәк.
Берсе елый көләр чакта,
Берсе һаман язга бара,
Икенчесе көзгә таба.
Берсе керә ут эченә,
Берсе суны читләп үтә.
Бер йөрәккә бер көн җитә,
Берсе дөнья өмет итә.
Берсе кичен антлар бирә,
Яратам, дип, бары сине.
Икенчесе кемне уйлый
Йокламыйча төннәр буе?
Ике яшәү, ике кеше
Бер йөрәккә кушылганмы?
Әллә инде бу яшәүнең
Бөтен сере шушындамы?!

•

Әллә ни әйтермен кебек
Син тагын да миңа бер кил.
Тик өнемдә түгел, инде
Хыялый төшемә кер — кил.
Ялган бәхет булып түгел,
Моңсуланып, яшькә тулып,
Моңдый эссе кояш түгел,
Бер минутлык яшен булып,
Сагыш булып, сагыну булып
Бер килеп чык төшләремә.
Тиз узачак яңгыр сыман
Сарыл килеп өсләремә.
Сине күреп уянырмын,
Сине көтеп уйланырмын.
Сагыш белән уралырмын,
Сагыну белән юанырмын.

•

Күктә йолдыз сирәк кенә,
Әллә берәү чүпләп үткән.
Әллә инде бер өлеше
Димгә төшкән микән күктән?
Алар суда нишләр инде,—
Менә дулкын кага, кага...
Я йолдызлар югалырлар,
Куй, кадерлем, күп карама.
Куй, карама йолдызларга,
Җиргә төшкән якын санап.
Йолдызлар да күктә генә,
Күктә генә якты яңа.

# Лена Шакирҗанова

*Мин 1945 елда, Актаныш районы Пучы авылында, укытучы семьясында туганмын. Әти-әнием шул елда элекке Әтнә районы Күлле Киме авылына күчеп килгәннәр.*

*1962 елда Күлле Киме урта мәктәбен тәмамлап, Казан дәүләт педагогия институтының тел-әдәбият, тарих бүлегенә укырга кердем. 1967 елда аны тәмамладым һәм Казан шәһәренең 80 мәктәбендә әдәбият укыта башладым.*

*Хәзерге вакытта Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә эшлим.*

*Бала вакыттан ук әдәбиятка гашыйкмын. Авылыбызның матурлыгы, әти-әниемнең әдәбиятны тирән яратуы миндә дә, кечкенәдән үк, шигърияткә мәхәббәт уятты.*

## Юри генә



*Күрмисең дә мине, дисең,*
*Үпкәлисең.*
*Ә мин күрәм,*
*Күңелемнең мең күзе бар.*
*Барысын беләм,*
*Ишетәм, сизәм, тоям...*
*Ә җитмәсә, эзлим —*
*табам,*
*яшерәм —*

*Шундый тирән!..*
*Кайчак*
*Югалттым, ахры, дип,*
*Куркып куям...*
*Ә син үпкәлисең,*
*Мин бит сине*
*Юри генә күрмим...*

## Бар әле...

*...Алда озак еллар бар әле,*
*Башланмаган юллар бар әле.*
*Ялкынлы хис тулы күңелдә*
*Җырланмаган җырлар бар әле...*
*Икебез дә бәлки сизмәстән*
*Якынайтыр юллар араны.*
*Беләм, иркәм, кайчан булса да*
*Кавышасы көннәр бар әле.*
*Бакчабызда, алсу бер таңда,*
*Чәчәк атар гөлләр бар әле...*

## Яшел урам

*Алда кояш, алда юллар...*
*Тирә-ягым яшел урман.*
*Поезд чаба ыргып алга —*
*Ачык аңа яшел урам.*

*Туган йорттан рөхсәт сорап,*
*Китеп барам*
*Ерак-ерак...*
*Күп җирләрне урап-урап,*
*Киләчәккә бәхет юрап...*

*Китеп барам сабый чактан,*
*Бергә үскән дусларымнан,*
*Яшел яулык болгый-болгый,*
*Озатып калды яшел урам.*

*Алда кояш, алда таңнар,*
*Без менәсе текә таулар...*
*Яшьлегемә — яшел урам.*
*Шул урамда үзем торам.*

## Сине көтәм

*Алларымда ике касә*
*Мөлдерәмә, мөлдерәмә.*
*Бәхет тамчыларын саныйм,*
*Йөздер әллә, меңдер әллә...*
*Сине көтәм...*

*Ике күзем тәрәзәдә*
*Мөлдерәмә, мөлдерәмә...*
*Дүрт күз белән сине көтәм,*
*Чын бәхетем синдер әллә...*
*Синме әллә?*
*Синме әллә?..*

●

*Әле яз, иртә яз,*
*Бозлар яңа кузгала.*
*Алсу ефәк күлмәген*
*Яңа кигән кыз бала...*

*Әле җәй җитмәгән,*
*Әле яз узмаган.*
*Алсу ефәк күлмәген*
*Юып элгән кыз бала...*

## Нигә?..

*Яз иде...*
*Бакчам ачып, сиңа:*
*Кер! — дидем.*
*Алсу чәчәкләрен*
*Күр,— дидем.—*
*Ошатмадың.*
*Читтән карап*
*Көлдең...*

*Ә шулай да*
*Еллар үткәч,*
*Качып-посып*
*Син капкама*
*Килдең...*
*Түзә алмадың.*
*Нигә?..*



*БӨЕК ҖИҢҮГӘ ЕГЕРМЕ БИШ ЕЛ*

# МАРШАЛЛАР СҮЗЕ

**«Орденлы Татарстан хезмәт ияләрен котлыйм һәм немец-фашист юлбасарлар яуларын... тизрәк һәм тәмам тар-мар итү өчен хезмәт фронтында яңа җиңүләргә ирешүләрен теләп калам. Сугышчыларның һәм командирларның сугыш кырындагы героик батырлыклары кебек, каты сугыш шартларында Сезнең героик хезмәтегез безнең дошманнарны җиңүебезне якынайта, Кызыл Армиянең куәтле яңа ударлары өчен барлык кирәкле шартларны тудыра.**

**Фронтның рядовойлар, сержантлар составы, офицерлары һәм генераллары Ватаныбызның дошманнарына каршы көрәш тарихына күп кенә матур сәхифәләр язган, бигрәк тә Бөек Ватан сугышы көннәрендә бик күп геройлык үрнәкләре күрсәткән орденлы Татарстан улларының киләчәктә дә, Советлар Союзындагы башка халыкларның уллары белән бергәләп, данлыклы халкыбызның намусын лаеклы төстә саклаячакларына үзләренең сугышчан эшләре һәм тылдагы бөек хезмәт геройлыклары белән Совет Ватанының һәм аның Кызыл Армиясенең көчен арттырачакларына ышаналар».**

Советлар Союзы маршалы К. К. РОКОСОВСКИЙ.

**«Мин, карт солдат буларак, сугыш кырларында татар сугышчыларын һәм офицерларын күп күрдем. һәм аларның сугышта какшамас ныклык күрсәтүләренә һәм корыч ихтыярларына һәрвакыт сокланып киләм. Советлар Союзының бәйсезлеге өчен алып барыла торган бөек көрәшебездә татар халкы үзенең сугыш эшендә чыдам һәм батыр йөрәкле солдатлары белән бөтен армиябез каршында хөрмәт казанды».**

Советлар Союзы маршалы Р. Я. МАЛИНОВСКИЙ.

**«Совет халкы гадел, азатлык сугышы алып бара, моны аңлау сугышта геройлар тудыра. Геройлык масса төсендәге күренешкә әйләнде. Татарстанда туган сугышчылар да арсланнар кебек сугышалар».**

Советлар Союзы маршалы И. С. КОНЕВ.

«Татар солдатларының сугышчан эшчәнлекләре иң югары бәягә лаеклы...

Татар сугышчылары сугыш кырларында татар халкының иң яхшы сыйфатларын — Ватанга чиксез бирелгәнлек, дошманга аяусыз нәфрәт, җиңеп чыгу өчен үлемнән курыкмау, батырлык, кыюлык, чыдамлык һәм теләсә нинди авырлыкларга да түзү сыйфатларын гәүдәләндерәләр. Алар Совет Ватаны алдындагы хәрби бурычларын намус белән үтиләр».

Советлар Союзы маршалы Л. А. ГОВОРОВ.

«Татар сугышчылары һәм офицерлары бик күп бәрелешләрдә үзләренең исемнәрен дан белән бизәделәр. Солдатлык хисе каннарына кадәр сеңгән татарларның, рус сугышчылары белән бергәләп, берничә тапкыр инде немецларны кыйнаганлыкларын без беләбез. Моннан 400 еллар элек Ливон сугышы вакытында бик күп татар егетләре рус солдатлары белән бер сафта торып, немецларга каршы сугыштылар. Немец тарихчылары, ак атларга атланып, Нарва шәһәренә бәреп кергән куркусыз гаскәрләребез турында котлары чыгып яздылар...

Немецлар, үткәндәге сабакларын онытып, безнең Ватаныбызга һөҗүм башлагач, Татарстан уллары... үзләренең Совет Ватанын саклаучылар сафына кыюлык белән килеп бастылар һәм ул батыр егетләрнең дәһшәтле көчен немецлар тагын да ныграк татыдылар.

Бу турыда немец ефрейторы Рудольф Вольтанг фронттан үзенең туганына болай дип яза: «Монда безгә каршы бик күп татарлар сугыша. Мин хәтта төшемдә дә татар белән очрашырга теләмәс идем». Ләкин немецларга Кызыл Армия сугышчылары булган татарлар белән төштә түгел, бәлки өндә очрашырга туры килде. Ә бу күп тапкырлар куркынычрак булып чыкты...

Бөек рус язучысы Максим Горький татар халкы турында болай дигән иде: «Мин татарларны бик яхшы беләм. Алар намуслы халык, каһарман йөрәкле халык, нинди генә батырлыкка да сәләтле халык». Бу сыйфатлар барысы да солдатка кирәкле иң беренче сыйфатлар»...

Советлар Союзы маршалы А. ЕРЕМЕНКО.

Мөхәммәт Садри

# УТ ЭЧЕНДӘ ОЧРАШУЛАР

*Хәрби хәбәрче-оештыручы язмалары*

## Автордан

*Фронтка Ватан сугышы башлангач ук китсәм дә, бу язмаларны сугышның соңгы елларында гына эшли алдым. «Сере» шунда: каләм тотарга ара булмады. Сугышка кадәр армиядә артиллерия, бигрәк тә артиллерия приборлары эшенә өйрәнеп, «кече техник» исемен алып кайткан идем. Полкта миңа комбинезон, каска, шинель биреп, Бөек Ватан сугышы фронтына әнә шул һөнәрем буенча җибәрделәр. Шуның белән бергә, Казаннан фронтка кадәр хәрби эшелон начальнигы итеп билгеләндем. Безнең эшелон Мәскәү аша көнбатышка юнәлде. Смоленск шәһәре тимер юл станциясеннән башлап эшелонга дошман самолетлары күп кенә бомба ташладылар. Оршага җитәрәк, кара тәреле козгыннар һөҗүме тагын да көчәйде. Паровоз бригадасының кыюлыгы, оста маневрлар ясавы аркасында, безгә ташлаган бомбалар тик юл буйларында гына шартладылар, вагоннарга ярчыклар гына тигәләде. Без, түгелми-чәчелми, ватылмый-җимерелми, Орша тимер юлы станциясенә — билгеләнгән урынга килеп җитеп, яшен тизлеге белән вагоннардан төштек тә, барлык солдатларыбыз, техникабыз, атларыбыз белән Мәскәү — Минск юлыннан алга ашыктык. Орша күпере аша чыгып, үзебезнең частька кушылдык. Сугыш дигән коточкыч нәрсә безнең өчен икенче көн таңында ук башланды. Әллә таң, әллә кичке эңгер-меңгер иде, урман, аның аланнары, зур юл һәм аның тирә-юне ут-төтен өермәсе, янгын болыты, шартлау тавышлары белән капланды.*

Мондый чакта кая ул приборлар «кече техникына» эш?! Разведчик итеп билгеләндем. Башта Орша — Могилев, аннары Ельня шәһәренә килгән юлларда дошман танклары, дошман көчләрен, десантларын күзәтеп, хәбәр итеп йөрдем. Сугыш үзенә бер «академия» икән: бүген солдат, ә иртәгә — офицер да, начальник та булырга туры килә. Минем белән дә шулайрак килеп чыкты: Ельня янында, көтмәгәндә, армия хәрби (кыр) складының кораллар бүлеге начальнигы хезмәтен үтәргә керештем. Склад карьерына иң элек снарядлар төягән эшелоннар килә башлады. Орел һәм Брянск тимер юл деполарыннан килгән өлкән яшьтәге эшче-солдатлар һәм шоферлар белән ул снарядларны автомашиналарга төяп, кичтән таңга кадәр алгы сызыкка ташыдык. Анда артиллеристлар безне көтеп алалар һәм йөкне шунда ук узләре бушаталар иде. Дошман танкларына каршы снарядлар төялгән эшелоннарның вакытында килеп торуы, безнең склад коллективының йокы-ялны белмичә эшләп, сугыш припасларын алгы сызыкка төгәл җиткерүе Мәскәүгә таба котырынып килгән гитлерчыларны туктатырга, юлларын кисәргә ярдәм итте. Алгы сызыкка үз автомашина белән Волоста — Пятница карьерыннан снаряд ташучы төнге транспорт начальнигы булырга да туры килде. Аннан трофей снарядлары, кораллар төяп, көндезләрен безне эзәрлекләгән фашист самолетларыннан кача-кача автомашиналарыбыз белән төрле якларга юнәлеп, маневрлар ясап, үзебезнең складка кайтып туплана идек һәм әле алып кайткан снарядларны, коралларны яңадан ходка җибәрү өчен рәтләп, урман эченә яшерә идек. Бу эшләрдән соң көндез үз заводларыбыздан килгән тупларны, автоматларны бушатып, эңгер-меңгерләр җиткәндә, снарядлар төяп, яңадан алгы сызыкка ашыга идек.



Без йокы-ялны белмәүче кешеләргә әверелдек. Машинада барганда бераз черем итеп алыр идек, ярамый: төнлә дошман десантыннан сакланып, сугышка әзер булырга, ә көндез ачык кабинадан башыңны чыгарып «һава» күзәтеп барырга кирәк. Төнлә әлеге төяү-бушату, ташу-илтү кебек бик зур авыр эшләрне башкарып кайткач, көндез без, чират белән генә, берәр сәгать йоклап ала идек.

Без склад өчен яңа карьер ачтык, коллектив икегә бүленде, минем белән җидесигез кеше калды. Әгәр шоферлар һәм эшелонны саклап килгән солдат иптәшләр булышмаса, без бөтенләй аяктан егылган булыр идек. Шулай итеп, киеренке сугышчан бу эшебез йөз көн, йөз төн дияpлек дәвам итте.

Дошман безне чолгап алырга килгәндә, ахыр чиктә, складта тик орудие-мылтык чистарта торган бер-ике чүпрәк тюгы гына калдырып, биш меңгә якын трофей снарядларны шартлатып, приказ белән чигендек. Вязьма янында тупланып, Гжатск аша Нарофоминск янына килеп, яңадан үз эшебезгә керештек. Монда дошман безне бомбага тотканда контузия алдым. Бу өченче контузия иде.

Күп тә үтмәде, мине аерым танк частена артиллерия-сугыш припаслары белән тәэмин итү начальнигы итеп җибәрделәр. 1941 елның 7 ноябрь парадында Кызыл мәйданнан танкта үттем. Аннан соң, Совет Армиясенең Армия Артиллерия Баш идарәсе мине «катюша»лар янына — гвардия минометлары дивизионына эшкә җибәрде.

Күрәсез, кая инде миңа бу чакларда кулга каләм алу, ике юллык шигырь язарга да ара юк иде. 1942 ел башында әлеге контузияләр, өшүләр мине тәмам аяктан екты, госпитальгә озаттылар. Госпитальдән чыккач, тагын хәрби складта эшләдем.

*1943 елда Мәскәүгә, Артиллерия Баш Идарәсенә командировкага килгәндә, СССР язучылар союзының Хәрби комиссиясенә кергән идем:*

*«Без сезне күптәннән эзлибез, кайда икәнлегегезне белми идек»,— диделәр. Әл мин үзем турында бераз сөйләп: «Хәзер фронт газетасында бик эшлисем килә»,— дип әйтеп тә өлгермәдем, комиссия членнарының берсе: «Хәзер киңәшәбез»,— дип Александр Фадеев янына кереп китте. Бераз көткәч, миңа ашарга талоннар биреп: «Бездә кунак булыгыз да үз частегызга кайта торыгыз»,— диделәр. Әле яңа гына оештырылып алгы сызыкка юнәлгән гаскәри зенит артиллерия частена кайтып җитеп, берике көн дә үтмәде, менә ГлавПУРККА чакырган күрсәтмә килде. Мәскәүдә биш көн ял бирделәр һәм, ялым бетәсе көнне үк чакырдылар да, сугышчан пакет тоттырып, Беренче Украина фронты штабына җибәрделәр. Татар телендә чыга торган «Ватан намусы өчен» газетасына хәрби хәбәрче-оештыручы хезмәтенә җибәрелүемне шул штабка килгәч белдем...*

*Карлы-бозлы кышкы караңгы төндә, Житомир янындагы Лясовка дигән хуторда бер өйнең ишеген кактым. Ирләр тавышы ишетелде, ут янды. «Кем бар?» — дип сорагач, әйткән идем, ишек ачылды, биткә җылы бәрелде. Эчке күлмәктән генә каршымда басып торган Гали Хуҗиевны, өс-башым юеш килеш, кочаклап алдым. Шунда ук яныма килеп җиткән Риза Ишморат белән дә кочаклаштык. Алар ашаттылар, җылыттылар, үзләре янында урын бирделәр. Күргән-кичергәннәрне сөйләшә-сөйләшә йоклап киттек. Әл икенче көнне бергәләп эшкә керештек.*

*Бу язмаларны шушы редакциягә килеп, фронтны айкап йөри башлагач, алгы сызыкларда җаннарын да аямыйча көрәшүче якташларыбыз белән авыр сугыш юлларын үткәндә язарга керештем. Фронтның алгы сызыкларында ут эчендә очрашкан, күргән-белгән батырларның бу язмаларда бары тик уннан бер-ике өлеше генә чагылды дисәм дә ялгыш булмас. Башка батырлар да онытылмас дип уйлыйм.*

## Эзләгән табар...

Дошманга каршы җәйге һөҗүм башланды. «Ватан намусы өчен» газетасы редакторы Риза Ишморатов һәм секретаребыз Гали Хуҗиев белән киңәшеп, биш газетаның баш редакторы иптәш С. Жуковтан рөхсәт алып, яңа һөҗүм батырларын күрергә, якташларны эзләп табарга, газетага солдатлардан да материал оештырырга сугышлар районына киттем. Фронт штабына барып киңәшкәннән соң, хәзер инде сер түгел: генерал-полковник Д. Д. Лелюшенко частьларына — Дүртенче танк армиясенә юнәлдем.

Җилкәмдә автомат, биштәрдә запас диск, ике граната, катыргы тышлы ике блокнот, билдә пистолет, кесә саен карандаш. Армия штабыннан чамалап белешмә алгач, армиянең хәрби почта начальнигы (сугышка кадәр Мәскәүдәге үзәк газета-журнал почтамтында директор урынбасары булган) майор Константин Иванович Федоров, почта машинасы белән, танк гаскәрләре генералы Е. Е. Белов корпусына озатты.

Егерме биш километр чамасы баргач, әле яңа гына каты сугыш булып үткән районга кердек. Калкулыктан күз алдына гаҗәп тамаша килеп басты: кырмыскадай кайнаган солдатлар, меңләгән танклар, үзйөрешле орудиеләр, бронетранспортерлар, «катюша»лар... Юл буйларында үлгән фашистлар, кәкрәйгән, җимерелгән, янган танклар, «фердинанд»лар, машиналар, гигант зур соры елandай сузылган әсир фрицлар колоннасы...

Бөтен тирә-як нәкъ уч төбендә кебек күренгән әлеге калкулыктан төшеп, пычрак ерып бара-бара икенче калкулыкка күтәрелә башлаган идек, кайдандыр дүрт «мессершмид» килеп чыкты, безнекеләр дәррәү ата башладылар, һәм самолетлар ашык-пошык берничә бомба ташлап, кире сыздылар. Тимер ташкын колонналары ашыга-ашыга тагын үргә үрмәләде. Мин әсирләргә карадым: үзләренең самолетларын-

нан куркып, пычракта аунап өлгергәннәр, аларны саклаучы безнең автоматчылар: «Шнель, шнель! Днепрогэсны торгызасы бар»,— дип, яңадан сафка тезәләр иде.

Яңа үр соңгысы булса кирәк, бусыннан ерактагы авыллар күренә. Йортлары ярым җимерек, кайберләренең тик мич-морҗалары гына утырып калган, кайсылары әле дә янып-поскып торган авыл читенә туктадык.

— Килеп җиттек,— диде шофер, үзен көткән машиналарны, кешеләрне танып,— йөгемне шушы машиналар ала, ә штаб моннан ерак булмас...

Корпус штабына яңа килгән хәбәрләр белән танышкан гына идем, агач өйнең икенче башыннан бер майор чыкты. Ныклабрак карасам, күземә күренәме дип торам: таныш кеше — Казандагы өченче мех фабрикасының элекке слесаре, Хасан күле янында япон самурайларына, аннары ак финнарга каршы сугышларда чыныккан батыр, Советлар Союзы Герое, гвардия майоры Максим Васильевич Димитриев булып чыкты.

Аның белән шактый ашыгыч, әмма туганнарча күрешеп, сөйләшеп алгач, якташларны эзләп йөрим дип әйтүем булды, ул кунакка чакыргандай киң күңел белән, җилтерәтеп:

— Алайса, безгә киттек, калганын юлда сөйләшербез! — дип, машинада урын күрсәтте, һәм без китеп тә бардык.

Көнбатыш фронтында, Мәскәүне саклауда катнашкан, Ленинград өчен сугышкан, Брянск шәһәрен азат итешкән безнең Казан батыры Димитриев хәзер дә танкист — үзйөрешле авыр артиллерия гвардия полкында командирның техник эшләр буенча ярдәмчесе икән.

Каршыбызда — Львов каласы. Сулда — Ибанчу дигән авыл. Басуда, төтеннәре әле дә сүрелеп бетмәгән танк, аннан ары «фердинанд» күренә. Танк янында бер хәрби кеше кайнаша. «Дошманның үзенә каршы «ырылдатып» булмасмы икән дигән идем, кирәген алган икән»,— диде ул. Димитриев та танкның эчен-тышын тикшерде.

— Кем яндырган?

— Ибраһимов диделәр, молодец егет икән! — дип куйды хәрби.

— Безнең егет ич ул, таныштырырмын,— дип естәде Димитриев.

Львовка килеп кердек. Фронт гаскәрләре аны чолгап алып азат иткәннәр. Кайдадыр, арткы урамдамы, берәр йорттанмы, автомат, пулемет тавышлары ишетелә. Безнең автоматчылар шәһәрне дошман калдыкларыннан чистарталар икән. Үзәк урамда, колонналары каралган зур йорт янында, бер ишек алдыннан фрицларны тотып чыккан автоматчыларны күреп туктыйбыз.

— Подвалдан атып яталар, каһәрләр, чын фашистлар икән,— диде безнең бер солдат, пилоткасы белән битен сөртеп.

Йөзләгән машиналарны узып, Львовтан чыктык, тагын егерме километр үткәч, Димитриев хезмәт иткән полкның төп көчләрен куып җиттек. Штаб та ерак түгел икән. Өсте ачык кечкенә «газик»ка урта буйлы, ябык йөзле, җитез хәрәкәтле, өстенә плащ кигән бер хәрби чыгып утырды.

— Сынатмагыз, тагын килерлек булсын! — диде ул, уң кулын селтәп, ә сул кулы белән шоферга кузгалырга ишарә ясады.

Бу кеше командарм, генерал Д.Д. Лелюшенко булып чыкты. Дошманның унөч контратакасын кире кайтарып, Львовны азат иткән бу частьтагы батырларга СССР Верховный Советы исеменнән орденнар, медальләр тапшырып, рәхмәтләр белдергән икән.

Монда мин төрле милләт кешеләре: рус егетләреннән гвардия кече лейтенантлары Воронов, Шаломин, казакъ егете Сахап Нельдешенков, үзбәк егете Кәрим Һашимов, чуваш егете гвардия кече сержанты Афанасий Алексеев, Башкортстан егетләреннән Кәрам Хәтмуллин, Әхмәт Бадамшин һәм башка күп кенә батыр танкист егетләр белән таныштым. Ә татар егете Ибраһимовны якташым Димитриев табып бирде.

Үзйөрешле орудие командиры Ибраһим Ибраһимов җиңел сөякле, җитез, телгә дә, сугышка да оста кеше булып чыкты. Аны монда «Абдул» дип тә йөртәләр икән. Проскуров өчен сугышканда ул, «самоходка»сы белән дошман тылына әйләнеп кереп, бер «фердинанд» белән утызлап гитлерчыны юк иткән. Әле туптан, әле пулеметтан

ут яудырып паника ясаган. Менә шуңа күрә дә иптәшләре аңа дошманны син оста «обдул» дигәннәр.

Ул мине машинасы, орудиесе янына якынрак алып килеп:

— Әйдә, керәсеңме? Корыч крепость! — дип, ачык люкка күрсәтте.

— Әле кермик! — дидем мин.

— Алай-болай кинәт ата башласалар, монда ышыграк! — дип, люктан төшеп бер кечерәк су чиләге алып чыкты да кызу-кызу атлап китеп барды.

Мин ялгыз калгач, люктан эчкә кердем, эссе иде, шабыр тиргә баткач, яңадан чыктым. Бераз уйланып, блокнотымны чыгардым, һәм берничә җөмлә генә язган идем, Ибраһимов:

— Командир исән икән, санчастьта гына икән, сәлам әйткән, тиздән чыга икән,— дип шатлыгын белдерде, чиләгеннән куеп, каерып-каерып икмәк кисте, кашыгын алды: ашны да, ботканы да казылыклары белән бергә салдырдым, чиләктән чыгып качмаслар, мин әйтәм, кунакка да салабыз, командирың өчен дә диделәр... кашыгың бармы?

Юл ыгы-зыгысы белән ашау кайгысы китkән, ачыгуымны борынга аш исе бәреп кергәч кенә сиздем. Итек кунычымнан шомарып беткән кашыгымны чыгарып, кулыма калын гына бер кисәк ипи алдым.

— Бу һөҗүмгә күчкәннән бирле кайнар аш эләккәне юк иде,— дип, ул Львов янындагы сугышны искә төшерде:

— Приказ булу белән, дошманның тар-мар ителгән оборонасыннан безнең часть алга омтылды. Туплар җитәрлек, патрон күп, ягулык бар. Менә Львовка җитәбез инде дигәндә, фашист танклары һәм техникасы юлны өзәргә маташты. «Тигр»ларга һәм автомат тоткан ерткычларга каршы туплардан ут ачтык, безнең бер-бер артлы аткан туплардан бер «тигр» шып туктады. Безгә дә аттылар. Командир аңын югалтты һәм яраланды. Аның ярасын тиз генә бәйләдем дә, машинадан чыгарып, чокыргарак урнаштырыйм, дигән идем, санитар килеп җитте. Үзем яңадан машина эченә кереп чумдым. Карыйм: безнең сул яктан баручы «самоходка»га таба бер «фердинанд» килә. Тәзәп атып җибәргән идем, аннан ут-төтен күтәрелде. Артында гитлерчылар булган икән, монда таба килә башлаганнар иде, пулемет уты яудырдым. Сугыш тынды, юл ачылды. Люктан чыгып, машинаны тикшердем, әллә ни зарар килмәгән, аны көйләп тагын алга киттем. Күңектем үзебезнең «самоходка»га — алтын куллар койган корычтан эшләнгән крепость ул! — Түбән Иделдән Карпат итәкләренә күтәрелдек, туган, Берлинга якынлашабыз... Аша инде,— диде ул, кашыгымны сөртә башлаганны күреп, ашаган кешенең көче күп була! Астраханьга килсәң, безгә керми китмә, әни кунак сыйларга ярата, исемен дә язып куй: «Мәхмүдә!..»

Без Самбатка — эре тимер юл үзәгенең иң куркыныч җирендә дошман тылына кереп, аның чигенү юлына туктаганбыз икән, зур-зур туплы авыр танклар, коры елганың биек ярына ышыкланып, яшеренеп торалар. Вакытлы тынлык бозылды. Шәһәрнең төн ягыннан һәм көнчыгыштан танклар ут ачтылар. Шул арада Максим Димитриев килеп, мине арткарак, икенче машина янына алып китте. Күк күкрәде, яшен яшьнәде, чиләкләп яңгыр коя башлады. Шушы күкрәүләргә кушылып, безнең баш очыннан үтебрәк, коры елгада пычрак чәчрәтеп туплар шартларга кереште. Без бер «крепость» янына ышыкландык. Әле генә туплар шартлаган урынга каяндыр бер хәрби хатын-кыз килеп чыкты.

— Анна, безнең янга кил! — диде Димитриев.— Минем хатын, полк санинструкторы,— дип өстәп куйды ул аннары.

Анна Михайловна безнең янга килеп җиткән генә иде, якында гына зәһәрләнеп нәрсәдер зырылдады, шартлау тавышыннан колак тонды, күз алды караңгыланган-дай булды...

— Сез исәнме? — дигән тавышка күземне ачсам, вак ташлы, кызыллы-каралы пычракта ятам икән, шартлау дулкыны бәреп екkән. Димитриевлар һәм яндагы танк та пычракка күмелгән. Торып битне сөртә башлаган идем, яулык чат кан булды. Борыннан кан килә, ирен ачыта.

— Әйдәгез, тиз генә санчастька киттек! — ди Анна.

— Юк, юк,— дим мин, кырт кисеп,— катырак төшкәнмен, зарар юк...

— Һөҗүм башлыйбыз, сезгә күзәтү пунктына күчәргә кирәк, сугышны күрүе уңайлырак булыр,— диде Максим Васильевич һәм корыелганың икенче ягына алып чыгып, шоферына биштәрне сузды. Күңелемә аны тиз генә күреп булмас, дигән уй килде һәм мин:

— Казанга җибәрергә бер-ике сүз язсагыз иде,— дип, блокнотымны суздым.

Ул тиз генә язды да саубуллашып китеп барды. Кабинада мин аның шундый юлларын укыдым:

**«Орденлы Татарстандагы кадерле дуслар һәм туганнар!**

**Җиңү өчен, фронт өчен тагын да яхшырак эшләгез!**

**Без, гвардия танкистлары, кабахәт фашист юлбасарларны армый-талмый эзәрлекләп, җиңеп алга барабыз.**

**Бөек җиңүебезнең тантаналы көннәре бик якын инде.**

**Советлар Союзы Герое, гвардия майоры**
**М. В. ДИМИТРИЕВ».**

— Чү! Без каядыр ераккарак, икенче җиргә барабыз түгелме?

— Килеп җиттек инде, иптәш корреспондент, Армия штабы шушы авылда!

— Ни өчен Армия штабы?

— Миңа шулай боердылар!

Машинадан төштем, ул борылып китте. Менә сиңа, мә, алгы сызыктан хәйләләп озатканнар, күрәсең.

Өс-башны бераз чистартып, бит-башны сөрткәләдем дә штабны эзләргә керештем. Борынга типография буяулары исе бәреп керде. Армиянең «Вперед на врага» газетасы редакциясе дә монда икән. Аның редакторы В. Е. Федотов кочагына элактем. Ул «Комсомолец Татарии» газетасы редакторы иде бит! Күрештек, сөйләштек, һәм, тиз күрешкән кебек үк, тиз аерылыштык та. Штабта миңа полковник Жуков телеграммасын бирделәр. Анда һөҗүм батырлары турында язган хәбәрләрем өчен рәхмәт белдерелгән иде.

Хөкүмәт бүләкләренә тәкъдим ителгән бик күп батырларга язылган характеристикаларны укыганда: «Нәҗиб Набеевич Фазлыев, Ленин комсомолы члены...» дип башланган мактау сүзләрен укыйм:

«Безнең полк һөҗүм итеп барганда, Водынка авылы янында, дошман безнең юлны кисәргә, һөҗүмне туктатырга маташты. Шушы вакытта өлкән лейтенант Нәҗип Фазлыевка, унбиш автоматчы белән, гитлерчыларны юлдан тиз генә алып ташларга боерык бирелде. Фазлыев, автсматчылар белән ерактан әйләнеп, яшеренеп, дошман тылына көтмәгән яктан бәреп керде дә автоматлардан куәтле ут ачып паника тудырды. Шушы паникадан файдаланып, полкның төп көчләре алга киттеләр. Фазлыев боерыкны батырларча үтәде: бер взводка якын гитлерчыны юк итте, ике тягач яндырды, сугыш кораллары кулга төшерде.

Тактик яктан әһәмиятле калкулыкка урнашкан, тирә-як уч төбендәгедәй күренгән Букаво авылы өчен сугыш барганда, безнең автоматчыларны кысрыклап, дошман әлеге авылның төн ягына яңадан бәреп керде. Ул, өч «пантера»сы, ике бронетранспортеры, ике орудиесе һәм бер ротадан артык автоматчылары белән авылның уртасына кереп, безне бөтенләй бәреп чыгарырга уйлады. Шушы чакта полк командиры подполковник Шульженко беренче батарея командиры капитан Гуцалога үз батареясы белән авылның уртасына керергә, ә өлкән лейтенант Фазлыевка дошманның тылына үтәргә кушты. Гуцало яшеренеп кенә авыл чиркәве янына урнашканда, Фазлыев, комсомолецлардан — сержант И. Погребняк, В. Книга, сержант И. Трофимов, өлкән сержант С. Иванов иптәшләр белән разведкага китеп, пычракка кереп баткан «пантера» янында маташкан фрицларны күреп алды. Алар икенче «пантера» китерттеләр. Качып-посып аларны күзәтеп торган Фазлыев, кинәт кузгалып, ата-ата, «Ура!» кычкырып, иптәшләре белән атакага ташланды һәм әлеге фрицларны юк итте. Аннары ул арырак китеп, тагын ике орудие сугышып алды. Шул арада аларга ярдәмгә безнең башка автоматчылар кушылдылар. Нәҗип Фазлыевның кыюлыгы аркасында Букаво һәм аның күршесендәге авыл да дошманнан азат ителде».

Уйга калдым. «Шәп егет икән бу Фазлыев! Кайда туган, нинди ата баласы икән, фронтта күптәннәнме? Күрәсе иде, сөйләшәсе иде үзе белән. Эзләргә кирәк, ә эзләгән табар...»

Ул, танкларның алдынгы отрядлары белән бергә, кайчакларда алардан да алгарак үтеп, дошман танкларын кырып йөрүче полк разведчигы, артиллерист икән. Бу полк штабы яңа азат ителгән Перемышль шәһәре артында, Карпат итәгенә үк поскан, әйтергә бик авыр Витощинцы дигән авылда икән. Ут-төтен, ату-шартлау, пычрак юллар, янган авыллар аша үткәннән соң, мондагы яшеллекне, бакчаларда сыгылып торган алма, груша агачларын карап торганнан соң: «Дөньяда яшел җирләр дә бар икән әле»,— дим үз-үземә.

Бакча түреннән бер карт килеп чыкты. Күрештек. Исеме Олексо, фамилиясе Сенько икән.

— Фашистлар инде килмәсләрме? Алмаларымны җыярга кемнән рөхсәт алырга икән?

Бу сорау бик сәер тоелды.

— Җыегыз,— дидем мин, кыю гына, һәм: — Нигә җыймыйсыз? — дип сорадым.

— Алмаларны, грушаларны, армиягә дип, алар җыеп китәләр иде, үзебез калдык-постыгы белән генә канәгатьләнә идек,— дип сөйли-сөйли бакчасына чакырды, грушалар белән сыйларга тотынды.— Алай булгач, җыярга ярый икән!..

Полк штабы төнлә тагын кузгалачак.

— Гуцало белән Фазлыевны Карпатка менә торган юл тирәсеннән, алгы отрядтан, менә шушы квадраттан эзләп табарсыз! — диделәр.

Юл уңаена барган зур йөк машинасына утырып, әлеге «квадрат»ка таба киттем.

Бер сәгать чамасы баргач, машина туктады. Бергә килгән өлкән лейтенант белән кабинадан төштек. Ул картага күрсәтеп:

— Без сулга, көньяккарак керәбез, ә сезгә Карпат өстенәрәк менәргә кирәк, алар ерак булмаска тиешләр. Уңга борылсагыз, Варшавага барып чыгарсыз,— диде ул, елмаеп.

Ялгыз калдым. Якын-тирәдә кем дә юк. Кояш та таулар артына керергә чамалый. Ташлар, куаклыклар янында иң элек автоматны көйләдем, биштәрдәге ике гранат чалбар кесәләренә күчте. Кызу-кызу атлап, таулар арасына менеп киттем. Юл буйларында янган йортлар пыскый калды. Бер сәгать чамасы атлый торгач, юл өскә менде, якындагы таулар түбәндәрәк калгандай булдылар. Эңгер-меңгер пәрдәсе күтәрелде. Янымнан гына пулялар очып, якындагы ташта тузан бөртекләре күтәрелде. Кайдан аталар, кемнәр ата икән? Көндез андый чакта тәмәке көйрәтеп алыр идең, ә хәзер шырпы сызарга ярамый, мишень буласың. Ачуым чыгып кузгалдым да, автоматымны әйбәтләбрәк тотып, алга ашыктым. Тонык кына мотор тавышы ишетелде. Җиргә ятып тыңлыйм, миңа таба килә икән. Көтәм. Юлның уртасына чыгып:

— Стой, кто идет!? — дип кычкырдым.

Машина йөрешен акрынайтты:

— Свой!

Русча ачык итеп бирелгән җавапка бераз тынычланып, янына ук бардым.

Алар да миңа автомат төзәгәннәр иде.

— Тс-с,— диделәр болар,— ни булды, кем сез?

Әйтеп бирдем. Сүз кыска булды. Тиз аңлаштык.

— Утырыгыз, алар монда гына!..

«Амфибия» — суны да, сазлыкны да, коры җирне дә тиз үтүче корпус штабы машинасы — төнне ярып очып кына барды да туктады. Моннан юл тагын икегә бүленә икән.

— Сезгә кирәкле кешеләр моннан ике-өч йөз адымда гына, киң кыя өстеннән күзәтәләр...

Ташлар арасындагы ниндидер юлдан бераз барган идем, хәзер үзе мне дә:

— Стой, кто идет? — дип каршы алдылар.

Сакчы сүзләрен ишетеп, бер офицер килеп чыкты һәм ул мине штабка тапшырды. Полк командиры подполковник Шульженко һәм политик эшләр буенча аның урынбасары майор Слепцов белән таныштым. Беренче батарея командиры Гуцало да Фазлыевны аеруча мактады һәм аның үзе белән таныштырды.

— Сез кайдан? — дип сорадым мин аның белән күрешкәч үк.

— Казан егете булам, әллә сез дә Казаннанмы? — диде ул.— Мактап йөрисез икән, рәхим итегез, көндезге трофей,— ул миңа кәгазьгә төргән бер кирпеч сузды,— Украина балын немецлар Германиягә кирпечләп озатканнар икән...

— Сине эзләгәндә тау когызыннарына азык була яздым бит әле. Сират күпере кичтем, юлда кемнәрдер аттылар...

— Тау араларында өч меңгә якын коралллы ерткыч бар. Аларны ауларга махсус тау укчылары килә.

Аның чандыр, ачык йөзен, кара чәчен палаткага кергәч, саклык белән шырпы сызып, тәмәке кабызганда гына күрдем.

Нәҗип Казанда туып үскән, җиде классны Ленин районында тәмамлаган. Тагын укыган. Төньяк Двина елгасында пароходта механик ярдәмчесе булган. 1940 елда армиягә алынып Белоруссиядә артиллерия мәктәбендә укыган, Брестта хезмәт итәргә килгәч, сугыш башланган. Брест өчен, Слуцк, Могилев, Орша шәһәрләре өчен сугышларда катнашкан. Аннары Курск дугасы, Курск һәм Орел шәһәрләре... Днепр, Днестр елгалары... Барысы да сугыш белән үтелгән.

— Инде күп калмады! — диде ул.

Арылган иде. Автоматны яныма куеп, гранаталарны биштәргә күчереп, башны Нәҗип шинеленә салдым да аны тыңлый-тыңлый йокыга киткәнмен...

— Подъем! — дигән йомшак кына итеп әйткән тавышка күзне ачам.

— Торыгыз, тревога булды, китәбез.

Палаткалар җыелган, туплар машина артына тагылган.

Юлга чыктык. Барган саен тауларга җан кергәндәй булды, моннан-тегеннән машиналар, туплар, автоматчылар чыгып кушылдылар. Аларның исәбе-хисабы юк иде.

Күрәсе килгән кешеләрне эзләп таптым шикелле. Ә Фазлыев белән хәтта Карпат тавы кыясында Казанча, баллы-майлы чәй эчә-эчә сөйләштек. Тагын нәрсә кирәк! «Обозда» йөрмәдем бит! Инде редакциягә кайтып, биштәрдәге блокнотларны ачып яза башларга да мөмкин. Ләкин күңел әле һаман алга тарта:

— Бераз йөрим әле, алар күргәнне күрим, алар кичергәнне кичерим,— дидем.

Караңгылы-яктылы чакта, борыла-сырыла үрдән үзәнгә төшеп, көнбатышка таба киттек. Мелява, Липа-Долина, Яворник-Русский дигән авылларны тыныч кына үткән чакта, безнең кечкенә, җитез, ачык машиналар беренчеләр рәтенә чыкты. Алда еслөре ябык берничә зур машина бара. Аларда саперлар өчен кирәкле йөкләр булса кирәк, ләкин аларның төп көчләре бу юллардан кичә кич үк үткәннәр икән инде. Үзәннең болай да йомшак җире, көчле яңгырлардан соң тагын да йомшарган, юл әле, пычранып елгермәсә дә, сыгылып-сыгылып тора. Бара торгач, алдагы олы машиналар авыр тарта башлап арттагыларның йөрешен акрынайттылар. Ул арада ачык кечкенә машина белән кемдер ашыгып килеп җитте. Бата язган алдагы ике машина көпчәкләре астына нечкә бүрәнәләр, кочак-кочак куаклар салынды һәм юлга тагын җан керде. Фазлыев әлеге кеше турында әйтте. Ул безнең унынчы гвардия танк корпусының командиры, танк гаскәрләре генерал-лейтенанты Е. Е. Белов икән. Генерал, машинасын кире борып, алгы отрядларны күзәтә-күзәтә арткарак калды, аннары тагын алга килеп чыкты.

Сидлиска авылы янында бензин һәм су алырга рөхсәт ителде.

Шушы арада, беренче батарея санинструкторы старшина Тәлгат Юсупов, орудие йөртүче машина шоферы Абдрахим Абдрахманов, казакъ егетләреннән — снаряд ташучы Җәфабай Исмаилов, замковый Казакъбай Түләганов иптәшләр белән дә танышып, сөйләшеп алдык. Алар эшенә, алар батырлыгына да капитан Гуцало әйбәт бәя бирде, һәм:

— Сугыш юлларыннан бергәләп ике мең километр үттек! — диде ул.

Хәрәкәт көчәйде. Фазлыев, кабина ишеген ачып, күкне күзәтә башлады.

Әле төнлә белән генә саперлар елгерткән күпергә керәбез. Кичүне командарм Пелюшенко һәм башка хәрби начальниклар күзәтәләр, теге якта да командирлар бар. Тирә-як тыныч, дошман самолетлары күренми. Без, дошман китмәгән урыннан, Сан елгасын кичәбез икән. Тар күпердән сакланып кына икенче якка чыгып, туры киттек.

Бездән соңгы колонналарның кайсыларын уңга, икенчеләрен сулга бордылар. Армия Сан елгасы плацдармын киңәйтә икән.

Безнең беренче батарея алда баруын дәвам итте һәм биш поляк авылын азат иттек. Ә Пильно дигәне, ерактарак, калкулыкка тәрәлеп утырган иде. Пильно очыннан сулдарак калкулыкка юл сузылган һәм шул юлдан, кара ерткычлар шикелле, дошман танклары күтәрелә.

— Фашистларны машина белән дә куып җитеп булмый,— диде Фазлыев, шул танкларга күрсәтеп.

Индрушевка дигән авыл уртасына җиткәч, тупчылар, машиналарыннан төшеп, тупларын көйли башладылар. Фазлыев гади бер йортның тәрәзәсен чиртте. Ут күренмәслек итеп капланган тәрәзә пәрдәсенең бер читеннән кемнеңдер башы күренде һәм, кемнәр икәнебезне белгәч, сакланып кына ишекне ачып түргә өндәде. Үзләренчә, кемгәдер эндәшү белән, зал түреннәнрәк идән асты капкачы ачылды, аннан шәм тоткан бер хатын-кыз башы калыкты.

— Бу минем хатыным, ә үзем поляк инженеры — нефтьче, Фиерлай Станислав булам,— диде ишек ачкан әлеге кеше.

Фазлыев немецләр турында сорашты.

— Шнейль! Лосс! (Тизрәк кузгалыгыз!) дип качканнарына әле бер сәгать тә юк,— диде Станислав һәм безне берәр чәшке кофе эчәргә өстәл янына чакырды.

— Әле генә, немецлар киткәч, кайнаттык, рәхим итегез! — дип, инженер хатыны яңадан идән астына төшеп, шуннан буы чыгып торган чәшке сузды.

Инженер, анысын өстәлгә куеп, икенчесен алырга үрелгәндә, туплар шартлый башлап, җир тетрәгәндәй булды. Шартлаулар көчәйде, Фазлыев ишектән орудие янына атылып чыкты, инженер идән астына төште. Мин өстәл артында, кайнар кофе янында, ялгыз калдым. Фазлыевлар өй янында гына. Ә фашистларның танкларда качып китүләрен үзем күрдем. Авыл тагын тетрәде, безнең өй дә селкенгәндәй булды. Ямьсез, таныш тавыш, колакка таныш шартлаулар ишетелде: дошман алты көпшәле минометларыннан ата...

Фазлыев йөгереп керде һәм кулымдагы әлеге кофены күреп елмайды да:

— Киттек! — диде.

Корпусның төп көчләре сулдагы калкулыкларны алалар, ә безнең тупчылар Пильно авылы янында сугышып разведка ясарга, дошман игътибарын үзләренә юнәлтергә тиешләр икән.

Фашистлар яндырган өйләрдән ераграк, караңгырак урыннарда басуларга, юлга чыгып, төрле якка сибелеп, разведчиклар тиз генә тупларын көйли башлаганнар гына иде, каршы калкулыктан ракеталар очты, болытлы караңгы төн яктырып китте. Оккупантлар, үзләре дә аңламастан, цель күрсәттеләр. Безнекеләргә шул гына кирәк иде. Дошманга каршы дәһшәтле өермәдәй ут ачылды. Аллы-гөлле эз калдырып, һаваны кисеп безнең яктан очырган зур калибрлы пуляләр, зенит орудиеләре уты, снарядлар дошман яшеренгән калкулыкны әллә ничәгә яргандай итеп тетрәтте. Безнекеләр ярсып аттылар. Ләкин дошман алты көпшәле минометлардан авылга түгел, мондарак атса, безгә җиңел булмаячак иде. Чөнки әле эскертләргә дә салынмаган, сирәкмирәк өелеп-өелеп куелган юеш көлтәләргә генә ышыкланган идек. Әмма аның паникага бирелеп теләсә кая атуы безгә зарар китерә алмады.

Тупчы разведчикларның, бигрәк тә беренче батареяның дәһшәтле залплары таңга кадәр дәвам итте. Калкулык өстеннән кызарып аккан болытлар тагын каралдылар.

Разведка сугышы арытты. Тупларын, коралларын тәртипкә китереп, брезентлар ябып, солдатлар көлтәләр янына утырып хәл алдылар. Фазлыев та, минем янга килеп, бер көлтәгә башын салды. Ә дежур сакчылар тирә-якны күзәтәләр иде.

Утырган җиремнән торып, юл буена чыктым. Чамалыйм: Пильно авылы очына өч йөз адымнар гына калган. Юлда машина, танк эзләре һәм туктаусыз сибелгән оннар, ярмалар, алмалар, грушалар, ә арырак он, ярма капчык-капчык ята. Безнекеләр өсләренә басып килгәч, качарга җиңел булсын дип, ташлап калдырганнар иде аларны гитлерчылар. Төнге кофе, Индрушевканың тетрәве, төн буенча дәвам иткән атышлар турында уйлап, оккупантларның хурлыклы чигенү юлларын карый-карый авыл очына

житкәндә, тиз-тиз генә безнең ике автоматчы килеп, мине борылырга мәҗбүр иттеләр. Аларны капитан Гуцало җибәргән икән:

— Монда куркыныч, авыл уртасында немецлар, бер сәгатьтән штурм ясыйбыз, сезгә монда калырга ярамый, редакция дә эзли үзегезне,— дип, туп йөртүче миңа җиңел машинага утырырга кушты.

Юл читында сәубуллашып, машинадан төшәм. Уңдарак күпер күренә. Аның янына житәрәк, дошман самолетлары килеп чыга һәм һөҗүм юлы дәррәү шул самолетларга ата башлый. Берсен кинәт төтен чорнап ала һәм ул каядыр еракка атылып төшә. Бу — тимер юл күпере икән. Якында гына туктаган танк янында безнең телдә сөйләшкән егетләр янына барам.

— Саумысез! Кайдан җил ташлады, егетләр?!

— Урaлдан без, Карпатны чистартып төштек, Берлинга барабыз! — диделәр алар чыннын-шаяруны бергә кушып.

Ефрейтор Хәби Кәлимуллин белән Мирза Ибраһимов Пермь өлкәсеннән, ә рядовой Кәләй Гәрәев белән кече сержант Якуб Ямаев Башкортстан егетләре икән.

— Минем танкның менә дигән автоматчы-десантчыларын да мактап телгә алырга онытмагыз! — диде танк командиры өлкән лейтенант Гребнев.

Алар, кузгалып, Сандомир юлыннан тагын алга киттеләр.

Польша җирләрен азат итү сугышлары вакытында тагын бер якташны очратып сөйләштем. Бу безнең бик зур кешебез: Мәскәүдә Фрунзе исемендәге Хәрби Академияне тәгәлләгән, Казан танк училищесы начальнигы булган, Бөек Ватан сугышында Кызыл Байраклы дүртенче гвардия танк корпусы штабы начальнигы Исмәгыйль Әхмәт улы Нагайбәков иде. Аның бабасы, рядовой казак Гәрәй Нагайбәков, 1812 елгы Ватан сугышында әверүчә зур батырлыклар күрсәткән, дүрт Георгий медале белән бүләкләнеп, зур шөһрәт казанган. Ә атаклы Гәрәй оныгы Исмәгыйль Нагайбәков Совет халкының Бөек Ватан сугышында, гвардия танклары корпусын җиңүләргә илтүче зур хәрби начальник булып, данлыклы совет генералларының берсе булып үсте. Бу генерал турында үзенә бер китап язарга кирәк.

Эзләгән табар, ди халык. Сугыш юлларында, сугыш районнарында командировкада эзләнеп йөри торгач, мин дә редакциягә зур байлык — батырлар китабына алтын хәрефләр белән язылырлык кешеләрнең Ватанга, бөек Ленин партиясенә чиксез бирелгән кешеләрнең ялкынлы хисләрен, корыч дуслыклары җырын, изге исемнәрен алып кайттым.

## Сапер Хәйрулла Шакиров

Шәһәр үзәгенә юл ачкан тупчыларны эзләп барганда, дошманнан тартып алынган урам чатларында, стеналарда: «Мина юк, Шакиров» дип, зур хәрефләр белән язылган кешелекле сүзләр күңелгә сеңгән иде. Бик табигый: аның үзен дә күрәсе килде. Автоматчылар белән очрашканда да, тупчылар янында да Шакиров күңелдән китмәде: кем икән, кайсы якларда туып үскән? Хәрабәләр эченнән, кәл-тузан, таш өемнәре арасыннан миналар тартып чыгаручы, мәкерле дошман мең төрле хәйлә белән яшереп калдырган миналарны табып, меңләгән ватандашларын коткаручы бу Шакиров үлемне җиңәргә кайда өйрәнгән икән?

Сугыш барган меңләгән йортлардан, хәрабәләр эченнән, шундый зур гаскәр арасыннан аны ничек эзләп табарга? Ләкин ефрейтор Хәйрулла Шакировны табуы җиңел булды: аны бөтен дивизия белә, ә полкта әверүчә яраталар икән:

— Безнең инженер ул, сугыш остасы ул! — диделәр аның турында.

— Кайда укыган?

— Кайда дисезме? Сталинград урамнарында, Дон буйларында, сугыш кырларында өйрәнеп үсте ул!..

Без аның белән әле сугышып алган йортта, автоматын чистартканда күрештек. Ул яңа операциягә чыгарга җыена икән. Чандыр йөзенә карaганда, инде шактый олы яшьтә күренгән, киң акыллы маңгаена үткән тормыш һәм сугыш елларының юллары

сызылып калган Хәйрулла Шакиров, үзенең җиңеллеге, җитезлеге һәм шаянлыгы белән, әле яңа тормыш башларга йөргән уттай егетләрне хәтерләтте. Җиңү өчен, халык өчен, азат илнең бәхете өчен янып яшәүче, курку белмәс коммунист булып чыкты бу инженер колачлы сапер Шакиров.

Без сөйләшеп утырган әлеге йортны да беренче булып Хәйрулла Шакиров алган. Ничек алган дисезмее? Менә болай:

Шәһәр үзәгенә чыга торган урам чатындагы бу йорт подвалына яшеренеп, безнең сугышчыларның һөҗүмен туктатмакчы булып, гитлерчылар автоматлардан, фаустпатроннардан туктаусыз ут яудырып торалар. Шушы вакытта, янган янәшә йортның җимерек стенасына яшеренеп, Шакиров, берничә дусты белән, дошман кулындагы йортның беренче катына бәреп керә. Шуннан Хәйрулла подвалдагы фашистларга:

— Хенде хох!! Бирелегез, Гитлер капут! — дип кычкыра.

Фашистлар тагын да көчлерәк ата башлыйлар.

Иптәшләренә подвалның икенче як ишеген сакларга кушып, Шакиров үзе фашистлар аткан тәрәзәләргә үрелеп тиз-тиз генә берничә шешә тондыра:

— Сталинградтан көчтәнәч алып килдек, «Московская особая» белән сыйланыгыз! — ди ул.

Яна торган сыекча салынган шешәләр подвалда чәлпәрәмә килеп, ут һәм төтен өермәсе чыгаралар. Үзләрен моңар кадәр бик иркен тотып атып яткан фашистлар, ач күселәр кебек, акылларыннан шашарга ирешеп подвалның икенче ягыннан качып котылмакчы булалар. Шунда инде аларны безнең автоматчылар көтеп тора, дошманның берсе дә котыла алмый, ә бишесен Шакиров үзе дөмектерә...

Бреслауда урам сугышлары һаман дәвам итә. Шакиров яңа заданиегә китә. Ул, бер зур йортны ышыклап торган таш койманы тол белән шартлата да, автоматчы иптәшләре белән, үзе әлеге йортның беренче катына килеп керә. Бу катны кулга төшереп урнашкач, болар шаккаталар: йортның икенче, өченче катларында һәм подвалында гитлерчылар мыж килә, санап бетергесез күп икән. Алар, беренче катны чолгап алырга, Шакиров группасын юк итәргә исәпләп, ишекне дә терәтеп куйганнар. Шушы куркыныч вакытта Шакиров, иптәшләре белән киңәшеп, тәрәзәдән сикереп төшә, таш коймада үзе ачкан ярыктан атылып чыга да команда пунктына чаба. Аның артыннан пулялар сызгырып, гранаталар шартлап кала. Тиргә, тузанга баткан Хәйрулла команда пунктында хәлне аңлату белән, командир шундук тупчылар, автоматчылар белән ярдәмгә ашыга. Сугыш бик каты була. Йорт тирәләрендә, подвалда һәм өстәге катларда эсэсовчыларның җансыз, җирәнгеч гәүдәләре генә аунап кала. Ә командир, Шакировны кочаклап алып:

— Рәхмәт, туганкай, синең кыюлыгың аркасында дусларың да исән калды, яңа йортлы да булдык! — ди.

Сугыш остасы Шакировның батырлыгы турында блокнотта тагын бер вакыйга язылган:

Безнең егетләр штурм белән йорт арты йорт алып барганда, бер зур таш пулатны ныгытып өлгергән фашистлар бик нык каршылык күрсәтәләр, бер адым атларга да ирек бирмиләр. Безнекеләр, башта әлеге йорт янында туп та ала алмаслык калын таш коймага ышыкланалар, аннары янәшәдәге ярым җимерек йортка кереп урнашалар. Караңгы төшә башлый, ә таң алдыннан һөҗүм башларга, алга үтәргә кирәк. Ни эшләргә? Таш койманы шартлатырга булып, командование бу сугышчан бурычны да оста сапер Хәйрулла Шакировка йөкли.

Дошман тирә-якны яңгыратып, тавыш күтәреп бертуктаусыз атып яткан арада, Хәйрулла яшеренеп кенә койма тирәләрен тикшереп чыга да эшкә керешә. Иптәшләре аңар койма асларын казышырга, тол китерешергә булышалар. Гитлерчылар, ата-ата хәлдән таеп ялга тынган чакта, операциягә хәзерлек эше тәгәлләнгән була. Таң сызыла башлау белән, шәһәрне тетрәтеп куәтле шартлау яңгырый һәм таш койманы икегә аерган яңа юлдан безнең артиллеристлар, автоматчылар һөҗүмгә ташланалар, дошманның тагын бер ныгытылган терәк пунктын кулга төшерәләр.

Гитлерчыларны Германиядә, үз өннәрендә оста кыйнау эшенә, инженер корылмаларын җимерү яки төзү эшенә, миналар кую яки аларны зарарсызландыруга Хәйрулла Шакиров Сталинград яннарында, Изге Идел буйларында өйрәнгән. Ул куйган мина кырларында Сталинградка керергә маташкан өч танк шартлаган. Дөнны кичкәндә

Шакиров, дошманның атып торуына да карамастан, кеймә белән теге як ярга автоматчылар чыгара, җиде рейс ясый һәм үзе дә алар белән һөҗүмгә ташлана. Днепрны кичеп чыккач, дошман килүе мөмкин булган юлларга Башкортстан егете, дусты Исмәгыйль Сабирҗанов һәм башка иптәшләре белән йөзләрчә мина куеп, плацдармны саклап калу өчен бөтен көчен биреп тырыша. Сандомир плацдармында, дусты Наумов белән бергәләп, дошманның җиде йөз метр арага сибелгән миналарын арчып, һөҗүм итүче танкларыбызга, автоматчыларыбызга юл ача һәм дошман траншеяларына бәреп кереп үзе дә җиде фашистны теге дөньяга озата. Сталинградтан Германия җирләренә җиткәнче сугыша-сугыша килеп ул шул кадәр остара: бер сәгатьтә йөз минаны зарарсызландыра. Германиягә кергәндә инде ул сугыш кырларында дошманның ун меңгә якын минасын зарарсызландырып, безнең гаскәрләргә санап бетергесез күп туры юллар ачкан була. Аеруча тәгаллек таләп иткән мондый авыр хезмәтне үз эшенең чын остасы, инженеры гына башкара ала, әлбәттә. Кыскасы, Бреслаудагы урам сугышларында бездән уч алырга маташкан гитлерчылар үз өннәрендә әнә шундый баһадирлар белән очраштылар. Дошманны безнең әнә шундый җиңелмәс баһадирларыбыз, Ленин партиясе тәрбияләп үстергән корыч ихтыярлы сугышчыларыбыз тез чүктерде.

Шулай бер көнне фронтта язган хәбәрләремне укып, анда күргән якташларым турында уйланып утырганда Хәйрулла Шакировны искә төшердем һәм аның исәнлеген, кайдалыгын беләсем килеп, «Яшь ленинчы» газетасына бер мәкалә язып бастырдым. Күп тә үтмәде, безнең сагынган саперыбыз табылды. Ул, гаиләсе белән, Чиләбе өлкәсенең Гривен совхозында гомер итә икән. Бреслаудагы батырлыгы өчен аңа икенче Кызыл Йолдыз орденын биргәннәр. Бу хатында иптәш Шакиров: «Үз урыныма биш егет үстердем. Өч егетем өйләнде, алар да балалар үстерәләр, ике улым тракторчы, берсе электромонтер. Икесе механизаторлар курсында укый. Үзем совхозда эшлим, тазалыгым яхшы»,— дип яза. Бу хат — аеруча зур шатлыклы хат иде. Әйе, баһадир сапер Хәйрулла Шакиров сугыш кырларында Ватаныбыз азатлыгын намус белән яклаган булса, уллары тыныч кырларда мул иген үстереп, халкыбызның көчен, Ватаныбызның куәтен арттыралар.

*Ахыры бар.*

## Нәби Дәүли

### Фронттан кайталмасам...

Миңа инде
тиздән алтмыш тула,
Томаннарга еллар күмелде.
Ялан аяк чыктым ерак юлга,
Җәяү генә узам гомерне.
Алтмыш язлар,
җәйләр, кышлар аша
Йөгереп кенә үттем шикелле.
Бер генә төн җирдә кундым да мин,
Таң атканын көттем шикелле.
Үпкәләмим,
авыр уфтанмыйм да,
Узды диеп, яшьлек чакларым.
Мин яшәдем гади кеше булып,
Яңа котып җирдә ачмадым.
Гади кеше,—
шушы исем җитә,
Дан бизәген эзләп йөрмәдем.
Исем белән түгел,— эше белән
Ватан үлчи кеше йөрәген.
Мин дә тыңлыйм
бүген йөрәгемнең
Күкрәгемдә кайнар тибешен.
Ул бит әле янып шартлый ала
Окопларда, туган ил өчен.
Йөрәк әле һаман сөя ала,
Аннан башка яши белмәдем.
Бу җирдә мин алтмыш яшькә кадәр
Торыр өчен генә килмәдем.
Көрәшләрдә
янар өчен килдем,
Җылытырга килдем тормышны.
Кайгырырга килдем, шатланырга,
Яратырга килдем чын дусны.
Килдем дошман белән сугышырга
Утлы яуда, тыныч көннәрдә.
Башкаемда чәчләр агарганчы
Мин өйрәндем шушы һөнәргә.
Һәм шигырь дә
килде минем белән
Авыр юлны бергә үтәргә.

Халкым өчен, туган илем өчен
Турылыклы хезмәт итәргә.
Гомер уза,
нигә борчылырга?
Иртән тор да, шагыйрь, сафка бас!
Матур кызлар бәлки онытырлар,
Мине музам әле ташламас.
Әйе, муза,
Безгә алтмыш тула,
Дөбердәтеп бәйрәм ясыйкмы?
Шешәләрне тезеп табыннарга
Тавык суеп, казан асыйкмы?
Килсен микән
әллә корреспондентлар
Портретны төшереп алырга?
Мактый-мактый минем сакалымны
Бар дөньяга хәбәр салырга:
Ләкин сакал
булмый кайсы ирдә,
Бу — батырлык диеп кем әйтә?
Картайтырга мине ашыкмагыз,
Катыргылар биреп бүләккә.
(Бәлем, анда матур сүзләр була,
Сулар тормый ләкин иләктә).
Мин бит әле гашыйк йолдызларга,
Яз танынннан әле ут алам.
Уйламагыз, инде тынар диеп,
Яратудан барыбер туктамам.
Очрашырга телим давыл белән,
Солдат кебек юлда мин һаман.
Ил чакырса мине набат кагып,
Мин хәбәрсез җирдән югалмам.
Егерме ел
тагын яшь алсам,
Миңа атап бәйрәм ясарсыз.
Тантанага инде килми калсам,
Ул фронттан кайталмады диеп
Минем хакта хәбәр язарсыз.

1970.

## Зәки Нури

# КҮҢЕЛ ДӘФТӘРЕННӘН

## Күкрәүле яңгыр

Варшавада күк күкрәде,—
Таш-таулар ишкән сыман,
Кайчандыр кала өстенә
Бомбалар төшкән сыман.

Әйе, фашистлар каланы
Нәкъ шулай ишкәннәр шул,
Бомбалар һәр йорт өстенә
Тонналап төшкәннәр шул.

Варшава! Аяк астына
Таш булып яткан кала,
Дошман өстенә ут итеп
Үч-нәфрәт аткан кала!

Күкрәмәде бүген күгең
Куркытып-калтыратып.
Яңа йортларның түбәсен
Юды ул ялтыратып.

Үләннәр өскә үрелде,
Урамнар сафландылар,
Яшәрде яшел бакчалар,
Чәчәкләр шатландылар...

Варшавада күк күкрәде,
Бу — гүзәл иртә иде:
Фашистлар куылган көнне
Ил бәйрәм итә иде.

Яңгыр тиз узды, мәйданнар
Шаулады халык тулып.
Хәтердә минем бу күкрәү
Сакланыр салют булып.

Кул кыса дуслар — поляклар:
Син Совет иленнән,— дип,—
Җилферди безнең байраклар
Сезнең ил җиленнән,— дип.

Ә берсе, Ежи дигәне,
Билдән үк алды кысып.
Сүзләре йөзендә балкый —
Әйтерсең, таңгы офык:

— Күп еллар үтте төшкәнгә
Җилкәдән газап йөге.
Сезнең җилкәләрдә килде
Варшава азатлыгы!..

## Вислада су кергәндә

...Генрих — поляк. Ә мин — Казан улы.
Бергә төштек талгын Вислага.
Мин Вислада йөзәм, ә күңелдә
Идел булып тулган хис ага.

Сине яклап, Идел, көрәшкәндә
Мин бу суда бата яздым бит...
Күптән йөрдем шуны ничек әйтим,
Ничек итеп шуны языйм дип.

Фашист атты миңа кат-кат төбәп,
Кат-кат атты... ләкин тимәде.
Йөрәк әйтте: ярга чык та ат! — дип,—
Качыйк моннан тизрәк! — димәде.

Арыган тәнне Висла суы юды...
Текә ярга менә алдым мин.
Бу атышта шулай Идел өчен,
Илем өчен исән калдым мин.

Сез якыннар җанга, елга-күлләр,
Һәркайда да рәхәт сез тәнгә.
Әмма кочам Идел дулкыннарын,
Нинди генә суда йөзсәм дә.

Дөрес аңла мине, Генрих дустым!
Юк, мин, Висла, сине кимсетмим.
Эш тик шунда: никтер мин үземне
Иделдәге кебек хис итмим.

1969, Польша.

## Әдип Маликов

●

Бу гасырның корыч давыллары
Аз кичмәде безнең баштан да.
Сыкрап ята иде Ил кырлары
Кайтып буразнага басканда.

— Бирердәен әле жир бирмәгән,
Сай сөрәме әллә төрәнем?
...Дуслар белән инне-иңгә куеп,
Күтәрдек без нефть чирәмен.

Шинельләрне иңнән төшерсәк тә,
Адымнар бит — солдат адымы.
Сугыш утын томалаган куллар
Жирдә тормыш уты кабызды!

●

Хаклы идең кая жибәрсәң дә,
Ни кушсаң да, Илем, син безгә.
Самурайга юлны бикләр өчен
Кыя булып бастык диңгезгә.

Окопташлар каны тибә миндә,
Дәшә дуслар еллар аркылы:
Туфрак аша тойсын табаныгыз
Жиргә күчкән йөрәк ялкынын.

Дусларым күп. Шунысын ачык беләм:
Дуслык булсын утка чыдарлык;
Туган жиргә булган мәхәббәтне
Үлем аша алып чыгарлык!

## Мөнир Мазунов

### Хәтерлим аның зәңгәр күзләрен

Жирне тетрәтеп ярылды туплар,
Һавада — сөрем, төтен һәм ялкын.
Шушы тәмугтан рус кызы мине
Коткарып калды, белмәдем атын.

Ярамны бәйләп, нәрсәдер әйтте,
Мин ишетмәдем аның сүзләрен.
Телсез һәм чукрак хәлдә ятсам да,
Хәтерләп калдым зәңгәр күзләрен.

Еллар үтәләр, бик күп нәрсәләр
Хәтердән чыга — хәтердә калмый.
Ләкин ул кызның зәңгәр күзләрен
Хәзер дә әле оныта алмыйм.

Сугышлар тынды, хәсрәтләр бетте,
Тормышта тагын ни көтә безне?
Якты юлларда, бәлки, бу язмыш
Очратыр миңа ул зәңгәр күзне.

**Әхмәтгәрәй Рамазанов,**
отставкадагы авиация генерал-лейтенанты.

# ҺӘР МИНУТЫ ХӘТЕРДӘ

Планетабыз кешеләре 1418 көн дәвам иткән Бөек Ватан сугышының һәр минутын хәтерләрендә саклыйлар.

Хәзер, чирек гасыр узгач, сугышның беренче көннәре күз алдына килә...

1941 елның августы. Гитлер баскыннары, Брянск, Орел, Тула шәһәрләре янына җитеп, Ватаныбыз башкаласы Мәскәүгә куркыныч тудырдылар.



Брянск фронты (командующие генерал А. И. Еременко, фронт Хәрби Советы члены — дивизия комиссары П. И. Мазепов) Мәскәүгә килү юлларын сакларга һәм шушы районда дошманның удар группасын тар-мар итәргә тиеш иде. Фронтның Хәрби һава Көчләре командующие итеп генерал Ф. П. Полынин, комиссары итеп мин билгеләндем.

Очучылар ике ай дәвамында, бүтән төр гаскәрләр белән берлектә, дошманга Десна елгасын кичәргә ирек бирмәделәр, аның көчләрен какшаттылар.

30 августта фронт гаскәрләренә шундый бурыч куелды: дошманның икенче танк группасын тар-мар итәргә! Хәрби һава көчләре Баш командование резервысы һәм еракка оча торган авиация исәбенә тулыландырылды. Һөҗүмгә безнең 464 самолет катнашты, бер көн эчендә 1200 сугышчан очыш булды, 4500 бомба дошман өстенә ташланды. Боларның нәтиҗәсе шул булды: гитлерчылар уннарча танкларын, 800 автомашинасын, 50 ләп самолетларын югалттылар...

1942 елның май аенда Брянск фронты базасында Икенче һава армиясе оешты. Шушы армия белән мин Берлинга һәм Прагага кадәр барып җиттем.

Икенче һава армиясе сугышның соңгы елында Беренче Украина фронты составында сугышты. Хәзер безнең сугышчан экипажлар саны дошманныкына караганда

ике тапкыр, истребительләр 5 тапкыр, штурмовиклар алты тапкыр артык иде. Очучыларның сугышчан осталыклары да сугышның беренче көннәренә караганда бик нык үскән иде.

1945 елның 16 апрелендә совет солдатлары грандиоз һөҗүм башлап җибәрделәр. Ул елны апрель ае яңгырлы булды, шунлыктан вакытлы аэродромнарда җир өсте тәмам сазлыкка әверелде. Авиациянең фронт гаскәрләреннән артта калу куркынычы туды.

Менә шундый шартларда безнең очучылар самолетларны Бреслау — Берлин автострадасына утыртырга тәвәккәлләделәр. Ә юлның киңлеге 24 метр гына. Иң беренче булып бу юлга өч тапкыр Советлар Союзы Герое А. Покрышкин самолеты утырды, аңардан соң — аның шәкертләре.

Икенче һава армиясенә, сугышчан батырлыклары өчен, апрель — май айларында гына Верховный Башкомандующийның 10 приказында рәхмәт белдерелде. 130 очучыга һәм командирларга Советлар Союзы Герое исеме бирелде. Алар арасында безнең якташларыбыз — Татарстан уллары: Рәшитов Абураим, Фәтхуллин Әнвәр дә бар иде. Советлар Союзы Геройлары М. Мостафин, И. Газизуллин һ. б. лар тагын орденнар белән бүләкләнде. Армиянең күп кенә берләшмәләренә, частьларына орденнар һәм «Берлин» исеме бирелде.

**Гани Сафиуллин,**

*Советлар Союзы Герое, запастагы генерал-лейтенант.*

# ГВАРДИЯЧЕЛӘР СЫНАТМЫЙЛАР

Белгород һәм Харьков тирәсендә гитлерчылар бик зур удар группировка туплаган иде. Уйсулыкларга һәм куаклыкларга фашистлар яңа «тигр», «пантера» танкларын, үзйөрешле «фердинанд» туппарын яшергәннәр. Мин командалык иткән 25 нче гвардия корпусы кергән 7 нче гвардия армиясе полосасына дошман куәтле танк һөҗүме ясый ала иде. Шуңа күрә безнең корпус гаскәрләре алда торган сугышларга бик җитди һәм ныклап әзерләнделәр.

Дошманның ударын зәгыйфьләндерү өчен совет гаскәрләре һөҗүмне үзләре башларга тиешләр иде.

1943 елның 5 июле. Сәгать иртәнге ике. Минем күзәтү пунктында кинәт телефон шалтырады. Трубкадан армия командующие генерал М. С. Шумилов тавышы ишетелде.

— Барысына да хәбәр итегез,— диде ул.— һөҗүм нәкъ план буенча башланачак.

Бер сәгатьтән соң, таң алды тынлыгын бозып, туплар, минометлар гөрселдәде, танк орудиеләре, пулеметлар атарга кереште. Безнең снарядлар, миналар гитлерчыларның ныгытмаларын актарды, атакага әзер торган пехотасы, танклары, орудиеләре, резервлары урнашкан районнары, складлары өстендә шартлады. Дошманга бик зур зыян килде.

Артиллерия әзерлеге, кинәт башланган кебек, кинәт тынды да. Тирән тынлык урнашты. Давыл алды тынлыгы иде бу. Һәм озакламый фашистлар барлык төр корал-



ларыннан давыллы җавап уты ачты, һавадан, төркем-төркем булып, кара свастикалы самолетлары безнең позицияләр өстенә бомбалар яудырды. «Тигр»ларга, «пантера»ларга, «фердинанд»ларга ышыкланып, мотопехотасы безнең корпус позицияләренә ташланды. Ләкин гвардиячеләр каушап калмадылар, дошман атакасын көчле ут белән кире кактылар. Фашистлар яңа көчләрен сугышка кертеп, тагын һөҗүмгә күтәрелделәр, тагын чигенергә мәҗбүр булдылар.

Каты сугышлар җиде көн, җиде төн туктаусыз дәвам итте...

Бу сугышларда мин командалык иткән корпустагы безнең якташларыбыз гаять зур батырлык үрнәкләре күрсәттеләр.

Танкка каршы ата торган орудиеләр взводы командиры кече лейтенант, комсомолец Бакиров җиде сәгать дәвам иткән бер сугышта 17 гитлерчыны юк итте, орудиесеннән туры төзәп атып, дүрт «тигр» танкысын яндырды. Ул, иптәшләре Касаржанов белән Закутуллин үлгәч тә, каушап калмады: тагын дошманның ике танкысын шартлатты.

А. А. Бельгин батальоны урнашкан позициягә дошманның 100 танкысы, бер полк чамасы пехотасы һөҗүм итте. Бу дәһшәтле сугыш унике сәгать барды. Батальон сугышчылары гитлерчыларның унөч атакасын кире кактылар, әледән-әле кул сугышлары булып торды. Каты яраланган батальон командирын рота командиры капитан И. В. Ильясов алыштырды. Атакаларның берсендә «тигр танкысы, траншеялар аша үтеп, 28 яралы совет солдаты һәм офицеры яткан блиндажга юнәлде. Батальон парторгы Сушков, биленә гранаталар бәйләп, танк астына ташланды. Каты шартлаудан соң, танкка ут капты. Шулай итеп, яралылар коткарылды.

39 танкысын һәм меңнән артык мәетләрен калдырып, фашистлар чигенделәр. Бу сугышта күрсәткән батырлыклары өчен капитан А. А. Бельгинга, И. В. Ильясовка, сержант С. П. Зорингә Советлар Союзы Герое исеме бирелде, парторг В. Л. Сушков, үлгәннән соң, Ленин ордены белән бүләкләнде.

Кукмара районы егете, санитар Юсупов Хузьят унике яралы сугышчыны сугыш кырыннан алып чыкты һәм шул ук вакытта алты гитлерчыны юк итте.

СССР Верховный Советы Президиумының 1944 елның 22 февраль Указы нигезендә сержант Замир Усманович Хөсәеновка 1943 елның июлендә Белгород янында күрсәткән батырлыгы өчен Советлар Союзы Герое исеме бирелде.

Нәрсәдән гыйбарәт иде соң аның бу батырлыгы!

Фашистлар танкларга ышыкланып һөҗүмгә күчкәч, Хөсәенов отделениесе аларның бик күп автоматчыларын һәм берничә танкысын юк итә. Шулай да «тигр»ларның берсе отделение позициясенә якынлаша. Ә Хөсәеновта инде патроннар да, яндыргыч шешәләр дә беткән була. Ул биленә танкка каршы гранаталар бәйли, шуның берсен фашистлар өеренә ташлый да: «Гвардиячеләр бирелмиләр!» — дип кычкырып, «тигр» астына ташлана һәм аны шартлата...

Гитлер гаскәрләренең «Цитадель» операциясе тулысынча җимерелде. Безнең 25 нче гвардия корпусы 24 июльдә үзе һөҗүмгә күчте һәм ике көннән соң Харьков шәһәренә бәреп керде. Украинаның икенче башкаласы азат ителде...

Еллар үтте. Күптән инде сугыш кырларындагы окоплар тигезләнде, алар өстенә үләннәр, ашлык үсте. Ләкин тормышларын да кызганмыйча Ватан өчен сугышкан батырларны совет кешеләре бер вакытта да, һич кайчан да онытмас!

**Минзакир Әпсәләмов,**
отставкадагы генерал-майор.

# БЛОКАДА ӨЗЕЛДЕ

1944 елның башында, Ленинград һәм Волхов фронтларының һөҗүм операцияләре нәтиҗәсендә, немец-фашист гаскәрләре тар-мар ителде һәм 220—280 километрга куылды, Ленин шәһәре дошман блокадасыннан азат ителде.

Бу операцияләрдә, башта Волхов фронты, аннан Ленинград фронты составында, мин командалык иткән 18 нче укчы дивизия дә катнашты. Куәтле оборона ныгытмаларын җимереп, дошман контратакаларын кире кага-кага, дивизия Ладога күленнән Псков, Остров шәһәрләре чигенә җитте. Мга, Тосно, Плюсса, Струги-Красные, Карамышево шәһәрләрен һәм бик күп авылларны азат итте.



Бу операциядәге уңышлы сугыш хәрәкәтләре өчен дивизиягә «Мга» исеме бирелде, Тосно шәһәрен азат итүе өчен Кызыл Байрак ордены тапшырылды. Ватаныбыз башкаласы Мәскәү ике тапкыр (аннары блокададан азат ителгән Ленинград та), 18 нче Кызыл Байраклы укчы дивизия гаскәрләрен котлап, салют бирде.

Бу юлның авырлыгы хәзер дә күз алдыннан китми. Әйе, бик кыен булды бу юл, бик зур мораль һәм физик киеренкелек таләп итте. Анда безнең солдатларыбыз һәм командирлар бик күп массовый һәм шәхси батырлык үрнәкләре күрсәттеләр.

Без юлсыз җирләр буйлап, урманнар, сазлыклар аша һөҗүм иттек. Ләкин сугышчылар зарланмадылар, киресенчә, аларны җиңү шатлыгы рухландырды. Хәрабә хәленә китерелгән шәһәрләр, яндырылган авыллар, газаплап үтерелгән совет кешеләренең гәүдәләре дошманнан тагы да катырак үч алырга өндәде.

**Якуб Чанышев,**
отставкадагы генерал-лейтенант.

# БРЕСТНЫ АЗАТ ИТҮ

«Казан утлары» редакциясе минем алга: «Бөек Ватан сугышының сезнең өчен иң истә калган көне нинди!» — дигән сорау куйды.

Җавап бирәм.

Мин командалык иткән корпусның иң зур батырлык күрсәткән сугышы — фашист армиясенең Брест группасын тар-мар итүдә катнашуы булды.



Брест крепосте, Брест шәһәре халкы сугышның беренче көннәрендәге оборона тотучыларның легендар батырлыгы белән хаклы рәвештә горурлана. Шулай ук алар үзләрен азат иткән совет солдатларының үз-үзләрен аямыйча сугышуын да яхшы хәтерлиләр.

Фашист командованиесе, Белоруссия территориясен югалтуның үзе өчен никадәр куркыныч булуын яхшы аңлап, безнең һөҗүмне туктатуга бөтен көчен куйды.

Брест крепосте өч ел дәвамында немецлар тарафыннан көчле ныгытылган районга әверелдерелеп, аның алдына өч рәт оборона чиге корылган, аларның һәрберсендә өч-дүрт траншея казылган иде. Ә крепостьның үзендә яңа фортлар төзелгән, алар яңа типтагы орудиеләр, пулеметлар белән тәэмин ителгән иде. Шуңа күрә крепость гарнизоны, бу көчләргә нык ышанып, безнең гаскәрләр якын ук килеп җиткәч тә шәһәрдән чигенү турында уйлап та карамады.

Безнең 96 нчы Кызыл Байраклы корпус Брест шәһәрен камап алуда төп рольне уйнарга тиеш иде.

1 нче һәм 38 нче гвардия дивизияләре тимер юлны, шулай ук Брест — Варшава шоссе юлын кулга төшергәннән соң, 70 нче армия командующие генерал В. С. Попов мине телефонга чакырды. Ул дошманның Бресттан чигенә башлавы турында әйтте. «Дошманны көнбатышка таба җибәрмә! — диде ул.— Сезгә ярдәмгә авиация җибәрелә».

«Катюша» залплары һаваны тетрәтте. Аларның уты дошман солдатлары һәм офицерлары арасында паника тудырды. Фашистлар тәмам шаштылар, кайберләре безгә каршы — көнбатышка ташланды, ә икенчеләре кире крепостька кереп яшеренде. Ә безнең пулеметлар һәм туплар аларны йөзәрләп-йөзәрләп кырдылар.

Брест өчен барган сугышларда безнең 96 нчы корпус солдатлары һәм командирлары гаять зур батырлык үрнәкләре күрсәттеләр. Брест операциясендә безнең

корпус дошманның биш дивизиясен һәм башка төрле частьларын тар-мар итте. Корпус сугышчылары егерме меңгә якын фашистны теге дөньяга олактырдылар, ике мең немецны әсир иттеләр. Дошманның 1100 автомашинасы, 20 тягачы, 115 пулеметы, 388 орудие, 30 танкысы һ. б. бик күп сугыш техникасы сафтан чыгарылды, ә 580 машина, 15 паровоз, 100 вагон, 800 дән артык ат, меңнәрчә винтовкалар, пулеметлар безнең кулга төште.

28 июльдә Брест крепостен азат итүчеләр хөрмәтенә Мәскәү егерме артиллерия залпы белән салют бирде. Верховный Башкомандующий приказы белән корпуска рәхмәт белдерелде һәм аңа «Брест» исеме бирелде. Йөзләрчә сугышчылар һәм офицерлар бу сугыш өчен орденнар белән бүләкләнделәр, ә миңа Беренче дәрәҗә Кутузов ордены тапшырылды.

**Фатих Булатов,**

отставкадагы генерал-майор.

# СУГЫШНЫҢ СОҢГЫ КӨННӘРЕ

Бөек Ватан сугышы тарихта моңа кадәр булмаганча иң авыр, иң каты сугыш булды. Бу сугыш елларында совет кешеләренең югары мораль сыйфатлары, данлы сугышчан традицияләре, Ватанга, Коммунистлар партиясенә бирелгәнлекләре тагын бер кабат бик ачык булып чагылдылар, анда яңа тип армия — Совет Армиясенең төп үзенчәлекләре бөтен бөеклеге белән күренде.

...Туп авазлары, танк моторлары гөрелтесе тынганга инде чирек гасыр узды. Бу чор эчендә яңа буын үсеп җитте. Әмма фронт көннәрендәге авырлыклар һәм җиңү шатлыгы безнең хәтердә әле нык саклана.



Мин бүген сугышның ахыргы көннәрен хәтергә төшерәм. Бу көннәрдә дә фронтларда сугышлар каты һәм кан коегыч булды.

1945 елның 25 марты. 3 нче Белоруссия фронтының 48 нче армиясе Кенигсбергтан көнбатыштарак Фриш-Гаф култыгында сугышлар алып бара. Безнең дивизия һәм күршебез бу киң култыкны кичеп чыгарга һәм, 11 нче гвардия армиясенең частьларын алыштырып, Фриш-Нерунг борынында дошманны юк итәргә тиеш.

Бу борын — киңлеге бер километрдан өч километрга җиткән бер полоса, аның озынлыгы җитмеш километрга якын. Җир өсте куаклыклар һәм урман белән капланган. Анда бары тик бер генә юл бар — ул Балтик диңгезе буйлап уза.

Борынны дошман нык крепостька әверелдергән, бик күп дзотлар, блиндажлар төзегән, танкка каршы чокырлар казыган, гаять күп корал һәм техника туплаган.

1945 елның 1 маенда, Мәскәүдә Кызыл Мәйданда бәйрәм парады башланган вакытта, нәкъ сәгать 10 да безнең дивизия һәм күршебез 194 нче дивизия сугышчылары көчле артиллерия әзерлегеннән соң, «Ура!» кычкырып, атакага күтәрелделәр. Без борынның төньягыннан, диңгез яры буйлап һөҗүм иттек. Безнең дивизия фронтына каршы немецларның дүрт пехота дивизиясе частьлары һәм подразделениеләре, сайлап алынган эсэс «фолксштурм» отрядлары тора; алар әсир төшүдән үлемнән дә катырак куркалар иде.

Төн җитте. Коеп яңгыр ява. Снарядлар һәм миналар төшеп ярылалар да урмандагы агачларны төпләре-ниләре белән каерып ташлыйлар, бөтен тирә-як ут һәм төтен белән чолганып алынган: урман яна, сугыш техникасы яна, җир яна. Безнең сугышчылар шушы тәмуг аша алга ыргылдылар һәм сигез көн эчендә, 50 километр җирне сугышып алып, материкка чыктылар. Безнең берләшмә сугышчылары бу вакыт эчендә дошманның 2500 солдатын һәм офицерын юк иттеләр, 600 ен әсир алдылар. Шуның өстенә фашистларның 57 танкысы, бик күп техникасы, 448 тубы һәм минометы, 10 мең автомашинасы h. б. лар юк ителде, яулап алынды.

Кыскасы, Фриш-Нерунг борынында капитуляция вакытында 23 мең немец солдаты һәм офицеры әсир ителде. Бу шул нәрсәне ачык күрсәтә: мондагы сугышлар вакытында немецлар көч ягыннан безнең гаскәрләргә караганда өч-дүрт мәртәбә өстен булган. Ул сугышларда безнең солдатлар да, офицерлар да гаҗәеп батырлык һәм фидакарьлек үрнәкләре күрсәттеләр. Анда мин командалык иткән Кызыл Байраклы, Суворов орденлы Гомель дивизиясе сугышчылары һәм командирлары фашизм өстеннән җиңүгә үзләренең зур өлешләрен керттеләр.

Һәм, ниһаять, тарихка мәңгегә кереп калган 9 май таңы атты. Кояш чыкканда без алгы сызыкта идек. Уйсулык җир. Фашист Германиясенең «данлыклы» солдатлары, бер-бер артлы килеп, коралларын ташлыйлар. Башлары түбән иелгән, мескенләнеп калганнар. Менә, бер төркем офицерлар белән, немец генералы. Ул озак кына безгә карап тора. Аннан, башын иеп, солдат автоматлары янына үзенең пистолетын куя.

Фриш-Нерунг борыны өстендә Кызыл Байрак — җиңү байрагы җилферди. Җиңү тантанасы. Меңнәрчә сугышчылар «Ура!» кычкыра, пилоткаларын чөя. Һава пулеметлардан, автоматлардан бирелгән салюттан тетрәп тора.

Әлбәттә, бу салютлар булсын өчен боерык бирелмәде. Һәр сугышчының шатлыгы чиксез иде. Без, командирлар да, бу көчле шатлык ташкынына кушылдык. Мин сугышчан дусларымны һәм 1942 елдан бирле алгы сызыкта сугышкан абыем Харисны, өч сугыш ветеранын, кысып кочаклыйм...

Николай Шевченко

# УЛ—МАТРОСОВЛАР САФЫНДА

Менә 130 ел инде Кара диңгез буенда Новороссийск шәһәре тора. Ул әлек-электән Россиянең сәүдә дөньясына көньяк тәрәзәсе булып килгән. Аның һәр урамы, һәр йорты безнең дәүләтебезнең, революциябезнең, бишьеллыкларыбызның тарихы белән бәйле.

Бу шәһәр — Тамань армиясенең тимер ташкыны даны, монда, В. И. Ленин кушуы буенча, флот, дошман кулына калмасын өчен, Кара диңгез төбенә батырыла.

Зәңгәр таулар артыннан теләр-теләмәс кенә кояш чыгып килгәндә, тын шәһәр өстендә кечкенә кыңгырауларның хрусталь чаңы яңгырый башлый. Бу чаң, исәннәргә Ватан өчен башын салганнарның данын искә төшереп, матәм маршына әверелә. Новороссийск курантлары — матрос бушлаты, солдат шинеле киеп сугышкан йөзләрчә батырларның истәлеге ул, алар данына мәңгелек һәйкәл.

Новороссийск өчен барган сугышларда һәлак булган батырлар кабере өстенә салынган һәйкәлләр, аларның йокысы бүленмәсен дигәндәй, мәңгелек сакта тора... Ә матәм маршы һаман көчәя, менә аңа тантаналы аккордлар кушыла, һәм ул, үсеннән-үсә барып, бөтен тирә-якка җәелә, мәңгелек дан утының кызгылт нурлары якыннан үтүчеләрнең йөзләренә төшә.

Бирелә көн шулай башлана. Хәрби һәм хезмәт даны шәһәре уяна. Диңгезчеләр, порт эшчеләре, машина төзүчеләр, тимер юлчылар эшкә ашыга. Кибетләрнең һәм мәктәпләрнең ишекләре киң ачыла, портта пароход гудоклары яңгырый.

...Новороссийск кешеләре туган шәһәрләре өчен сугышларда һәлак булганнарның истәлекләрен кадерләп саклыйлар, аларның барысының да исемлеген төзегәннәр.

Исемнәр, фамилияләр, аларның хәрби дәрәҗәләре... Алар меңнәрчә. Менә шуларның берсе: «Өлкән сержант Мансур Гали улы Вәлиуллин. 1943 елның 15 сентябрендә үз тормышы бәрабәренә сугышта уңышка ирешүне тәэмин итте. Немец-фашист дотының амбразурасына күкрәге белән ташланды, Советлар Союзы Герое Александр Матросов батырлыгын кабатлады».

Шунда ук рәттән карандаш белән түбәндәге сүзләр язылган:

«Исән. Адресы: Татарстан, нефтьчеләр шәһәрендә яши».

Әйе, Мансур Вәлиуллин исән, һәм ул Татарстан нефтьчеләренең башкаласы Әлмәттә яши. Әйе, 1943 елның сентябрендә дошман доты амбразурасын күкрәге белән ул каплаган.

* * *

...Новороссийск шәһәренең үзендә дә, аның тирә-юнендә дә каты сугышлар инде алтынчы көн бара иде. Менә, ниһаять, 10 сентябрьдә 200 орудие залпы шәһәр өчен хәлиткеч һөҗүмгә кучүне белдерде. Цемес бухтасының ике як ярын да ут каплап алды. Гаваньга иң беренче булып торпеда катерлары ыргылды, алар, торпедалар шартлатып, портка юл ачтылар, дошманның ут нокталарын юк иттеләр. Алар артыннан, десант төяп, сак катерлары һәм «диңгез аучылары» юлга чыкты. Капитан-лейтенант Василий Ботылев командалыгындагы десант батальоны диңгезчеләре, порт причалларына беренче аяк басып, урам сугышлары башлап җибәрделәр. Десантчыларга шәһәргә ике яклап һөҗүм итүче «Кече җир»дәге диңгезчеләр, пехотачылар һәм 318 нче дивизия сугышчылары ярдәм итте. Өзлексез шартлап торган снарядлардан һәм миналардан җир тетрәде, төтен һәм тузан болыты кояшны каплады.

...Җылы сентябрь көне. Төш уртасы. Җир өсте җәй буена кыздырган эссе кояш нурларыннан яргаланып беткән.

Өлкән сержант Мансур Вәлиуллин хезмәт иткән батальон Новороссийск янындагы Мефодиевка торак пунктына һөҗүм итеп килә иде. Алда — шәһәрне каплап торган калкулыкларга кадәр — ялкыннан һәм төтеннән соргылт төскә кергән тигезлек җир. Фашистлар андагы калкулыкларга ныгып урнашканнар. Фашист командованиесе Тамань ярым утравының капкасы булган бу шәһәрне, бернинди югалтуларга карамыйча, сакларга боерык биргән. Шуңа күрә һәр калкулык, һәр траншея зур сугышлар белән яулап алынды. Тигезлектәге һәр сантиметр җир артиллериядән дә, миномет һәм пулеметлардан да утка тотарга уңай — уч төбендәге кебек күренеп тора.

Дошман безнең сугышчыларны көчле ут белән каршылады, әйтерсең, ул үзенең барлык үлем машиналарын шушында, бер үзәккә туплаган. Һөҗүм итүчеләр җиргә сыендылар.

— Алга, иптәшләр, алга! — дип кычкырды батальон командиры. Бу җәһәннәм гөрелтесе аша аның тавышын ишетүче булдымы икән?!

Ул тагын кычкырды:

— Коммунистлар, алга!

Шул вакыт шоссе тирәсенә һәм Дооб борынына урнашкан безнең батареялар һөҗүм итүчеләргә ярдәмгә килде. Снарядлар баш өстеннән улап уздылар да, дошман окопларына төшеп, бөтен калкулыкны ут һәм төтен пәрдәсенә күмделәр. Артиллерия уты көчәйгәннән көчәя барды. Моның белән рухланган безнең сугышчылар атакага күтәрелделәр, «ура!» тавышлары яңгырады.

Калкулыкларның берсен яулап алганнан соң, сугышчылар тагын җиргә сыенырга мәҗбүр булдылар: алдагы бер калкулык түбәсеннән исән калган гитлерчылар пулеметлардан һәм автоматлардан ут ачты. Батальон сугышчылары арасында үлүчеләр дә, яралanучылар да күбәйде.

Шул вакыт өлкән сержант Вәлиуллин батальон командирына мөрәҗәгать итте.

— Иптәш командир,— диде ул,— миңа үземә генә дот янына үтеп карарга рөхсәт итегез. Тамагын тыгылдырыйм әле!

Капитан уйга калды. Әгәр өлкән сержант планы барып чыкса, батальонга алга юл ачылачак, ирешелгән уңышны җәелдерергә мөмкинлек туачак.

— Тәвәккәлләә, Мансур! — диде командир, туганына эндәшкәндәй якын итеп.

Биленә гранаталар бәйләп, автоматын алып, Вәлиуллин дошман дотына таба шуышты. Гитлерчылар аны бик тиз күреп алдылар һәм минометтан ут ачтылар. Миналар бик якында шартлый башлагач, Мансур кисәк кенә кулын болгаган булды да, аркасына ятып, тынып калды. Фашистлар, аны үлде дип уйлап, утны киметтеләр. Шуны гына көткән Вәлиуллин тагын алга шуышты. Баш өстеннән тагын пуляләр сызгырырга кереште, эсседән һәм тузаннан сулыш алу кыенлашты, куллар арыды, авызга-борынга ком тулды. Бәлки, бу азаплануларның барысы да бушкадыр, бер пуля тидеме — беттең... Ләкин Мансур, бернигә карамастан, шуышты да шуышты.

Дот калкулыкның нәкъ түбәсендә үк диярлек иде. Ә калкулык алдында тимер чыбык киртәләр. Аны әйләнеп үтәргә кирәк. Әйтергә генә ансат: давыллы ут астында киң дигәндә 40—50 метр өстәмә юл үтәргә кирәк... Куллар сызлый, арка сөякләре чат-

ный, ләкин өлкән сержант, җиргә сыенган хәлдә, тигез суларга тырышып, шуышты да шуышты.

Якында гына төшеп снаряд шартлады. Егетнең өстенә туфрак коелды, вак ташлар тиеп кулларын авырттырды. Әмма дотка да ерак калмаган иде инде. Йөрәк тагы да кызурак тибәргә кереште. Ә башта бер генә уй: дошманның ут ноктасын ничек кенә булса да юк итәргә! Амбразурадан дошман пулеметы туктаусыз ут сибә, тирә-якта пулялар сызгыра.

Шунда аның күз алдына бөтен тормышын тирән мәгънә, бәхет һәм шатлык белән бизәгән минутлар килде. Аннан Ватанга бирелгән ант сүзләрен хәтерләде: «Бөтен көчемне, бөтен сәләтемне, актык тамчысына кадәр бөтен канымны халык бәхете өчен бирергә әзер торам!..» Тагын шуны искә төшерде: хәзер иптәшләренең күзләре өмет белән аңа текәлгән. Алар көтәләр. Алар гына түгел, шәһәрләр һәм авыллар көтә, халыклар көтә. Халыкның коммунистка булган ышанычын алдарга ярамый. Ул үзенә көч өстәлгәндәй тойды.

Беренче мөмкинлек булу белән атакага күтәрелергә торган сугышчылар Мансурның һәр хәрәкәтен дулкынланып күзәттеләр.

— Барып кына җитсен иде!

Ул бик сакланып шуышты. Әле бик тиз хәрәкәт итте, әле бөтенләй тынып калды. Пулялар, тузан күтәреп, якын гына килеп кадалалар. Әмма, нинди могҗиза беләндер, берсе дә аңа тими.

...Метр үтелде, тагын бер метр... Ут бөркеп торган дот амбразурасы якында гына: аңа кадәр 15—20 метрлап кына калды. Шул вакыт Вәлиуллин, күтәрелеп, амбразурага бер-бер артлы ике граната ташлады һәм автоматтан озын очередь бирде. Каты шартлау яңгырады, һавага туфрак, төтен болыты күтәрелде. Дошман пулеметы тынды. Әмма совет сугышчылары атакага күтәрелгәннәр генә иде, дотка тагын җан керде, безнең берничә солдат пулялар тиеп егылды, калганнары кабат җиргә сыендылар.

«Сержантның бүтән гранатасы юк. Хәзер нишләр икән инде ул?» — дип уйланды батальон командиры, борчылып.

Ә Мансур фашист дотына һаман якынрак шуышты, һәм... бөтен буена күтәрелде дә алга, гомеренең соңгы чигенә, дошман амбразурасына ташланды. Пулемет тынып калды. Батыр сугышчы дошман доты амбразурасын күкрәге белән каплады.

Батальон сугышчылары, бердәм булып, үч ялкыны белән дошманга ташландылар

— Ватан өчен!

Менә — Мефодиевка азат. Бу сугышта йөзләрчә гитлерчылар юк ителде.

...Шәфкать туташы дошман доты янында өлкән сержантның хәрәкәтсез гәүдәсен табып алды. Колагын аның канлы күкрәгенә куйды да шатланып кычкырып җибәрде:

— Исән! Ул исән!..

* * *

Мансур дәваланган госпиталь диңгез буенда иде. Сугышка кадәр анда санаторий булган. Бакча белән әйләндереп алынган якты биналарның тәрәзәләре диңгезгә карап тора. Тыштан караганда, монда сугышка кадәргедән берни дә үзгәрмәгән кебек. Ә эчтән бөтенләй башкача. Палаталар чәчәк исе белән түгел, дарулар исе белән тулы. Алардан ял итүчеләрнең ваемсыз көлүләре түгел, сугышта гарипләнгән кешеләрнең ыңгырашулары ишетелә.

Вәлиуллинны аерым палатага урнаштырдылар.

Ике йөз кырык биш көн көрәште Мансур үлем белән. Бу бер кешелек палатада сигез ай буена бер тавыш та ишетелмәде. Ике йөз кырык биш көн буена батыр аңына килмәде.

Яз көне, ап-ак чәчәккә күмелгән алмагачлар, чиәләр исерткеч хуш исләр бөркеп утырган чакта, Мансур күзләрен ачты. Иң элек ул түгәрәк битле шәфкать туташының зәңгәр күзләрен күрде.

— Мин кайда? — дип сорады Мансур, хәлсез тавыш белән.

Шәфкать туташы җавап урынына шатланып кычкырып җибәрде:

— Аңына килде! Безнең Мансур аңына килде! — һәм ул палатадан чыгып йөгерде.

— Доктор, Вәлиуллин аңына килде! Җиңү!

Палатага врачлар һәм шәфкать туташлары җыелдылар. Барысы да теге дөньядан кайткан, үлемне җиңгән батырга сокланып карадылар.

— Молодец,— диде врач һәм күзләреннән бәреп чыккан яшьләрен сөртергә читкә борылды.

Вәлиуллин нәрсәдер әйтергә теләгән иде,— ләкин врач аны бүлде:

— Бер сүз дәшмә, герой... Хәзер яшисең, яшәргә тиешсең...

...Бер айдан соң Мансурга йөрергә рөхсәт иттеләр. Соры тестәге халатын киеп, билен буып, өлкән сержант бакчага чыкты. Эссе иде. Диңгез өстендә, ерак офыкка кадәр, бер генә дулкын да юк. Агач яфраклары да, йокыга талгандай, селкенеп тә карамыйлар.

Терелеп килә торган яралылар аллеялар буйлап йөри. Күпләре култык таякларына таянган.

Мансур да бер аллея буйлап атлады, мен төрле чәчәкләрне, пальмаларны, кипарисларны исе китеп карап йөрде. Аннары диңгез буена төште... Яшел беседка эчендә кемдер саф тавыш белән бик матур һәм моңлы итеп җырлый иде. «Кара әле, безнең турыда, Новороссийскины саклаучылар турында, җырлый түгелме соң бу?» — дип, бик бирелеп җырны тыңларга кереште.

**«Мой нежный друг свой город вспоминает,**
**Где он любимую когда-то повстречал...**
**А город близко... В синей дымке тает**
**Далекий развороченный причал.**

**Там дым пожарищ, там — огонь и слезы,**
**Там город ждет, любимый и родной,**
**Чтоб навсегда забыть про бомбовозы,**
**Про все страдания, пришедшие с войной.**

**О наших будут петь с любовью,**
**О схватках наших боевой поры.**
**Как обжигали наши лица кровью**
**Новороссийские суровые ветры.**

**К родным руинам мы придем, товарищ!**
**Мы опрокинем банду палачей!**
**И встреча средь развалин и пожарищ**
**Огня пожаров будет горячей».**

Җыр Мансурны дулкынландырды. Новороссийск таулары, «Кече җир», шәһәрдәге җимерекләр, һәлак булган иптәшләре хәтеренә төште.

Көннәрнең берендә, җыеп барылган газета битләрен караштырып утырганда, Мансур Новороссийск өчен барган сугышлар турындагы язмаларга юлыкты. Иптәшләренең батырлыгы, үзе катнашкан бу сугышның әһәмияте турында ул тетрәнеп укыды.

Сугышчан иптәшләре кайда икән хәзер? Ул госпитальдә яткан арада сугыша-сугыша әллә ни кадәр җир үткәннәрдер инде алар! Сугышлар инде Украинада, Белоруссиядә, Молдавиядә бара. Тиздән безнең гаскәрләр Ватан чикләрен атлап чыгарлар...

Көн артыннан көннәр үтә торды. Мансур да инде сәламәтләнде диярлек. Ләкин врачлар аны чыгармадылар.

Көннәрнең берендә ул врачтан сорады:

— Доктор, хәзер миңа нишләргә инде?

— Моңа җавап бирү авыр түгел. Өегезгә китәсез, гражданскига.

— Мин инвалид түгел бит, сау-таза.

— Тазасын таза, ләкин бик үк түгел. Сезгә әле дәваланырга кирәк. Аннары күз күрер.

Тагын бер ай узды. Ниһаять, аңа госпитальдән чыгарга мөмкин булуын белдерделәр. Документларын алгач, үз киемнәрен кигәч, Мансур ординатор бүлмәсенә керде.

— Менә, доктор, китәм инде. Рәхмәт сезгә, минем өчен бик күп тырыштыгыз.

— Ни эшләргә мөмкин, барысын да эшләдек,— диде хәрби врач, тыйнак кына.— Безнең эшебез шул. Ләкин иң күбесен сез үзегез эшләдегез. Сез, Вәлиуллин, тимер кеше. Терелерсез дип уйламаган идек. Хәзер инде әйтергә мөмкин: хәлегез бик авыр иде... Молодец сез, молодец! Үлемне җиңдегез. Мөмкин булганны гына түгел, мөмкин булмаганны да эшләдегез.

Госпитальдән чыккач, Мансур Вәлиуллинны Бобруйск шәһәрен азат итү өчен сугыш алып бара торган частьларның берсенә җибәрделәр.

Тирә-якта — фашистлар тарафыннан яндырылган, көйдерелгән, тәмам бөлгенлеккә төшерелгән белорус җире. Борынгы шәһәрләр урынына — төтен белән сөремләнгән ташлар өеме, авыллар урынына — тырпаеп торган морҗалар, тол хатыннарның, аналарның елаудан шешенеп беткән күзләре. Боларны күреп, күпне кичергән сугышчыларның да йөрәге тетрәде, алар дошманнан үч алырга омтылдылар.

Шәһәр өчен сугышлар ун көн барды. Ун көн Мансур сугыштан чыкмады. Ә унберенче көнне дошман минасы ярчыгы... яралады. Тагын медсанбат, тагын госпиталь койкасы.

Ике ай дәваланганнан соң, госпитальдәш дуслары белән саубуллашкач, Мансур Бакуга иң кадерле кешесе Гали Вәлиуллин янына китәргә уйлады. Аның иң кадерле хисләре, иң кадерле истәлекләр бу кеше белән бәйле...

Мансур бик яшьли ятим калды, озак вакытлар сукбайлыкта йөрде. Шулай йөри торгач, аңа гаять киң күңелле кеше — Гали ага очрады. Ул Мансурны аякка бастырды, тормышның олы юлына алып чыкты, аны чын кеше итеп тәрбияләде. Менә шуңа күрә Мансур Гали аганың фамилиясен дә үзенә дә яздырды.

26 Баку комиссары исемендәге нефть промыселлары идарәсендә Мансур Вәлиуллин мактаулы нефтьче һөнәренә өйрәнде.

1953 елда идарәгә Әзербайҗан ССР Верховный Советы Президиумы вәкилләре килделәр. Шул көнне Мансур Вәлиуллинга югары бүләк — сугышчан Кызыл Байрак ордены тапшырдылар. Бүләк батырны ун елдан соң эзләп тапты. Менә шунда гына иптәшләре Мансурның 1943 елның сентябрендә Новороссийск шәһәре янында нинди батырлык күрсәткәнен белделәр. Аның күкрәгендә Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыкларының билгесе булып хәзер сигез орден һәм медаль балкый инде.

Аннары ул туган ягына — Татарстанга кайтып, Әлмәттә нефтьче булып эшкә кереште. Ләкин сугыш елларында алган яралар үзләрен сиздерде, сәламәтлеге мактанырлык түгел иде. Мансур промыселдан китәргә мәҗбүр булды. Хәзер ул 14 номерлы Әлмәт автохуҗалыгы коллективы члены, маляр булып эшли.

Һәркөн иртән шоферлар, слесарьлар, электриклар, механиклар бу гади, тыйнак кешене ерактан ук сәламләп узалар:

— Хәерле иртә, Мансур абый, исәнмесез!

Матур итеп, шома итеп буялган, ялтырап торган машиналарын кабул итеп алганда, шоферлар:

— Рәхмәт, Мансур абый,— диләр,— кулларыгыз алтын сезнең!

Куллар... Бик күп эшләр башкарды ул куллар, күпне күрделәр. 1943 елда пулемет пулялары белән тишкәләнеп беткән булсалар да, алар — хәзер дә әле сафта.

...Новороссийск шәһәре Цемес бухтасы буйлап җәелеп утырган. Бухтаның сул як ярында кулына автомат тоткан маһабәт матрос һәйкәле тора. Бу — билгесез матроска салынган һәйкәл. Аның тирәсендә чәчәкләр үсә. Ә Батырлар мәйданында мәңгелек ут яна, курантлар тавышы яңгырый.

Мәңгелек дан уты мәңге сүнмәгән кебек, Ватан өчен, бәхет һәм азатлык өчен көрәшләрдә соңгы тамчы каннарын да кызганмаган батырларның исемнәре кешеләр күңелендә мәңге яши. Шундый исемнәр арасында безнең якташыбыз — Матросов батырлыгын кабатлаган, куркусыз батыр, сугыш ветераны, коммунист Мансур Вәлиуллин да бар.

## Альберт Айнетдинов

# ХӨРМӘТ БЕЛӘН ТЕЛГӘ АЛАБЫЗ

*Фронт газеталары битләреннән*

Хәрби архивта Төньяк-Көнбатыш фронты каршында татар телендә чыккан «Ватан өчен» газетасының беренче номерын зур кызыксыну һәм дулкынлану белән карыйм. Газета 1942 елның 10 июлендә чыга башлый. Редакторы Гани Гыйльманов, хәрби хәбәрчеләре — Х. Госман, А. Әхмәдиев, Ш. Мөдәррис, Н. Яһүдин, Г. Насрый, А. Салеевлар була. Аннары башка фронтларда да татар телендә газеталар бер-бер артлы чыга башлый: «Алга, дошман өстенә», «Ватан намусы өчен», «Ватанны саклауда», «Кызыл сугышчы», «Фронт правдасы», «Ватан өчен сугышка», «Совет сугышчысы», «Фронт хакыйкате», «Сталин байрагы», «Сталин сугышчысы», «Кызыл Армия», «Суворовча кысрыклау», «Җиңү байрагы», «Суворовчы», «Тревога».

Бу газеталарда Ш. Маннур, А. Шамов, А. Әхмәт, М. Гыймадиев, К. Ахмеров, Ә. Ерикәй, Р. Ишморат, Г. Хуҗи, М. Садри, Ф. Басыйров, И. Гази, Ә. Фәйзи, К. Хисмәтуллин, Г. Әпсәләмов, Г. Хәбиб, М. Савельев, М. Максуд, Г. Галиев, Г. Кутуй, М. Кәрим, Г. Әхметшин, М. Шәйми, Р. Бәһау, Б. Корбанов һәм башка бик күп язучылар һәм журналистлар актив катнаша.

...Фронт газеталары битләрендә патриотизм темасы күп вакытта туган ил образы, халкыбызның патриотик һәм азатлык традицияләре белән бәйләнештә күрсәтелә. Мәсәлән, хәрби журналист Х. Госман үзенең бер мәкаләсендә болай ди:

«...1917 елның октябрендә халыклар азатлык алдылар, хөр Россия барлыкка килде... Татар халкы дәүләте — Татарстан төзелде. Бу татар халкының тарихында беренче бөек көн, чиксез бәйрәм иде. Социалистик реконструкция елларында Татарстан хезмәт иляәре электән хыялга да китерә алмаслык юл үттеләр... Гасырлар буе караңгылыкта изелеп яткан татар халкы социалистик культураның биеклекләренә күтәрелде. Татар халкы арасыннан галимнәр, атаклы шагыйрьләр, язучылар, композиторлар күтәрелеп чыктылар...» [1].

«Без элек ярлы һәм хокуксыз идек,— ди яза ефрейтор Г. Камалетдинов.— Октябрь безгә ирек, хокук алып бирде. Совет хөкүмәте, колхоз мине баетты, мул тормышлы итте. Мин ятсыз, сыерсыз идем. Колхоз мине сыерлы итте, һәр ел саен эш көненә 8—10 килограмм икмәк ала идек. Тормыш бик яхшырган иде. Дүрт баламның өчесе мәктәпләрдә укыйлар иде. Тик бу немец каһәрләр безнең тынычлыкны боздылар» [2].

---

[1] «Ватан өчен». 28 июль. 1942 ел.
[2] «Фронт хакыйкате». 12 ноябрь. 1944 ел.

Хәрби газеталардагы «Орденлы Татарстан», «Татарстан фронтка», «Татарстанның 25 еллыгы алдыннан» һәм башка бик күп мәкаләләрдә халкыбызның социализм төзүдә ирешкән уңышлары һәм Совет Татарстанының фронтка ярдәме турында язылган.

Фронт газеталарында ил образын чагылдырган, сугышчыларны канлы көрәшкә чакырган ялкынлы шигырьләр дә даими басылып килгән. Менә шуларның берсе:

...Монда һәр нәрсә минеке,
Монда мин үзем хуҗа,
Ул мине, сөтен имезеп,
Көрәшче иткән җирем.

Салкында да, ялкында да
Мин илем өчен барам;
Тик аның яшәве генә —
Данлы яшәвем минем [1].

Татар егетләре Ак диңгездән алып Кара диңгезгәчә меңләгән чакрым сугыш кырларында үзләрен аямыйча көрәшәләр.

«Мин үземнең туган авылымны (Карамалы, ТАССР) саклау өчен килдем,— дип яза Гобәй Гафиятуллин,— ә Алеша Огородников үзенең туган Смоленск җирләре өчен сугыша. Без икебез дә Ватаныбыз өчен сугышабыз...» [2]. Шушы ук фикерне Г. Кутуй менә шундый шигырь юллары белән куәтли:

Рус шәһәрен ярсып яклаганда
Күзләремә Казан күренә [3].

Хәрби журналист Гамир Насрыйның «Мәңгелек дан» дигән мәкаләсе татар халкы мәкале: «Ир егет үзе өчен туа, ил өчен үлә»,— дигән сүзләр белән башлана. Мәкаләнең кыскача эчтәлеге түбәндәгечә: өлкән сержант Каюм Миңнуллин команда пункты белән хәрби бүлекчәләр арасындагы элемтәнең өзеклеген кат-кат тикшерә. Ниһаять, батальон сугышка әзер. Башта безнең артиллерия эшкә керешә, ә аннан дошман ут ача. Кинәт элемтә өзелә. Миңнуллин, ярдәмчесе кече сержант Фроловка КП да калырга боера да, үзе ут астында элемтәне ялгарга чыгып китә. Шуышканда аның башына снаряд китеге тия, чигәсе буйлап кан ага башлый. Алга үрмәләп, өзелгән чыбыкның бер башын эләктереп, икенчесен эзли, шул вакыт снаряд ярыла һәм аның кулы катып кала. Икенче кулы белән чыбыкның очын таба һәм тырнагы белән изолентасын каера, шул вакыт Миңнуллинның аркасы буйлап чемердәп нәрсәдер үтеп китә. Ул һәлак була, әмма аның ике кулында тотылган чыбык аша ток үтә башлый, элемтә урнаша, бу безнең батальонның җиңүенә зур ярдәм итә. Өлкән сержант Миңнуллин үлгәннән соң I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә. Без аның батырлыгы, илгә бирелгәнлеге белән горурланабыз һәм Г. Насрыйның шигыренә кушылабыз:

Мәңгә көчле, мәңге мәгърур булып
Исемең калыр йөрәк түрендә.
Синең даның сүнмәс бер нур булып
Балкып торыр Ватан күгендә [4].

Халкыбызның азатлык һәм бәйсезлек өчен көрәшү традициясе турында язып, хәрби газеталар сугышларда Ватанга мәхәббәт хисләрен көчәйтәләр. «Татар халкының фронтовик-татарларга хатында, «Халкыбызның батыр уллары кебек сугышыгыз» дигән мәкаләләрдә һәм башка материалларда, мәсәлән, татар халкының Ливон сугышында (1558—1582 еллар), Наполеонны кууда катнашуы, 1853—56 елларда Севастополь

1 Ә. Ерикәй. «Ил». «Ватан намусы өчен». 12 январь. 1944 ел.
2 «Ватан өчен». 25 сентябрь. 1942 ел.
3 «Кызыл Армия». 10 декабрь. 1944 ел.
4 «Фронт хакыйкате». 23 сентябрь. 1944 ел.

оборонасында һәм беренче бөтендөнья сугышында үзләрен кыю, оста сугышчылар итеп танытуы хакында языла.

Гаскәри Кызыл Байракка турылыклы булу традициясенә багышланган материаллар да газета битләрендә күп күренә.

1942 елның 21 декабрендә гаскәри Кызыл Байракның яңа үрнәге кертелә. Газеталар Кызыл Байрак турындагы Положениене татарчага тәрҗемә итеп басалар.

Ватан сугышы кырларында совет солдатлары гаскәри Кызыл Байракка турылыклы булуларын бик күп тапкырлар күрсәтәләр, гомерләрен биреп булса да гаскәри Кызыл Байракны — батырлык, намус һәм дан символын — саклап калалар.

Мәскәүдә Кызыл Армия музеенда бер частьның Кызыл Байрагы эленеп тора. Ни өчен ул Кызыл Байрак музейга куелган соң!

Шушы сорауга җавапны без «Ватанны саклауда» газетасы һәм хәрби архив материалларында табабыз.

— Полкның хәле яхшыдан түгел,— ди полк командиры Бикеев гвардия старшинасы Казанбаевка.— Безгә ярдәмгә җибәрелгән кавалерия дивизиясе бер-ике сәгатьтән генә килеп җитәчәк, ә бу вакытта фашистларның штабны камап алулары мөмкин. Син — коммунист, сиңа полкның Кызыл Байрагын саклап калу бурычы йөкләнә.

Шәрифҗан Казанбаев Байрак йөртүчеләр белән шоссе буендагы куаклыклар арасыннан дошман позицияләрен читләтеп үтәргә тели, әмма аларны бер взводка якын фашистлар чолгап алалар.

Бу бәрелештә 5 совет солдаты җиңеп чыга, дошман чигенергә мәҗбүр була. Моны күреп ярсыган фашистлар бер ротага якын пехота һәм бронетранспортер белән яңа атака башлыйлар.

Казанбаев, кул пулеметыннан атып, дошман бронетранспортерын сафтан чыгара һәм фрицларны кыра. Бу каты сугышта безнең солдатлар өстенә фашистлар шактый мул кургаш яңгыры һәм ут сиптерәләр.

Казанбаев исән калган кызылармеец Терентьевка:

— Син мине утың белән саклап һәм каплап тор, ә мин Байракны җиргә күмәм. Полкташлар, бәлки, биредә безнең гәүдәләрне күргәч, Байракны кайдан эзләргә кирәк икәнен аңларлар,— ди.

Байракны җиргә күмгән арада Терентьев та каты яраланып үлә. Шәрифҗан дошман белән берүзе йөзгә-йөз кала, немец солдатларын бер-бер артлы дөмектерә, әмма үзе дә ике мәртәбә яралана — пуля аның күкрәгенә һәм сул кулына тия. Инде үндүртенче фашистны чәнчелдергәндә, Казанбаев өченче мәртәбә яралана һәм аңын югалта...

Беравыктан Шәрифҗан аңына килә һәм шоссе буйлап узучы машиналарны, атлы кешеләрне күрә. Атлыларны кубанкаларыннан танып, ул аларның безнең казаклар икәнен белә. Соңгы көчен җыеп, Казанбаев атлыларга кычкыра, яраланмаган уң кулын болгый.

— Сиңа, старшина, врач кирәкми,— ди Казанбаев янына килеп җиткән бер карт офицер.

— Монда, минем аста... Байрак...— ди Казанбаев һәм күмелгән җирдән полк Байрагын тартып чыгарырга тели, әмма аның куллары көчсезләнеп кала...

Шушы ук көнне гвардия Кызыл Байрагы полкка тапшырыла. Полк намусы шулай саклап калына. Шәрифҗан Габдрахман улы Казанбаевка, үзе үлгәннән соң, 1944 елның 13 сентябрендә Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

Фронт газеталары совет командирларына сугышчыларны кыю һәм батыр итеп тәрбияләүдә зур ярдәм итәләр. Тәрбия эшенең нәтиҗәсе сугыш кырында күренә. Мисал итеп Гали Хуҗиевның «Хатип Хәсәнов — Советлар Союзы Герое» дигән очеркын алырга була.

1943 елның август аенда дошман белән бер бәрелештә, Нехаевка авылы янында, Хәсәнов, яраланган килеш, 30 дан артык немецны дөмектерә. Шушы сугыш кырында күп кан агудан аңын югалтып, Хәсәнов немецлар кулына әсир төшә. Фашистлар, Хәсәнов һушына килгәч, аңардан сорау ала башлыйлар, телен ачтырырга теләп, аны җәзалыйлар һәм ахырда, совет солдатыннан бернинди хәрби серне сөйләтә алмаячакларын аңлагач, Нехаевка авылының бөтен халкы алдында Хәсәновның башын балта белән чабалар.

Хатип Хәсәен улы Хәсәновка, шулай ук үзе үлгәннән соң, 1943 елның 17 октябрендә Советлар Союзы Герое исеме бирелә[1].

Илгә көчле мәхәббәт дошманга нәфрәтне арттыра — бу ике мораль категория бер-берсе белән бик нык бәйле. Менә шуның өчен дә татар фронт газеталары, үз эпиграфлары итеп «Немец оккупантларына үлем!» дигән лозунгны алалар.

«Совет сугышчысы» газетасы, мәсәлән, 1944 елның 3 мартында Гадәттән Тыш Комиссиянең актын урнаштыра. Бу актта фашистларның совет дәүләт учреждениеләрен, мәктәпләрне, балалар бакчаларын һәм яслиләрен, шәхси өйләрне җимерүләре күрсәтелгән.

Безнең гаскәрләр Киев шәһәрен азат иткәч, «Алга, дошман өстенә» газетасы үзенең баш мәкаләсендә гитлерчыларның анда бер гаепсез 95 мең кешене үтерүе турында яза.

Шушы ук мәкаләдә комсомолец Сибгатуллинның Украина җирендә, дошманнан үч алып, 4 фрицны юк итүе, ә аның взводы 25 гитлерчыны дөмектерүе турында языла.

«Алга, дошман өстенә» газетасы[2] татар хатыны Гайшә Исламованың хатын бастыра. Ул үзенең хатында иренең Ленин шәһәрен саклаганда һәлак булуын, малае Иосыфның югалуын, Волхов шәһәрендә өч баласының немецлар тарафыннан үтерелүен яза.

Ананың йөрәк әрнеткеч сүзләре сугышчыларга нык тәэсир итә. Редакциягә Гайшә апаның кайгысын уртаклашкан һәм дошманнан үч алырга сүз биргән хатлар килә.

Сугышчыларда дошманга карата көчле нәфрәт тудыруда Германиягә куылып киткән совет хатын-кызларының хатлары һәм фашистлар тарафыннан әсирлектә җәзалап үтерелгән совет солдатлары турындагы мәкаләләр дә зур роль уйныйлар.

Менә «Ватан намусы өчен» газетасыннан (1944 ел, 11 апрель) берничә юл. Днепропетровск шәһәреннән Германиягә коллыкка алып кителгән уналты яшьлек Зөлхия Акчурина әнисе Хәбибә апага: «Әнкәем... без монда бер хуҗада 60 кыз эшлибез. Рус кызлары, татар кызлары, украинкалар. Безнең хәлне күз алдыгызга китерә алмассыз, безгә баш күтәрергә дә ирек юк»,— дип яза.

«Немецлардан үч алам,— дип яза кызылармеец Кәрим Гайнуллин, татар халкының фронтовикларга хатына җавап итеп.— Мин 30 фашист солдатын һәм офицерын дөмектердем, немецларның 5 пулемет точкасын һәм бер автомашинасын юк иттем»[3].

Сугышчыларның шундый рапортларын газеталар битләрендә йөзләп санарга була.

Ватан сугышы елларында илебез халыклары дуслыгын тагын да ныгыту һәм көчәйтү бурычын күп телдә, шул исәптән татар телендә дә, чыгучы фронт газеталары намус белән үтәделәр.

Татар солдатлары газета редакцияләренә җибәргән хатларында рус солдатларының хәрби эшне өйрәнүдә күрсәткән ярдәмнәре өчен чиксез зур рәхмәт белдерәләр. Менә, мәсәлән, Гомәр Азамов хатыннан өзек: «...Үземне рядовойдан офицер итеп тәрбияләп үстергән рус офицерларына мин чын күңелемнән рәхмәтләр укыйм...»[4].

Хәрби газеталар битләрендә шундый дуслыкка багышланган гомуми материаллардан тыш аерым дуслык үрнәкләре турында язылган хәбәрләр еш очрый.

Татар егете Булатов рус егете Смирнов белән дуслаша. Алар икесе дә автоматчылар. Бер сугышка керер алдыннан икесенә дә комсомол билеты тапшырыла. Мөһим бер биеклекне саклауда бу ике туган атакага күтәрелгән дошманны, бер-берсенә ярдәм итеп, кыралар һәм җиңеп чыгалар[5].

Гвардия капитаны А. Бикчәнтәев «Семья» исемле хәбәрендә бер орудие расчеты турында яза:

---

[1] «Ватан намусы өчен». 18 январь. 1944 ел.
[2] «Алга, дошман өстенә». 19 декабрь. 1944 ел.
[3] «Ватан намусы өчен». 11 февраль. 1944 ел.
[4] «Совет сугышчысы». 2 июнь. 1945 ел.
[5] «Ватан намусы өчен». 1 февраль. 1944 ел.

«...Орудие командиры Павел Иванович Чернобровкин — карелияле, төзәүче Александр Николаевич Хомченко — Белоруссиядән, тупны коручы Николай Андреевич Бабанов — мәскәүле. Установщик Хөсәен Гарифулла улы Ибраһимов — татар егете. Сәет Мәхмүдов — таҗик баласы.

Ватанның бу биш улының язмышын көрәш бергә бәйләде. 15 ай инде алар дошманга каршы рәхимсез сугышалар. 1943 елда да алар зур сынаулар үтте.

Август ае иде. Алар расчеты дүртенче числода зур бер урман районында дошманның миномет батареясын җимерде, танк атакасын кире кайтарды һәм бер взводка якын пехотасын юк итте. Шул ук көнне расчет мөһим биеклеккә налет ясады. Бишесендә — алар дошманның орудие утын бастырдылар. Алтысында — «тигр» яндырылды һәм тугызында — станоклы пулемет юк ителде. Августның унынчы көнендә — расчет дошманның сугыш кораллары складын, унберендә — үзйөрешле пушкасын һәм унөчендә — бер танкысын яндырды! Сентябрь, октябрь һәм ноябрь айларында да көрәш шулай дәвам итте...» [1].

«Фронт хакыйкате» газетасының 1944 елның 27 август санында чыккан «Корычтай чыныккан дуслык» дигән мәкаләсендә лейтенант Исламовның миномет взводында сугышчылар дуслыгы аеруча гыйбрәтле итеп сурәтләнә: «Лейтенант Исламов взводында рус Клименков, белорус Заводский, украинец Власюк, үзбәк Абич Базаров һәм башкалар күрсәткән батырлыклары өчен орденнар һәм медальләр белән бүләкләнәләр»,— диелә газетада. Аннары взвод командиры үзенең хәбәрендә барлык халыкларның бердәмлегенә туктала. Кече сержант Ю. Колыбенков «Кайгыбыз да, шатлыгыбыз да уртак» һәм өлкән сержант М. Клименков «Иптәшләремә ярдәм итәм» дигән хәбәрләрендә күп милләтле взвод солдатлары бер-берсенә хәрби техниканы өйрәнүдә ярдәм итүләре, кайгыларын уртаклашулары турында язалар. Шушы ук биттә ике дусның фоторәсеме бирелгән. Берсе рус — өлкән сержант В. Кошелов. Ул «Кызыл Йолдыз» ордены һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән. Ә икенчесе — «Сугышчан хезмәтләре өчен» һәм ике «Батырлык өчен» медальләре белән бүләкләнгән татар сугышчысы Т. Минһаҗев.

Траншеяда немецлар лейтенант Бәширов өстенә ташланалар. Лейтенант дүрт фрицны автоматтан атып үтерә. Шул арада бер немец, почмактан посып, лейтенант Бәшировка мылтыгын төзи. Яков Кучеров моны күреп ала да, йөгереп барып, Бәшировны кочаклый һәм дошман пулясы аңа тия. Кучеров, үлгән чагында, иптәшләренә болай ди: «Мин үземнең командирым һәм дустым Ислам Бәшировны коткардым. Мин үләм, ләкин үз бурычымны үтәвем белән үземне бәхетле саныйм».

Татар халкына фронтовикларның җавап хатын кабул иткәндә Советлар Союзы Герое Салих Вәлиев әйткән түбәндәге сүзләр мондый һәм шуңа охшаш мисалларга бик ачык нәтиҗә ясый:

«СССР халыкларының какшамас дуслык һәм туганлыклары, немец-ерткычны кыйнап бетереп безнең тулы җиңүгә ирешүебезне тәэмин итәр».

Салих Вәлиев чыгышыннан соң «Сугышчан хезмәтләре өчен» медале белән бүләкләнгән Мәрьям Гыймадиева да халыклар туганлыгы турында сөйли [2].

«Пулялар сызгыруы тынган арада,— дип яза өлкән сержант Җ. Хәсәнов,— безнең частьта төрле милләт сугышчылары кичәсе үткәрелде. Башта казакъ телендә доклад тыңладык, ә аннан соң күңелле үзешчән сәнгать концерты булды [3].

Сабан туе — халкыбызның бик яраткан бәйрәме. Ул хәтта фронтта да үткәрелә.

«...Мәйдан уртасына биек колга утыртып, аның башына кызыл флаг элдек,— дип яза кече сержант Гали Ибраһимов.— Күчмә китапханә төзедек, трофей кораллары күргәзмәсе оештырдык. Уен өчен кирәк булган капчыклар һәм башкаларны әзерләдек.

---

[1] «Ватан намусы өчен». 1 февраль. 1944 ел.
[2] «Ватан намусы өчен». 16 июль. 1944 ел.
[3] «Алга, дошман өстенә». 20 май. 1944 ел.

Сабан туеның төп өлеше бигрәк тә күңелле булды. Сугышчылар, бүрәнә өстенә менеп утырып, капчыклар белән сугыштылар. Аннан соң аякларына капчыклар киеп һәм йомыркалы кашыклар кабып узыштылар. Татарча көрәштә руслар, украиннар, татар, башкорт, казакъ егетләре катнашты. Сугышчылардан Саттаров һәм Киньягулов иптәшләр батыр булып калдылар...

Урал егете рядовой Иштәкбаев иптәшнең курайда татар, башкорт көйләрен уйнавын бик яратып, рәхәтләнеп тыңладык.

Шулай итеп, азат ителгән украин җирендә үткәрелгән сабан туе халыклар дуслыгы бәйрәменә әверелде».

Советлар Союзында яшәүче төрле халыкларның уллары, җиңү бәйрәменә багышлап, үзләренең тарихи автографларын Рейхстаг стенасында калдыралар. «Рейхстаг стенасында,— дип яза Берлинга кадәр барып җиткән журналист Шәрәф Мөдәррис,— рус исеме белән янәшә үк, үзеңә кечкенәдән таныш булган татар исемен дә очратасың. Алар гаять күп, саный китсәң — очына чыга алмассың. Менә алар: «Биредә Идел лачыннары булды. Аларны Берлинга ефрейтор Насыйров алып килде», «Сугышлар белән Сталинградтан алып Берлинга кадәр үттем. Галиев Абдул». «Монда Бранденбургны алучылардан: Сәхәбетдинов, Парушев, Гарешполь, Белкин, Карацука, Санников, Габриян, Хәбибуллиннар булдылар». «Минем сугышчан юлым: Сталинград — Берлин. Абделҗанов Х. С. Ульяновск». «Майор Хәмидуллин, майор Малыгин — Казань». «Ваһапов. Казан». «Халикова, Казан» һәм... башка бик күпләр [1].

Бөек Ватан сугышы елларында татар телендә чыккан 16 фронт газетасы сугышчыларны туган илгә бирелгәнлек, дуслык, дошманнарга карата көчле нәфрәт рухында тәрбияләү өчен зур эш алып барганнар. Газеталарның шул эше белән кыска гына таныштырган бу сүзне өлкән язучыбыз Афзал Шамовның моннан чирек гасыр элек әйткән сүзләре белән тәмамлау бик урынлы булырдыр шикелле: «Еллар үтәр, тарихчылар безнең газеталарыбызның саргайган битләрен дулкынланып актарырлар һәм хәбәрчеләребезнең иң кечкенә генә хәбәрләрен укып та: нинди изге, нинди бөек эш эшләгәннәр! — дип аларның исемнәрен бик зур хөрмәт белән телгә алырлар».

---

[1] «Фронт хакыйкате». 12 июль. 1945 ел.

Габдрахман Әпсәләмов

# ВАТАН КАЙДА ДА БЕР ГЕНӘ

Көннәр бер-бер артлы үтә барган саен Бөек Ватан сугышы еракрак кала, аңа инде тарих сәхифәләре итеп карыйлар. Соң шулай булмыйча! Сугышның безнең җиңү белән тәмамлануына нәкъ чирек гасыр үтте. Егерме биш ел кеше гомерендә аз вакыт түгел. Ләкин безгә, шул дәһшәтле вакыйгаларга турыдан-туры катнашкангамы, әллә кабатланмас яшьлегебез нәкъ шул чорга туры килгәнгәме, Бөек Ватан сугышы бер дә тарих булып тоелмый, барысы да әле кичә генә булган кебек, күңелдә аз гына да тонықланмаган, суынмаган. Ул чактагы көйдергеч нәфрәт тә, яңа ачылган зур, якты, бәхетле дөньяга бөркатлырак караш та, сугыш утларына кererгә әзер тору да — барысы да йөрәктә.

Минем хәтердә сугышның беренче атналары бик нык сакланып калган. Ул чакта мин Татгосиздатта комсомол комитеты секретаре идем. Безнең Казанга урыннарыннан сугыш кузгаткан кешеләр — Белоруссия язучылары килә башлаган, ашыгыч рәвештә госпиталь итеп корылган «Казан» гостиницасында беренче яралылар ята. Без, комсомоллар, Бауман райкомолында дежур торабыз, бер төркемебез Чернышевский урамында эшли — яңа госпиталь әзерли. Үзебез көн саен военкоматтан хәбәр көтәбез. Татар язучылары да берәм-берәм китә торалар. Бер көнне Татгосиздат коридорларында өстенә хәрби кием кигән, аягына обмотка ураган Габдулла Алиш күренде. Сөйләшкәндә һаман елмая иде. Бу минем аны соңгы күрүем булды. Шулай елмая-елмая ул үлемсезлеккә таба атлады. Тик ул чакта аның шулай буласын кем белгән!

Озакламыйча мин дә фронтка киттем. Сугыш елларында бик кыска итеп, көнен көнгә язгап, көндәлек язып барганмын. Шул көндәлекләрнең бер өлеше 1942 елда «Совет әдәбияты» журналында басылып та чыккан иде. (№ 7, 9, 10). Аларның басылып калуына бик шатмын. 1942 елның апрель, май, июнь айлары бит! Ватан сугышының иң авыр, иң кискен чагы. Совет кешесеннән бөтен яктан бик зур ныклык сорала торган чор. Дөресрәге, бу айларда совет системасының яшәү көче, совет кешеләренең аңа никадәр тирән ышанганлыгы тагын бер тапкыр сыналды. Минем язулар, билгеле, әллә ни түгел, ләкин анда миллионлаган совет кешеләреннән берсенең шул дәһшәтле еллардагы рухи йөзе чагыла.

Шуннан соң мин ул көндәлекләрнең дәвамын бастырмаганмын. Хәзер, редакциянең үтенүе буенча, шуннан кыска бер өзек бирәм. Әлбәттә, көндәлекләрне үзгәртмим, еллар инде аларга «тарихилык» төсен салганнар.

«... 26. 6. 1942 ел. Төннәр юк, кояш батарга да өлгермичә күтәрелә башлый. Агач башлары төннең төн буена алтынсуланып тора.



Ничә көн үтте инде, ә мин һаман кулыма карандаш ала алмыйм. Элекке взвод юк. Аңардан бары тик аерым кешеләр генә калган. Мишков, Алексеев, Гытин, Горбачев яраланганнар. Коваленко, Савченко, Зинков һәлак булганнар. Взвод, әйтүләренә караганда, сугышта зур батырлык күрсәткән. Безнең замполит Крамник «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән. Госпитальдән кайтучылар икәү — сержант Степанов һәм мин. Лейтенант Иващенко, ахрысы, бөтенләй кайтмас, дип сөйли Степанов.

Җәйге урман бигрәк матур, ләкин черкиләр бихисап. Иптәшләр алты көнгә разведкага киттәләр. Без вахтада торабыз, районны ныгытырга йөрибез. Җир монда бик әшәке икән, таш та ком, чирек метр казысаң — су, сазлык. Хәзергә бездә тынычлык, бары тик артиллерия генә ике яктан да ата. Без икенче эшелонда икән. «В бой за Родину» дигән фронт газетасында (русча) минем «Ротный миномет в бою» дигән мәкаләм басылган. Кичә политрук миңа Горький турында взводта беседа үткәрергә задание бирде. Шуңа әзерләнәм.

29. 6. Көннәр үтәләр дә китәләр. Безнең тормышта яңалыклар юк. Икенче эшелонда тыныч икән, тик артиллерия белән полковой минометлар гына ата. Миңа еш кына постта торырга туры килә. Отделение биргәннәре юк әле, чөнки комплект тулы түгел. Вакыт тизрәк үтсен өчен табигатьне күзәтәм. Ак төннәргә сәерсенеп карыйм. Кояш югары күтәрелмичә, тирәләй генә әйләнеп йөри кебек. Бөтенләй батмый. Тик төн үтеп, таң ата башлаганда буяулар гына ничектер нечкәрә, күктәге зәңгәрлеккә алсу төс йөгерә, бөдрә һәм ак кар кебек ак болытлар да алсулана. Барысы да ничектер үтә җиңел сыман. Һава гаҗәеп тын, шылт иткән тавыш юк, урман эче төтенле — салкынча.

1. 7. Иртә-кич өйрәнүләр. Миңа отделение бирделәр. Замполит медаль алып кайтты. Хәзер батальон штабы янында утырам. Мине бригаданың комсомол җыелышына делегат итеп сайладылар. Халык җыйналган арада шушы юлларны сызгалыйм. Салкынча җил исә. Йөз метрда гына күл. Күл өсте шадраланып тора: бер карыйсың — күгелҗем, бер карыйсың — зәңгәрсу.

Примакны күрдем, шигырь яза башладым, ди. Елмаям. Яратам шул гади украин егетен.

2. 7. Минометлардан атабыз. Бөтен начальство килгән. Атыш башлангач минем расчет беренче мина белән үк цельга тидерде.

— Записать установку! — дигән команда килә.

Кич белән киного алып бардылар. «Мылтыклы кеше»не карадык.

1. 8. Көндезге икеләрдә дошман артиллериясе көчле атыш башлады. Хәзер төнге унберләр, дошман уты тынтамый. Бездә сугышчан тревога. Тиз һәм яхшы әзерләнүебез өчен подполковниктан (аны бригада командиры диделәр) рәхмәт алдык. Мөгаен, бүген яки иртәгә дошман монда да һөҗүм башлар. Ни диим, без әзер.

2. 8. Дошман безнең алгы кырыйны тупка тота. Һөҗүм итәргә маташа, дигән хәбәр бар. Безнең частьлар нык тора, ди. Төнлә без дә разведкада булдык.

5. 8. Яңадан тревога, яңадан төнге разведкага йөрибез.

10. 8. И. Газиздан кичә хат алдым. Якын күргән каләмдәш дуслардан ерак җирләрдә хат алу — никадәр яхшы.

16. 8. Каен яфраклары саргая башлады инде. Яңгырлар ешайганнан ешая бара, ак төннәрдән соң төннәр һаман караңгырак. Без көн саен оборонаны ныгытабыз. Хәзер оборонаның ныклыгы никадәр әһәмияткә ия икәнен үз җилкәбездә татып беләбез, югыйсә солдат сүзгә генә артык ышанмый. Алгы кырыйда дошманның йөзләрчә үлекләрен күргәч, әһә, алай икән, дип куя. Хәзер «бер адым да чигенмәскә» дигән девиз да конкретрак төс алды.

31. 8. Мин байтактан бирле тарих белән мәшгуль [1].

10. 9. Әзерләнәбез. Иртәгә биш тәүлеккә разведкага китәбез. Безнең группада ике миномет булачак: минеке һәм сержант Степановныкы. Минем расчетымда гадәттәгечә өч кеше: Анисимов, Трушов һәм Размази. Соңгысы яңа кеше, белмим, калганнарына ышаныч зур, алар белән мин разведкага йөрдем инде. Авыр минутларда югалып калмаячаклар.

11. 9. Иртән биштә тордык. Караңгы иде әле. Киттек. Язгы сугыш урыннарын үттек. Исемсез үрләрдә туганнар каберләре. Анда минем иптәшләрем Коваленко, Калабухов, Хмара һәм башкалар ята. Каберлекләр яныннан тын гына үтәргә мөмкин, ләкин күңелдә бик тирән эз кала. Сугышта булмаганнар моны аңлар микән!

Кич белән акфиннарның оборонасына 200—300 метрга якын килеп яттык. Тегеләрнең сөйләшүләре, балта тавышлары, поход кухнясының килгәне ишетелә. Без күзәтәбез. Төнлә артка чигенәбез. Караңгы. Кешеләргә ял бирергә кирәк. Башкалар нарат төпләренә йомарланып яталар. Мин дежурный. Аяк астында ботак сынса, бераү йөткерсә — йөрәккә барып тия. Иптәшләр болай үзләрен тыныч тоталар, аптырау сизелми. Финнар төне буенча әледән-әле аталар, мөгаен, урманны «тарыйлардыр».

12. 9. Безнең снайперлар ике финны теге дөньяга озатты. Без, минометчылар, күзәтәбез, мәгълүматлар әзерлибез, дошманның ут нокталарын белгегә алабыз.

13.9. Дошман әллә инде безнең мондалыкны сизенә — пулеметлардан, минометлардан бертуктаусыз сиптереп кенә тора. Без икенче сопкага күчәргә мәҗбүр. Салкын.

14.8. Бүген безнең көн. Күзәтү нәтиҗәсе: алда дошманның сугышчан сагы, яңа дзот ясыйлар, шунда ук землянкалар, төш вакытында кыр кухнясы килә. Безгә приказ: дошманны аш вакытында юк итәргә. Мин үзем белән Анисимовны, Степанов наводчик Белуханы ала. Алга шуышып ут позицияләренә урнашабыз. Кинәт финнар ягыннан әллә безне күреп, әллә күрмичә, болай гына миномет ата. Миналар бераз читтәрәк төшеп ярыла. Безнекеләр аптырамый, тыныч кына көтәләр. Менә кухня да килә, күңелле шаулашып, аны финнар сырып ала. Вакыт! Без ут ачабыз, ярты минутта дошман башына егермеләп мина җибәрәбез. Нәтиҗә — уннан артык дошман солдаты һәм ике ат үтерелә, кыр кухнясы ватыла. Дошман арасында аптыраш, без ашыгып икенче сопкага күчәбез. Дошман аңына килә, артиллериядән ут ача, һавада разведка самолеты күренә. Без үзебезгә генә мәгълүм сукмаклардан частька кайтабыз. Кәефләр шәп, югалтулар юк.

15. 9. Без «өйдә». Сугышчан бурычны яхшы үтәгән өчен командование Анисимовка, Белухага, сержант Степановка һәм миңа рәхмәт белдерә.

24. 9. Афзал Шамовтан матур хат. Бик шатмын. Язасы килә, ләкин вакыт юк. Хәзер көннәр кыскарганнан кыскара бара, землянкада караңгы, бары тик мич яктысы гына, ә көндез утырып тын да ала алмыйсың.

19. 10. Безнең ротада Гыйззәтов дигән бер сугышчы бар. Ул яраланган булган. Дошманның шартлаткыч пулясы аның бер яңагыннан кергән, икенчесеннән актарып чыккан. Аны аңларга кирәк, югыйсә ул бик юаш сыман күренә. Миңа калса, җырлаган вакытта аның җаны ачыла. Ул татарча җырлый, әкрен генә, ләкин шундый моңлы, әйтерлек тә түгел.

Политотдел кушуы буенча көне буе минометчылар турында мәкалә яздым. 1942 елның 25 октябрендә безнең бригада төзелүгә бер ел тула. Мәкалә шуңа карата.

---

[1] Дәфтәрдә ниндидер җирле урыннарның, күлләрнең исемнәре бар. Ләкин алар нәрсә турында сөйли — хәтерләмим. Мине бервакыт бригаданың тарихын рәткә китерергә утырткannар иде. Сүз әллә шул турыда барамы икән?..

**31. 10.** Шинельләрне тапшырып, полушубкалар алдык. Минем тунымның кесәсеннән язу чыкты. «Дорогому бойцу! Чинила шубу Иванова Лида. г. Иркутск, ул. Желябова, 18, кв. 3».

Кичә Илья Эренбургның татарлар турындагы мәкаләсен укыдык. Бүген аңа хат яздым.

**17. 11.** Бүген Илья Эренбургтан хат һәм истәлеккә китап алдым. Менә аның хаты (югалса, монысы саклансын дип күчерүем):

«42 елның 10 ноябре.

Кадерле иптәш Әпсәләмов!

Дусларча хатыгыз өчен зур рәхмәт. Герой татарлар турындагы минем мәкаләмнең сезгә — татар кешесенә һәм язучыга (икеләтә компетенцияле судьяга) ошавына шатмын.

Сез дөрес язасыз: әдәбият белән шигырьләнер чак та килер әле. Җиңү булса — халык булыр, халык булса — әдәбият та булыр. Хәзер иң мөһиме — фрицларны юк итү.

Истәлек өчен сезгә үземнең мәкаләләр җыентыгымны җибәрәм. Үзегезнең сугышчан дусларыгызга кайнар сәлам тапшырыгыз.

Чын күңелдән уңыш һәм көч телим.

Илья Эренбург» [1].

**18. 11.** Мине партиягә кандидат итеп алдылар. Бу бөек исемне акларга бөтен көчемне бирәчәкмен.

**20. 11.** Сугышчан хәзерлеккә күчү турында приказ. Кич, караңгы землянка, иптәшләр әкрен генә җырлый:

В дали догорала заря...

**10. 12.** Комсомолец Джигало. Бер үзе дзотта калып, аны актык чиккәчә саклый һәм һәлак була. Шартлатылган дзот аңа һәйкәл сыман тора. Мин шул җимерекләргә бик озак карап тордым.

**11. 12.** Күптән инде «Искәндәр һәйкәле» дигән бер хикәя язасым килә. Ләкин утырып язарга кәгазь дә, вакыт та юк [2].

**18. 12.** Джигало турында армия газетасына мәкалә яздым.

**16. 3. 1943 ел.** Снайпер Г. Хафизов 33, снайпер Х. Сибгатуллин 54 фашистны үтергән [3].

**17. 3.** Бүген погоннар алдык. Тантаналы тостә сугышчыларга өләштем. Мин хәзер вакытлыча взвод командиры урынында.

**29. 3.** Бүген Казаннан Гази Кашшафтан хат алдым.

«Габдрахман дус!

Бик күп сәлам. Ниһаять, син минем бер хатымны алгансың икән. Мин шат. Тагын бер ачык хат язам, ул тизрәк барыр. Эшләр ничек бара соң! Ничек измәсен нәсез дошманның! Синең «Үлемнән көчлерәк» дигән хикәяң килде, аны «Совет әдәбияты»нда бастырырга торабыз. Син бит бу сугыш вакытында бик күп үстең. Кыска хикәянең тәменә һәм серенә төшенеп җиттең. Мин синең өчен куанып бетә алмыйм. Теге «Көндәлекләрең» дә бик көчле, син аны дәвам ит!.. Коралыңа да, каләмеңә дә зур уңышлар телим.

Хәзер Союзга Х. Хәйрине китереп утырттык. Таҗи язу эшенә китте. Ф. Кәрим өч көн торып, яңадан фронтка китте. Бик матур бер очерк калдырды. М. Максуд әле монда командировкага кайтты. Башка яңалык юк. Үзең ничек соң! Кәефең, сәламәт-

---

[1] Хатның русча оригиналы Казандагы әдәбият музеенда.

[2] Соңыннан бу хикәя «Үлемнән көчлерәк» исеме белән «Совет әдәбияты» журналында басылды. № 2, 3, 1943 ел.

[3] Моны мин берәр газетадан күчереп алганмын. Алар безнең частьта юк иде. Соңыннан, редакциягә күчеп эшли башлагач, Хәйдәр Сибгатуллин турында мәкаләләр дә яздым. 1965 елда Әгерҗедә Сибгатуллинны тагын очраттым. Ул инкассатор булып эшли иде.

легең! Кунакка кайтып китәргә исәп юкмы? Нәрсәләр язасың! А. Гомәрдән, Һаҗәрдән һәм малайлардан күп сәлам.

Сәлам һәм хөрмәт белән Гази Кашшаф»[1].

Кәндәлекләрдән чүпләп алган өзекләргә шушында нокта куям.

Сугыш елларында миңа кеше дә йөрми торган Карелия урманнарында, Заполярье таулары арасында, аннары Ерак Көнчыгышта хезмәт итәргә туры килде. Элек, сугышка кадәр, Ватан дигәндә үз тирәләребез генә күз алдына килә торган иде. Сугыш еллары Ватан төшенчәсен гаять тә киңәйтте һәм конкретлаштырды. Хәзер мин Ватан дигәндә кыргый урманнарда, күктә төньяк балкышы уйнаган, җирдә салкын җилләр генә сызгырган шәрә таш-тау арасында, исемсез күлләр читендәге солдат каберләрен дә күрәм. Алар, ул солдатлар, безнең кебек тормыш яратучы яшь кешеләр иде. Дусларын, семьяларын, туган якларын сагыналар иде. Кирәк булгач, гомерләрен, актык тамчы каннарына кадәр газиз Ватанга бирделәр һәм туган җирләреннән еракта ятып калдылар. Ләкин аларның исәннәргә әйтеп калдырган изге васыятьләре бүген дә яши: Социалистик Ватанны яратыгыз, аны беркемгә дә бирмәгез!

Бүген, Җиңү бәйрәме көнендә, бу сүзләрне тагын бер мәртәбә искә төшерәбез һәм алар безнең йөрәкләргә язылган, алар мәңге онытылмаслар, дип әйтәбез. Бу фронтовикларның һәм барлык совет кешеләренең иң олы анты. Ватан безнең өчен кайда да бер генә. Без Ватаныбыз белән үлемсез.

Моннан чирек гасыр элек без фашизмны тар-мар иттек. Ләкин аларның явыз калдыклары бүген Көнбатыш Германиядә тагын баш калкыталар, нацист башкисәрләренең җинаятьләрен төрле юллар белән акларга, ә дөньяга тынычлык алып килгән совет солдатларының бөек җиңүен ничек тә кечерәйтергә, аңа кара күләгә төшерергә тырышалар. Бүген без аларга тагын бер мәртәбә ачыктан-ачык әйтәбез: тыкшынмагыз, бәдбәхетләр! Совет кешеләре, җирдә тынычлык сөюче барлык илләрнең хезмәт ияләре сезнең чын йөзегезне бик яхшы күрәләр. Без уяу! Әнә, күрәсезме, ишетәсезме, безнең тыгыз сафлар ничек баралар! Без беренче дә янамыйбыз, әмма ут белән шаяручыларның кулларына суга беләбез!

## Госман Бакир

# ҖИҢҮ СӘГАТЕ СУККАНДА

**Сталинград тирәсендә фашист өерләрен дөмбәсләгәндә җиңү сәгатьләре тиздән киләчәгенә нык ышана идек инде. Ләкин ул көннәргә ирешү өчен алда бик озын һәм канлы сугыш юллары үтәргә кирәклеген дә төшенә идек без.**

**Мин — 120 миллиметрлы миномет батареясы командиры — дошман өстенә очырылган һәр мина җиңү сәгатьләрен якынайта кебек хис итәм. Дөрес, дошман белән һәр очрашу корбансыз үтми, ләкин без төшенкелеккә бирелмибез. Бу югалтулар дошманга каршы безнең ачуыбызны көчәйтә.**

**Беренче Украина фронтында чыгарыла торган «Ватан намусы өчен» газетасында хәрби хәбәрче булып эшли башладым. Менә шулай сугыш коралы каләмгә әйләнде. Тиздән дошман чиген үттек. Бер-бер артлы немец шәһәрләрен яулап алабыз. Шәһәр-**

---

[1] Сугыш елларында мин Г. Кашшаф, А. Шамов, И. Гази, Кави Нәҗми, Г. Бәширов, Х. Хәйри, А. Расих, Ә. Камал һәм башкалардан хат алганмын. Аларның кайберләре бүген дә миндә сакланалар.



*«Бөек Ватан сугышында җиңүнең 20 еллыгы» юбилей медале белән бүләкләнгән язучылардан бер төркем. Беренче рәттә (сулдан уңга): Мөхәммәт Садри, Госман Бакиров, Габдрахман Минский, Афзал Шамов, Гариф Галиев, Әхмәт Ерикәй; икенче рәттә: Сибгат Хәким, Мәҗит Рафиков, Газиз Иделле, Нәби Дәүли, Зәки Нури һәм Гали Хуҗи.*

ләр буш. Берлин тирәләрендә каты сугышлар бара. Без Заган исемле кечерәк кенә бер шәһәргә туктап, газетабызның чираттагы санын әзерлибез, кайберләребез Берлин тирәсенә барып килә, яңа хәбәрләр алып кайта. Күңел күтәренке, җиңү сәгатьләре якынлаша. Без көн-төн йокламый шул сәгатьләрне көтәбез. Ләкин дошман тиз генә бирелми. Гитлер үзе дәмекте. Ниһаять, Рейхстаг түбәсенә Совет байрагы эленде, 9 майга каршы төндә дошман бирелде. Фронт газетасында эшләүчеләр белән очрашканда, генерал Шатилов: «Без Берлинда булачакбыз!» — дигән иде. Шулай булды да. Без Берлинда! Җиңү бәйрәме итәбез, ләкин газетабызның редакторы Р. Ишморатов Берлин урамнарында барган сугышларда яраланып кайта. Казакъ газетасының хәбәрчесе Сухырбиков та уң кулын югалта. Җиңү көннәрен алар яралылар койкасында каршылыйлар.

Туп тавышлары тынгач, без немецларның атаклы шәһәре Дрезденга күченәбез. Эшләр шәп. Немец байларының менә дигән йортларында, мамык мендәрләр өстендә рәхәтләнеп ятабыз. Бүлмәбездә пианино бар. Шау китереп уйныйбыз, наборщик татар кызлары матур җырларын сузалар, ачык тәрәзә аркылы немец шәһәре урамнарында беренче тапкыр татарча җыр яңгырый.

Фашистик Германия тулысынча җиңелде. Шулай да Чехословакиядә аларның калдыклары әле үзләрен күрсәтәләр. Прага урамнарында рәхимсез сугыш бара. Ләкин алар гына тарих тәгәрмәчен кирегә борып җибәрә алалармы соң! Бу фашист калдыклары да җиңелде, Чехословакия туфрагы дошманнан азат ителде, фашист калдыклары, кая житте — шунда качып, тынып калдылар. Дөньялар монда да тынычлангач, безне Чехословакия аркылы Австриягә күчерделәр.

23 июнь. Җәйге матур кояшлы көн. Алда 500 километрлы озын юл үтәсе бар. Машиналарга төянеп Дрезденнан чыгып китәбез. Тигез асфальт юлда машиналар шуып кына бара. Уралга кадәр җиребезне басып алырга хыялланган дошманның үз туфрагында тантаналы юл үтәбез. Юл читләрендәге агачларда кызарып чиyәләр пешеп тора. Без, машиналарны туктатып, шулардан авыз итәбез. Тын гына утырган бу җимеш агачлары да: «Рәхим итегез, сез — җиңүчеләр!» — дигән кебек тоелалар.

Менә Чехословакия туфрагы. Игән кырлары диңгез кебек дулкынлап утыралар. Әле күптән түгел генә дошманнан азат ителгән Прага урамнары гөрләп тора. Ләкин без анда туктамадык, шәһәрдән ерак түгел бер авылга кердек. Су тегермәне янындагы бер йорт янында машиналардан төштек. Тегермәнченең алты почмаклы кирпеч өенең түшәменә тутый кош читлеге эленгән. Ят кешеләрне күргәч, ул, без аңламаган телдә, нәрсәдер быкылдый. Шаян гына бер иптәшем аның телен «аңлый» икән: «Гитлер капут, Гитлер капут»,— ди имеш ул. Әйләнә-тирәдәге һәрнәрсә безгә җиңү турында сөйли кебек шул!

Венада эшли башлагач, күңел түрендә сакланырлык бер гүзәл эш тормышка ашырылды: шәһәрнең үзәк районында Шварценбергганплац мәйданында җиңүчеләргә һәйкәл куелды. Менә шунда, 19 августта, безнең гаскәрләр парадка җыелдылар. Алар арасында Вена исемендәге полк гвардиячеләре дә бар. Алар — Австриянең башкаласы Венаны азат иткән батырлар. Советлар Союзы Герое генерал-полковник Гусев тантаналы чыгыш ясый. һәйкәл өстенә ябылган җаймә ачыла. 32 метр биеклектәге мәрмәр һәйкәлгә халык сокланып карый. Венаны азат иткәндә һәлак булган сугышчыларның исемнәре аңа алтын белән язылган. Бу һәйкәл — совет сугышчыларының батырлыгы турында мәңгелек истәлек.

## Илья Эренбург

# ТАТАРЛАР [1]

Донда артиллерист Хәсәнов Татарстанны яклый. Аның бите янган, көйгән. Дошман безнең батареяны тупка тота иде. Сугыш припаслары саклана торган сарай яна башлады. Хәсәнов уйлап-нитеп тормады. Ул йөзләп снарядны читкә алып китте. Ут аның битен һәм кулларын яндырды. Ә Хәсәнов әйтә: «Иң кирәге — снарядлар... Инде немецларны без көйдерәбез...»

Алар Татарстаннан, Башкортстаннан, Уралдан, Идел буйларыннан килгәннәр — һәйбәт солдатлар, кыюлар һәм хәйләкәрләр. Фронтта: «Бу — татар, сынатмас ул»,— дигән сүзләрне еш ишетәсең.

Гафиятулла Нигъмәтуллин — снайпер. Ул әйтә: «Мин гади фрицны да кыйныйм, әмма офицерларны һәм корректировщикларны кыйнау аерата куанычлы. Болар — ләгънәт төшкән шайтаннар...»

Иптәшләре аңардан: «Нәрсә соң ул шайтан!» — дип сорыйлар. Гафиятулла көлә: «Фриц ни, шайтан ни — икесе бер — фашист».

«Ал кирәгеңне, шайтан»,— дип кычкырып җибәрде дә Мөхәммәтшәриф Хафизов немецның башына приклад белән ямады. Кулга кул килеп сугышканда татар ачулы, һәм немец ефрейторы Рудольф Вольгангның үзенең кардәшләренә зарлануы юкка гына түгел: «Монда безгә каршы татар күп. Болар шашкан халык, һәм мин татар белән хәтта төшемдә дә очрашырга теләмәс идем».

Әбүбәкиров үзенең кәләше Зөһрәгә: «һәр көн саен бер немец үтерергә сиңа сүз бирәм»,— дип язды. Зөһрә белә: аның сөйгәне алдамас. Татар гвардеецлар — татар кызларының намусы өчен сугышка баралар. Татар егетләренең зәңгәр шәл турында үзләренең җырлары бар. һәм Байкузин җырлый:

Бибкәй матур суга бара,
Зәңгәр шәлен ябынган,
Яратса да, күзен салмый
Узып китә янымнан.

---

[1] И. Эренбургның бу мәкаләсен журналга А. Айнетдинов тәкъдим итте.

Юк, егет сугыштан кайтып: «Мин Ленинград янында сугыштым. Без шәһәрне саклап калдык. Без сине саклап калдык, чибәр Бибкәй»,— дигәч, Бибкәй Байкузинга карар.

Татар карты Сөнгат Гыйниятуллин улын сугышка озатканда: «Батыр бул, улым, Гыйниятуллиннар семьясын кешеләр хөрмәт итәрлек булсын»,— диде.

Зиннәт Гыйниятуллин Ленинград янында сугышты. Немецлар йөз, безнекеләр тугыз кеше иде. Зиннәт Гыйниятуллин чигенмәде. Ул батырларча корбан булды. Аның батырлыгын Ленинград исендә саклый, һәм бөек шәһәр карт Сөнгат Гыйниятуллинга әйтә: «Синең хәсрәтең — минем хәсрәт һәм синең горурлыгың — минем горурлык».

Татар егете Нурый Хәлиуллин нәрсә өчен сугыша! Ул сугышка кадәр ничек торганлыгын бик куанып сөйли: «Яхшы тордым... Бездә бодай менә нинди була!.. Ике сыер. Колхоз ат бүләк итте. Яхшы ат, аксыл кола ат...» Нурый Хәлиуллин нәрсә өчен сугыша! Ул уйчан гына итеп өсти: «Татарлар — горур халык. Без немец коллыгын теләмибез, азатлык сөябез».

Менә сугышчылар атакага баралар. Нурый Хәлиуллин белән беррәттән рус бара, чуваш Ларионов һәм Нурыйның дусты — немецлар пленлыгындагы Конотоптан килгән Гриценко бара. Алар һәммәсе дә немец өстенә баралар. Һәммәсенең дә баш очында, яшендәй булып, рус «ура»сы кукри. Иртәнге кояштан озын шәүләләр төшә, һәм сугышчылар белән бергә, шәүләләр сыман булып, аларның якыннары да баралар төсле тоела. Ә анда нәрсә шәүләсе! Азатлык шәүләсе. Горур кешеләр азатлык өчен һәм Ватан өчен сугышалар. Нурый Хәлиуллин татар егете һәм ул сынатмас.

Йөрәкне сүзләрдән дә көчлерәк ялкынландыра торган саннар бар: 85 — Садыйк Гомәров сиксән биш фрицны үтерде. 56 — Әхмәт Иштиряков сугыш кырыннан яраланган илле алты сугышчыны һәм илле алты мылтык алып чыкты. Ике гвардеец ничәмә рус кешесенең тормышларын коткарып калды!

Сержант Алексей Федорович Сибатилов миңа яза: «Гади рус сүзләре өчен сезгә рәхмәт, алар йөрәккә барып җиттеләр. Безнең Ватаныбыз нинди куркыныч эчендә икәнен без беләбез. Немецларга без пуля кызганмыйбыз. Ләгънәт төшкән немецларны без кырып бетерербез». Һәм минем сержант Сибатиловка җавап бирәсем килә: аның сүзләре минем йөрәгемә килеп җиттеләр, һәм мин аның пулялары немец йөрәгенә җитәчәкләренә ышанам.

Бар иде ике дус: Гобәй Гафиятуллин һәм Алеша Огородников — ике кыю пулеметчы. Алеша — Смоленск ягыннан, ә Гобәй — Татарстанның Карамалы авылыннан. Алар турында иптәшләре: «Хәзер аларны ут та, су да аера алмас»,— дилә‌р иде. Немецлар һөҗүм иттеләр. Алеша Огородниковны пуля аяктан екты. Гобәй ялгызы калды. Ә немецлар инде биш саженьда гына. Гобәй сөйли: «Мин Алешага карап алдым. Ул ята... Юк, совет кешеләре чигенмиләр! Минем дискларым бетте. Мин, сүгендем дә, гранаталарга тотындым. Немецлар белән мин озак сугыштым. Ахырда фрицлар чыдый алмадылар, качтылар...» Траншея каршында утыз немец үләксәсе ятып калган иде: Гобәй Гафиятуллин Алеша өчен үч алды.

Аларны хәзер ут та, су да аера алмас... Дуслык — бөек хис. Турылыклы дус һәммәсеннән кыйммәтле. Руслар белән татарлар гасырларча бергә яшәделәр, бергә хәсрәт чиктеләр, бергәләп шатлык күрделәр, дөньяның ачысын-төчесен бергә татыдылар һәм аларны хәзер инде ут та, су да аера алмас. Сугыш — кати, дәһшәтле эш. Без, немецлар кебек, сугышны: «Иң яхшы эш»,— димибез. Без тыныч хезмәт яратабыз, безнең гербта урак һәм чүкеч. Әмма безнең халкыбыз — батыр халык, ул тыныч кырларын кулына корал тотып яклый. Ул хәзер уракны кызга, чүкечне хатынга тапшырды, ул рус мылтыгыннан аерылмый. Ул ләгънәт төшкән басып алучыларны кырып бетерергә карар бирде, һәм ул аларны кырып бетерәчәк. Сугышта күп нәрсәнең асылы ачыклана. Сугыш — ул кешеләрнең хисләрен тикшерә торган лаборатория. Сугыш — югары дәрәҗәле дуслык чоры. Окоптагы кешеләр — дуслар. Һәммәсеннән дә — якыннарыңнан да, кардәшләреңнән дә кадерлерәк. Дустың өчен үз тормышыңны бирерсең һәм, икенче тормышым булса, анысын да дустым өчен бирер идем дип, икенче тормышың булмаганга үкенерсең. Шайтан-фрицлар өстенә дуслар — рус һәм татар баралар. Аларның дуслыгы утта сыналган. Аларның дуслыгы — немецларның үлеме ул[1].

[1] «Ватан өчен» газетасы, 1942 ел, 3 ноябрь.

# ФРОНТТАН ХАТЛАР

*Татарстан Дәүләт музееның татар әдәбияты экспозициясен ачу алдыннан безгә язучылардан, аларның туганнарыннан, дусларыннан Бөек Ватан сугышы фронтларыннан алынган күп кенә хатлар килә.*

*Хәзер инде саргаеп беткән бу кәгазь битләрен укыганда гаҗәпләнәсең: безнең фронтовик язучылар иң авыр моментларда да үзләренең тылда калган якыннары, туганнары турында гына түгел, татар әдәбиятының язмышы турында да чын күңелдән кайгырткannар. Үзләренең сугышчан үрнәкләре белән дә, иҗади эшчәнлекләре белән дә татар язучылары татар әдәбиятында хәрби-героик һәм патриотик теманы үстерү өстендә актив эшләгәннәр.*

*Татар язучыларының түбәндә укучыларга тәкъдим ителә торган хатлары бу турыда ачык сөйли.*

Флера АБДУЛЛИНА,
Татарстан Дәүләт музееның
әдәби бүлеге фәнни хезмәткәре.

Гази дус! [1]

Мин әле хәзер генә Союздан, мине озату кичәсеннән, кайтып кердем. Тагын ике сәгатьтән соң вокзалга төшәм. Син: «Нишләттеләр инде!» диярсең. Әйе, китәргә туры килә.

Соңгы сүзләремне сиңа язып калдырам. Исән-сау яшәгез. Тату булыгыз. Фронтовик язучыларның гаиләләрен ташламагыз. Күз-колак була торыгыз.

Мин русча җыентык калдырдым. Дөньяга чыгар дип ышанып китәм. «Рөстәм»нең дәвамын җибәрермен, А. Гомәр аны үзе китап итеп бирер (3 табагы «С. Ә.» журналында).

2 аем күңелле генә узды. Рәхмәт. Гаиләмнең хәленнән хәбәрдар булып тор, карточкадан өзмә.

Сәламәтлек теләп: Гадел.

12 июль, 44 ел.

Кадерле Таҗи ага!

Сиңа һәм Мәликә апага миннән кайнар фронт сәламе. Шулай ук бөтен язучы иптәшләргә миннән сәлам. Мин тагын бераз яраланып, яра төзәтеп ятам — өченче тапкыр утка керергә көч җыйнап ятам. Хәлем яхшыланып килә, шулай да бераз ятармын әле. Кичә-бүген күңел аеруча күтәренке. Беркемнән бернинди хат алганым юк иде. Кичә Кадриядән [2], кош теле хәтле генә булса да, бик матур хат алдым. Өстәвенә кичә: «Яраланган алдынгы фронтовикка» дигән, тылдан килгән бер бүләкне миңа тапшырдылар. Ул бүләк эчендәге хатны укыгач, минем (утны-суны берничә тапкыр кичеп, тормышның әллә нинди дәһшәтләрен күргән егетнең) күзләремнән яшьләр килде. Ул хатны әти-әнисен, бөтен якыннарын фронтта югалткан бер яшь кыз язган.

---

[1] Гази Кашшафка Гадел Кутуй язган хат.

[2] Кадрия — Ф. Кәримнең тормыш иптәше.

Таҗи абзый, мин фронтта бу юлы да сер бирмәдем, мылтык тотып ут эчендә актарылганда, татар совет язучыларының исемнәренә тап төшермәдем. Шулай ук, үземчә, бик тырышып иҗат өстендә дә эшләдем. «Кызыл Татарстан»га алты шигырь җибәрдем. «Совет әдәбияты»на зур гына бер цикл шигырьләр (12 шигырь) җибәрдем. Шул ук «Совет әдәбияты» журналына күптән түгел «Тимер һәм тимерче» дигән баллада һәм «Үлем уены» дигән үсмерләр өчен бер поэма җибәрдем. Вакытың булып кызыксынсаң, алып карап чык. Гомумән, минем җибәргән әсәрләремнең язмышлары белән бераз кызыксынып, аларның сыйфатлары турында бер-ике юл хат яз. Язучылар союзында нинди уңышлы яңалыклар бар, фронттагы язучы иптәшләрнең хәлләре һәм үзегезнең улларыгызның хәлләре ничек? Җәүдәттә байтак кына җырлар калдырган идем, файдаландылармы икән.

Үзем хәзер «Совет әдәбияты» өчен «Разведчик язмалары» дигән зур гына проза әсәре өстендә эшлим. Мин бит «Шакир Шигаев» дигән пьеса язган идем. Аны Сарымсаков иптәш кенә укып чыга алды. Башка иптәшләрне таныштырып өлгерә алмадым, яңадан фронтка китеп бардым. Шуны бик эшләп бетерәсе килә дә, мөмкинлек табып булмый. Ничек тә эшләп, Татар театрында куярлык дәрәҗәгә китереп, 42—43 ел сезонында файдаланылса бик әйбәт эш булыр иде. Ләкин әле кул тигезә алганым юк. Хикәямне дә өлгерү кешегә тиеш булган төнгә йокы сәгатьләрен бүлеп кенә, коптилка яктысында, тез өстендәге такта өстенә салып кына язам. Көндез һич мөмкинлек юк.

Шул чаклы язасы килә. Язган әйберләр күп. Аннан мин бер хәбәр ишеттем. Маннур эшләгән җирдә татарча фронт газетасы оештырыла булса кирәк. Фадеевлар аша мине шул тирәгә — Калинин фронтына якынайтып булмыймы? Матбугатка якынрак булыр идем. Анда булмаса, гомумән, язучылык юлы белән файдалану мәсьәләсен җайлап булмыймы? Татарча бернинди газета-журнал күргәнем юк. Китабым һаман чыкмый бугай әле.

Фатих Хөсни, Әхмәт Фәйзи иптәшләргә кыска гына хатлар язган идем, җавап алганым юк. Әллә хатларым бармады, әллә минем адресым алмашыну аркасында, язган хатлары миңа юлыкмады. Юкса, бу иптәшләр мине җавапсыз калдырырлар дип һич уйламыйм. Аларга миннән чын дусларча сәлам. Кави Нәҗмине дә фронтта дигән хәбәр ишеттем, әгәр Казанда булса, аңа һәм Сәрвәр апага күп сәлам. Менә шул. Үзең ниләр җимерәсең? Иҗат юлыңда нинди адымнар ясадың? Драма һәм опера театрларыбызның хәлләре ничек?

Ярый, хуш. Девалана торган җирем сугышкан җирем тирәсендә үк. Ә сугышкан җирем — сезнең хатлар килергә тиеш урам, ягъни адресым:

633 полевая почта, часть 204

Каримову Фатиху Валиевичу.

Сәлам белән кулыңны кысып — Фатих Кәрим.

22. XI. 42 ел.

Төхфәт! [1]

Мин бер ай буена Москвада политакадемиядә яттым. Күп кенә яхшы лекцияләр тыңларга туры килде. Хәзер инде дивизия газетасының редакторы итеп билгеләндем. 3 мартта Ташкентка чыгып китәм. Сәфәр Южный фронтка булыр, ахры. Кәефем ярыйсы. Бары тик синнән шуны гына сорыйм: минем семьяны кайвакыт хәтердә тоткалый тор. Аларның кәефләре яхшыдан түгел булса кирәк.

Ике Әхмәт тә вакытлыча Казанга кайттылар, уйлыйм: озакламый кире чакырырлар. Чөнки газета работниклары күп кирәк. Андый кешеләр газета өчен кадерле кадрлар. Ә запас һәрвакытта кирәк булып тора...

Кашшаф Гази, Ибраһим Гази, Кутуй, Шамов, Исхак дусларга сәлам.

Башка сүзем юк. Хат язгалагыз.

Сәлам белән Нур.

2 март, 1942 ел.

---

[1] Абдулла Төхфәткә (тәрҗемәче) Нур Баян язган хат



*Ватан сугышында катнашкан бер төркем шагыйрьләр.*
*Беренче рәттә сулдан: Ә. Маликов, С. Хәким, М. Хөсәен, икенче рәттә: Ш. Маннур, Ә. Фәйзи, Ә. Ерикәй, В. Земной, өченче рәттә: М. Мазунов, Ә. Исхак, Ш. Мөдәррис.*

Кашшаф иптәш!

Мин Кызыл Армия сафына алындым. Сиңа минем бер-ике соңгы үтенечем бар:

1) Минем «Кечкенә хикәяләр»гә договор төзесәң иде. Аннан «Яңа әни» хикәясен төшерергә кирәк. Редакцияләүгә А. Әхмәткә бирсәң шәп булыр иде. Син әйткәнчә әйбер өстәп булмады, ләкин шулай да ул кече балалар өчен кирәкле әйбер. Мин сездән аны чыгаруны бик сорар идем.

2) «Кечкенә тоткын» исемле пьеса, Германия белән договор төзешкәч, планда булса да, чыкмаган иде. Хәзер вакыты җитте дип уйлыйм. Үзегез карарсыз.

3) Мин Н. Булатның китабын редакцияләгән идем, ул $13^{1}/_{2}$ табак иде, бик кыскарды, 8—9 табакка калды. Шуның редакцияләү тәртибендә кыскартылуын акт белән оформить итәргә иде...

Сәлам белән А. Алиш.

14. VIII. 41 ел.

Дускай Хан! [1]

Хатыңны алгач та җавап язарга булдым. Сиңа мена ничек дип рәхмәтләр укып бетерергә дә белмим. Якыннарыңнан, дусларыңнан ичмаса бер генә җылы сүз уку да күңелне күтәреп, рухландырып җибәрә. Кайбер буш чакларны землянкага янсә блиндажга җыелышабыз да мактанышa-мактанышa бер-беребезгә хатларыбызны укышабыз. Күбрәк хат алучыларыбызны артык бәхетлеләр, азрак хат алучыларны уртача бәхетлеләр, ә бер дә алмаучыларны бөтенләй бәхетсезләр категориясенә кертәбез. Соңгы вакытларда мин урталар категориясенә кердем. Чөнки өйдән дә 15 көнгә якын хат килгәне юк иде. Нәрсә булгандыр, белмим.

Хан дускай! Мин хәзергә «аллага шөкер» исән әле. Кыска гына вакыт эчендә бик күп нәрсәләр кичерергә туры килде. Кайнар сугышлар, зур-зур походлар, шуның өстенә һәрбер сугышчың өчен кайгырту эзсез калмыйлар, әлбәттә...

---

[1] Хан Җәмилгә Рахман Ильяс язган хат.

Күбрәк фрицны үтереп, үз кешеңне азрак югалту турында кайгыртасың. Тирән һәм авыр кайгы. Хәер, сине башка нәрсәләр күбрәк кызыксындырадыр. Лакин, дускай, фронт картиналарын каләм белән язып бетерү мөмкинме соң? Күз алдына китер. Хыяллан. Сугыш. Моторлар шаулавы, снарядлар гөрселдәве, пуляларның туктаусыз очулары — кан, үлек гәүдәләр. Гаҗәеп күренеш. Нәкъ экрандагы төсле пейзаж... Бу бик табигый хәл булып күренә. Шулай булырга тиеш төсле. Тик якында, бик якында снаряд яисә мина шартлаганда, я булмаса җир белән күмеп киткәндә, яисә җүләр пулялар киемеңнең берәр җирен тишеп үткәндә генә йөрәк кылт итеп куя да, шул чакны гына яшәүнең никадәр кыйммәтле икәнлеген сизеп куясың.

Әй аннан тагын онытыласың. Дөресен әйткәндә, уйланырга вакыт булмый. Болай җәелеп хат язуыма гаҗәпләнмә. Алгы сызыктан бер километр чамасында торабыз. Аннан соң минем землянкамның түбәсе шулчаклы калын — 4 кат бүрәнә салынган, шайтан да алырлык түгел. Озынга китте, туярсың.

Үзем буш вакытларны, ягъни ялга чыккан араларда, язгалыйм. Дистәдән артык хикәя яздым. Пьеса язар өчен материаллар, эшләнгән темалар да бар. Тик озак итеп утырып язарга вакыт кына юк.

Риза Ишмораттан хат алдым. «Ватан намусы өчен» газетасында эшли икән. Алар анда күбәү. Газеталары сирәк-мирәк килгәли. М. Максудка «Совет сугышчысы»на хат язган идем. Җавабы юк әле. Аның анда эшләвен газеталары буенча белдем...

Безнең фронт — юго-зап. фронт газетасы ул. Настроение турында язып тормыйм. Ишең хаклы булгач, рух ничек булуы сиңа мәгълүм. Күңел күтәренке. Орел юнәлешендә безнең гаскәрләрнең һөҗүмгә күчүләре һәм союзникларның актив хәрәкәтләре бик шатландыра...

Иптәшеңә, гафу итсен, исемен оныттым, бик күп сәлам әйт. Иптәшләргә дә сәлам сөйлә.

Кашшафка, Кавига, Мирсәйгә, Гомәргә әйт, хат язсыннар. Кавига хат язган идем. нигәдер җавап язмый, иренә торгандыр, ахрысы. Ни әйтсәң дә, сез хат язарга күбрәк вакыт таба аласыз.

Хуш. Кулыңны кысам. Кайнар сәлам белән Рахман.

16. 07. 43.

Минем адрес бераз үзгәрде

Полевая почта 43020 а

Ильясову А. В.

# ЧУВАШ ХАЛКЫНЫҢ БӨЕК ШАГЫЙРЕ

Кешедән дә көчле юк
Шушы якты дөньяда,
Хуҗа булып ул яши
Җиргә дә һәм суга да.

*Максим Горькийның «Кеше — ул горур яңгырый» дигән канатлы сүзләре белән авazдаш бу юлларны чуваш халкының атаклы шагыйре Константин Иванов язган.*

*Константин Ивановның тормыш һәм иҗат юлы бик кыска була. Шагыйрь 25 яше тулыр-тулмас, 1915 елда, туган авылы Слакбашта үпкә авыруыннан үлә. Шул кыска гомерендә ул күп кенә шигырьләр, проза һәм драма әсәрләре язып калдыра. Аның «Нарспи» поэмасы — чуваш халкының иң сөекле әсәре. Ул шагыйрь Шәрәф Мөдәррис тарафыннан татар теленә дә тәрҗемә ителде.*

*Константин Иванов язмышы белән генә түгел, иҗатының рухы белән дә безнең Тукаебызга охшаш. Әнә шуңа күрә дә чуваш халкы аны без Тукаебызны яраткан кебек ярата, хөрмәт итә.*

*Константин Иванов 1890 елның 27 маенда, Башкортстан АССРның Бишбүләк районы (элекке Уфа губернасы, Бәләбәй өязе) Слакбаш авылында крестьян семьясында туа. Әти-әниләре, белемнең кадерен белгән кешеләр буларак, күп кыенлыкларга да карамастан, аны укытырга тырышалар. Сембер шәһәрендә укыганда һәм эшләгән чакларында шагыйрьгә Илья Николаевич Ульяновның дусты, чуваш мәктәпләре инспекторы, беренче чуваш мәгърифәтчесе Иван Яковлевич Яковлев та зур булышлык күрсәтә, аның иҗатына демократик юнәлеш бирә.*

*Тууына 80 ел тулу уңае белән без журналыбызда чуваш халкының сөекле шагыйре Константин Ивановның «Тимер талкы» исемле балладасын беркадәр кыскартып тәкъдим итәбез.*

## Тимер талкы

БАЛЛАДА

Безнең чуваш хатыннары
Күп талкыны яратмый:
Булса булсын, ди, жиз талкы!
Тимер талкы? Я, рабби!
Тимер талкының эчендә
Утыра, ди, карт шайтан.
Көтәләр икән кешеләр
Чыгар диеп ул кайчан?
Талкыны кеше тотуга
Тешен шыкырдата, ди.
Җитен талкыйм дигән чакта,
Ул күзгә чүп ата, ди.

Әгәр шул чүп күзгә керсә,
Булмый күреп чара, ди.
Карт шайтанның әмере белән
Тимер талкы, дөбер-шатыр,
Урам буйлап чаба, ди.

* * *

Борын-борын заманнарда
Яшәгән, ди, бер әби.
(Хәзер инде ул үлгән, ди,
Ята икән гүрдә, ди).
Ул карчыкның, исән чакта,
Булган ике сарыгы.
Сава торган бер кәҗәсе,
Бер мәче, бер тавыгы.
Яшәгән, ди, ябалаклар
Кыек өй чарлагында.
Теге тимер талкы булган
Шулар карамагында.
Бигрәк яман нәрсә икән —
Талкы китсә котырып.
Сукыр карчык нишли алсын,
Утыра, ди, аһ орып.
Карлыгач исемле киленен
Никтер ул яратмаган.
Гел тырышкан бәйләнергә,
Ләкин сәбәп тапмаган.

* * *

Бу килен бер көнне үзе
Сүз кушкан бит аңарга.
«Кунакка, апам янына,
Җибәр мине Агарга![1]»
— Аптыратма әле, зинһар,
Баш авырта болай да.
Вакыт җиткәч җибәрермен,
Бөтен язмыш ходайда...
Ял итми Карлыгач килен
Көн-төн эшли, тырыша.
Ә карчык аңа бәйләнә,
Ялкау син дип орыша.
Карчык күзләре, күрәсең,
Сукыраймаган юкка.
Сабыр бул, Карлыгач килен,
Үлгәч җибәрер, тукта!..
Өч көннән соң чибәр килен
Болай дия аңарга:
«Кунакка, апам янына,
Җибәр мине Агарга!»
— Үз башыңа сорыйсыңдыр,
Җир йоткыры үзеңне.
Нинди генә килен булдың,
Тыңламыйсың сүземне.
«Синнән сорыйм мин тагын да,

---

[1] Агар — авыл исеме.

Җибәр апам янына».
— Бик теләсәң, әйдә кит,
Сәфәр чыгып газап чик!..

Тиз генә Карлыгач килен
Сөт белән камыр изде.
Беләсез чуашта юсман[1]
Ризык буларак изге.
Ерак сәфәр чыккан чакта
Һәркем юсман пешерә.
Бәла-каза килсә аны
Һәркем искә төшерә.
Әнә безнең чибәр килен
Ипләп кенә ат җикте.
Тәмле пешкән юсман алып
Агарга чыгып китте.

* * *

Тимер талкы шалт-шылт итә,
Сүс талкый усал карчык.
Сихерле сүзләрен әйтә,
Тупсалы капка ачып:
«Шалт-шылт, талкы, шалт-шылт,
талкы!
Агар юлы белән кит.
Шалт-шылт итеп, тимер талкы,
Шул килен башына җит!»
Тимер талкы дөбер-шатыр
Чабып китте юл буйлап.
Күңеле бәла сизгәнгә,
Җибәрде килен җырлап:
«Ай яктысы бик якты,
Агар юлы тап-такыр.
Атым-лашам, һәй, чаптыр...
Котын ал син дошманның,
Сөттә изгән юсманым!»
Бер юсманын чибәр килен
Ташлый узган юлына —
Җиттем генә дигән чакта,
Талкы кире борыла.
«Шалт-шылт, талкы,
Шалт-шылт, талкы!
Агар юлы белән кит.
Шалт-шылт итеп, тимер талкы,
Шул килен башына җит!»
Тимер талкы дөбер-шатыр
Чабып бара юл буйлап.
Күңеле бәла сизгәнгә,
Җибәрә килен җырлап:
«Ай яктысы бик якты,
Агар юлы тап-такыр.
Атым-лашам, һәй, чаптыр...
Котын ал син дошманның,
Сөттә изгән юсманым!»

* Төче күмәч.

Иң соңгы юсманың килен
Ташлый узган юлына.
Життем генә дигән чакта,
Талкы кире борыла...

* * *

Житсә килен туганына,
Бикле икән зур капка.
«Ач капканны, ач, апа,
Коточкыч нәрсә артта.
Явыз дошман куалый,
Минем артымнан калмый!»
— Нинди кунак, кайдан килгән?
Йокы тәмле бу чакта.
Көткән кунагым юк минем,
Үз юлың белән атла!
«Алай булса, хуш, апа!»
Безнең килен атын тотып
Күрше урамга атлый.
Икенче бер апасының
Капкасын шак-шок шакый.
«Ач капканны, ач, апа,
Коточкыч нәрсә артта.
Усал дошман куалый,
Минем артымнан калмый!»
— Нинди кунак, кайдан килгән?
Йокы тәмле бу чакта.
Көткән кунагым юк минем,
Үз юлың белән атла!
«Алай булса, хуш, апа!»
Инде Карлыгач каршында
Тора өченче капка.
«Абый, абый, ач әле, дим,
Коточкыч нәрсә артта.
Явыз дошман куалый,
Минем артымнан калмый!»
— Нинди кунак, кайдан килгән?
Йокы тәмле бу чакта.
Көткән кунагым юк минем,
Үз юлың белән атла!
Кем ул анда шакып йөри
Төнлә йокы бирмичә!
«Алай булса, хуш, пиччә! [1]»
Елап талгач, чибәр килен
Эвенлектә йоклады.
Туганнарының берсе дә
Аңа каршы чыкмады.

* * *

Зарыгып көтә талкысын
Карчык капка төбендә:
«Тилергәндер ул, күрәсең,
Юк, күренми бүген дә».

---

[1] Абый, ага (чувашча).

Аптырагач, күз бууччы
Чакыра үз янына,
Сихерле сүзләрен әйтә
Карап Агар ягына:
«Шалт-шолт итеп, тимер талкы,
Үз өемә кайтсана.
Үз түреңдә, үз иркеңдә
Чарлагымда ятсана».
Менә кайдадыр еракта
Аждаһадай үкерә,
Котыргандыр тимер шайтан,
Ул дөбер-шатыр кылә.
Тимер талкы кайтып житте,
Урам буйлатып гизде.
Өй янында көтеп торган
Карчыкның башын өзде.

* * *

Үтеп китте караңгы төн,
Сызылып ал таң атты.
Ниһаять, яңа көн туды,
Көмеш нур чәчте якты.
Авыр йокыдан уянды
Таныш авыл Агара.
Чуваш, чуваш, нужа күреп
Синең чәчең агара.
Әнә эшкә таңнан торып
Кереште безнең піччә.
Күргәч, сеңлесе гәүдәсен
Сулыш алалмый һич тә...
Бер карт бара урам буйлап
Сакалы ике колач.
Жил тегерменендә эшләп
Көн уздырадыр чуваш.
Бөкересе ике пот, имеш,
Ә кулында таягы.
Үрдәк сыман атлый үзе,
Кәлтер-көлтер аягы.

* * *

Иртән жиңгиләр, пиччәләр
Һәй, урамга жыелган.
Сукыр карчык үлеп ята,
Тирәсе — дегеттәй кан.
Башы карчыкның читтәрәк
Гәүдәсеннән чак кына.
Үле тынлык. Юк, чарлакта
Шалт-шолт итми талкы да...
Барысы талкы турында
Фикер йөртә үзенчә,
Сөйли телләре талганчы
Йөзесе йөз төрлечә.

Чувашчадан **Кави Латыйпов**
тәрҗемәсе

# РЕСПУБЛИКАБЫЗНЫҢ КУЛЬТУРА ҮСЕШЕ

*ТАССР Культура министры Булат Гыйззәтуллин белән әңгәмә*

**СОРАУ.** Иптәш министр, бүген Татарстан культура, сәнгать учакларының хәлләре ничек һәм аларда Татарстанның илле еллыгына әзерлек эшләре ничек бара!

**ҖАВАП.** Безнең Татарстанда хәзер ике мең ярымнан артык культура йортлары бар. Авылларда культура учаклары соңгы елларда, культура йортлары төзелешенең өчьеллык планнары үтәлгән елларда, аеруча нык үсте. 1965—1967 елларда үткән беренче өчьеллык чорында бездә 72 мең урынлы 414 клуб биналары, миллионнан артык китап урнаштыра ала торган 122 китапханә төзелде. 1968—70 еллар өчен төзелгән өчьеллык план да уңышлы үтәлә. Соңгы ике ел эчендә югарыда сөйләнгән саннарга тагын 160 клуб бинасы, 29 китапханә өстәлде. Клуб бинаралы типовой проектлар буенча икешәр катлы итеп төзеләләр, уртача дүртәр йөз урынлы булалар. Аларда түгәрәкләр өчен бүлмәләр, ял кабинетлары, лекция заллары булдырыла.

Культура учаклары төзелешендә тагын шундый бер яңалык бар. Бездә авыл клублары урынына культура йортлары салу киң колач алды. Хәзер ел саен җитмешәр авыл клубы культура йортына әверелә бара. 1975 елны Татарстанда икешәр катлы культура йорты булмаган бер генә авыл Советы да калмаячак.

Колхозларның экономик яктан үсүләре, ныгулары культура учаклары төзелешенә бик зур йогынты ясады. Колхоз идарәләре хәзер культура учакларын үзләре теләп төзиләр һәм җиһазландыралар. Моңа мисал итеп үткән ел Әгерҗе районында — Салагыш, Тәбәрле, Бима, Баулы районында — Кәрәкәшле, Урыс Тамак, Кукмара районында — Кәрәкәвеш, Байлангар, Түбән Үрәс, Арча районында — Бәрәскә, Күпер Баш, Ташкичү, Буа районында — Суыксу, Иске Тинчәле авыл клубларының турыдан-туры колхоз средстволары белән культура йортларына әверелүләрен әйтеп үтү дә җитә.

Элекке шыксыз, артсыз эскәмияләр хәзер культура учакларында соңгы көннәрен кичерәләр инде. Авыл культура йортларындагы тамаша заллары хәзер кыйммәтле җиһазлар, затлы урындыклар белән бизәлә. Аларга соңгы ике ел эчендә генә дә 82 мең партер креслолары алынды. Хәзер авылларда гармуны, баяны булмаган культура учагы юк. Аларда йөздән артык пианино, рояль, йөздән артык тынлы һәм халык инструментлары оркестрлары, биш йөздән артык телевизорлар, 300 дән артык фотоаппарат, кинокамералар, техник эпидиоскопик фильм аппаратлары бар. Хәзер авылларда спектакль уйнаган саен кием эзләп йөрү чорлары күптән үтте инде. Концертлар, спектакльләр өчен кирәкле костюмнарны хәзер колхозлар үзләре тектерәләр. Мисал өчен Лениногорск районы Зәй-Каратай авылы культура йорты өчен «Уңыш» колхозының алты мең сумлык костюм тектерүен, Октябрь районы Ульянов исемендәге колхозның 50—60 кешелек җыр-бию ансамблен баштанаяк киендерүен әйтеп үтү дә җитә.



Соңгы елларда Татарстан культура учакларының моңа кадәр күрелмәгән тагын бер яңа төре — автоклублар барлыкка килде. Ул автомашинадан, җыелма залдан, магнитофоннан, киноаппараттан тора. Аңа ике кеше хезмәт күрсәтә. Мондый автоклублар кечкенә авылларга, кыр станнарына культура хезмәте күрсәтү өчен оештырылалар. Аларның саны хәзер бездә кырыкка якын һәм киләчәктә тагын да арта барачаклар. Эре культура учаклары аз вакытта авыл халкына культура хезмәте күрсәтүнең төп чыганаклары булып килгән кызыл почмаклар авыл үзәкләреннән фермаларга, трактор бригадаларына күчтеләр һәм алар да ял итү, күңел ачу урыннарына әверелделәр. Ләкин, элеккеләрдән аермалы буларак, бу кызыл почмаклар да культура йортлары шикелле үк телевизорлар, радиоалгычлар, газета-журналлар белән тәэмин ителгәннәр. Аларда җылы, якты һәм чиста. Кызыл почмаклар әле моннан соң да бик күп файда китерәчәкләр.

Инде авыл культура учакларын кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләсенә килик. Хәзер республикабызның культура учакларында өч мең ярымга якын кеше эшли. Шуларның ике меңгә якыны урта белемлеләр, ике йөздән артыгы, Алабуга культура-агарту техникумын бетереп, махсус белем алган белгечләр. Шуның өстенә культура учаклары өчен квалификацияле сәнгать кадрлары әзерләү буенча да төрле чаралар күрелеп килә. Казан театр училищесы янында халык театрларына режиссерлар әзерләү өчен өч еллык бүлек ачылды. Татарстан халык иҗаты йорты каршында үзешчән сәнгать түгәрәкләре өчен махсус биш һәм тугыз айлык курслар даими эшләп киләләр. бу курслар соңгы биш ел эчендә биш йөздән артык җитәкчеләр әзерләп чыгардылар инде. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, бу курсларда укучыларның күпчелеге колхозлар хисабына укыйлар. Колхоз идарәләре үз клубларындагы үзешчән сәнгать түгәрәкләрен әзерлекле җитәкчеләр белән тәэмин итү өчен барысын да эшлиләр. Мәсәлән, Октябрь районы колхозлары 1966—67 уку елында гына да бу курсларда үз хисапларына унсигез кеше укыттылар.

Узган елда Казанда Ленинград культура институтының филиалы ачылуы безнең культура тормышыбызда шатлыклы вакыйга булды. Хәзер бу яңа институтның клуб һәм китапханә факультетларында алтмыштан артык кеше укый. Институтта читтән торып уку бүлекләре дә оештырылды. Алар биш ел буе укыячаклар һәм югары квалификацияле белгечләр булып чыгачаклар. Бу нәрсә культура-агарту учакларын югары белемле кадрлар белән тәэмин итү бурычын хәл итүне дә җиңеләйтәчәк.

Урыннарда культура учаклары челтәренең киңәюе, аларның ныклы материаль базага корылулары, квалификацияле белгечләр белән тәэмин ителә барулары республикабызда үзешчән сәнгать түгәрәкләренең гөрләп чәчәк атуларына, елдан-ел массовый төс ала баруларына китерде. Хәзер бездә профсоюз түгәрәкләреннән тыш, 190 мең кешелек унбер меңнән артык үзешчән сәнгать түгәрәкләре яшәп килә. Үзешчән сәнгать түгәрәкләренең алдынгыларына халык театрлары, халык җыр-бию ансамбльләре, үзешчән сәнгатьтә озак еллар нәтиҗәле эшләгән кешеләргә Атказанган культура эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелә. Халыкка иллешәр ел культура-сәнгать хезмәте күрсәткән Әтнә, Чаллы культура йортлары драмтүгәрәкләре республикабызда халык театрларының беренче карлыгачлары булдылар. Әтнә халык театрына нигез салучыларның берсе булган иптәш Сибгатуллинага һәм Гомәр Мәрдәновка Атказанган культура эшлеклесе исеме бирелде. Чаллы халык театры режиссеры Мансур Кашапов Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән, шул ук театрның активларыннан Нәсимә Гарипова, Равия Булатова, Хәниф Гомәровлар Татарстан Верховный Советы Президиумының Мактау Грамотасы белән бүләкләнделәр. Хәзер мондый халык театр-

ларының саны егермедән артып китте инде. Ул киләчәктә тагын да артачак. Чөнки бу мактаулы исемне яулап алу өчен үзешчән сәнгать түгәрәкләре арасында чын-чынлыгын ярыш бара.

Без үзешчән сәнгать дөньясында барган шушы гүзәл ярышны стимуллаштыру, аларны тагын да ныграк чәчәк атуга китерү өчен, Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел, Татарстанның оештырылуына илле ел тулу бәйрәмнәре уңае белән республика смотры үткәрәбез. Смотр ике турда үткәрелде. Авылларда үткән беренче турда 95 мең кешене эченә алган 5 мең түгәрәк катнашты. Беренче тур драма, хор, бию түгәрәкләренең күп катнашуы, вокаль номерларның жанр ягыннан бай, массовый төстә булулары белән характерлы булды. Смотрның икенче туры берничә зонага бүленеп үткәрелде һәм аларда ун меңгә якын кешене берләштергән 40 коллектив катнашты. Зона смотрларында алдынгылыкны алган коллективлар һәм аерым башкаручылар РСФСР күләмендә үткәрелә торган зона смотрына Уфага барачаклар һәм Татарстанның илле еллыгы бәйрәме көннәрендә йомгаклау концертында катнашачаклар.

Болардан тыш республикабызның башкаласы Казанда халык театрлары, агитбригадалар һәм сүз осталарының махсус юбилей декадасы үткәрелде. Бу декадада сигез авыл коллективы, алты шәһәр халык театры катнашты. Казандагы Маяковский исемендәге халык театры Риза Ишморатның студент Ульяновка багышланган «Давылга табан» дигән драмасын, Әтнә халык театры Мирсәй Әмирнең «Тормыш җыры»н, Түбән Кама драма түгәрәге Хәлим Ибраһимовның «Башмагым» комедиясен, «Родина» совхоз халык театры Фәтхи Бурнашның «Яшь йөрәкләр»ен күрсәтте. Декадада җиңеп чыккан коллективларның эшләренә дә юбилей көннәрендә тиешле бәя биреләчәк.

Үзешчән сәнгать коллективларына смотр барган көннәрдә авыл үзешчән художникларының, нәкыш сәнгате осталарының, фото һәм кино һәваскәрләренең район күргәзмәләре булып үтте. Күргәзмәләргә куелган күп санлы экспонатларның байтагы республика күргәзмәсенә сайлап алынды. Болар өстенә район күргәзмәләрендә 18 һәвәскәр кинофильм каралды. Шулардан Ш. Ибраһимовның «Барысы да кечкенәдән башлана», «Ике плюс ике» дигән (Азнакай), Вәлидевнең «Волга» колхозы» (Балтач) дигән фильмнары, Кирилловның «Ике кинохроника»сы (Чаллы) һәм 150 дән артык фотонегативлар сайлап алынды.

**СОРАУ:** Бәлки сез республикабыз китапханәләре һәм аларның эшләре турында да берничә сүз әйтерсез!

**ҖАВАП:** Безнең республикабызда бүген 14 миллион 200 мең китап тупланган мең ярымга якын китапханә эшләп килә. Шулардан авыллардагы китапханәләрнең саны 1263 кә җитә. Алардагы китапларның саны 7 миллион 900 меңнән артык. Бу китапханәләрдә 2 меңнән артык кеше эшли. Шуларның якынча 15 проценты махсус югары уку йортлары бетергән белгечләр. Республика китапханәләре хезмәткәрләре бик яхшы эшләүче китапханә дигән исемне яулап алу өчен көрәшеп эшлиләр. Юбилей елына чаклы да бу мактаулы исем йөздән артык китапханәгә бирелгән иде инде. Әтнә зона китапханәсе, Лениногорск районы Сугышлы авыл китапханәсе, Әгерҗе районы Тирсә авыл китапханәсе, Кукмара район китапханәсе әнә шундыйлардан.

Татарстан китапханәләре Владимир Ильич Ленинның тууына йөз ел тулуга багышланган бөтенсоюз смотрында да актив катнаштылар. Смотрда җиңеп чыккан китапханәләргә Татарстанның илле еллыгы көннәрендә бик яхшы эшләүче дигән исемнәр, дипломнар биреләчәк. Үзләрен эштә күрсәткән китапханә хезмәткәрләре РСФСР һәм ТАССРның Атказанган культура эшлеклеләре дигән мактаулы исемнәр алачаклар.

**СОРАУ:** Республикабызның музейлары бөек юбилейларга әзерлек уңае белән нинди эшләр башкаралар!

**ҖАВАП:** Татарстанда, партия өлкә комитеты карамагындагы Ленин йорт-музейларыннан, югары уку йортларына караган тарих, табигать музейларыннан тыш, Культура министрлыгының үз карамагында янә җиде музей бар. Казандагы Үзәк музей, Октябрьның илле еллыгы уңае белән оештырылган республика сынлы сәнгать музее, Максим Горький, Шәриф Камал музейлары, Бөгелмә, Чистай, Тәтеш район музейлары шундыйлардан. Юбилейларга әзерлек елларында музейларга да игътибар бик көчәйде. Музейларның финанс яклары яхшыртылды. Аларны махсус фонд саклау биналары белән тәэмин итү эшләре дә әкренләп юлга салынып килә. Үзәк музей өчен ДОСААФ биләгән заллар бушатып бирелде, трамвай-троллейбус идарәсе биләгән бина да буша-

тылу алдында тора. Сынлы сәнгать музее фонды өчен дә махсус бина әзерләнә. Шәриф Камал йорт-музее өр-яңадан реконструкцияләнә. Якын киләчәктә бу музей Татарстанның әдәбият музеена әвереләчәк. Бөгелмә дәүләт музеена яңа бина бирелде. Музейның элекке бинасында Ярослав Гашек музее булачак. Чистай шәһәр музее бинасы да киңәйтелде.

Музейлар турында сөйләгәндә, республикабыз тормышында булып үткән шатлыклы бер хәл турында әйтми үтеп булмый. Былтыр РСФСР Министрлар Советы карары нигезендә Татарстанның Куйбышев районында борынгы бөек Болгар шәһәре истәлекләре җирлегендә дәүләт тарихи архитектура музей-заповеднигы ачылды. Бу заповедникка борынгы Болгар, Биләр (хәзерге Биләр авылы янындагы) шәһәрләренең һәм Болгар дәүләтенең IX—XIV гасырларындагы барлык архитектура һәм археология истәлекләре керә. Бу заповедник, фәнни-тикшерену институтлары белән берлектә, татар, башкорт, чуваш, мари, мордва, удмурт халыкларының борынгы Болгар һәм Казан ханлыгы чорларындагы тарихларын өйрәнәчәк һәм аларның ядкарьләрен саклау, пропагандалау чаралары күрәчәк. Музей-заповедник Куйбышев районындагы элекке крайны өйрәнү музее белән берләштерелә.

Татарстанда соңгы елларда дәүләт музейларыннан тыш мәктәпләр, колхозлар, заводлар каршында меңнән артык җәмәгать музейлары барлыкка килде. Болар белән пенсионерлар, укытучылар, мәктәп балалары җитәкчелек итә. Алар авылларның, колхозларның, заводларның тарихларын өйрәнәләр һәм еш кына фәнни-тарихи яктан шактый әһәмияткә ия булган экспонатлар да туплыйлар. Бу җәмәгать музейларының махсус биналары юк, әлбәттә. Алар мәктәпләрнең, китапханәләрнең мөешләрендә генә урнашканнар. Ләкин мондый музейларга да әһәмият биреп караучы, аларны биналар белән тәэмин итүче колхозлар да, заводлар да юк түгел. Бу яктан Лениногорск районы Елхов колхоз музееның тарихы бик тә кызыклы. Бу авылда пенсионер Әхметшин, авылның тарихына хас материаллар туплап, авыл китапханәсенең бер почмагында музей оештыра. Соңыннан колхоз җитәкчеләре китапханәне икенче яңа бинага күчереп, бу бинаны колхоз музеена әверелдерәләр. 1968 елда Менделеев шәһәре химия заводы янында да завод музее барлыкка килде. Завод дирекциясе бу музей өчен алты бүлмәле якты, җиһазландырылган бина, акча һәм штат бирде. Тәкәнеш авылындагы укытучы Әмир Ганиев оештырган музей, шулай ук Казан шәһәренең Ленин районы Муса Җәлил исемендәге мәктәптәге Муса Җәлил музее да һәртөрле мактауга лаек.

Хәзер дәүләт музейлары Татарстанның илле ел тулу юбилейлары уңае белән төрле күргәзмәләр оештыралар. Үзәк музей Ленинның тормышын һәм эшчәнлеген чагылдырган махсус күргәзмә эшләде. Анда Ленинның яшьлек еллары, Казан, Самара, Петроград чорлары, Октябрь революциясе ясаган, Совет дәүләте төзегән чаклары, өченче Интернационалны һәм Татарстан республикасын оештырган вакытлары яктыртылды. Шул ук күргәзмәдә Татарстанның илле ел эчендә ирешкән уңышларын күрсәтүгә багышланган бүлек тә бар. Бу бүлектә Татарстанның промышленносте да, авыл хуҗалыгы да, культура, сәнгать һәм мәгариф төзелешләре дә яктыртыла. Республиканың башка музейлары да Ленин һәм Татарстан темасына багышланган күргәзмәләр әзерлиләр.

**СОРАУ:** Әдәбият, сәнгать дөньясында нәрсәләр эшләнә?

**ҖАВАП:** Татарстанда тугыз профессиональ театр һәм дәүләт филармониясе бар. Филармония каршында дәүләт симфоник оркестры, җыр-бию ансамбле һәм концерт-эстрада бригадалары эшли. Бу сәнгать учреждениеләрен кадрлар белән тәэмин итү өчен бездә Дәүләт консерваториясе, театр, художество һәм өч музыка училищесы эшли. Алардан ел саен дистәләрчә югары һәм урта квалификацияле кадрлар чыгып торалар. Болардан тыш бездә резервлар сыйфатында биш мең ярым баланы укыта торган 38 музыка һәм 6 художество мәктәбе эшләп килә. Шуның өстенә без Ленинград театр институты янында унбиш кешелек театр студиясе оештырдык. Эстрада сәнгатенең Бөтенсоюз иҗат мастерское янында да унбиш кешелек студиябез бар. Мәскәү, Ленинград, Ташкент хореография училищеларында да 18 кеше укытабыз. Йөздән артык яшьләребез төрле сәнгать югары уку йортларында махсус белем ала. Казан дәүләт курчак театрының рус группасы өчен театр училищесында 13 кешелек махсус труппа әзерләнде. Училище шул ук театрның татар группасы өчен дә артист-

лар әзерләргә керешге. Быел Казанда беренче мәртәбә милли татар циркы эшли башлаячак. Казан тамашачылары бөек юбилей көннәрендә цирк сәнгатенең Бөтенсоюз үзәк мастерскоенда укып кайткан 40 кешелек татар цирк труппасының беренче чыгышларын караячаклар.

Татарстанның барлык театрлары һәм сәнгать учреждениеләре Татарстанның илле еллыгын лаеклы каршылау өчен бөтен көчләрен куялар. Качалов исемендәге Зур драма театры А. Штейнның «Көчле яңгырлар арасында» әсәрен һәм В. Вишневскийның «Беренче атлы»сын, Кәрим Тинчуринның «Җилкәнсезләр»ен сәхнәгә чыгарды. Тамашачылар Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә Галимҗан Ибраһимовның мәшһүр романы буенча эшләнгән «Тирән тамырлар» драмасын карадылар инде. Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры Нәҗип Җиһановның «Алтынчәч» операсын, Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балетын яңадан күрсәтә. Республика күчмә театры юбилейга багышлап драматург Юныс Әминевның «Умырзая чәчәкләре» дигән әсәрен тамашачыларга күрсәтте. Шул ук әсәрне Ленин комсомолы исемендәге яшьләр театры да рус тамашачыларына күрсәтә. Минзәлә театры Нәкый Исәнбәтнең «Качаклар» сатирасын, Әлмәт театры Таҗи Гыйззәтнең «Бишбүләк» драмасын, Бөгелмә театры Н. Чапуринның «Күңелем синең белән» дигән әсәрен сәхнәгә чыгара. Болардан тыш театрларның портфельләрендә юбилей көннәрендә куела торган яңа әсәрләр булуы да сер түгел. Татарстанның илле еллыгы көннәрендә Татар дәүләт академия театры илебезнең башкаласына гастрольгә барачак.

Юбилейларга әзерлек көннәрендә Татар дәүләт филармониясе аеруча активлык күрсәтте. Ул үткән елның март, июнь айларында Казанда һәм Татарстан районнарында «Ленин һәм музыка», «Күңелем Ленин белән сөйләшә», «Ильичның яраткан көйләре» дигән темаларга концерт-лекцияләр үткәрде. Аннары ул «Ленин турында уйлар», «Юлбашчының исеме бөтен дөньяга нур чәчә» дигән темаларга әдәби-музыкаль концертлар әзерләде. Дәүләт симфоник оркестры Владимир Ильич Ленинга багышланган махсус симфоник программа әзерләде.

Татарстан язучылары һәм композиторлары үзләренең бөек юбилейларга багышланган әсәрләре өстендә эшлиләр. Юбилей уңае белән иң яхшы җырларга һәм пьесаларга конкурс игълан ителгән иде. Без юбилей көннәрендә бу конкурсларга да йомгак ясарга җыенабыз. Татарстан юбилее көннәрендә Казанда «Илле ел эчендә Татарстан сәнгате» дигән темага сынлы сәнгать күргәзмәсе оештырыла. Бу күргәзмәгә, Х. Якупов, Л. Фәттахов, М. Семенов кебек күренекле художниклар белән бер рәттән, яшь рәссамнарыбыз да катнашалар. Хәзер художниклар күргәзмәгә катнашу өчен Ленин һәм Татарстан темасына багышланган әсәрләрен тәгәлләп килиләр.

Кыскасы, Татарстан культура-агарту учаклары, әдәбият, сәнгать эшлеклеләре бөек юбилей көннәрендә үзләренең иң яхшы эшләрен, иң кадерле хезмәт җимешләрен совет тамашачыларына күрсәтү өчен кирәкле эш алып баралар. Әйдәгез, аларга эш, иҗат уңышлары телик!

Әңгәмәне Ш. Зәйни язып алды.

# ФОЛЬКЛОРДА СТИХИЯЛЕ МАТЕРИАЛИЗМ

Татар фольклоры һәм аның әкият, җыр, бәет, мәкаль, табышмак кебек жанрлары турында, әйтергә кирәк, галимнәребез күп эзләнделәр һәм күп яздылар. Ә менә фольклорны халыкның дөньяга карашы буларак өйрәнгән эзләнүләрнең (Нәкый ага Исәнбәтнең зур һәм мактаулы хезмәтеннән тыш) күренгәне юк дәрәҗәсендә.

Фольклорның кайсы гына жанрын алма, аларның һәркайсында халыкның дөньяга материалистик карашы чагыла. Әмма төрле жанрда төрлечә. Бу исә аерым жанрларның иҗтимагый һәм эстетик функцияләреннән чыгып аңлатыла.

Мәкальләр һәм сынамышлар аеруча зур игътибарга лаек. Чөнки алар борынгы бабаларыбызның табигать күренешләрен һәм иҗтимагый сыйныфлар арасындагы мөнәсәбәтләрне танып-белүдә материалистик позициягә килүен конкрет, фәлсәфи эчтәлекле мисаллар белән раслыйлар.

Халык массаларының теге яки бу материаль күренешкә, материаль әйберләргә һәм аларның яшәвенә дөрес, объектив бәя бирүе озак һәм каршылыклы юл уза. «Бардан юк булмый, юктан бар булмый», ди татар халык мәкале. Белмим, бу мәкаль кайчан тугандыр. Ләкин аның төбендә бөек рус галиме Ломоносов ачкан законның (энергиянең саклану һәм үзгәрүе) халыкча гомумиләштерелгән варианты ята. Хезмәт ияләре үзләренең көндәлек тормышларында дөньяның алла кодрәте белән яратылмавын, бәлки аның материаль булуын, мәңге яшәгәнлеген һәм яшәячәген күреп һәм аңлап килгәннәр.

Халык массалары дөньяны материаль хәлдә танып белгәннәр дидек. Материаль чынбарлык исә мәңгелек үсештә, яңарышта: бер күренеш, әйбер вакыйгаларның икенчеләре белән аерылгысыз бәйләнештә булуы белән характерлана. Мәсьәләнең бу ягы мәкаль һәм сынамышларда ничегрәк чагыла соң? Мәгълүм ки, кешене күп төрле сыйфат һәм үзенчәлекләргә ия предмет һәм күренешләрдән торган материаль чынбарлык чолгап алган. Бу чынбарлыкта бер генә нәрсә дә башкалардан аерым хәлдә, үзлегеннән яши һәм үлә алмый — һәммә нәрсә гомуми бәйләнештә. Халык моны фәкать хезмәт иткәндә танып-белүгә ирешкән. «Һәрнәрсә вакытына, урынына карап» (Н. Исәнбәт. Татар халык мәкальләре. Казан. 1959. т. 1. № 1683); «Һәрнәрсәнең урыны бар» (т. 1. № 1684), ди халык. Әлеге мисаллардан күренгәнчә, халыкның дөньяга карашында әйберләрнең вакыт һәм урын (пространство) белән бәйләнештә булуына да ишарә ителә. Сыйнфый җәмгыятьтә изүчеләр белән изелүчеләр арасындагы мөнәсәбәт тә гомуми бәйләнешнең бер төрен тәшкил итә. Мисалга түбәндәге мәкальне китерергә мөмкин: «Мужикның җаны — алланыкы, тәне — патшаныкы, аркасы — боярныкы, шуннан калган газаплары — бар да үзенеке» («Татар халык мәкальләре һәм әйтемнәре. Җыючысы һәм төзүчесе Х. Ярми. Казан. 1960. 197 бит).

Дөрес, гомуми бәйләнешкә дин әһелләре дә дәгъва итәләр. Әмма алар бу бәйләнешне кешенең аллага ышануында, алла каршында намаз укуында, кыскасы, алла белән «рухи аралашуында» күрәләр. Ләкин юк нәрсә белән бәйләнеш урнаштырып булмаган кебек, алла белән дә бернинди бәйләнешнең булуы мөмкин түгел. «Аллага ышанган ач калган» (т. 3. № 38278); «Ишәкне элек бәйлә, аннан аллага тапшыр» (т. 1. 6756) кебек татар мәкальләре аллага ышануның мәгънәсез бер нәрсә икәнлеген тагын бер кат раслыйлар.

Табигатьтәге әйберләрнең үзара бәйләнеше аларны закончалыклы үсү, үзгәрү процессына китерә. Ә соңгысы исә материалистик диалектиканың закон һәм категорияләреннән тыш берничек тә була алмый. Нинди законнар һәм категорияләр соң алар?

Халык массаларының һәр предметта, һәр күренештә капма-каршы як, сыйфат үзенчәлекләре күрүе табигый хәл. Чөнки алар кеше аңыннан тыш материаль әйберләрнең объектив яшәүләре белән характерланалар. Фән булмаган яки бик түбән дәрәҗәдә торган чорда борынгы кешеләр аларны фәкать тышкы яклары, тышкы билгеләре, тышкы сыйфатлары аша гына танып белергә өйрәнгәннәр. «Башы барның соңы бар; әүвәле барның ахыры бар» (т. 1. № 1496); «Асты барның өсте бар, өсте барның асты бар» (т. 1. № 1693); «Яхшының начары бар» (т. 1. № 1555) һ. б.

Халык шушы капма-каршылыкларның үз-үзләренә яшәү өчен шарт булуларын тануга да ирешкән: «Искесе булмаганның яңасы булмый» (т. 1. № 1528); «Яңаны алдым дип искене ташлама (т. 3. № 38 165). Күренә ки, яңаның үсүе өчен искенең булуы шарт. Яки менә «Иске яңага урын бирер» (т. 1. № 1530); «Иске яңаны асрый» (т. 1. № 1531); «Искесез яңа булмас, ямансыз яхшы булмас» (т. 1. № 1529) кебек мәкальләрне алыгыз.

Диалектик үсештәге материаль чынбарлыкны тәҗрибә аша үзләштерә барып, халык материалистик диалектиканың икенче законын — сан үзгәрешләренең сыйфатка күчүен практик рәвештә таныган һәм, шуннан чыгып, үзенең стихияле философик фикерләрен фольклорның теге яки бу жанры аша әйтеп биргән. Сан һәм сыйфат һәр әйбергә, һәр күренешкә хас. Санның артуы яки кимүе, тиешле ноктадан ашса, сыйфатның үзгәрүенә китерә. Татар халык мәкальләре моны бик дөрес тотып алган: «һәр камәлнең бер ноктасы бар» (т. 1. № 1633); «һәр нәрсәнең чиге бар» (т. 1. № 1634); «һәрнәрсә чигеннән ашса, киресенә әйләнә» (т. 1. № 1635) һ. б.

Практик тормышта халык сыйфатның яхшы булуына ныграк игътибар итә: «Аз булсын — үз булсын» (т. 1. № 1661) яки «Чүп булып күп булганчы, аз булып үз булсын» (т. 1. 1669).

Инкарьны инкарь итү материалистик диалектиканың төп законнарыннан санала. Ул табигатьтә мәңге яшәп килгән һәм мәңге дәвам итәчәк. Инкарьны инкарь итү законының тышкы гади элементлары көндәлек тормыш мисалларында да чагыла: «һәрнәрсә үз асылына кайта» (т. 1. № 1470); «Аздан күп була, күптән юк була» (т. 1. № 1662); «Күпнең ташуы бар, ташуның кайтуы бар» (т. 1. № 1624); «Ким артыр, тулы кайтыр» (т. 1. № 1623). Эчке каршылыклары аркасында әйбер һәм күренешләр үзүзләрен юкка чыгаралар, дөресрәге, бу процесс иске белән яңа арасында бәйләүче баскыч ролен үти.

Без санап үткән законнар гына материаль чынбарлыкның диалектик үсешен бөтен тулылыгы белән күз алдына китерә алмыйлар әле. Материалистик диалектика үзенең категорияләренә дә таянып эш итә. Алар нинди категорияләр һәм халык авыз иҗатында ни дәрәҗәдә чагылыш тапканнар?

Әйберләрнең билгеле бер формада йөрүе борынгы кешеләр өчен мәгълүм нәрсә булган. Бу очракта кешеләр предметларны танып-белүне формадан башларга тиешләр кебек иде. Ләкин алар әйберләрнең формасына, күренешенә караганда, эчтәлекләре, асыллары белән күбрәк кызыксынганнар. Шул кадәресен дә әйтергә кирәк, халык аңында форма белән эчтәлек һәм асыл белән күренеш мөстәкыйль категорияләр булып аерымланмаган.

Мөмкинлек һәм чынбарлык тормышта еш очрый торган күренешләрдән. «Юрганыңа карап аягыңны суз», ди татар халкы. Мәгънәсе «мөмкинлегеңә карап эш йөртәкә туры килә. Мөмкинлек чынбарлыкның үзендә ята һәм, әйтергә кирәк, үзенең потенциальлеге белән чынбарлыктан киңрәк һәм зуррак. «Ихтималның арты киң» (т. 1. № 1774); «Мөмкиннең төбе киң» (т. 1. № 1775). Әмма мөмкинлекнең тормышка ашуы өчен шартлар кирәк. Әйтик, герой шагыйрь Муса Җәлилнең сугышка кадәр күренмәгән баһадир сыйфатлары фашистлар тырнагында ныграк һәм тирәнрәк ачылдылар.

Сәбәп һәм нәтиҗә — бер-берләреннән аерылгысыз төшенчәләр. Татар халкының бу хакта бик күп мәкальләре бар: «Кояш барда — көн бар, көн барда — тереклек бар (т. 1. № 1836); «Чакма чакмый ут чыкмас» (т. 1. № 1796); «Сәбәпсез сәгать сукмый» (т. 1. № 1797) һәм башка бик күпләр.

Санап үткән закон һәм категорияләрдән тыш, халык массаларының дөньяга материалистик карашы әкият, бәет, җыр, табышмак, сынамыш кебек фольклор жанрларын-

да да чагыла. Шулардан без сынамышларга тукталып үтик.

Кешенең хайваннар дөньясыннан аерылуы борынгы ыручылык чорларына кадәр үк башлана. Фәкать хезмәт аркасында гына ул бүгенге дәрәҗәсенә ирешә алган. Һәр яңа һөнәр борынгы кешене табигатьне танып белүдә яңа баскычка күтәрә, аның аңын камилләштерә. Ә камилләшкән аң яңадан хезмәт процессын җиңеләйтү, җитештерү коралларын яхшырту өчен ярдәм итә. Шулай ук вакытның да кадерен белергә өйрәтә. Әйтик, аучылык, балык тоту, торыр өчен куыш әзерләү, үлән тамырлары җыю кебек эшләрне бер үк вакытта башкарып булмый. Кеше бүгеннән иртәге көн өчен кайгырта, ә иртәге көннең язмышы бик күп нәрсәләргә бәйле. Кеше ул шартларны белми, ләкин көннең нинди булырын белергә тели. Янәшә-тирәгә күз сала, һәрвакыт үзгәреп торган үсемлекләр һәм хайваннар дөньясын күзәтә. Аларның үзгәрүенә бәйле рәвештә көннең дә үзгәрүен күрә.

Киләчәкне, бигрәк тә алдагы ел уңышын алдан күрергә тырышу хезмәт халкы өчен һәрвакыт мөһим мәсьәлә булып тора. Елның уңышлы яки уңышсыз булуы бик күп шартлардан бәйле. Һава шартларының үзгәрүен кешеләр зур игътибар белән күзәткәннәр. Һәм шулардан чыгып нәтиҗә ясарга өйрәнгәннәр. Болар бар да — борынгы кешеләрнең табигать күренешләрен танып белүе, ләкин аларның үз көчләре, үз аңнары белән табигатьне үзгәртергә тырышулары түгел әле. Кеше, аңы үскән саен, тормыш тәҗрибәсеннән алынган белемен табигатьне буйсындырырга сарыф итә. Чәчүлек мәйданнарыннан кирәкле уңыш алу өчен табигатьне күзәтеп, аның яңгырлымы, яңгырсызмы булырын белү генә җитми. Чыннан да, әгәр җәй коры киләсен белсә, кеше уңышның түбән булырын да белә һәм үз көче, үз аңы белән бер дә соңламыйча ясалма чаралар күрә башлый: җирне яхшырак эшкәртә, ашлый, чүп үләннәреннән арындыра.

Еллар узган саен, кеше һава һәм климат шартларының билгеле әзлеклелек һәм ритм белән үзгәрүен тоя. Гәрчә ул мондый үзгәрүләрнең сәбәбен һәм закончалыгын белмәсә дә, үткән күренешләрнең системалы рәвештә яңадан кабатлануын күреп дедуктив нәтиҗәләргә килә. Мондый өзлексез күзәтүләрнең нәтиҗәсе, теге яки бу географик урынның тарихы буларак, бер буыннан икенче буынга фольклор ярдәмендә тапшырыла тора. Алар бу дәвердә тел ягыннан шомаралар, тапкырланалар һәм, ниһаять, мәкаль булып китәләр. Мондый мәкальләр халык арасында практик әһәмиятләрен югалтмый, үз функцияләрен бик уңышлы үтәп киләләр.

Дөрес, андый мәкальләрнең бөтенесе дә табигать күренешләренең материаль бәйләнешеннән тумаган. Аларның шактые буталчык һәм каршылыклы, чөнки алар очраклы күренешләргә генә нигезләнгәннәр. Ә шул ук вакытта аерым закончалыклардан туган сынамышларның дөреслеген фән һич тә инкарь итми. Киресенчә, табигатьне танып белүдә халыкның стихияле рәвештә материалистик карашка басканлыгын дәлилли.

Йорт хайваннары, кош-корт, бөҗәк һәм ерткычларның яңгыр я буран алдыннан үз-үзләрен тотышларын күреп, кешеләр билгеле бер үзенчәлекле нәтиҗәгә килгәннәр. Монда шуны да искәртергә кирәк, хайваннарның холкы үзгәрү, табигать үзгәрүгә шарт түгел, киресенчә, табигать үзгәрү хайваннарның холкы үзгәрүгә китерә. «Эт аунаса буран булыр», «Карлыгачлар түбән очса, яңгыр булыр» дигән мәкаль-сынамыш бик күп халыкларның фольклорында яши.

Гадәттә карт-корылар: «Арка сөякләре сызласа, яңгыр булыр» диләр. Мәгълүм булганча, кеше сөягенең шактый өлешен известь тәшкил итә. Кеше картайган саен известь үзенең ныклыгын югалта. Һәм, шуңа күрә, картлар сөяге тизрәк сынучан, дымлы һаваның тәэсирен тизрәк сизмәлүчән була. Һава шартларының үзгәрүе җанлы организмда төрлечә чагыла. «Көндез йокы килеп торса, яңгыр явар» (т. 1. № 7936); «Теш сызласа һавалар бозылыр, яңгыр я буран булыр» (т. 1. № 7924); «Картлар авыраеп, җилкә яки билләре сызлый башласа, һава бозылыр (т. 1. № 7926) һ. б. ш.

Һәркемнең күзәткәне бардыр, мунчадан соң чәчләр нәзегәеп, озынаеп калалар. Димәк, чәч юештә сузыла, ә корыда тартыла. Бу күренеш тә борынгылар игътибарыннан читтә калмаган, әлбәттә. Шуннан файдаланып 1783 елда Швейцария геологы Гораций Бенедикт де Соссюр атмосфераның дымлылыгын билгели торган дөньяда беренче гигрометр ясый. Моның өчен ул гади чәч бөртеге куллана.

Татар халык фольклорында, томан, чык төшүгә карап, һаваның нинди буласын алдан билгеләү киң таралган. Әлбәттә, чык

белән бәйләнгән күп санлы мәкальләрнең гади ышанудан узмаганнары да шактый. Чөнки күп гасырлар буе аны, яңгыр кебек, күктән төшә дип уйлыйлар. Шуңа да төшү, чык төшү, кырау төшү дип йөртелә. Мондый караш, билгеле, чыкның объектив сәбәбен ачып сала алмый. Фәкать 1814 елда гына инглиз врачы Чарльз Уэллз бу күренешне фәнни исбат итә. Җылы һава катламы җирнең салкынча өстен каплап торганда, аның аскы өлешендә температура төшә һәм вак кына су тамчылары хасил була. Мондый күренеш, гадәттә, инсу урыннарда, урман, болын, тугайларда еш була. Чык төшү атмосферада җылы һава агымының якынлашуын, димәк, көннең аяз булырын хәбәр итә. «Иртә белән чык күп төшсә, бик эссе булу галәмәте»,— диелә татарда (т. 1. № 7727). Бу төргә шулай ук «Тоз дымланса, яңгыр булыр (т. 1. № 7727); «Тәрәзә тирләсә, яңгыр булыр» (т. 1. № 7943) кебек сынамышларны да кертү урынлы.

Әйткәнебезчә, яңгырларның вакытында булуы игеннәрнең үсүе өчен кирәк. Халык массалары яңгырның булуын-булмавын табигатьнең башка күренешләреннән чыгып, шактый дөрес әйтә белсәләр дә, аның физик сәбәбен озак гасырлар буе аңламыйлар. Корылык булган елларны татар авылларында яңгыр боткалары оештыру яңгырның кешеләр теләге буенча алла тарафыннан булдырылуына ышанудан килгән. Чынлыкта исә, яңгырның сәбәбе — һавадагы су парларының салкынаеп авыраюы. Киңәеп югарыга күтәрелгән һава атмосфераның өске катлавында суына һәм тарая. Яңгыр һәм боз явулар шуннан килә. Борынгы чорларда, фән булмаганлыктан, гади халык моны аңлый алмаган һәм фәкать физик күренешләрнең бәйләнешеннән чыгып кына практик фикер йөрткән. Фән әйрәткәнчә, һава җылынганда киңәя, салкынайганда кысыла. Азия чүлләрендә еш була торган Сәмум җилләрен һаваның чиктән тыш кызуыннан һәм киңәюеннән дип карарга кирәк.

Мәкальләр һәм сынамышлар мисалында без халыкның дөньяга материалистик карашы чагылышын күреп уздык. Халык массалары аларны бүген дә практик тормышта актив кулланалар. Димәк, Горький әйткәнчә, язучылар аларны җыярга, өйрәнергә һәм иҗатларында кулланырга тиешләр. Бу исә матур әдәбият әсәрләрен тагын да тормышчанрак, халыкчанрак итәчәк.

**К. ДӘҮЛӘТШИН.**

**Миркасыйм Госманов**

# ТАРИХТАГЫ ТИРӘН ЭЗЛӘРДӘН

## «Кырыс бабай»

Өметнең соңгы җепләре өзелер чиккә җитеп килә. Каршымда, зур агач карават кырыенда утырган какча йөзле, сирәк ак сакаллы бабай менә ничәнче мәртәбә:

— Юк, юк дигәч юк инде! — дип кабатлый.

Ләкин, нигәдер, күзләрен яшерергә теләгәндәй, үзе читкә борыла. Мин дә тиз генә китәргә җыенмыйм — күңел нидер сизә. Моңарчы, яулык чите белән авызын каплап, тыныч кына утырган шадра әби дә сүзгә кушыла:

— Бездә андыйларның булганы да юк. Башкалардан сораштыр, аларда табылыр, бәлкем.

Ләкин мин барыбер ашыкмыйм — авыл халкы юкка гына монда җибәрмәгәндер ләбаса!.. Әллә ничә җырланган «җырның» икенче төшеннән көйли башлыйм һәм, сүз җаен китереп, бабайдан:

— Әллә сезнең үз ата-бабаларыгызга берәр ачуыгыз, үч-мазарыгыз бармы? — дип сорыйм.

Сорау көткәннән дә артыграк нәтиҗә бирә: картның кырыс чыраена ачу бәреп чыга. Агач карават бер шыгырдап ала. Соры күзләр, яшьнәп алгандай, ялт-йолт киләләр.

— Безнең дә ачуыбыз юк аларга,— дим, аның күзләренә туры караган килеш.— Безнең бары беләсебез килә, күбрәк беләсебез килә!

— Бәй, сүзгә бер дә ышанмый торган адәм икән бу! — диде түрдәге әби, авызын ача төшеп. Һәм тагы нидер кыстырырга җыенган иде:

— Ярар!..— дип, карт бер җикереп алды.

Яулык чите әбинең борынына хәтле менә. Карт янә миңа текәлә:

— Көләр өчен, хакарәтләр өченме?

— Ә көләргә, мыскыл итәргә галим булу, күп белү хаҗәтмени? — дим.

Бабайның йөзендәге кырыслык кими төшә, күзләре дә бер мәлгә идәнгә төбәлә. Мин исә һөҗүмне дәвам иттерәм:

— Максат көлү, хурлау гына булса, шулхәтле җиргә эзләнеп килүнең нәрсәгә кирәге бар?

— И улым,— ди бабай ачыргаланып.— Дөресен әйткәндә, алар бездә бик күп иде. Авылдагы һәрбер йортта да бар иде. Тик харап булып өлгерделәр инде. Алданрак эзләргә кирәк иде!..

— Ләкин калган хәтлесен коткарырга кирәк бит!

Карт беравык хәрәкәтсез тора. Аның күзләре тагы житдиләнә төшә. Кинәт ул тураеп куя. Йөзенә янә баягы кырыслык чыга. Кайчандыр затлы гына булган зур агач карават тагы бер кат шыгырдап ала — бабай аякларына баса:

— Әйдә.

Каты-коры белән тулы утын келәтенә керүгә карт жирдә яткан зур гына чыпта капка ишарә ясый. Ул мин көткәннән зуррак, ләкин авыл кешеләре сөйләгәннән кечерәк иде.

Капны ишек төбендә торган сәке өстенә куеп, аның авызын чишеп жибәрәм һәм аптырап калам: аннан укмашып, бөтәрләнеп беткән иске китап битләре, кәкрәеп-бөкрәеп каткан катыргы тышлар ишелеп төшә. Шулай да бабайга сер бирмәскә телим.

— Һи, нихәтле байлык монда! Ә сез «юк» дигән буласыз тагы! — дип актарына башлыйм.

Әмма кырыс бабай арзанлы комплиментка гына алданучылардан түгел икән:

— Монысы чүпкә әверелгәннәре генә. Жүнлеләрәкләре төптә,— ди.

Чыннан да, капның уртарак төшеннән бөтен китаплар, күн тышлы калын кулъязмалар да чыга башлады. Менә бу мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» китабы. Унсигезенче гасырда күчерелгән нөсхә. Әсәр үзе исә, мәгълүм булганча, моннан 750 еллар элек ижат ителгән. Бәхетле дә кеше булган бу Колгали дигән шагыйрь! Менә ничәнче рәт инде аның поэмасының күчерелмәләрен табам. Һәм ышанам ки, бу соңгысы да булмас. Ә моңарчы билгеле булганнары нихәтле? Саф әхлаклы гүзәл Йосыф, кайнар хисле, олы мәхәббәт иясе Зөләйха турындагы бу гажәеп дастан безнең халык арасында, мөгаен, йөзләгән, хәтта меңләгән күчермәләрдә таралгандыр. Нәрсә ди әле шагыйрь?

Гәүһәр даштыр, вәләкин даш гәүһәр улмаз;
Дикмә кеше гәүһәр кадерен кыяс кылмаз.
Бу назымның кадерене ахмак белмәз,
Гакыйль кеше дыңлар, аңлар, белер имди.

Шулай, чын поэзиянең кадерен һәрвакыт аңлыйлар, аны тирән ихтирам итәләр. Кабатланмас музыкаль аһәң, поэтик моң белән язылган «Йосыф китабы» да ничә йөз еллардан бирле халыкның күңел түреннән урын алып, буыннан буынга, гасырдан гасырга күчә килә...

Тукта, бу нәрсә тагы? Әйе, моңарчы миңа очрамаган билгесез әсәр бу. Күгелҗем төстәге кыштырдап торган битләрне актарам. Ниһаять, әсәрнең исеме табыла: «Нафигъ эн-нас», ягъни кешеләр файдасы. Бик матур исем, чөнки медицина гыйлеме беренче планга чыннан да кешеләр файдасын куйган фән бит. Менә авторның исеме дә мәгълүм — Нәдаи. Ә кайчан язган соң ул бу әсәрен? Сәхибгәрәй хан заманында икән. Димәк, XVI йөзнең беренче яртысы була. Нәдаи үз китабын халык медицинасы тәжрибәсенә таянып, Әбүгалисина кебек даһи галимнәрдән өйрәнеп ижат иткән...

— Бик тә борынгы нәрсә кебек,— дип, бабай тагын бер китап суза.

Ул чыннан да ялтышмый иде. Ноктасыз-өтерсез хәрефләре буенча да, мамыктан эшләнгән калын кәгазе белән дә XIII—XIV гасыр күчермәсе иде бу. Күчерелгән елы да бар икән: һижри белән 719, милади буенча 1319 ел дигән сүз! Әсәрнең исеме «Конияте-мөния...», язучысы исә Нәҗметдин әз-Заһиди дигән мәшһүр галим, ул 1260 елда үлгән. Болар барысы да билгеле. Ләкин мондый бик борынгы күчермә бу тирәләргә кайчан, ничек килгән соң? Һичшиксез, шул борынгы дәверләрдә үк, чөнки мондый иске почеркны китапны XVI гасырлардан соң уку бик читен булган...

Ә инде гарәпчәне укыган кешеләр үз телләрендә язылган китапларны, ягъни үзләренең төркесен «су кебек эчәргә» тиешләр. Димәк, бу тирәләрдә бик борынгы төрки әсәрләренең дә табылуы ихтимал икән...

Уйларымны «кырыс бабай» бүлдерде:

— Күмелгәннәре арасында моннан битәрләре дә бар иде. Үзебезнең төркичәләре дә күп иде...

— Күмелгәннәре?!

Җавап бирү урынына, карт минем кулдан җиргә төшеп киткән «Конияне» алды, җиңнәре белән тузаннарын сөртеп, бер читкә — сайланган кульязмалар янына куйды.

...Ярты сәгатьтән без җир казый идек. Дымлы кара туфракны берәр метрдай уеп төшкәч, череп изрәгән кәгазь калдыклары чыга башлады. Ләкин сөенерлек урын юк: болар, кәгазь булудан бигрәк, туфрак белән аралашкан әллә нинди соры ботка гына иде. Дөрес, ара-тирә күн белән капланган катыргылар да очрый, тик ни файда — кәгазе түгел, күне дә кулга алуга таралып бетә. Бер мәлне бөтенләй диярлек исән калган бер китап килеп чыкты. Серле нәрсәдән сокланган дай, чак кына хәрәкәтсез калдым, аннары чүгәләп утырып, аның әйләнә-тирәсендәге туфракларны, кәгазь череләрен арчыдым. Һәм йөрәгем дөп-дөп типкән хәлдә китапның читеннән тоттым... Тик минем кулымда бөтен китап түгел, бәлки суга чыланган ипи телеме кебек умырылып аның бер кисәге генә калды. Ике куллап, җайлап-хәстәрләп карасам да, аның нәрсә икәнен белү мөмкин булмады. Бер битен ачып карыйм диюгә, «чыланган ипи телеме»нең тагы бер кисәге умырылып чыкты...

Шунысы да зур үкенеч, бу бик борыннан күчерелгән төрки телле әсәр иде. Хәрефләрнең язылу формасы да, аерым сүзләре дә шуны күрсәтә. Мәсәлән, «тип», «айды» кебек архаик фигыльләр, «Чулман», «Болгар» кебек борынгы исемнәр...

Тагы ярты сәгатьтән көрәкләр кара туфракка җиттеләр. Чокыр янында исә тау кебек кәгазь боткасы...

Мин, салам арасыннан инә эзләгәндәй, шул соры ботканы актарам. Ичмаса, әлеге «Чулман»лы, «Болгар»лы китап кебек әсәрнең берәр бите, хәтта дүрт-биш җөмләле бер кисәге генә табылсын иде!.. Ләкин юк. Күпме актарсам да, соры ботка мәрхәмәтсез рәвештә «телсез-өнсез» кала бирде...

Саз туфрагыннан юешләнгән чалбар тезләрен кагып, читкә китеп утырган бабай янына килдем. Аның соры күзләре черегән кәгазь чүмәләсенә төбәлгән иде. Кинәт үзе белән үзе сөйләшкәндәй тезеп китте:

— Безнең бөтен нәселебез укымышлылар иде. Мәсәлән, минем унберенче бабам Болгар якларыннан килеп шушы авылда мәдрәсә тоткан кеше икән. Ишетмештән түгел, аның үзе язганнарыннан укыганымны әйтәм. Нәселдән нәселгә күчә килгән көтепханәбез дә бик бай иде. Дүрт сандык тулы иде. Совет властеның беренче елларында дуамал егетләр бар ие безнең авылда. Гарәп хәрефе белән язылган китап күзләренә чалынмасын инде шуларның... Күпме байлык шулай әрәм булды. Тора-бара бетте дә бит андый хәлләр... Ә исән калганнарын теләсә кемгә ышанып, тоттырып җибәрәсе дә килми.

...Бу сәер һәм күңелсез вакыйга моннан өч ел элек Рязань өлкәсе Кадом районында урманнар эчендә адашып утырган бер... Хәер, картка биргән вәгъдәм бозылмасын өчен, мин аның үз исемен генә түгел, хәтта авылын да матбугатта атамаска тиеш, чөнки туксан яшьлек сәламәт акыллы, таза бәдәнле ул карт авылда да, тирә-юньдә дә мәшһүр иде. Шуңа күрә аны «кырыс бабай» дип атап килдем.

Ләкин борынгы кульязмаларны эзләгәндә гел мондый аяныч, йөрәк әрнеткеч вакыйгалар гына очрап тормый. Бабайлардан калган хәзинәләрне чын-чынлап кайгыртучыларның, аларны һәлакәттән коткаруда, тиешле гыйльми урыннарына тапшыруда зур эшчәнлек күрсәтүчеләрнең саны тагы да күбрәк. Димәк, гадел булыр өчен, алар турында да сөйләнергә тиеш.

## Традициянең дәвам итүе яки бер кечкенә белешмә

Узган дәверләрдән калган документларны, язма истәлекләрне төрле яклап өйрәнү һәм аларның әһәмиятлеләрен бастырып чыгару эше үзенә бер фән, дөресрәге зур, күп тармаклы тарих фәненең махсус һәм мөһим бер өлеше. Аңа археография диләр. Ләкин бер нәрсәне тикшерү, бастырып чыгарудан элек, аны булдырырга кирәк бит. Ә булдыру өчен — эзләргә. Менә шундый гыйльми максатлардан чыгып, төрле характердагы борынгы документларны, иске кульязмаларны җыяр өчен оештырылган махсус сәфәрләргә археографик экспедиция дип әйтәләр.

Мондый экспедицияләрнең эш мәйданы гаять киң: хосусый архивлардагы документларны, шәхси китапханәләрдәге кульязма истәлекләрне барлау да, официаль булмаган урыннарда саклануларын тәэмин ителмичә яткан тарихи материалларны бер урынга — официаль урынга туплау да экспедиция бурычына керә.

Менә шундый махсус археографик экспедиция 1963 елдан бирле Казан университетының СССР тарихы кафедрасы каршында эшләп килә. Узган 6—7 ел эчендә күп кенә төбәкләрдә булып, төрле кешеләр белән очрашырга туры килде. Һәм, эш дәвамында, шактый мул материал табылды.

Тик, университетның археографик экспедициясе турында сөйләгәндә, аның бөтенләй яна, моңарчы ят нәрсә булмавын да онытмаска кирәк. Чөнки кульязма мирасыбызны җыеп өйрәнә башлау эше шактый бай тарихка ия. Һәм татар археографиясенең беренче нигез ташларын салучы булып галим, педагог Ибраһим Хәлфин исәпләнергә тиеш. Мәсәлән, шул галим тарафыннан 1822 елда иске кульязма нигезендә басылып чыккан «Әхвале Чыңгызхан вә аксак Тимер» исемле китап гыйльми һәм педагогик максатлардан чыгып эшләгән татарча махсус нәшерләрнең иң тәүгеләреннән иде.

Университет китапханәсендә җыела башлаган шәрык һәм татар кульязмалары коллекциясенең төп маясы да шул Хәлфин китапханәсеннән күчкән кульязмалардан гыйбарәт була. 1922 елга хәтле уникаль әсәр булган Кадыйр Галибәкнең «Җәмигъэт-таварих» исемле әсәренең кульязмасы да (китап 1602 елда Касим шәһәрендә язылган) шул ук Хәлфиннең бүләге.

Бу фактлардан да татар археографиясенең тарихы Казан университеты белән бәйле булуы сизелә. Әйе, Ибраһим Хәлфин атамасы белән әйткәндә, безнең «олуг мәдрәсәбезнең» бу өлкәдәге хезмәте гаять зур. Чөнки соңрак дәверләрдә татар язма китабын җыюда, өйрәнүдә зур өлешләр керткән Х. Френ, К. Фукс, М. Казем-бек, И. Березин, И. Готвальд, Н. Катановлар да шул университетта эшләгән галимнәр бит.

Борынгы язмаларны барлау, аларга бәя бирүдә Г. Тукай «шәп хәзрәт» дип атаган Шиһап Мәрҗанинның роле аерата зур. Аңардан соң эстафетаны тарихчы, журналист Риза Фәхретдинов кабул итә.

Моннан соң без кульязма «мәҗнүне» Сәет Вахидины күрәбез. Һәвәскәр сыйфатында башлап, профессиональ галим дәрәҗәсенә күтәрелгән Вахиди гаҗәеп бер хосусиятка ия булган: татар язмалары дәрьясында кайчандыр бер сикереп куйган көмеш чабакны тотар өчен дә ул ун елдан артык кармак салып йөри. Тырышкан табар дияр. Галим тарафыннан СССР Фәннәр академиясенә, Казан дәүләт университетына 3000 нән артык кульязма бүләк ителүен искә төшерсәк (әйе, сатып түгел, ә бүләк итеп), бу шәхеснең әхлакый йөзен тагы да ачыграк күрербез. Ләкин, билгеле булганча, Сәет Вахиди озак эшли алмый. Аңардан соң татар кульязмаларын җыю бөтенләй диярлек сүрелеп кала...

Шулай, хәзер Казан университеты СССР тарихы кафедрасы каршында эшли башлаган археографик экспедиция күптәнге традицияләрне дәвам итә. Беренче сәфәрдә аңа экспедицияне актив оештыручыларның берсе булган тарихчы доцент Шамил Мөхәммәдъяров җитәкчелек иткән иде. Әүвәлге чыгышларда актив катнашкан профессорларыбыз Х. Госман, М. Зәкиев, китап белгечләреннән Ә. Кәримуллин, А. Фәтхи, ул чактагы студентлардан К. Дәүләтшин һәм башка иптәшләр бу башлангычка зур өлеш керттеләр.

Узган 6—7 ел эчендә археографик экспедициябез, Оренбург өлкәсендә, Рязань өлкәсенең Касим шәһәрендә, Горький өлкәсенең Сергач районында, Пермь өлкәсенең Барда районында һәм илебезнең татарлар яши торган башка төбәкләрендә булып, әллә никадәр байлык туплады.

Ләкин бу елларда шушы сәфәрләр нәтиҗәсендә бер зур кимчелек ачылуын әйтмәсәк, гаделсезлек булыр иде. Бүген монда, иртәгә тегендә дигәндәй, әллә кайларга барганбыз баруын, тик Татарстан үзе игътибардан төшеп калган. Ә шул Татарстанда, бигрәк тә Казан артында күчерелгән кульязмаларны Касим белән Оренбургта да, Нократ белән Волгоградта та табарга туры килде. Димәк, әллә кайларга очып киткән «кошчыкларны» тоту белән бергә, алар үсеп чыккан бәрәкәтле «ояны» да яхшылап актарырга, бер үк вакытта ике юнәлештә эшләргә кирәк икән. Менә шуның өчен дә 1968 елгы сәфәрләрнең берсе үзебезнең Тау ягына, ягъни Чүпрәле, Буа, Тәтеш район-

нарына оештырылса, икенчесендә, танышып кайту максаты белән булса да, Астраханьга юнәлдек. Тау ягыннан 120 дән артык кулъязма алып кайтсак, «яңа таныш» Астрахань да 30 дан артык китап бүләк итте. Ә киләсе елда тагы...

## Җыюдан максат өеп куюда түгел

Соңгы елларда табылган кулъязмалар арасында да нинди генә юк! Ничәничә гасырлар буена үсә килгән матур әдәбият истәлекләре дисеңме, фольклор текстларын сорыйсыңмы; тарих, фәлсәфә, тел белеме буенча китаплар эзлисеңме, яки юриспруденция, педагогика һәм математика мәсьәләләре белән кызыксынасыңмы; элекке кешеләрнең дөньяга карашларын, инануларын төпченеп тикшерергә уйлыйсыңмы, яисә аларның үзара мөгамәләләрен, интим хисләрен белергә телисеңме — барысы өчен дә ул кулъязмалардан теге яки бу күләмдә материал табып була.

Табылган кулъязмаларның сыйфатлары да төрлечә. Алай гына да түгел, хәтта бер билгеле әсәрнең күчермәләре дә төрле кыяфәттә, төрле күләмдә, төрле санда.

«Сан» турында сүз чыккач, шуңа да игътибар итәсе килә: гадәттә, теге яки бу мәгълүм әсәрнең яңа күчермәсе табылуга артык әһәмият биреп тормыйлар. Янәсе, ул билгеле инде, егет икәнсең, яңасын, таныш булмаганнарын тап! Бер карауга бу бик гадел хөкем сыман. Ләкин мәсьәләгә якынрак килсәк, туксан тугызынчы күчермә дә аерым бер кыйммәткә ия. Мәсәлән, ул — яңа нөсхә — моңарчы мәгълүм булган барча күчермәләрдән дә сыйфатлы, төгәл һәм борынгы булырга мөмкин. Хәтта, бу таләпләргә җавап бирмәгән очракта да, аның үзенә күрә әһәмияте булачак. Аңлаешлырак булсын өчен, берничә мисалга мөрәҗәгать итик.

XIII гасыр истәлеге «Кыйссаи Йосыф» китабы — халкыбызның Болгар чорларыннан калган әдәби җәүһәрләреннән. Ләкин Колгали тарафыннан язылган бу конкрет дастанның кайсы төбәктә иҗат ителүен исбатлар өчен, күп эзләнергә, төрле фактларны тикшерергә туры килгән. Шул мәсьәләләрнең берсе әсәрнең тел үзенчәлекләрен билгеләү булса, икенчесе — аның кай төбәкләрдә таралып, кайсы конкрет милли әдәбиятта үзенә җирлек таба алуын ачыклау иде. Нәкъ менә шунда, әсәрнең эчтәлеге белән бергә, аның яшәеш факторы булган кулъязмаларына да игътибар итәргә кирәк табыла. Һәм шул соңгы пландагы тикшеренүләр нәтиҗәсендә бер факт ачыла: «Йосыф китабы»ның фәндә мәгълүм 33 кулъязма нөсхәләренең барысы да, Ж. Алмаз хәбәр иткәнчә, татарлар тарафыннан күчерелгән икән («Совет әдәбияты» журналы. 1960 ел. 2 сан). Ә «Кыйссаи Йосыф» дастанын хәзерге чор укучыларга тиешле дәрәҗәдә тәфсилләп аңлатылып, тәкъдим ителде дип әйтә алабызмы? Минемчә, юк. Чөнки ул истәлекнең әдәби хосусиятләрен, тел үзенчәлекләрен җентекләп тикшергән зур хезмәт киң катлам укучыларыбызга әле җитмәде. Юк, мин бу өлкәдә бер нәрсә дә эшләнми дип әйтергә җыенмыйм. Ленинград галиме Г. Таһирҗановның гаять эчтәлекле мәкаләсен («Казан утлары». 1968 ел. 12 сан) укучылар күрделәр инде. Шулай ук Фәннәр академиясенең Казан институтында да дастанга багышланган зур хезмәт тәмамлануы мәгълүм. Әлеге истәлекне җентекләп тикшерер, аның бөтен эчке хосусиятләрен ачыклар өчен галимнәргә иң сыйфатлы, иң тулы һәм, мөмкин булса, иң борынгы нөсхәсен табарга кирәк. Сүз бары шул турыда гына бара. Һәм кайчакларда нәкъ менә шундый моментларда ярдәмгә археография килә. Мәсәлән, филолог Ф. Фасиевның әйтүенә караганда, «Йосыф китабы»ның соңгы елларда Казанда, археографик эзләнүләр вакытында, табылган бер нөсхәсе үзенең тулылыгы белән моңарчы мәгълүм булган барлык кулъязмалардан күп дәрәҗәдә югары тора икән. Ләкин бу өлкәдәге табышлар шул бер нөсхә белән генә чикләнми. Мәсәлән, Ж. Алмаз мәкаләсе басылып чыкканнан соң Колгали дастанының дистәдән артык яңа күчермәләре табылды, аларның кайберләре шактый әлегрәк күчерелгән...

Ләкин, күрәсездер, археография биредә ярдәмче роль уйный. Һәм археографик дәлилләрне төп критерийга әверелдерергә дә ярамый. Кызганычка каршы, бездә мондый күңелсез фактлар да юк түгел. Мәсәлән, «Борынгы татар әдәбияты» исемле китапта (1963) авторларның берсе Сәяди дигән бер шагыйрь тарафыннан язылган «Дастаны Бабахан» исемле поэманы Идел буе җирлеге әсәре дип тәкъдим итә. Авторның төп археографик дәлиле «бу әсәрнең безгә мәгълүм бердәнбер кулъязмасы Куян

авылының Бибигамбәр исемле татар кызы тарафыннан күчерелгән» дип әйтүгә кайтып кала; шунда ук ул әсәрнең «әле басылганы юк» дигән фикер үткәрә. Ләкин, тикшерә торгач, Сәяди поэмасының Ташкентта берничә мәртәбә басылган булуы ачыкланды. Һәм 1962 елга хәтле үк. Моннан тыш, безнең археографик эзләнүләр нәтиҗәсендә, «Дастаны Бабахан»ның тагы ике нөсхәсе табылды. Берсе — типик үзбәк почеркы белән күчерелгән Урта Азия кулъязмасы, икенчесе — төрекмән күчермәсе. Димәк, «Борынгы татар әдәбияты» тарихы авторларының бер генә нөсхәгә нигезләнеп ясаган нәтиҗәләре ашыгычрак булган икән.

Идел буе төрки әдәби мирасга 1358 елда иҗат ителгән «Нәһҗел-фәрадис» исемле әһәмиятле истәлек тә бар. Аның кулъязмалары сирәк очрый. Ләкин истәлекнең чыгышы турында кайбер каршылыклы фикерләр дә юк түгел. Бу табигый, чөнки ул әсәрнең әле чын-чынлап, әтрафлап тикшерелгәне юк. Димәк, «Нәһҗел-фәрадис»ны җентекләп тикшерү — киләчәктәге бурычларның берсе. Экспедицион эзләнүләр бу мәсьәләгә дә берникадәр өлеш кертте: 1968 елда Буа районында шул әсәрнең тагы бер татар күчермәсе табылды. Әгәр бу фактка Фәннәр академиясенең тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәре М. Юсупов тапкан нөсхәне өстәсәк, татарлар арасында «Нәһҗел-фәрадис»ның соңгы дәверләрдә дә киң таралган, димәк, әдәби процесска өзлексез тәэсир ясаган әсәр булуын күрербез.

Югарыда бер урында Горький өлкәсендә күп нәрсәләр табылуы әйтелгән иде. Моңа мисал итеп, «Җөмҗөмә солтан» поэмасының (ул 1370 елда Идел буенда язылган) бик сыйфатлы күчермәсен күрсәтергә мөмкин. Шул ук өлкәдә Камка авылында очраклы рәвештә табылган «Сәкам кыйссасы»ның нөсхәсе аерата игътибарга лаек. Чөнки XIII—XIV йөзләрдә Идел буе төркисе белән иҗат ителгән бу кызыклы әсәрнең (дини-легендар сюжетка төзелгән героик поэма) күчермәләре бик сирәк очрый. Мәсәлән, университетның гаять бай коллекциясендә дә моңарчы ул әсәрнең берниндн нөсхәсе юк иде. Ә хәзер шактый сыйфатлы һәм тулы текстыбыз бар.

Әлбәттә, археографик экспедиция вакытында җыелган кулъязмаларның әһәмиятен гел борынгы чор әдәби истәлекләр белән билгеләү дә беръяклылык булыр иде. Табылган әйберләр арасында Г. Кандалый, Г. Утыз Имәни, Г. Чокрый, Һ. Салихов кебек шагыйрьләребез, әдипләребезнең яңа-яңа күчермәләре күп. Алар арасында моңарчы киң мәгълүм булмаганнары да очрый.

Табышларның кыйммәтле төрләреннән берсе итеп, фольклор текстлары теркәлгән күп санлы кулъязмаларны күрсәтергә кирәк. Әйтергә яраса, мондый характердагы кулъязмалар фольклористика фәнебезне яңа баскычка күтәрергә сәләтлеләр. Мәсәлән, моңарчы басыла килгән җырларның, бәетләрнең күпчелеге замандашларыбыз теленнән белгечләр тарафыннан безнең көннәрдә язылып алынганнар. Менә шул әсәрләрнең XIX гасыр урталарында, хәтта әлегрәк тә кәгазьгә беркетелеп калган текстлары да шактый икән. Димәк, төрле дәверләрдә теркәлгән текстларны тарихи-чагыштыру ысулы белән тикшерер өчен дә мөмкинлекләр арта башлады. Бу исә бик перспективалы һәм актуаль мәсьәләләрнең берсе.

Археографик экспедицияләрдән максат бер әдәби истәлекләр артыннан гына чабу дип уйлау да дөрес булмас иде. Чыннан да, халыкның рухи дөньясы бер әдәбият, авыз иҗаты белән генә чикләнми бит. Өстәвенә, бу ике өлкәне аерым алган тәкъдирдә, без узган тарихыбызны күп яклап белүдән мәхрүм булабыз. Мәсәлән, төрле чорда ил өчендә хөкем сөргән фәлсәфи тенденцияләрне белми торып, әдәби хәрәкәтләргә дөрес бәя бирә алыр идекме? Яки төрле дәверләрдә яшәгән юридик нормаларны аңламыйча торып, шул чорлардагы гореф-гадәтләрне төшенергә мөмкинме? Янсә, тарихи белем дәрәҗәсен тулаем билгеләмичә, аерым тарихи әсәрләрнең конкрет әһәмиятен ача алырбызмы? Димәк, узган тарихны гыйльми объектив рәвештә тулы белер өчен, аны төрле яктан яктырткан чыганакларның да саннарын ишәйтергә, баетырга кирәк икән. Ә яңа җыелган кулъязмалар арасында андый төр документлар да шактый. Бер генә мисал китерик. Тарихчы Ш. Мәрҗанинның хәбәр итүенә караганда, Болгар шәһәрендә Хәсән Болгари исемле бер зур галим яшәгән. Җирле хакимнәр белән конфликтка кереп, ул чит илләргә качарга мәҗбүр була. Менә шул галимнең фәннең кайсы өлкәсендә эшләве, дөресрәге, аның әсәрләре моңарчы тәгаен мәгълүм түгел иде. Без Оренбург өлкәсеннән алып кайткан кулъязмалар арасында менә шул Хәсән Болгари әсәрләреннән мисаллар китергән шактый борынгы бер җыентык бар. Юриспруденциягә

караган ул китап «Мәҗмәгъ әр-рисалә» дип атала. Әсәрнең теле дә шактый архаик. Димәк, бу табыш та җентекләп тикшерүгә лаек...

Экспедицияләрнең максатын бер татар дөньясы белән генә чикләп кую да гыйльми тарлыкка, ягъни берьяклылыкка китерер иде. Игътибар иткәнсездер, китерелгән аерым фактлардан да безнең җирлектә башка халыкларның культурасы һәм әдәбиятларына мөнәсәбәтле истәлекләрнең табылулары чагылып киткәләде. Халкыбыз арасында, төрки телләрдә иҗат ителгән китаплардан тыш, гарәпчә, фарсыча әсәрләр дә гаять киң таралган.

Кайберәүләрнең «булса ни, алар бит дини әсәрләр» дип уйлаулары да ихтимал. Ләкин аларның һәммәсе дә гел дини китаплар гына түгел. Чөнки кешелек прогрессында хаклы рәвештә беренче дәрәҗәдәге якты йолдызлардан саналган Фәраби, Әбугалисина, Сәгъди, Хәйям, Ибн Хәлдун әсәрләре безгә гарәп һәм фарсы дөньясы аша килгән.

Чит ил истәлекләренә карата бездә кайчакларын икенче бер мөнәсәбәт тә очрый. Мәсәлән, борынгы кулъязмаларга сокланып караучыларның кайберләренә: «бу — Димәшкъ шәһәрендә язылган гарәпчә китап» дисәң, аларның шунда ук күңелләре сүрелә. Янәсе, «безнеке» түгел икән... Мондый мөнәсәбәт белән дә килешәсе килми. Теләсә нинди милли культураның мирасын барлауда, өйрәнүдә төрле халыкларның галимнәре арасында иҗади, самими хезмәттәшлек булырга тиеш. Һәм бу, тулаем алганда, шулай. Мәсәлән, Алтын Урта дәвере Идел буе төрки әдәбиятының классик үрнәкләре булган Хорәзми, Котып, Сәйфи Сараи әсәрләрен без шундый хезмәттәшлек нәтиҗәсендә генә белә алдык. Чөнки аларның бердәнбер кулъязмалары чит ил китапханәләрендә сакланалар. Безнең илдә булган гарәпчә, фарсыча, латинча, французча, кытайча сирәк кулъязмаларның эчтәлекләре белән дә кызыксынучы чит ил галимнәре бездән җибәрелгән фотокопияләр ярдәмендә танышалар. Мондый сирәк әйберләр Казан университеты китапханәсендә дә шактый һәм аларның саны киләчәктә тагы да артырга тиеш. Чөнки археографик сәфәрләр вакытында, югарыда телгә алынган «Кония»дән тыш, «Хөласәт ел-фәтави», «Мишкәте мәсабих» кебек борынгы әсәрләрнең XIV—XV гасырларга караган күчермәләре табылды. Боларның хосусый сыйфатлары, конкрет әһәмиятләре турында, вакыты килгәч, үз белгечләре тәфсилләп сөйләр әле.

Бездә киң таралган шәрык әсәрләре турында сөйләгәндә, бөек фарсы поэзиясен телгә алмый узу зур гаделсезлек булыр иде. Чөнки тирән акыл иясе хәким Сәгъди, әхлакый сафлыкның ялыкмас вәгазьчесе суфи Гаттар, мәхәббәт һәм ләззәт җырчысы шашкын Хафиз, бунтарь философ, үткен телле Хәйям әсәрләре дә татарларда киң таралып, сөелеп укылганнар.

Тугандаш әдәбиятлар тарихына караган археографик материалларның нәтиҗәләре исә тагын да күңеллерәк. Сәйяди поэмасыннан тыш, үзбәк шагыйрьләреннән Нәваи, Сәкакали, Һөвәйда, Мәшрәбләрнең әсәрләре табылды. Әзербәйҗан шагыйре Физулиның шигырьләре дә бездә киң таралган.

Икенче бер факт исә игътибарга аерата лаек, чөнки аның белән әдәби мөнәсәбәтләр тарихыбызда яңа сәхифә ачыла. Сүз тирән уйлы, кайнар хисле бөек төрекмән шагыйре Мәхтүмколый шигырьләренең татар күчермәләре табылуы хакында бара. Әгәр Мәхтүмколый әсәрләренең күчермәләре гомумән сирәк булуын игътибарга алсак, яңа табылган төрле сыйфатлы дүрт нөсханең кыйммәте тагы да арта.

Киләчәктә, экспедициябез составында рус-европа төркеме дә эшли башлагач, ихтимал, табышларның төрләре тагы да ишәерләр. Чөнки Урта Идел буе борынгы гасырлардан ук шәрык белән гареп уртасындагы ачык капка иде...

## Китапларга кемнәр канат биргән?

Без әле борынгы китапларны нәсел-гомерле, киләчәкле итеп, аларга чорлардан-чорларга очып узарлык, илләрдән илләргә барып житәрлек канатларны бирүчеләр, ягъни оригинал текстның башка күчермә нөсхәләрен булдыручылар турында берни дә әйтмәдек. Әгәр безнең көннәргә хәтле сакланган борынгы әсәрләрнең якынча 95 проценты оригиналда түгел, бәлки копияләрдә килеп житүләрен игътибарга алсак, язма культура тарихында күчерүчеләр тоткан урын беркадәре ачыклана төшәр.

Ләкин күчерүчеләрнең язмышлары төрле илләрдә төрлечә. Мәсәлән, Иран, Һиндстан, Төркиядә һәм башка шәрык илләрендә хаттат — каллиграфлар хөкем сөргән. Аларда, кагыйдә буларак, матур язулы, махсус әзерлекле профессиональ хаттатлар өстенлек иткәннәр, һәм бу кәсеп бик мактаулы булган. Шуна күрә дә борынгы Иран, Һинд һәм төрек хаттатлары турында үз заманнарында ук мәдхияләр иҗат ителеп, зур-зур трактатлар да язылган. Ә бездә?..

Чыннан да, кем соң син татар хаттаты?

Гадәттә, борынгы кульязмалар, гомумән иске китаплар турында уйлаганда, безнең алга иң әлек яшел чапанлы, зур чалмалы, мәгәр кечтеки генә акыллы фанатик мулла килеп баса. Әгәр үзебез ул язуларны укый алмасак, андый хисләр тагы да көчәя. Әмма биредә сүз, э с ә р д ә н бигрәк, аның к ү ч е р м ә л ә р е турында бара.

Беренчедән, бездә таралган кульязмаларның зур бер өлеше дөньяви әсәрләрдән гыйбарәт.

Икенчедән, дини әйберләрне күчереп утыру өчен дә «мөгътәбәр хәзрәтләр», әгәр бик саран булмасалар, вакыт әрәм итмәячәкләр. Чөнки алар өчен намаз укыту, корьән-хәтем кылу, җеназа чыгу күп мәртәбәләр файдалырак. Шуларның берсеннән төшкән килергә дә ул кирәк китабын сатып алачак.

Димәк, дини эчтәлекле мәгълүм әсәрләрнең т а р а л у л а р ы н д а руханилар сәбәп булсалар, дини китапларның да, дөньяви әсәрләрнең дә күчермәләре б а р л ы к к а к и л ү д ә муллаларның каләм көче хәлиткеч рольне уйнамаган.

Шуна да игътибар итәргә кирәк: татарлар арасында иң күп табылган күчермәләр үзләренең эчтәлекләре, формалары белән дә руханилар көтепханәләрендә була торган (булуы зарури) «җитди» мишкәтләрдән, авторитетлы «яшел китаплар»дан нык аерылалар. Гадәти татар китабына җитдиятсезлек, чуарлык хас. Менә боларның барысы да китап күчерүчеләр, хаттатлар армиясенең бөтенләй икенче даирәдән булуын күрсәтә.

Кайберәүләрнең, ихтимал, бездәге кульязмаларның зур өлешен алпавыт-морзалар, гомумән феодаллар даирәсендә генә үскән «җимешләр» дип уйлаулары бар. Әмма татар халкының XVI—XIX йөзләрдәге конкрет тарихында хәлләр икенчерәк төс алган. Беренчедән, татар милли феодаллары, реаль властьтан мәхрүм ителеп, диктаторлык хокукын югалтып, экономик яктан зәгыйфьләнгән килеш яшәгәннәр. Икенчедән, ул феодалларның иң затлыларының бер өлеше репрессияләргә эләгеп, «чабаталы морзалар» — горур хаерчеләргә әверелсә, калган зур төркеме дин алмаштырып, икенче культураны кабул иткән. Нәтиҗәдә татар феодал сыйныфы вакланып, чәрдәкләнеп, тирән эчке деградация кичергән. Менә шуның өчен дә т а т а р күчермәләре арасында алтын белән язылып, хәтфә тышлары көмеш белән бизәлгән купшы фолиантлар юк дәрәҗәсендә сирәк. Аларның күпчелеге халыкның түбәнрәк катламнарының вәкилләре тарафыннан эшләнгән. һәм, әллә кемнәр өчен түгел, нигездә үзләре өчен күчерелгәннәр. Агачына күрә җимеше дигәндәй, татар кульязмалары да гади чикмәнле, мескен бүрекле, тула оек, юкә чабатадан. Күчерелгән китапларның иң зур өлеше төрле стильдәге матур почерклар, чын зәгъфыран кара белән сыйфатлы кәгазьләрдә язылып, затлы күннәр белән тышланмаган. Кара кирәк икән, татар күчерүчесе казан корымына нидер кушкан; каләм дисәң — күркә белән каз канаты бетмәгән; тышлыкка катыргы булмаса, сәхтиян әзләп торма, менә сиңа эшкә яраксыз иске китапның җиде-сигез бите, менә арыш оны белән су, кат-кат итеп ябыштыр — вәссәлам! Ә тактадан юнып тыш ясыйсың икән, бу инде, җанкисәгем... мә, чиртеп кара!

Димәк, масьәлә биредә зәвык-мазарда түгел, ә максат һәм мөмкинлекләрдә икән. Татар кульязмаларының да зур күпчелеге, һәм дөньявиларының барысы диярлек, күчерүчеләрнең үзләре өчен язылганнар. Ә күчерүчеләр, югарыда әйтеп киткәнебезчә, нигездә гади халык вәкилләре [1].

---

[1] Дөрес, татарлар арасында да профессиональ хаттатларның булгалавы турында кайбер мәгълүматлар бар. Ләкин алар күп очракта эре руханиларга дин-канун китапларын күчерү белән мәшгуль булганнар һәм ара-тирә сыңар татар морзасының яки башкорт кантонының ялгыз-ярты заказларын үтәгәннәр. Менә шуның өчен дә татар җирлегендә күчерелгән дини китаплар үзләренең кыяфәтләре белән дөньяви әсәрләрнең күчермәләреннән чак кына пөхтәрәк, купшырак. Әмма Иран, Урта Азия, Төркия һәм Һиндстаннан килгән «коллегалары» алдында алар «янарал», «пулкауниклар» каршындагы капраллар гына...

Менә бу хәлләр барысы да татар каллиграфлары тарафыннан күчерелгән китапларда колофон дигән өстәмә язуның, ягъни күчермә паспортының сирәк булуына китерәләр. Чөнки күчерүче мәшһүр хаттат түгел, бәлки тар даирәдә билгеле һәм китап язуны өстәмә кәсеп иткән бер агай. Ә шәрык илләрендә картина икенчерәк. Китап күчерү — хаттатларның төп кәсебе. Кәсепчеләр исә күп. Сан өчен түгел, базарда сыйфат өчен дә көрәш бара; китапның матур почеркы белән пөхтә, затлы формасы да акчага тиңләнә. Менә шулай базар өчен барган кискен һәм дәвамлы көрәштә товарның конкрет сыйфаты белән аның турындагы рекламаның да әһәмияте арта. Нәтиҗәдә, һәр китапта диярлек каллиграфның исеме, күчермәнең эшләнү датасы, урыны күрсәтелә бара, яисә бу мәгълүматлар китапның стандарт тышлыгына уеп сугылган мөһердә бирелә. XVII—XIX йөзләрдә эшләнгән Урта Азия һәм башка шәрык илләре китаплары бу таләпләрне җиренә шактый төгәл җиткергәннәр.

Мондый төгәл колофон-мәгълүматлар борынгырак дәвердә әзерләнгән күчермәләр өчен дә хас. Ләкин аларда хаттатның исеменнән тыш, кагыйдә буларак, бу конкрет нөсхәнең нинди эре рухани, кодрәтле вәзир яисә затлы бәкнең заказы буенча эшләнүе дә күрсәтелә. Кыскасы, күчермәнең ата-анасы да, туган җире дә мәгълүм.

Безнең дөньяви кульязмаларыбызда бу хәл ничегрәк соң? Күп очракта бернинди мәгълүмат юк. Кайбер очракта бу нөсхәнең «алла ярдәме белән фәлән елны» күчерелүе әйтелә. Ә кем эшләве күрсәтелми. Чөнки китап хуҗасы үз исемен болай да белгән. Ләкин кайчакларын тулырак «колофон»нар да очрап куйгалый. Мәсәлән, «Ошбу китап мартның егерме өченче көнендә, кече җомга көнендә, аш вакытында тәмам булды. Язучы Фәхретдин Биккол дия белерсез, хаер-дога кыласызлар. Ошбу китапны Яңа Чәчкап авылының дәмелла Бикмулла мәдрәсәсендә яздым, мин Фәхретдин, Түбән Наратбашның Биккол углы».

Игътибар итегез: ай да, көн дә, хәтта сәгать тә бар, ә ел юк! Кайда, кем тарафыннан күчерелү әйтелгән, сәбәп-максат исә хаер-догадан гыйбарәт...

Әйе, татар шәкерте китап язуны кәсепкә, акча эшләүгә әверелдермәгән. Шуңа күрә ул үз күчермәсен күп очракта мондый юллар белән тәмамлаган:

Моны яздым ядкяр улмак өчен,
Укыганлар бер дога кылмак өчен...

Бу фикерләрне дәлилләр өчен, берничә типик шәкерт кульязмаларына күз салыйк. Менә Олы Әтрәч авылында табылган бер кульязма җыентык. Иң элек (әлбәттә, дежур «бисмилладан» соң) гарәп теле грамматикасы буенча зур гына текст китерелә. Аратирә ул текстны бүлеп, кайда һәм кайчан нинди хәлләр булуы теркәлеп куела. Мәсәлән, «бу ел рамазан шәрифтә пәнҗешәмбе көн зәвал вакытында мәгърип тарафыдин бер койрыклы йолдыз пәйда булды. Хода ахырын хәерле кылсын». Әлеге конспект тәмам булгач, берничә дини текст китерелеп, шуларга аңлатма бирелә. Моннан соң халык арасында киң таралган өч-дүрт бәет тексты язылган. Һәрберсенә «Илаһи бәет» дигән баш бирелгән. Шул исәптән «Сак-сок бәете», «Хан кызы» бәетенә дә. Моннан соң нинди чирне ничек өшкерергә кирәк икәнен беләбез. Аннары хатынның ир бала тапсын өчен нинди догалар укып, ничек йокларга кирәклеге турында «рецепт» бирелә. Ниһаять, хат язу буенча кулланма — әзер шаблоннар күчерелгән. Аларның берсе остазхәлфәләргә, икенчесе ата-ана һәм туганнарга языла торган хат формасы.

Менә шул хатлардан икенчесе игътибарга лаек. Мәсәлән, әти-әни, ага-җингә, әне-сеңел вә барча кардәшләргә «күптин күп, чуктин чук сәламләр» әйтелеп, үз хәле турында да хәбәр ителгәч, аңа нәрсәләр кирәк булуын беләбез.

«Әүвәл бер мичкә бал вә һәм ун кадак май» җибәрергә диелә. Аннары он, каймак, чәй-шикәрләр турында да сөйләнгәч, «мең сумса, өч йөз таба бәлеш, сигез йөз төче коймак» ашыйсы килгәнен укыйбыз. Һәм, ниһаять, «актыгында бикәч бик кирәк» икәнлеген дә аңлыйбыз. Әлбәттә, хат-шаблонның соңгы өлеше шаярып язылган, аның үрнәк өлеше баш ягында — сәламнәрдә. Мәгәр әлеге шаяруда да шәкерт кешенең хәле чагылып китә: ач тавык төшендә тары күрә... диләр.

Менә шулардан соң бу кульязманы кем язу хакындагы колофонны күрәбез: «Бу китапны язгучы Җиһанша бине Корбан мәрхүм углы. Укыгучылардан дога-хәер өмет итеп яздым. Шәһре Казанда Яңа бистәнең Шаһи Әхмәт хәзрәт мәдрәсәсендә. Кул тотты, каләм язды, кара төште, күз күрде, гакыл белде».

Игътибар итегез: «бине» һәм «углы» сүзләре янәшә китерелеп, тавтология барлыкка килгән. Дата да юк. Шулай да аның XIX йөз урталары булуы ачык: кәгазь, кара, почерк һәм катыргы тыш шул чорга карый.

Бу — тасвирланганы гади генә, дөресен әйткәндә, сәләмә генә бер китап. Ә менә монысы (аны Аллабирде авылыннан таптык) 235 кәгазьле, ягъни 470 битле «Мишкәт ел-әнвар» исемле төзек язулы фолиант — зур күләмле китап. Эчтәлеге һәм вазифасы буенча ул әре руханиларда булырга тиеш. Ләкин, гарәпчә язылган колофоннан күренгәнчә, ул да 1190 ел һиҗридә (ягъни 1776 елда) Бәрәскә авылында, Бикчәнтәй хәзрәт мәдрәсәсендә «зәгыйфь һәм кимсетелгән» Сәгыйть бине Габдеразак дигән шәкерт кулы белән язылган икән.

Кул Черкене авылында табылган бик чуар эчтәлекле бер җыентык (эчендә «Һафтияк тәфсире» дә бар) исә 1843 елда Казан шәһәрендәге Хәбибулла хәзрәт мәдрәсәсендә укучы Габденасыйр бине Сәйфулла Коллары әт-Тави (янәсе Тау ягының Коллар авылы кешесе) дигән егет тарафыннан күчерелгән.

Бу кыскача тасвирланган кулъязмалар элек үзләрен күчерүчеләргә хезмәт иткән, чөнки хуҗа бит кырыйларына шул ук почерк белән соңрак та өстәмә текстлар язып барган. Әмма еллар узу белән әлеге китаплар икенче кешеләргә сатылган. Мәсәлән, 1776 елда күчерелгән «Мишкәт ел-әнвар» турында аның тышлыгында шундый сүзләр укыйбыз: «1854 нче [елда] декабрьның унысында Бурнаш мелла Сәгыйдетдиндән бу «Мишкәт ел-әнвар»ны алдым, Бишна илендә Әхмәт Гобәйдулла углы. Хакы 15 сум. Алла хәерле кылыр».

Кул Черкене җыентыгының сатылуы исә гаять официаль төстә уза: «1848 нче елда февральнең 23 нче көнендә Тәтеш өязе Коллар иленең Мөхәммәтрәхим Сәйф углы саттым бу «Һафтияк тәфсирене» Югары Наратбаш иленең мулла Гобәйдулла Мөслим углына, бер «Әнмүзәҗ» китабы илән. Бәһасы өч сум илле тиен, нәкъ акча алдым. Мәзкүр Мөхәммәтрәхим Сәйф углы кулым куйдым, вә янә шул иленең Хәсән Бикбау углы гуаһ булып кулым куйдым; вә янә шул ук Коллар иленең мин Вәлиулла Рәхмәтулла углы гуаһ булып кулым куйдым».

Шушы фактлардан да кайчандыр «хәер-дога» өчен бирәүләр күчергән китапларның соңрак икенче кешеләр тарафыннан «нәкъ акча»га сатылуын күрәбез. Мондый дәлилләрне тагы да күп табарга мөмкин. Менә шуңа күрә дә югарыда «татар шәкерте китап күчерүне үзенә кәсеп итмәгән» дип әйтелгән иде. Әлбәттә, кайбер шәкертләрнең үзе язган китапны сату очраклары да бар. Тик андый фактлар сирәк очрый.

Менә шуңа күрә дә без узган тарихыбыздагы язу тану — грамоталылык түтәлләре булган бихисап күп әреле-вакллы мәктәп-мәдрәсәләребезгә, мәгърифәт орлыклары булып шуларга сибелгән шәкерт бабаларыбызга, аларның көчсез якларын яхшы белгән хәлдә дә, зур ихтирам белән карыйбыз. Алар моңа лаек. XVII—XIX йөзләрдәге татар язма әдәбияты үсүгә дә шуларның күз нуры, кул көче сәбәп булган. Хәтта элеккерәк дәвер әдәби истәлекләрнең әзме-күпме сакланып калуларына да без шул шәкерт бабаларыбызга бурычлы. Чөнки ул истәлекләрнең исән калган нөсхәләренең барысы да диярлек шул шәкертләрнең каләме белән «фәлән хәзрәт мәдрәсәсендә» күчерелгәннәр. Чөнки алар, хәлләре кайтыш, белемнәре чамалы булуга карамастан, укырга, язарга, күчерергә яратканнар. Язу дигән нәрсәнең кодрәтле көчкә ия булуын аңлаганнар.

Каләм үгрән, каләм сине изгегә тартар,
Каләм берлә кайда барсаң — гыйззәтең артар.

Белемебез аз, күп укыр өчен мөмкинлек юк, шулай булгач, китап мәсьәләсе — муллалар эше, дип, читкә тайпылмаганнар. Ә тырышып укыганнар, ялыкмыйча күчереп язганнар, хаталары була калса дип, алдан ала гафу сорап куйганнар:

Хат хатадыр, хатасын орма йөзгә,
Хатадин хали ирмәс хакдин үзгә...
Хата ирсә — каләм илә сыяһы,—
Фәкыйрь язгучының күптер гөнаһы;
Хата йирен төзәтмәй китмәңезләр,
Догаңыздан фәрамуш итмәңезләр [1].

[1] Сүзлек: хали ирмәс — азат түгел; сыяһ — кара; фәрамуш итү — ташлау, мәхрүм итү.

Әлбәттә, зур мәдрәсәләрдә галим мөдәррисләрдән укып җитлеккән яисә китапны күчерә-күчерә шомарып беткән кешеләрнең сүзе түгел бу! Андыйлар хата да җибәрмәс, кем күренгәннең «догасына» да мохтаҗ булмас. Мондый тыйнаклык гади кешеләр өчен генә хас...

## Турылыклы варислар

Борынгы кулъязмалар безнең китап хәзинәләренә, оясына кайткан почта күгәрченнәре кебек, үзләреннән үзләре очып килмиләр. Безгә килеп җиткәнче, алар төрле юлларда каңгыраганнар, абынмалы сукмакларда сөртенгәннәр. Ә ул юллар, ул сукмаклар еллар, гасырлар озынлыгы белән үлчәнгән. Башларына төшкән җәфалар исә бер нәрсә белән дә үлчәнерлек түгел. Һәм аларның бик күбесе мәңгегә һәлак булган инде. Бары бер өлеше генә, һәм кечкенә өлеше генә безнең көннәргә хәтле килеп җитә алган.

Ләкин болары да килеп җитү өчен ярдәмгә мохтаҗ иделәр. Ә ярдәмне кемнәр күрсәткән соң? Җавап катлаулы түгел — мәгърифәтле кешеләр һәм китапны, белемне сөючеләр. Мондыйларның исә төрле катламнардан чыгулары ихтимал. Мәсәлән, кайбер руханиларның бай китапханәләр туплавы, сирәк очрый торган кулъязмалары белән горурланулары тарихта мәгълүм факт. Шулай ук үзе иҗекне иҗеккә көчкә куша да, кулына очраклы рәвештә төшкән китапка ихтирам белән карап, «без булмасак, балалар үскәч укыр» дип, аны хатынының ала яулыгына төреп киштәгә алып куйган һәм өендә китабы барлыкка сөенгән ярлы-ябагай крестьян агайлар да күп булганнар. Ихтимал, менә шундый «кара халыкларыбыз»ның уллары әзме-күпме язу таныгач, башкаларны да укырга өндәп, язу-каләмнең көчен, файдасын пропагандалап йөргәннәрдер? Чөнки әләмә-сәләмә генә кулъязмаларда:

Каләм юндым иничкә, кылыч тик очы,  
Камуг әледин әлгә хәбәр биргүче [1],—

дигән кебек юллар очрыйлар. Һәм мондый пропагандистлар, язуның файдасын күрсәтү белән чикләнмичә, язусызлыкның зарарын да үзләренчә аңлатырга тырышканнар:

Каләм белгәнләр дөньяда чәчәктик,  
Каләмсез кешеләр сыгыр-ишәктик!

Еллар, хәтта гасырлар буена дәвам иткән мондый пропаганда халкыбызда язуга, китапка карата ихтирам, мәхәббәт хисе тәрбияләгән. Шуның өчен дә ул «каурый тоткан хур булмас», дип инанып, «укыган угыл атадан олы» булуын тәҗрибәдә сынап, «кәгазьнең йөзен агарткан кара язу», дип, гаҗәеп хикмәтле нәтиҗә чыгара. Ак йөзле кәгазь — китап ул, китап исә белем чишмәсе. Ә «гыйлем иясен газиз итә». Безнең кулъязмаларыбызның сугыш-вәйраннар, упкын-янгыннар иләге аша үтеп, бу заманнарга җитә алуларын да халкыбызның язу һәм белемгә, китап һәм гыйлемгә ихтирамының нәтиҗәсе дип карарга кирәк. Китапка хөрмәт — халкыбызга тулаем хас сыйфатларның берсе.

Китап сөючеләрдән аеруча кызыклы бер шәхес турында киңрәк тукталасы килә. Сүз Касим шәһәрендә мәдрәсә тотып (димәк, муллалык эшен дә үтәп), озак еллар шәкертләр тәрбияләгән мөдәррис Фәттахетдин Садретдин улы Бәшири турында барачак. Ул — тыныч кына гомер кичереп, 85 яшенә җиткәч, 1956 елда үз өендә балалары каршында вафат булган «урта кул» бер укымышлы. Ләкин Фәттах абзый сүзнең чын мәгънәсендә «китап җене кагылган» кешеләрнең берсе булган. Моны ишетмештән түгел, бәлки материаль фактлар — ул җыеп калдырган китапларның үзләренә нигезләнеп әйтәм. Ә алар исәп-хисапсыз иде.Ниндиләре генә юк биредә: борын-борын күчерелгән иске кулъязма дисеңме, әллә кайларда, хәтта ерак илләрдә басылган китапларны әйтәсеңме, калын-калын итеп төпләнгән газета-журналлар коллекциясен сорыйсыңмы — барысы да бар. Катып калган дини әйберләр дә, эзләнүче гыйльми хезмәтләр дә, әче телле атеистик әсәрләр дә киштәләрдә үз урынын тапканнар.

[1] Сүзлек: иничкә — нечкә; камуг әледин әлгә — барчасының (ягъни, күпчелекнең) кулыннан кулга.

Дүрт бүлмәнең стеналары буйлап тезелгән шкаф һәм киштәләрдән тыш сандыкларда да китаплар тулы иде. Без (Ә. Кәримуллин белән икәү), витриналагы уенчыкларга баккан малайлар шикелле, авыз ачып торабыз. Әйе, мондый бай китапханәне җыяр өчен аң-белемгә мәхәббәттән тыш зур түзем, озын гомер дә кирәк. Фәттахетдин абзый: «Минем ике байлыгым бар, берсе — балаларым, икенчесе — китапларым», дип горурланган; кайчакларын «беренчесе — китапларым», дип тә ялгыша булган.

Китапларны ул гомер буена җыйган: үзе күчергән, сатып алган, бүләк сыйфатында кабул иткән. Хәтта 20 елларда «кәчимески Ибрайлар» соңгы мәртәбә һәм мәңгегә «банкрот» булып таралган чакларда да Фәттах абзыйның бер шөгыле хуҗасыз калган йортларда, тәрәзәләре ватык иске мәдрәсәләрдә аунап яткан китапларны үлемнән коткару булган. Шуның өчен дә Бәшировлар коллекциясендәге кульязмалар арасында бөтенләй икенче кешеләрнең имзасы куелып, мөһере сугылган нөсхәләр бар.

Китаплар Фәттахетдин абзыйның башына да җитә язганнар. Бу хәл 1905—1906 еллар тирәсендә була. Казаннан шыгрым тулы ике саквояж китап алып кайтышлый, ул юлдагы кечкенә авылларның берсендә кунарга туктый. Кышкы юлда арып, күшегеп беткән мосафир ял итәргә җыена. Тик күрәктәй зур сакаллы йорт хуҗасы аның котын ала: әллә нинди сәер күзләр белән бер саквояжларга, бер юлчыга карый-карый ул тынгысыз йөренә башлый, аннары бер ноктага төбәлеп хәрәкәтсез кала. Хуҗа нидер хәл итә...

Хәвефнең каян киләсен сизеп алган юлчы саквояж янына барып, хуҗага дәшә:

— Әйдә, знакум, мин алып кайта торган байлыкны кара,— ди һәм бер-бер артлы китаплар чыгара башлый...

Ике саквояж да бушагач, күрәк сакал җиңел сулап куя:

— Син галим кеше икән, ә мин бай сәүдәгәр дип торам. Ярар, тыныч йокы...

Карт көннәрендә, күзләре тәмам сукырайгач та, Фәттах абзый үз куңелен китаплар белән юаткан: кармана-кармана киштәләрдәге китапларны капшап йөргән, заманында үзе сөеп укыган берәрсен кулына алган. Зур борынлы, түгәрәк ак сакаллы һәм күзләре дөм-сукыр чандыр бабай тезләре өстендә яткан китапны озак-озак сыйпап утырырга яраткан.

Фәттахетдин бабай вафат булгач, ул җыйган китаплар коллекциясе аның кызлары Фәрхәнас, Галимә апалар һәм улы Һади абзыйларга кала (өчесе дә бөтен гомерен яшь буынны тәрбияләүгә багышлаган элекке педагоглар, ә хәзер — мөхтәрәм пенсионерлар).

Иске китаплар саклау семья тормышы өчен шактый уңайсызлыклар тудырып торса да, ата мәхәббәтен мирас итеп алган балалар «мәйдан киңәйтер өчен» ашыкмыйлар. Ул китапларның ата истәлеге генә түгел, бәлки халык байлыгы булуын да варислар яхшы беләләр һәм аларның шәхси куллардан дәүләт-ил мөлкәтенә күчәчәкләренә, фән өчен хезмәт итәчәкләренә ышанып яшиләр. Шуңа күрә дә экспедиция хезмәткәрләре Касимга килгәч, Бәшировлар ул китапларны — язмасын да, басмасын да — Казан университетына бүләк иттеләр.

Хәзер университет хәзинәлегенә саклануга кабул ителгән бу уникаль коллекциянең әһәмиятен күрсәтер өчен бер аерым фактка, язмаларга түгел, ә басма әйберләргә генә тукталам. Сүз революциягә кадәр чыккан татар газета-журналларының җыелмалары һәм аларның безнең фәнебез өчен кыйммәтләре хакында бара. Мәсәлән, университетның бик байдан исәпләнгән фондында кайбер журналларның һәм газеталарның күп кенә саннары, нөсхәләре юк иде. Шуңа күрә аларны тикшерергә теләгән галимнәр бер-ике мәкаләне укыр өчен дә махсус командировкалар алып, Мәскәүгә, Ленинградка янсә башка җирләргә барырга мәҗбүрләр иде. Ә менә Бәшировларның кыйммәтле бүләкләре аркасында шундый «ертыклар», «тишек-тошыкларның» шактыйлары тулып ямалдылар.

Болардан тыш Бәшировлар коллекциясендә нөсхәләре башка бер җирдә дә сакланмаган һәм моңарчы фәндә үзләре дә мәгълүм булмаган аерым газета-журналлар да очрый. Мисал итеп революция елларында Касим шәһәрендә ташбасма ысулы белән чыккан «Аң» журналын, «Чалгы» газетасын күрсәтергә мөмкин. Хәер, Фәттах бабай мирасын бәйнәләп тасвирлар өчен махсус мәкалә кирәк булыр иде...

Әйе, мирас гомерле булсын өчен, аңа карата варисларның турылыклылыгы кирәк икән. Моның шулай икәнлеген гади авыл кешеләренең тарихи истәлекләрне җыюда

безгә шатлана-шатлана ярдәм итүләре, үзләрендә булган материалларын исә ышанып тапшырулары яки кайда нәрсә ятуын күрсәтүләре артыгы белән исбат итә.

Дөрес, бу мәхәббәтнең гарип формалары да юк түгел. Әңгәмәбез башында тасвир ителгән «кырыс бабай» вакыйгасы да шуны күрсәтә. Кызганычка каршы, кайбер авылларда картларның урынсыз курку фактларын да очраткаладык. Мәсәлән, бернечә төштә әби-бабайларның шамаильләрен яшереп куюлары мәгълүм булды. Нишлисең, алар безнең һәфтияк, Иман шарты, шәмаил кебек әйберләр белән бер дә кызыксынмавыбызны каян аңласыннар! Әгәр аңласалар, «Хәзрәте Гали» урынына «Хәсрәте Гали» дип «чумарилар» тарафыннан язылган (гарәп язуында бер ноктаның артыкмлеге менә шундый мәгънә бозуларга китерә!) буяулы пыяла кисәкләрен калтырый-калтырый качырып йөрмәсләр иде бит!

Ихтимал, кулларында сакланган башка язмаларны бездән яшереп калучылар да булгалагандыр. Үкенеч, чөнки ул китапларның зур өлешен череп бетү яисә ут көтә...

Ләкин, бәхеткә каршы, күпчелекне башкалар,— иске язмаларны «дин галәмәте» генә дип түгел, бәлки узган тарихның өйрәнелергә лаек истәлеге, бабайларның тарихтагы тирән эзләре дип, фәнни дөрес бәяләүчеләр тәшкил итә. Алар аз булсалар, безнең экспедицияләр дә югарыда күрсәтелгән казанышларга ирешә алмаслар иде. Шуңа күрә бу форсаттан файдаланып, безгә тарихи материалларын тапшыручылардан чит өлкәләрдә торучы Фәрхәнас апа Бәширова, Кәрим ага Бәхтиев (Касим шәһәре), Маһирә апа Урманова (Рязань өлкәсе Әҗе авылы) Тәуфикъ ага Сабитов, Фәрит Шәймиев (Оренбург шәһәре), Габделбәр ага Хәбибуллин (Горький өлкәсе Кр. Горка авылы), Гатаулла абзый Әхтәмов, Солтан абзый Таһиров, Хәлиулла ага Евлаевларга (Астрахань шәһәре) һәм Татарстанда яшәүчеләрдән Кәшиф абзый Рәхимов (Бәйрәкә авылы), Рабига апа Миңһаҗова, Гөлсем апа Кәлимуллина (Кул Черкене), Сәгыйт Кишмаев (Яңа Тинчәле), Вәзих Ибатуллин (Әхмәт авылы) һәм башкаларга чиксез зур рәхмәтләр укыйбыз.

Экспедиция сәфәрләре вакытында халык арасындагы кульязмаларны эзләшүдә якыннан ярдәм итүчеләр һәм акыллы киңәшләр бирүчеләр дә күп иделәр. Шулардан Абдулла ага Ибәтуллин (Кр. Горка авылы, Горький өлкәсе), Тәуфикъ абзый Вахитов (Яңа Тинчәле), Гәрәй абзый Алимов (Олы Чынлы), Борһан ага Низамов (Югары Наратбаш), Абдулла ага Дәминев (Олы Тархан), Кәрим абзый Конеев (Астрахань), Шәфигулла абзый Гыймранов (Аллабирде), Даян Бикмуллин (Яңа Чәчкап) һәм башка бик күпләргә үзебезнең зур бурычлы булуыбызны белдерәбез.

Шулай ук урыннардагы совет органнары, колхоз идарәләре хезмәткәрләренә дә безнең экспедициягә күрсәткән практик ярдәмнәре өчен күп рәхмәтләр әйтәбез.

Әгәр биредә исемнәре аталган һәм аталмаган күп санлы дусларыбыз якыннан ярдәм итмәсәләр, без алып кайтып, университет китапханәсенә саклауга тапшырган кульязмаларның (бары кульязмаларның гына) саны 700 гә якын да бармас иде. Ә «күп төкерсә, күл була» ди халык. Бәс, күмәкләшеп эшләсәк, җиде йөзнең җиде меңгә җитүе бер дә гаҗәп түгел. Сан сыйфатка әверелүчән. Бәлки, фәнебез, культурабыз һәм тарихыбыз өчен иң кирәкле, иң кадерле, иң мөһим булган борынгы әсәрләр менә шул җыелачак меңнәр арасында ятадыр?!

* * *

Бу мәкаләнең укучыларда төрле уйлар тудыруы ихтимал. Кайбер мәсьәләләр буенча фикер алышырга уйлаучылар да табылыр. Үзләрендә яисә гомумән авылларында саклана торган кульязмалар хакында хәбәр итәргә яки аларны галимнәргә бирергә теләүчеләр дә күп булыр. Кунакка чакырып, өеңнең кайдалыгын әйтмәү мәгънәсезлек булган кебек, хезмәттәшлеккә дәшеп, эш урыныңны күрсәтмәү дә нәтиҗәсезлеккә китерер иде. Шуңа күрә хәбәрләшергә теләүчеләр өчен түбәндәге адрес тәкъдим ителә:

г. Казань,
Университет, исторический факультет,
кафедра истории СССР.

# ДАНЛЫ КӨННӘР ЕЛЪЯЗМАСЫ

Бөек Октябрь социалистик революциясе җиңгәннән соң, Россия хезмәт ияләренә контрреволюцион эчке буржуазия һәм чит ил империалистлары тарафыннан авыр сугыш көчләп тагылды. Эчке һәм тышкы дошманнар үзара берләшеп, яшь совет дәүләтен аяктан егарга, эшче-крестьяннарны яңадан коллыкка, караңгылыкка дучар итәргә теләделәр. Хезмәт иясе халкыннан гаять зур корбаннар сораган гражданнар сугышы башланып китте.

Кыска гына вакыт эчендә хәзерге Татарстан территориясе ике мәртәбә ут-гарасат уртасында калды. Моннан тыш, Татарстан хезмәт ияләре, Совет дәүләтенең азатлыгын һәм иминлеген яклап, илебезнең төрле почмакларында акгвардиячеләргә һәм чит ил интервентларына каршы көрәштеләр, фронтны кирәк-ярак белән тәэмин итүдә актив катнаштылар.

Тарих фәннәре докторы, профессор Мидхәт Мөхәррәмовның күптән түгел Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Татарстанда гражданнар сугышы»[1] дигән монографиясе республикабыз тарихының әнә шул давыллы сәхифәләрен сурәтләүгә багышланган.

Иң әвәк хезмәтнең бай фактик материалга нигезләнеп язылуын билгеләп үтәсе килә. Автор, КПСС өлкә комитеты партия архивы, Татарстан үзәк дәүләт архивлары материалларыннан тыш, КПСС Үзәк Комитеты янындагы марксизм-ленинизм институтының үзәк партия архивы, Октябрь революциясе һәм социалистик төзелеш үзәк дәүләт архивы, Совет Армиясе үзәк дәүләт архивында саклана торган материаллардан киң файдаланган. Аңа барлыгы 35 фондта тупланган материалларны тикшереп чыгарга туры килгән. Моның өчен күпме вакыт сарыф итәргә һәм күпме көч куярга кирәк булуын тарихчылар яхшы белә. Шуның өстенә ул гражданнар сугышы елларында чыккан «Правда», «Знамя революции», «Бедняк» кебек рус газеталарының материалларын кулланышка керткән.

Галимнең фактик материалларга гаять бай, шул ук вакытта тарихчыларыбыз тарафыннан моңа кадәр аз файдаланылган татар газеталарыннан актив файдалануын аеруча басым ясап әйтергә кирәк. Бигрәк тә «Эш», «Кызыл Армия» газеталарыннан алынган мәгълүматлар игътибарга лаек. Шулай ук электән билгеле булган күп чыганаклар (документлар җыентыклары, монографияләр, истәлекләр һ. б.) файдаланылган. Болар барысы да монографияне бай эчтәлекле иткәннәр, хезмәт белән танышканда Татарстандагы гражданнар сугышының тулы картинасы күз алдына баса.

...1918 елның язында чит ил империалистлары һәм эчке контрреволюция тарафыннан Совет властена каршы яңа фетнә оештырыла. Революция дошманнары Совет хөкүмәтенең карары буенча ерак Көнчыгыш аша үз илләренә кайтырга чыккан әсир чех һәм словак солдатлары арасында төрле ялган хәбәрләр тараталар һәм нәтиҗәдә аларны Совет Россиясенә каршы көрәштә коралы көч итеп файдаланалар. Фетнә Идел буе шәһәрләренә дә тарала. М. Мөхәррәмов үз китабында бу фетнәгә киң туктала. Казан өчен барган авыр сугышларны, Коммунистлар партиясенең һәм Совет хөкүмәтенең Идел буен, шул исәптән хәзерге Татарстан башкаласын һәм республика территориясен фетнәчеләрдән азат итү өчен күргән чараларын автор ышандырырлык фактлар ярдәмендә сурәтли.

Китапның уңышлы якларыннан берсе — бөек юлбашчыбыз В. И. Ленинның гражданнар сугышын һәм чит ил хәрби интервенциясенә каршы көрәшне оештыруда титаник хезмәтен күрсәтүдә. Татарстанны азат итү мисалында гына да В. И. Ленинның һәр зур операцияне оештыруда һәм аны тормышка ашыруда якыннан торып катнашуын күрәбез. Татарстанны азат итүдә Идел флотилиясен куллану — шуның ачык мисалы. 1919 елда Татарстан территориясен Колчак бандаларыннан азат итүдә дә В. И. Ленин турыдан-туры катнаша. М. Мөхәррәмов китабында мондый мисаллар аз түгел, һәм алар Коммунистлар партиясенең гражданнар сугышы елларындагы югары ролен тирәнрәк аңларга ярдәм итәләр.

---

[1] М. Мухарямов. Гражданская война в Татарии (1918—1919). Рус телендә. Казан, 1969 ел.

Шул ук вакытта Татарстан территориясендә барган гражданнар сугышы бөтен илебез алып барган авыр көрәшнең бер өлеше генә иде. Бу авыр елларда илебез халыклары арасында эчкерсез дуслык тагын да ныгый барды, пролетар интернационализм принциплары тормышка ашырылды. Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәте тарафыннан Көнчыгыш фронтка җибәрелгән П. А. Кобозев, К. А. Мехоншин, С. И. Гусев, К. Х. Данишевский, П. К. Штернберг һ. б. кебек танылган хәрби-политик эшлеклеләрнең хезмәтен, В. И. Ленин кушуы буенча Казанга килгән Мулланур Вахитовның Идел буен, шул исәптән Татарстан территориясен азат итү өчен алып барган эшләрен автор югары бәяли. Китапта В. Азин, Н. Маркин, Ян Юдин, В. Чуйков, Л. Рейснер кебек гражданнар сугышы геройларының каһарманлыклары, татар халкының Сәхибгәрәй Сәетгалиев, Хөсәен Мавлютов, Камил Якубов, Якуб Чанышев, Бәкер Белоусов, Нурулла Яруллин, Гали Касыймов, Шәһит Әхмәдиев, Хәсән Урмановлар кебек танылган улларының социализм эше өчен данлы көрәшләре ачык һәм киң сурәтләнә.

Гражданнар сугышы һәм чит ил интервенциясе елларында Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәте милли мәсьәләне дөрес хәл итүгә аеруча зур игътибар бирделәр. Бу аңлашыла да. Халыкара империализм булсын, буржуаз милләтчеләр булсын, Россиянең күп милләтле ил булуын үзләренчә файдаланырга маташтылар. Алар илебезнең рус булмаган халыклары арасында төрле провокацияләр оештырдылар, патша хөкүмәте шартларында туган милли дошманлыкны Совет хөкүмәтенә, рус хезмәт ияләренә юнәлтергә тырыштылар.

1918 елның җәендә Идел һәм Урал буе халыклары, бигрәк тә татар һәм башкортлар арасында милли мәсьәлә шактый кискен төс алды. Акчехлар фетнәсе уңае белән, буржуаз милләтчеләр үзләренең корткычлык эшләрен бермә-бер көчәйтә төштеләр.

1918 елның 14 июнендә Совет дәүләтенең «Бөтен мөселман хезмәт ияләренә!» дигән махсус мөрәҗәгате басылып чыкты. Аңа Халык Комиссарлары Советы председателе В. И. Ленин, Үзәк Татар-Башкорт Комиссариаты председателе Мулланур Вахитов һәм совет дәүләтенең башка эшлеклеләре кул куйган иде. Бу документ совет хөкүмәтенең эчке һәм тышкы дошманнарның мәкерле планнарын фаш итүгә зур игътибар бирүе, мөселман халыклары арасындагы бөтен демократик көчләрне эксплуататорларга каршы көрәшкә туплавы турында сөйли.

М. Мөхәррәмов монографиясендә Татарстандагы милли мәсьәлә һәм партия совет органнарының бу мәсьәләгә игътибары шактый киң яктыртыла. Автор илебезнең башкаласында һәм урыннарда партия, совет һәм хәрби оешмалар составында милли секцияләр һәм бүлекләр булдырылуына һәм аларның хәзерге Татарстан территориясендә җирле халык арасында алып барган эшләренә киң туктала. Бигрәк тә хәрби берләшмәләр, шул исәптән Беренче татар укчы бригадасын оештыру, партия оешмалары җитәкчелегендә совет хәрби оешмаларының агитация-пропаганда эшләре уңышлы гына тасвирлана. Шул турыда сөйли торган кызыклы фактлар китерелә. Мәсәлән, Көнчыгыш фронтының Беренче армия политотделы чыгара торган «Кызыл йолдыз» газетасы үзенең битләрендә татар, төркмән, әзербәйҗан телләрендә материаллар бастыра (198 бит).

Вак буржуаз партияләрнең, буржуаз милләтчеләрнең гражданнар сугышы елларындагы мәкерле эшләрен күрсәтүгә шулай ук зур урын бирелгән. Нәкъ менә гражданнар сугышы елларында күп кенә «милли җитәкчеләрнең» чын йөзләре ачыла. Китапта болар конкрет фактлар белән дәлилләнә. Билгеле булганча, акгвардеецларның үзләре басып алган территорияләрдә хезмәт ияләренә карата ерткычларча мөнәсәбәте, иске тормыш тәртипләрен кайтарырга тырышулары кире нәтиҗәләр бирә. Халыкның моңа кадәр икеләнеп торган катлаулары Совет властен актив яклаучылар булып китәләр. Һәм кискен сыйнфый көрәштә акгвардиячеләрнең турыдан-туры ярдәмчеләренә, адвокатларына әверелгән вак буржуаз партияләре вәкилләре, милләтчеләр халык арасында үзләренең йогынтыларын бөтенләй югалталар. Ильяс Алкин, Гомәр Терегулов, Бари Баттал, Фуад Туктаровларның акчехларга армый-талмый булышулары да, Абдулла Апанаев, Һади Атласов кебек дин әһелләренең Совет яклы кешеләр өстеннән Колчак властьларына донос язулары да китапта конкрет мисаллар белән раслана. «Эш» газетасының 1919 елгы 21 апрель санында бу турыда сөйли торган характерлы материал басыла. Мөфти Галимҗан Баруди, Салихҗан Урманов һәм танылган милләтче Гаяз Исхакый Колчакта приемда булалар һәм аннан татарлар өчен милли автономия бирүен сорыйлар. Бик кызык картина килеп чыга: үзен «социалист» дип йөргән, «халык өчен көрәшәбез» дип авыз суы корыткан Гаяз Исхакый монархист Колчактан автономия сорый. Бу вакытта Совет хөкүмәте тарафыннан татар һәм башкорт халыклары өчен автономия күптән игълан ителгән иде бит инде!.. Бу фактлар «социалист» Гаяз Исхакыйның һәм аның коллегаларының сүздә генә социалист булуларын; ә асылда монархист Колчак биргән автономия белән канәгатьләнергә җыенучы буржуаз милләтче булуын тагын бер кат фаш итәләр. Канлы адмирал исә автономияләрне, милли парламентларны, милли идарәләрне күрергә дә теләми. Ул патша хөкүмәтенең шовинистик милли политикасын тормышка ашырырга җыена. Үзе басып алган өлкәләрдә бу политиканы эштә күрсәтә. Ләкин моңа карап «социалист» Гаяз Исхакыйның һәм аның компаниясе элекке изелгән халыкларга тулы автономия бирүче совет властена үзләренең карашларын үзгәртмиләр. Чөнки аларга социализм да, хәтта автономия дә түгел, ә бәлки эксплуататор сыйныфлар хакимлек итә торган система кирәк...

Автор, турыдан-туры хәрби вакыйгаларга кагылган мәсьәләләрдән тыш, элекке

Казан губернасында партия һәм совет органнарының төзелешенә һәм аларның эшчәнлегенә, авылда икмәк өчен барган көрәшкә һәм промышленностьны җайлауга багышланган мәсьәләләргә дә шактый зур урын бирә. Бер яктан, бу мәсьәләләрне яктырту ул вакыттагы вакыйгаларның катлаулыгын, партия һәм совет органнарының, эшче-крестьян халкының төрле өлкәләрдәге фидакарь көрәшен тирәнрәк аңларга ярдәм итә. Шул ук вакытта гражданнар сугышына турыдан-туры кагылмаган кайбер бүлекләрне, аерым вакыйгаларны бераз кыскартудан китап берни дә югалтмас иде, ә, киресенчә, отар гына иде кебек.

Монографиянең бу чорда Татарстан җирлегендәге социалистик төзелеш мәсьәләләрен эчкә алуы, күп кырлы булуы аның исемен: «Татарстанда гражданнар сугышы» дип түгел, ә бәлки «Гражданнар сугышында Татарстан» дип исемләргә, һәм хронологик рамкасын бераз арттырырга кирәк булгандыр дигән фикер тудыра. Безнең уебызча, кайбер мәсьәләләрне исә киңрәк яктыртырга мөмкин иде. Мәсәлән, монографиядә беренче Совет автономия проекты булган Татар-Башкорт Совет Социалистик республикасы игълан ителүнең әһәмиятенә киңрәк тукталырга мөмкин иде кебек. Билгеле булганча, В. И. Ленин кул куйган «Бөтен мөселман хезмәт ияләренә!» дигән мөрәҗәгатьтә дә нәкъ менә шушы туып килүче Татар-Башкорт Совет Социалистик республикасын якларга чакырыла бит. Дөрес, гражданнар сугышы беткәннән соң татар һәм башкорт халыкларының үз теләкләре буенча аерым автономияле республикалар төзелә, һәм ул практикада үзенең дөреслеген күрсәтте. Ләкин бу давыллы чорда буржуаз милләтчеләрне фаш итүдә, демократик көчләрне Совет власте тирәсенә туплауда бу беренче совет милли автономия проектының әһәмияте гаять зур булды.

Китап иллюстрацияләргә бай. Анда гражданнар сугышында актив катнашкан күп кенә хәрби-политик эшлеклеләрнең портретлары, рәсемнәре урнаштырылган. Шулай ук китап ахырында китерелгән белешмәләр, библиография дә китап белән эшләүне җиңеләйтәләр. Аны Татарстан тарихы белән махсус шөгыльләнүчеләр дә, пропагандистлар, агитаторлар, укытучылар да файдалана алачаклар. Һәм ул киң катлау укучылар арасында да кызыксыну уятыр дип ышанасы килә.

Гомумән алганда, М. Мөхәррәмов китабы Татарстан хезмәт ияләренең чит ил хәрби интервенциясе һәм гражданнар сугышы елларында илебезнең бәйсезлеге һәм ярлы эшче-крестьян халкының азатлыгы өчен барган авыр көрәшкә керткән өлешен шактый тирән чагылдыра. Анда Коммунистлар партиясенең Совет властенең беренче елларындагы титаник хезмәте тулы күрсәтелгән. Кыскасы, авторның бу монографиясе республикабыз тарихын өйрәнүгә лаек өлеш кертә.

**РИФ ХӘЙРЕТДИНОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

# ЧОРНЫҢ ШИГЪРИ ШӘҺАДӘТНАМӘСЕ

Бүгенге Җәлилиана — татар совет әдәбият белеменең (һәм бер татар әдәбиятының гына да түгел) үз предметы, үз тарихы, үз методикасы һәм хәзер инде дүрт урынлы саннар белән исәпләнә торган үз библиографиясе булган шактый киң һәм мөстәкыйль өлкәсе.

Күптән түгел бу исемлеккә тагын бер хезмәт — әдәбият галиме В. Г. Воздвиженскийның «Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» исемле китабы[1] өстәлде. (1969 ел башында, әлеге хезмәте нигезендә, автор кандидатлык диссертациясе яклаган иде).

В. Воздвиженский китабы аңа кадәр бу өлкәдә эшләгән кешеләрдән Г. Кашшаф, Р. Бикмөхәммәтов, Н. Юзиев һәм башкаларның хезмәтләренә таянып язылган. Анда шагыйрь иҗатына караган нинди дә булса ер-яңа фактлар юк диярлек. Автор үз алдына андый максат та куймаган. Аның максаты бераз башкачарак: ул «Моабит дәфтәрләре»н, дәвернең рухы, сугыш елларындагы әдәбиятның гомуми үсеше белән бәйләнештә карап, яңадан бер кат барлап-укып чыгарга тели.

Керештә һәм «Батырлыкка таба», «Чорның шигъри шәһадәтнамәсе» дип аталган бүлекләрдә автор нигездә әлектән билгеле факт һәм фикерләрне билгеле бер системага салып чыгудан әллә ни ерак китми. Китапның иң кызык һәм оригиналь бүлеге — «Романтизмның реальлеге» дип аталган бүлек. Тикшеренүче биредә Җәлилнең романтик сурәтләү чараларына мөрәҗәгать итүен өйрәнә. Ул аны гомум татар әдәбиятының традицияләреннән, тәҗрибә һәм мөмкинлекләреннән, шулай ук күп милләтле совет поэзиясенең сугыш елларында сизелерлек төстә романтик гомумиләштерү алымнарына йөз бору фактыннан чыгып аңлата.

Авторның романтизм турындагы мәсьәләгә фәнни карашы да кызыклы. Билгеле булганча, романтизм турында төрле карашлар яшәп килә. Күпчелек тикшеренүчеләр романтизмны шәхеснең социаль һәм рухи уянуы белән бәйлиләр һәм аны барлык (яки күпчелек) әдәбиятларның үсешендә билгеле бер **әдәби метод, конкрет тарихи** этап дип карыйлар. Воздвиженский аларны кире какмый. Шул ук вакытта ул роман-

[1] В. Г. Воздвиженский. «Моабитские тетради» Мусы Джалиля. Рус телендә. Мәскәү. «Наука» нәшрияты. 1969 ел.

тизмны тормышны образлы чагылдыручы төп ике якның, ике алымның берсе, бөтен үсеш тарихында әдәбиятка хас төп иҗат алымнарының берсе рәвешендә аңлаткан тикшеренүчеләргә (аерым алганда, Л. И. Тимофеевка) дә кушыла.

Әгәр реализм белән романтизмны берберсенә капма-каршы иҗат методлары дип карасак, өстенлек шуларның беренчесенә биреләчәк, чөнки реализм романтизмга алмашка килгән агым. Мәсьәләгә бу рәвешчә якын килгәндә, чынбарлыкны романтик алымнар белән сурәтләү еш кына вакытлы, кимчелекле бер нәрсә итеп каралачак. В. Воздвиженский исә бу ике алымның — берьяктан, чынбарлыкны конкрет-индивидуаль формаларда, башка сүзләр белән әйткәндә, күренеш һәм предметларны чынбарлыктагы үз формаларында чагылдыруның, икенче яктан, чынбарлыкның тышкы формаларын күчерүдән качуның, теге яки бу күренешләрне үткенәйтү, гиперболаштыруның, шартлылыкка, гадәттән тыш хәлләргә һәм ситуацияләргә омтылуның — элек-электән сәнгатьнең үз табигатендә булганлыгын һәм бер-берсенә каршы килми тынышып яшәгәнлеген ышандырырлык итеп дәлилли. Бу ике як һич тә бер-берсен инкарь итмиләр, киресенчә, үзара керешеп яшиләр. Конкрет тарихи-социаль шартларга бәйле рәвештә, әлеге ике алымның әле берсе, әле икенчесе алгы планга чыгарга мөмкин. Менә шунда инде иҗат принципларының һәм дөньяга сәнгатьчә карашның әлеге тарихи шартларга бәйле гомумилеге хакында әдәби метод, агым, юнәлеш буларак сөйләү мөмкинлеге туа. Билгеле бер тарихи шартларда күп кенә язучыларның иҗатында өстенлек алып, гомумиләштерүнең романтик алымы конкрет бер әдәби методның эстетик нигезен тәшкил итәргә мөмкин (Көнчыгыш һәм Көнбатыштагы бик күп әдәбиятлардагы «классик романтизм» дип йөртелгән метод белән нәкъ шулай була.) Ләкин күбесенчә тормышны реалистик һәм романтик сурәтләү формалары, органик рәвештә сәнгатькә хас ике иҗат тибы буларак, теләсә кайсы метод эчендә яшиләр. Тикшерүче дөрес язганча, тормышны танып-белүнең бер алымы буларак, романтизм теләсә нинди романтик мәктәп, агым чикләреннән тыш та үзенең әһәмиятен саклый.

Шулай итеп, «Моабит дәфтәрләре»н тикшергәндә, автор чынбарлыкны эстетик танып-белүдә үз «өстенлекләре» булган, тормыш куйган мәсьәләләргә үзенчә җавап биргән романтизмның совет әдәбиятында тулы хокуклы метод булуыннан чыгып эш итә. Реалистик иҗат тибы һәм гомумиләштерүнең реалистик алымнары совет әдәбиятында төп роль уйнавын инкарь итмәстән, Воздвиженский мәгълүм шартларда, конкрет тарихи-объектив һәм әдәби-субъектив сәбәпләр аркасында, романтик сурәтләү чараларының аеруча сизелерлек һәм күзгә ташланырлык төс алырга мөмкин икәнен күрсәтә. Октябрьның беренче елларындагы совет әдәбиятында һәм Бөек Ватан сугышы елларында нәкъ шулай була.

Эпоханың үз кискенлеге һәм драматизмы, ситуацияләрнең киеренкелеге һәм үзенчәлеге әдәбият каршына да махсус эстетик бурычлар куя. Менә шуның өчен дә бу елларда бөтен совет әдәбиятында, аеруча поэзиядә, романтик, героик-патетик агым көчәя. В. Воздвиженский сугыш елларындагы әдәбиятларда романтик башлангычның көчәюе милли әдәби традицияләрнең яңаруына бәйле, ди. Бу елларда фольклорга һәм аның алымнарына таяну, милли тарихка, халыкның борынгы каһарманнарына игътибар көчәя. Автор бик дөрес язганча, романтик сурәтләү алымнары борынгы традицияләре булган әдәбиятларда аеруча көчлерәк һәм киңрәк тарала.

М. Җәлил иҗатында романтик традицияләрнең урын алуына күп тикшеренүчеләр игътибар иткән. Ләкин еш кына ул традицияләр ниндидер кимчелек, очраклы күренеш, «шәрык традицияләре»нең йогынтысы дип каралган. Басым шагыйрьнең үз иҗатында алардан ничек арынуына, аларны ничек «җиңеп чыгуына» ясалган. Воздвиженский исә Җәлилнең романтизмын милли эстетик традицияләрнең аерылмас бер өлеше буларак тикшерә, дөньяга романтик карашның шагыйрь иҗатының бөтен чорлары өчен хас булуын исбатлый. Һәм әлеге «шәрык традицияләре» дигән нәрсәнең үзенә дә автор чит бер нәрсә итеп түгел, ә татар әдәбиятына органик хас, аның табигатендә үк булган күренеш итеп карый. Аның мәсьәләгә яңача килүе әнә шунда.

Романтизмга мондый караш Октябрьдан соңгы татар әдәбиятындагы иң катлаулы саналган һәм бүгенге көнгә кадәр төрле бәхәс, дискуссияләр уятып килгән агымнардан гыйсъянчылыкны дөрес аңлатырга да мөмкинлек бирә. Муса да гыйсъянчылык белән мавыккан кеше. Галим гыйсъянчылыкны «үсү чире», поэзиянең алга үсешендәге киртә дип кенә түгел, ә милли романтизмның мәгълүм тарихи шартлар һәм татар әдәбиятының милли традицияләре белән бәйләнгән характерлы бер чагылышы итеп карый.

Воздвиженский Җәлилнең беренче чор әсәрләре арасында «буш порода»ларның байтак булуына да күз йоммый. Романтик сурәтләү системаларының шартлылыгы һәм экспрессивлыгы үз максатка әйләнгәндә, алар әзер стандарт буларак кулланылганда, күбрәк шундый хәл туа. Шул чагында милли романтик шигърият үзенең эчтәлеген җуя, гасырлардан килгән образлылык экзотик бизәкләргә, югары эмоциональ киеренкелек мелодраматизмга һәм сентиментальлеккә әйләнеп китә. Ләкин Р. Бикмөхәммәтовтан, шулай ук үзенең Җәлилнең беренче чор иҗаты хакындагы элекке фикерләреннән аермалы буларак, В. Воздвиженский әлеге «явызлыкның» башын романтик традицияләрнең үзләрендә түгел, ә аның әзер алым, схемаларына эпигоннарча иярүдә күрә. Аның аерым шигырьләренең артык җирдән сөйрәлүендә реализмның гаебе булмаган кебек, беренче чор әсәрләренең йомшак булуында да романтизм гаепле түгел. М. Җәлил иҗатын татар әдәбиятындагы романтик традицияләр яктылыгында тикшерү галимне «Моабит дәфтәрләре»ндәге эмоциональ-психологик чын-

лыкның шартлылык һәм гомумилек белән кушылуы очраклы хәл түгел, ә алдан әзерләнгән җирлектә туган күренеш, дигән нәтиҗә ясауга китерә. Нәкъ менә романтик гомумиләштерү алымнарына һәвәслеге Җәлилне 1941—1945 еллар татар поэзиясендәге романтик күтәрелешнең иң күренекле вәкилләреннән берсе итә.

В. Воздвиженский татар халык авыз иҗаты һәм язма поэзиянең иң яхшы традицияләренә таянып иҗат ителгән «Моабит дәфтәрләре»нең пафосын күзәтә, аның чыганакларын — сугышучы шәхеснең героик хәлен турыдан-туры һәм күтәренке формада гәүдәләндерергә теләү омтылышын күрсәтә.

Ул, бик хаклы рәвештә, «Моабит дәфтәрләре»нең бөтен образлар системасына романтик караш хас булуын күрсәтә, шуның белән бергә, шагыйрь традицион образлы мотивларны терелтеп кенә калмый, аларны яңарта, заманга яраклаштыра, трансформацияли, ди. Бу Моабит шигырьләрендә реаль нәрсәләрнең шартлы әйберләр белән үзенчәлекле аралашуына, төгәл, конкрет детальләрнең абстракт, ачык романтик, урыны-урыны белән хәтта фантастик буяулар белән кушылуына китергән. Әйтик, М. Җәлил шигырьләрендә совет сугышчысы ярсу атка менгән батыр егет төсендә сурәтләнә, кулында да, автомат кебек чын мәгънәсендәге бүгенге сугыш кораллары белән бергә, сихерле кылыч аның. Сугышта һәлак булганнарны кабат терелтә торган серле күлмәк тә фронтка иң прозаик рәвештә — гадәти почта бүлегеннән, гадәти посылка белән җибәрелә һ. б.

Моабит циклына бу рәвешчә якын килү, яңа булуыннан тыш, Җәлилнең шул чор иҗатын сугыш елларындагы татар әдәбияты һәм бөтен совет поэзиясе яктылыгында бәяләргә мөмкинлек бирә. Шуның белән бергә, әлеге көчле ягыннан ук тикшеренүнең көчсез ягы да килеп чыга. Хезмәтнең бер урынында автор болай яза: «Моабит циклының барлык шигырьләрендә диярлек сизелгән романтик һәм традицион поэтика аларда ялгызы гына хакимлек итми. Дөньяны поэтик чагылдыруның реалистик алымнары да, югары һәм көчле кичерешләрнең сизелеп торуы да «Моабит дәфтәрләре»ндә аз роль уйнамый. Татар поэзиясендәге башында Г. Тукай торган психологик реализмга Моабит циклы яңа бизәкләр өсти, дип әйтергә мөмкин».

Дөрес искәрмә! Ләкин, кызганычка каршы, нәкъ менә искәрмә генә шул, чөнки ул конкрет анализ белән ныгытылмаган. Хәлбуки, «Моабит дәфтәрләре» күпкырлы. Җәлил анда романтик һәм реалистик шагыйрь буларак та, сатирик һәм юморист, философ һәм публицист буларак та күренә. Воздвиженский исә үзенең төп игътибарын Моабит циклының романтик ягына юнәлтә, шагыйрь талантының башка якларын я бөтенләй күрми, я өстән йөгертеп кенә уза. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, бу нәрсә Җәлилнең поэтик йөзен ярлыландыра. Алай гына да түгел, тикшерүче карашының берьяклылыгы еш кына аны артык кискен һәм шуңа да дөрес булмаган нәтиҗәләр ясарга этәргән. Бер урында, мәсәлән, Воздвиженский: «Моабит дәфтәрләре»нең герое тормышның көндәлек вак-төякләреннән, үзен чорнап алган тирәлектән югары тора. Әсир төшүнең конкрет шартлары, лагерь һәм төрмә тормышының реаль обстановкасы Моабит шигырьләрендә бөтенләй юк. Шагыйрь һәм аның герое аларны белергә дә теләмиләр» (147 бит), дип яза. Мондый караш Моабит циклындагы шартлы романтик стильдә, фольклор алымнарында язылган кайбер шигырьләргә карата («Ана бәйрәме», «Чишмә белән сандугач», «Кызыл ромашка» һ. б.) чыннан да дөрес. Ләкин бөтен Моабит циклы өчен һич тә төгәл түгел. Хәтта Воздвиженский үз фикерләрен дәлилләү өчен китергән мисал ук аның ул фикеренә каршы килә:

Тоткынлыкта хәзер мин... һәр көнне
Көн чыгышын комсыз күзәтәм.
Шигырь булып чыга үч ялкыны
Яраланган лачын йөрәктән...

Тик бер өмет: кара август төне
Илтер мине шунда җитәкләп.
Өстен килер түбән әсирлеккә
Үч һәм илгә кайнар мәхәббәт.

(«Кичер, илем»)

Әйтегез әле: «һәр көнне көн чыгышын комсыз күзәтәм» реаль җирлеге булган конкрет деталь түгелмени? Аннан соң июнь ахырында әсир төшкән шагыйрьнең, качу өчен, «кара август төне»н көтүе аның лагерь тормышының реаль обстановкасын «белергә дә теләмәве» хакында сөйлиме? Бу һәм Моабит циклындагы башка шигырьләрдән шагыйрь һәм аның героеның «тормышның көндәлек вак-төякләреннән, үзен чорнап алган тирәлектән» югары күтәрелмәве хакында сөйли торган уннарча мисал китерергә мөмкин.

Таш диварлар алды шатлыгымны,
Биреп картлык, кайгы, юталне.
Ишегемә барсам, ишек бикле,
Тәрәзәмә килсәм — челтәрле.

(«Хыял»)

Яки:

Чәнечкеле тимер чыбык белән
Уратылган безнең йортыбыз.
Көне буе шунда казынабыз.
Әйтерсең лә тирес корты без.

(«Кошчык»)

Биредә барысы да конкрет һәм чынбарлыктагыча төгәл. Хәтта беренче карашка шартлы һәм абстракт булып тоелган «тирес корт»лары дигән чагыштыру да шагыйрь башына очраклы рәвештә килеп кермәгән. Без хәзер беләбез: Двинскидагы лагерь элекке ат абзарларында урнашкан булган. Тикшеренүче шагыйрьнең фашист тоткынлыгындагы реаль тормыш шартларына һәрвакытта да җитәрлек игътибар биреп җиткерми, аны ялгыш нәтиҗәләргә китергән сәбәпләрнең берсе, бәлки, шундадыр да. Әйтик, М. Җәлил биографиясенең детальләрен конкрет белмәгән кешегә «Хөкем алдыннан» шигыре шартлы-романтик әсәр булып тоелырга мөмкин. Хәлбуки,

шагыйрь көрәштәшләреннән Р. Хисаметдиновның җәлилчеләргә беренче тапкыр суд ясалу турындагы истәлеге аның реаль вакыйгаларга нигезләнеп язылган булуы турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Әсирләр тезелгән буш урын, иртәнге сәгатьтә урман, таулар, күлләр арасына яшеренгән томан, җирнең җылысын тоючы ялан аяклар кебек детальләр реаль тормыштан алынган.

Әгәр «Моабит дәфтәрләре»ндә лагерь һәм төрмә тормышын чагылдыра торган конкрет детальләр азрак икән, бу башка мәсьәлә. (Моннан күп еллар элек бу нәрсәгә Р. Бикмөхәммәтов та игътибар иткән иде). Әмма алар бар, һәм Воздвиженскийның катгый нәтиҗәләренә кушылып булмый. Җәлилнең шигъри реализмы бөтенләй әлеге тышкы детальләрдә түгел, ә бәлки аның поэзиясенең көчле драматизмында, нечкә һәм тирән психологизмында. Кызганычка каршы, Моабит циклының бу ягына автор игътибар итмәгән диярлек.

Галимнең: «Моабит дәфтәрләре»ндә геройның рухи көче тышкы хәлләр, вакыйгалар өстеннән **һәрвакыт** тантана итә»,— дигән артык катгый, шул ук вакытта бик үк эзлекле булмаган карашы белән дә килешүе читен. Әйе, циклны тулаем алганда, Җәлил шигырьләренең герое, чыннан да, рухи яктан көчле шәхес, шул аңа палачлардан өстен булырга, аларны йөзенә карап көләргә, киләчәккә өмет белән карарга көч бирә. Ләкин Җәлил — ниндидер абстракт «лирик герой» түгел, ә тере кеше. Һәм аның Моабит шигырьләрендә әсирлекнең коточкыч ачысы да һәм йөрәкне сыкратырлык сагыш һәм икеләнүләр дә («Соңгы үпкә», «Син онытырсың», «Төрмәдә төш», «Соңгы җырым», «Назлы сөяркә» һ. б.) чагылыш тапкан. **«һәрвакыт»** сүзе бирелә урынлы булып бетмәс.

Минем уемча, В. Воздвиженский Җәлил поэзиясенең (аның романтик шигырьләренә нигезләнеп) гомумиләштерү характерын күпертеп, арттырып җибәрә. Җәлилнең мәхәббәт шигырьләре турында язганда ул, мәсәлән: «Мәхәббәт аларда сугышчы һәм аның сөйгәне арасындагы реаль хис булудан бигрәк, гомумән кешеләргә хас бер сыйфат, кешелекнең үзенә күрә квинтэссенциясе төсендә күренә», ди. Мин, мәсәлән, «кешелекнең андый квинтэссенциясен» һич тә күз алдына китерә алмыйм. Минем уемча, кешегә хас башка хисләр кебек үк, мәхәббәт хисе дә сәнгать әсәрләрендә конкрет кешеләрнең кичерешләре төсендә генә чагылырга мөмкин. Дөрес, аерым очракларда бу хис психологик яктан искиткеч тирән бирелгән («Ышанма», «Сөекләмә», «Син онытырсың» һ. б.), икенче бер шигырьләрдә йомшаграк индивидуальләштерелгән. Җәлилнең мәхәббәт лирикасын бары романтик традицияләр яктылыгында гына карау шулай ук аның шигырьләренең конкрет, реаль эчтәлеген күмеп калдыра язган.

Үз китабында автор Җәлил уйлары һәм хисләренең миллионнарның уй-хисләре белән уртак булуына еш басым ясый. Бу, әлбәттә, дөрес. Шуның белән бергә, Җәлил язмышы искиткеч дәрәҗәдә индивидуаль дә иде. Шагыйрьнең трагедиясе әсирлекнең һәм төрмә тормышының түзә алмаслык авыр шартларыннан гына килеп чыккан нәрсә түгел. Аның хәле вакытлыча гына булса да сатлык җан битлеге киеп, фашистларга хезмәт иткән төстә йөрүе белән дә катлауланa. Шагыйрьне үлем үзе түгел, ә пычрак исем белән, хурланган хәлендә үлү куркыта, аның тормышы һәм батырлыгы Илгә барып җитмәс дигән уй куркыта. Җәлил поэзиясенең менә шул индивидуаль ягына галим тиешле игътибар биреп җиткерми.

Китапта башка кимчелекләр дә бар. Урыны-урыны белән рус поэзиясенә һәм СССР халыклары әдәбиятларына мөрәҗәгать итү абстракт обзор төсен ала һәм «Моабит дәфтәрләре» белән бәйләнеп җитми. Галимнең гомуми фикерләре еш кына кирәгеннән артык абстракт һәм алар конкрет, ышандырырлык дәлилләр белән исбатланмый калалар.

Әмма ни генә булмасын, В. Воздвиженский М. Җәлил иҗатын өйрәнүгә үзеннән җитди өлеш кертә, аның чынбарлыкны романтик танып белүенең тирән тамырларын ача, «Моабит дәфтәрләре»н бер татар әдәбияты гына түгел, ә бөтен совет поэзиясе фонында күзәтеп чыга. Ләкин Моабит циклының башка якларын — аларның психологик һәм реалистик тирәнлеген, фәлсәфилеген, публицистик пафосын, ниһаять, сатирик һәм юмористик шигырьләрнең зур циклын өйрәнү — әле һаман киләчәк эше булып кала килә.

**РАФАЭЛЬ МОСТАФИН**

# *КЕЧКЕНӘ РЕЦЕНЗИЯЛӘР*

**Беренче карлыгачлар. Казан. 1969 ел.**

Татарстан китап нәшрияты һәр ел саен поэзия өлкәсендә үзләренең каләм көчләрен сынап караучы һәм бу юнәлештә инде житди генә уңышларга ирешкән яшь әдипләрнең әсәрләрен туплап калын-калын җыентыклар чыгарып килә. Моннан өч-дүрт ай элек «Беренче карлыгачлар» исемле ул җыентыкның өченче — 1969 елгы китабы басылып чыкты. Бу җыентык поэзия сөючеләргә Әхмәт Рәшитов, Зиннур Насыйбуллин, Айдар Хәлим, Флера Гыйззәтуллина, Кадыйр Сибгатуллин, Мөдәррис Әгъләмов, Харрас Әюпов, Роза Хәлиуллина кебек өметле яшьләрдән 14 авторның иң яхшы дип саналган шигырь һәм мәсәлләрен, поэма һәм балладаларын тәкъдим итә.

Китапның беренче битен яшь шагыйрь Әхмәт Рәшитов ача. Аның «Ленинград эскизлары» дип аталган шигырьләр циклы Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел тулуга багышланган. Циклдагы «Исәнме, Ленинград!», «Пролетарийлар юлдашы», «Җәйге бакчада уйланулар», «Пенсионерлар» һәм «Нева күперендә кыз бала» шигырьләре фәлсәфи рухта язылганнар. Бу шигырьләр кешеләргә шатлык-сөенечләр, кайгы-борчулар алып килгән вакыйгалар турында кат-кат уйланырга, үтелгән һәм үтеләчәк юлына шул вакыйгалар югарылыгыннан торып карарга мәҗбүр итә.

Зиннур Насыйбуллин шигырьләренә исә тирән лиризм, кешенең эчке кичерешләрен күңелдә куаныч та, моңсулык та уята торган поэтик картиналар аша әйтеп бирү хас. Унтугызда өйдән китеп, яу кырында ятып калган абыйсының рәсеменә карап:

**Китәсе лә килеп кемнәр киткән,**
**Кирәк булган өчен китәләр.**
**Кайтасыны аны кем дә көтә,**
**Кайтмасын да белеп көтәләр,—**

ди лирик герой «Яшьтәшләрең китә Армиягә» шигырендә. Уңышлы эшләнгән мондый строфаларны Зиннурның «Җөйсез яра», «Кара шәле килә сөйрәлеп», «Юллар», «Бер күрүдә гашыйк булганнар», «Кырларымны сагыну хисләре» кебек шигырьләреннән дә китерергә мөмкин булыр иде.

Кадыйр Сибгатуллин, Мөдәррис Әгъләмов, Харрас Әюпов шигырьләре дә Зиннур Насыйбуллин шигырьләре белән аваздаш янгырыйлар. Ләкин бу әлеге авторлар берберләрен кабатлыйлар дигән сүз түгел. Аларның иҗатындагы төп уртаклык — шигырьдә кешенең эчке дөньясына үтеп керергә, аның уй-хисләрен мөмкин кадәр тулырак чагылдырырга омтылу. Бу яшь каләмнәрнең шигырьләрендә алынган теге яки бу тема аларның үзләренә генә хас булган чагыштырулар, шигъри детальләр ярдәмендә чишелә.

Соңгы вакытта поэзиябезгә ышанычлы адымнар белән килүчеләр арасында хатын-кыз әдипләребезнең саны ишәйгәннән-ишәя бара. Моның шулай икәнлеген «Беренче карлыгачлар»да да күрергә була. Аның өченче китабына Флера Гыйззәтуллина, Динә Камалетдинова, Роза Хәлиуллинаның поэма һәм шигырьләре урнаштырылган. Ф. Гыйззәтуллинаның «Таныш тавыш» поэмасы, «Бер минут», «Камышлар үсә», «Кызлар күлмәк тектерә» шигырьләре бу шагыйрәнең поэзиягә үз көченә нык ышанган хәлдә килүе турында сөйли. Рәис Риян, Рим Идиятуллин, Азат Вергазов, Фарсел Зыятдинов шигырьләрендә дә матур-матур поэтик ярлагылар бар.

Яшь шагыйрь Сәлим Шәйдуллин нигездә мәсәл жанрында эшли. Аның бу китапка кертелгән мәсәлләре шактый шома һәм үткен язылганнар.

Җыентыкта һәр авторның фоторәсеме һәм автобиографиясе бирелгән. Җыеп кына әйткәндә, «Беренче карлыгачлар» авторларның һәм анда басылган әсәрләрнең төрле булулары ягыннан укучының игътибарын үзенә җәлеп итә алырлык булып чыккан. Аның алдагы елларда чыгачак китаплары тагын да кызыклырак, баерак эчтәлекле булсын иде.

**ФОТУЛА ЯННАКОПУЛУ. Эллада кызы. Казан. 1969 ел.**

Кешелек дөньясына үзенең дисталәрчә бөек гуманист әдипләрен бүләк иткән Греция җире бүген кара полковниклар табаны астында ыңгыраша. Ләкин ирек сөюче грек халкы коллык богауларын киярга теләми. Ул үз иленең, җиренең азатлыгы, бәйсезлеге өчен көрәшне бер генә минутка да туктатмый. Аның үз Ватанына ихлас күңелдән бирелгән, туган җирен ихлас күңелдән яраткан алдынгы фикерле әдипләре дә шул көрәш сафында атлыйлар. Каләмен грек халкының дошманнарына каршы юнәлткән кыю көрәшчеләрнең берсе — Фотула Яннакопулу. Немец-итальян фашистларына һәм Америка-Англия оккупантларына каршы көрәштә чыныккан бу шагыйрәнең әсәрләре грек халкын кол итәргә маташучыларга каршы ачы нәфрәт хисе белән сугарылган.

Күптән түгел Татарстан китап нәшрияты әнә шул шигырьләрнең бер өлешен

татар телендә аерым җыентык итеп бастырып чыгарды. Ул шигырьләрдә борынгы Элладаның бүгенге хәле, анда барган көрәшнең кискенлеге, грек халкының киләчәккә булган өмет-ышанычы шактый тулы гәүдәләнә. Бирредәге һәр көрәшче үзен халкының бер кисәге, бер өлеше итеп сизә. Шуңа күрә ул хәтта таш камерада утырганда да үзен ялгыз санамый, «монда минем кулларымны һәм йөрәгемне сөйгән халкым җылыта»,— дип юана, үзенең җиңүче булып чыгачагына ышана:

**Инде сызылып таң атадыр. Ләкин барыбер**
**Тоткын күзе аны моннан күрә алмас...**
**Ул — Прометей, Зевсны ул җиңә җирдә,**
**Бу көрәштә ул һичкайчан ялгыз калмас!**

«Көрәштә ул ялгыз калмас!» шигырендәге бу фикер «Җиңелмәс Элладам минем», «Кузгал, халкым!», «Мин — Эллада кызы», «Алга», «Ант итәм» шигырьләрендә тагын да үстерелә, көчәйтелә. «Илектра» шигырендә Фотула Яннакопулу фашизмга каршы көрәш героинясы, Греция коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты члены, 1944 елда фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелгән Илектра Апостолуның, «Ираклий Метаксас» шигырендә 26 Баку комиссарының берсе, грек халкының батыр улы Ираклий Метаксасның рухи көченә соклануын белдерә.

Аның «Сандугач һәм бөркет» исемле балладасы герой-шагыйрь Муса Җәлилгә, «Син дустыбыз безнең, туганыбыз» шигыре газап чигүче грек халкының бәхете өчен Эллада тауларында һәлак булган татар егете, партизан Марат Сәидовка багышланган. Фотула Яннакопулуның кайсы гына шигырен укып карама, син анда шагыйрәнең тормыштагы героик моментларны, һәртөрле кыенлыкларны җиңеп чыгарга әзер торучы көчле рухлы кешеләрне тасвирларга омтылуын күрәсең.

Хәзер Фотула Яннакопулу Советлар Союзында яши. Шуңа күрә аның күп кенә шигырьләренең безнең ил тормышына багышлануы һич тә гаҗәп түгел. Ул шигырьләрнең кайберләре әлеге җыентыкка да кертелгән. Әдхәт Синегулов тарафыннан төзелгән бу җыентыктагы шигырьләр Н. Арсланов, З. Нури, М. Садри, Ә. Синегулов, К. Фәсәхов һәм Н. Хисамов тарафыннан тәрҗемә ителгән. Фотула Яннакопулу шигырьләре турындагы сүз башын Мөхәммәт Садри язган.

**САМАТ ШАКИР. Үлемнән көчлерәк. Казан. 1969 ел.**

Узган сугышта фашист-палачлар эшләгән ерткычлыкларның исәбе-хисабы юк. Бухенвальд... Освенцим... Майданек... Дахау... Бу сүзләр җирдә тынычлык сөеп яшәүче миллионнарча кешеләрнең җаннарына әле бүген дә тынгылык бирми, аларның күңелләренә әле бүген дә борчу һәм шом сала. Әйе, бу үлем лагерьларында хәрби әсирләр һәм Германиягә куып китерелгән картлар һәм карчыклар, аналар һәм сабыйлар кичергән газапларны хәтта күз алдына китерүе дә кыен.

«Безнең турыда Ватанга сөйләгез!» — тоткыннарның үлем алдыннан әйткән үтенечләре әнә шул. Аларның васыятьләрен үтәү, укучыларны аларның тормышы һәм фашизм әсирлегендә алып барган көрәштәге батырлыклары белән таныштыру буенча татар язучылары да зур гына эш башкаралар. Бу өлкәдә безнең әдәбиятыбызда шактый актив эшләүчеләрнең берсе — Самат Шакир. Күптән түгел аның Германиядәге Дахау лагеренда крематорий мичендә яндырылып үтерелгән татар шагыйре, полк командиры Хәйретдин Мөҗәй турындагы очеркы, «Үлемнән көчлерәк» дигән исем белән, аерым китап булып басылып чыкты.

Очерк безне патриот шагыйрь һәм куркусыз командир Х. Мөҗәйнең, шулай ук аның көрәштәшләренең сугышчан юлы белән таныштыра. С. Шакир башта фашистларның Мюнхен һәм Дахау лагерьларындагы коточкыч ерткычлыкларын фаш иткән материалларга туктала да, Мөҗәйнең балалык һәм яшьлек еллары турында сөйләүгә күчә. Аннан соң безнең күз алдыбызда аның солдат булып Урта Азиядә, Ерак Көнчыгышта хезмәт иткән һәм Мәскәү янындагы Солнечногорскийда хәрби мәктәптә укыган еллары гәүдәләнә. Автор булачак полк командирының шагыйрь булырак та үсә, житлегә баруын аның иҗатыннан алынган материаллар белән исбатлый.

Китапның «Сугыш язмалары», «Аның батырлыклары», «Соңгы тамчы канга кадәр» дигән бүлекләрен аеруча тирән дулкынлану белән укыйсың. Анда язылганнар белән танышкач, Хәйретдин Мөҗәйнең нинди зур ихтыяр көченә ия булганлыгын, сугышның иң авыр, иң кискен моментларында да совет халкының җиңүче булып калачагына ышанычын бер генә минутка да югалтмаганлыгын тоясың. Сугышчы-шагыйрьнең тоткынлыкта да бөек көрәштән читтә калмавы, коммунист һәм совет офицеры исеменә тап төшермәве аңа карата тирән мәхәббәт һәм горурлык хисләре уята.

Самат Шакир үзенең китабында фашистлар лагеренда дошманга каршы көрәшү өчен төзелгән яшерен оешманың эшчәнлеген шактый киң яктырта. Бирредә без «Хәрби әсирләрнең туганнарча ярдәмләшүе» оешмасының Роман Петрушель, Иван Кононенко, Мария Кузькина, Иван Корбуков, Симон Перцов, Савелий Батовский кебек куркусыз һәм сабыр холыклы житәкчеләре белән очрашабыз. Алар Хәйретдин Мөҗәй белән кулга-кул тотынышып эшлиләр, үлемгә барыр алдыннан, бер-берләренә иннәрен куеп, дошман каршына тыгыз стена булып басалар.

Фашистлар тырнагыннан ычкынып, илгә исән-сау кайткан сугышчыларның хатлары, истәлекләре аерым бүлеккә тупланып бирелгән. Ул хатларда, истәлекләрдә Хәйретдин Мөҗәйнең кешелеклелеге, куркусызлыгы, үз иленә, үз халкына чиксез бирелгәнлеге тагын да ачыграк чагыла. Китапта файдаланылган хатларның берсе 227 нче укчы дивизия составындагы полковник

Хәйретдин Мөҗәй командалык иткән 789 нчы укчы полкның элекке хәрби комиссары, гвардия полковнигы Ф. А. Почагин тарафыннан язылган. Анда менә мондый юллар бар: «Коммунист иптәш Хәйретдинов Мөҗәһит фашистларга каршы сугышта үзен куркусыз сугышчы итеп күрсәтте. Ул партиягә, халыкка чын күңелдән бирелгән иде... Мөҗәһит Хәйретдинов сугыш барган вакытларда һәрвакыт полкның һөҗүм итүче алгы отрядында булды, частьның сугышчан эшләре һәм кешеләре турында язарга да вакыт тапты... Ул үзенең үлеме белән совет кешеләре алдында үлемсезлек яулады. Ватаныбыз һәм без, тере кешеләр, Туган ил өчен үзләренең тормышларын биргән Бөек Ватан сугышы геройларын бервакытта да онытырга тиеш түгелбез!»

Очеркка сайлап алынган башка хатлар да шул ук рухта язылганнар. Китапта Х. Мөҗәйнең полк белән командалык иткән вакытта, Украинадагы бер авылда штабта һәм композитор Латыйф Хәмиди белән төшкән фоторәсемнәре урнаштырылган.

**Ә. СИНЕГУЛОВ. Туплар һәм музалар. Казан. 1969 ел.**

«Мин геройларның билгесез булмавын, аларны бар кешеләрнең дә белүен теләр идем; аларның һәркайсының үз исемнәре, карашлары, уй-тойгылары, ышанычлары булган һәм шуңа күрә аларның, хәтта билгесезләрнең дә, газаплары тарих белгән шәхеснекеләрдән бер дә ким түгел. Сугышта корбан булганнар сезгә дусларыгыздай, туган-тумачаларыгыздай һәм үзегездәй һәрвакыт якын булсын!»

Яшь язучы Әдхәт Синегуловның «Туплар һәм музалар» дип аталган беренче китабы Чехословакия халкының милли герое Юлиус Фучикның әнә шушы сүзләре белән ачыла. Бу җыентык бүгенге укучыны Бөек Ватан сугышы кырларында мәңгелеккә ятып калган яшь язучыларның тормышы һәм иҗаты белән таныштыру теләгеннән чыгып язылган.

Совет халкының башка бик күп кыю уллары кебек үк, безнең якташларыбыз да узган сугышта тиңсез батырлык үрнәкләре күрсәттеләр. Алар арасында иҗат бөреләре әле яңа гына ачылып килгән яшь әдипләребез дә бар иде. Аларның күбесе яу кырыннан кире әйләнеп кайтмады. Китапның «Канга — кан... үлемгә — үлем», «Сугыш һәм шагыйрь» дигән бүлекләрендә автор сугышта катнашкан татар язучыларының, аерым алганда, яшь әдипләрнең шул чордагы иҗатларына гомуми анализ ясый, аларның кайбер әсәрләренә махсус тукталып үтә, үзенең фикерен ышандырырлык мисаллар белән дәлилли. Аннан соң ул Мансур Гаяз, Мифтах Вәдүт, Касыйм Вахит, Демьян Фәтхи һәм Гиз-эль Габидның һәркайсы турында аерым-аерым сөйләүгә күчә. Аларның сугышка кадәрге тормышы, үлем белән күзгә-күз очрашкан көннәрдәге батырлыклары, иҗатларының торган саен киңрәк колач җәя баруы «Җыр-бомба», «Халык — җиңүче», «Иле өчен, ирек өчен», «Сугыш сүзе — канлы роман», «Көрәш һәм җиңү җырчысы» дип исемләнгән аерым бүлекләрдә тасвирлана. Әлеге бүлекләрне укыганда безнең күз алдыбызга кулына мылтык һәм каләм тотып, изге яу кырында туган илнең бәйсезлеген яклап көрәшкән куркусыз сугышчы һәм шагыйрь килеп баса. Без аларның һәркайсының шәхесе һәм иҗаты белән шактый киң танышабыз. Китапта ул шагыйрьләрнең рәсемнәре урнаштырылуы да күңелне куандыра. Рәсемнәреннән карап торучы бу әдипләрнең күзләрендә әйтерсең лә алар үзләре белән алып киткән җырларга күчәргә тиешле ниндидер моң чагыла.

«Туплар һәм музалар» китабы кыска гына язылган «Йомгаклау сүзе» белән ябыла. Аның: «Күп вакытлар үтәр... Без киләчәктә дә сугыш чоры тудырган поэзиябезнең иң яхшы үрнәкләренә яңадан әйләнеп кайтырбыз һәм моңарчы үзебез күрмәгән яңа якларын ачарбыз»,— дигән соңгы җөмләсенә укучы да бик рәхәтләнеп кушылачак. Һәркайсыбыз өчен чиксез зур әһәмияткә ия булган тарихи бу көннәрдә — Ватан сугышы тәмамлануга 25 ел тулу алдыннан чыгарылган бик кирәкле һәм игътибарга лаеклы бу китапның кайбер кимчелекләре дә юк түгел, билгеле. Аерым алганда, мәсәлән, беренче һәм икенче бүлекләрне берләштергән очракта да җыентыкның эчтәлегенә берниндн дә зыян килмәгән булыр иде. Аннан соң автор Касыйм Вахит турындагы бүлектә лирик геройның дөньяга оптимистик карашы, яшь көрәшченең эчке рухи дөньясы хакында сөйләгәндә, «Тәрәзәңне ач та» дигән мәгълүм шигырьнең түбәндәге ике строфасын мисал итеп китерә:

**Давыл, давыл, ул бит минем**
**Тере хәбәрем.**
**Якын яшен, ялкын яшен —**
**Минем сәламем.**
**Мин сусармын, җирдә давыл**
**Тынмаса әгәр;**
**Мин янармын соңгы яшен**
**Сүнгәнгә кадәр.**

Билгеле булганча, бу шигырьнең авторы Касыйм Вахит түгел, ә Мостай Кәрим. К. Вахит иҗаты турында сөйләгәндә Ә. Синегулов сугышта һәлак булган яшь әдипләрнең әсәрләре тупланып чыгарылган «Алгы сафта» җыентыгыннан файдаланган. Ә ул китапта Мостай Кәримнең әлеге шигыре чыннан да Касыйм Вахит шигыре итеп урнаштырылган иде. Үз вакытында бу хакта «Алар сафта» җыентыгына карата язылган рецензиядә дә күрсәтеп үтелде. Китапта шулай ук бер үк характерда, хәтта бер үк сүзләр белән язылган җөмләләрне берничә урында очратырга мөмкин. Җыентыкны матбугатка чыгару өчен әзерләгән вакытта мондый кимчелекләрдән бик җиңел арынырга мөмкин булыр иде, әлбәттә. Кызганычка каршы, бу эшләнмәгән.

## Шәүкәт Галиев

### Төньяктагы дустыма хат




Сагындырдың
Оксана,
Әзрәк вакыт
Тапсана,
Сәлам хаты
Язсана.

Боз диңгезен
Баксана,
Истәлеккә,
Оксана,
Аю алып
Кайтсана...

Монысы булды
Такмаза,
Аю тотма,
Оксана,
Тик үзең кайт
Тап-таза!

### Чар

Үтмәс пычак
Кисә чак-чак,
Начар, начар...
Чар кирәк, чар!
Әйләнер чар,
Чыжылдар чар,
Очкын очар!
Менә шул чак
Була күр сак —
Үткен пычак!

## Кем белә?

Чыккач чаңгы
Шуарга,
Гаҗәпләнәм
Шуңарга —
Ел да чаңгым
Кыскара!
Ышанмасаң,
Дус, кара:
Иң беренче
Кигәндә
Озын иде
Миннән дә.

Аннан булды —
Борыннан,
Инде күкрәк
Турыннан...

Кыскарырмы
Гел генә,
Кем әйтала,
Кем белә?



## Кысла



Гыйлман судан
Эзли кысла:
— Таш астына
Посма, посма,
Тотарга мин
Шактый оста!
Әһә, әһә,
Менә, таптым!
Чү, чү, кулны
Нигә каптың?!
Җибә-әр, кыс-ма!
...Дусларына
Сөйли кысла
(Мактанырга
Ул да оста):
— Әле ауга
Чыккан идем,
Зу-ур бер малай
Тоткан идем!
Кызгандым да
Елагачтын,
Җибәрдем бик
Ялынгачтын!

# Акбай белән Аккай

Ай, усал да соң маэмай,
Вай, усал да соң Акбай!
Бөтен күрше-тирәләр,
Усаллыгын беләләр,
Акбай дип җайлап кына,
Йомшак сүз сайлап кына ,
Куркып кына керәләр.
Килсәң дә син чамала,
Укымыйча атлама:
Язу тора капкада,
Сурәте бар тактада...

Кәлиткәне чак кына
Ачып кына, сак кына,
Карасаң эчке якка —
Бозау хәтле эт ята!
«Ырр-р, ырр» дип ырылдый,
Исән чакта борыл! ди.

Куркып тора аңардан
Ишек алдында бар да.
Бозау, сарык, кәҗәләр
Бик тиз койрыкны кыса.
Сөзешергә ни оста —
Тәкә дә китеп поса.

...Хуҗа бер әтәч алды,
Гаҗәп хәл булып алды.
Әтәч бер дә посмады,
Койрыгын да кысмады,
Киергән дә күкрәген,
Кыңгыр салып кикриген,
Бик эре генә йөри,
Этне бар дип тә белми.
Маэмай сыртын кабарта,
Ярсуы яман арта.
Юл бирмәс ул башкага —
Һап! — әтәчкә ташлана!
Әүмәкләнә ырылдап,
Әтәч куна пырылдап,
Сикерә уңга, сулга,
Канаты белән суга.
Ошатмаган янавын —
Чукый этнең танавын.
Эт чиный-чиный кача,
Искиткеч хәл ләбаса!
Кереп ята ояга,
Күренергә ояла:
— Инкубатор әтәче!..
Хөрмәт белми олыга...
Бозау хәтле эт хәзер,
Юаш бозау күк хәзер...
...Ай, усал да соң әтәч,
Вай усал да соң әтәч!
Килсәң син дә чамала,
Укымыйча атлама:
Язу тора капкада,
Сурәте бар тактада...

## Афзал Шамов

# ДУСТЫМ ТУРЫНДА

Быел март аеның кояшлы, җылы көннәренең берендә, һич тә уйламаганда, көтмәгәндә, Татарстан язучылары союзына Чабаксар шәһәреннән кайгылы телеграмма килде. Анда түбәндәге сүзләр язылган иде: **«4 мартта, озак дәвам иткән каты авырудан соң, партиябезнең, халкыбызның тугрылыклы улы, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, СССР һәм РСФСР Язучылары союзы идарәләре члены, Чуваш АССРның К. Иванов исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, чуваш халык шагыйре Педер Хузангай вафат булды».**

Бу көтелмәгән хәбәр безгә, аның дусларына, иптәшләренә, берничек тә басылмый, онытылмый торган зур кайгы алып килде. Йөрәкләребез кинәт өзелеп киткәндәй булды, күңелләребезне ниндидер, тел белән әйтеп, аңлатып бирүе мөмкин булмаган бушлык, моңсулык урап алды.

Чуваш совет әдәбиятының нигез ташларын салучыларның берсе һәм иң күренеклесе булган, аны дистәләрчә еллар буенча әйдәп алып барган, киң Россия мәйданына алып чыгу юлында күп өлеш керткән һәм кайбер әсәрләре белән чит илләрдә дә танылган бу зур талантның арабыздан китүе тугандаш чуваш халкы, чуваш әдәбияты өчен генә түгел, шулай ук күп милләтле совет әдәбияты һәм совет халыклары өчен дә гаять зур югалту булды. Совет әдәбияты үзенең талантлы вәкилен, атаклы, ялкынлы шагыйрен, көрәшчесен югалтса, шуның өстенә без, татар язучылары, данлы якташыбызны, ачык чырайлы, саф күңелле дустыбызны, онытылмас иптәшебезне дә югалттык.

Педер Хузангай татар әдәбиятының чын дусты иде. Ул аның тарихын яхшы белә, классикларыбызның һәм бүгенге алдынгы язучыларыбызның әсәрләрен оригиналдан, татарча басмаларыннан укый иде. Татар әдәбиятын пассив укып баручылардан гына түгел иде ул. Уңае туры килгәндә матбугатта, җыелышларда, башкаладагы конференцияләрдә татар әдәбиятының уңышларын әледән-әле мактап телгә ала, белеп, аның эченә кереп сөйли, ә кайчакларда, үзара сөйләшкәндә, кайбер җитешсезлекләребезне, иң яхшы нияттән чыгып, дусларча тәнкыйтьли дә иде. Кыскасы, әдәбиятыбызны яратучы, күзәтеп баручы дустыбыз, киңәшчебез иде ул.

Югарыда мин П. Хузангайны якташыбыз дидем. Чыннан да якташыбыз ул. Хәтта фамилиясе дә Хузангай. Татарча Казанлы дигән сүз.

Педер Педерович Хузангай 1907 елның 22 гыйнварында Әлки районының Сихтәрмә авылында туа. Аның бала чагы, яшүсмер еллары шунда уза, башлангыч белемне дә шунда ала. Туган авылына багышланган шигырьләрендә әйтелгәнчә, ул шунда, күрше авыллардан килгән түбәтәйле, ялан аяклы татар малайлары, яшьтәшләре, дуслары белән бергә инеш буйларында, яшел болыннарда, әрәмәлекләрдә аунап үсә. Бераз олыгая төшкәч, урагын ура, сукасын сукалый, печәнен чаба, башлангыч тормыш мәктәбен уза.

Казанда Чуваш педагогия техникумын тәмамлаганнан соң, ул Көнчыгыш педагогия институтына укырга керә. Беренче әдәби-иҗади адымнарын да ул Татарстанда башлый. Казандагы чуваш әдәбияты түгәрәгенең актив члены булуы белән бергә, ул, шул ук вакытта, татар язучыларының җыелышларына да бик мавыгып йөри, анда Һ. Такташ, Г. Кутуй һәм башка шагыйрьләр белән таныша, алар белән аралаша. П. Хузангай талантының иҗади бөреләнүе өчен бик әһәмиятле булган бу аралашуларны, шагыйрьләребезнең җылы мөнәсәбәтләрен, дуслыкларын, кирәк чакларда аңа әдәби ярдәм күрсәтүләрен ул гомеренең соңгы көннәренә чаклы исеннән чыгармады һәм аларны еш кына зур ихтирам белән искә ала иде. «Туган Татарстанга» исемле шигырендә бу турыда ул:

**Синдә туды, нурлы Казан,**
**Минем иң беренче җырлар.**
**Кайда безнең өчәр телдә**
**Шигырь укып йөргән еллар! —**
**Һади Такташ, Гадел Кутуй**
**Миңа киңәш биргән чорлар!!**

**Бу кадерле исемнәрне**
**Онытмам мин гомердә дә.**
**Адәм үзе югалса да,**
**Сүзе кала күңелләрдә.**
**Безнең дуслык, безнең уйлар**
**Сезгә күчсен, яшь буыннар,—**

дип җырлый һәм бу матур әдәби дуслыкның киләчәк буыннарга күчүен тели.

Егерменче елларның башында туып, нигезләнеп кенә килгән чуваш совет әдәбияты күгендә якты йолдыздай балкып күренгән бу үзенчәлекле яшь талант беренче шигырьләре белән үк укучыларның күңелләрен үзенә җәлеп итә һәм тиз арада нигып, канат җәеп, әйдәп баручы шагыйрьләрнең берсе булып әверелә.

Педер Хузангай үзенең зур эрудицияле шагыйрь булуы, әдәби әсәрләренең тирән эчтәлеге, камиллеге, нәфислеге белән генә түгел, бәлки иҗади колачының киңлеге, жанрларының төрлелеге белән дә укучыларны сокландырып, аларның күңелләрен өзлексез җәлеп итеп яшәде. Ул шигырьләр, җырлар, поэмалар, шигъри романнар, легендалар, әкиятләр иҗат итте, Ленин идеяләренең тантанасы, халыклар дуслыгы, совет кешеләренең хезмәт һәм хәрби батырлыклары, туган якның матурлыгы, байлыгы турында җырлады.

Шуның белән бергә ул күренекле тәнкыйтьче дә, ялкынлы публицист та иде. Ул чуваш әдәбияты үсешен дистәләрчә еллар буенча зур игътибар белән күзәтеп барды, тирән эчтәлекле тәнкыйть мәкаләләре язды, каләмдәш иптәшләренең кимчелекләрен күрсәтте, уңышлары өчен чын күңеленнән шатланды. Ялкынлы һәм кызыклы публицистик мәкаләләре белән ул чуваш халкы тормышындагы иң әһәмиятле мәсьәләләрне күтәрә, кимчелекләрне, әхлакыбызга, идеябезгә туры килмәгән күләгәле якларны каты тәнкыйтьли, аларны бетерергә, тамырларын корытырга тырыша һәм, шулай итеп, укучыларны коммунистик рухта тәрбияли иде.

Аның шигъри юллар белән язылган «Аптраман нәселе» романы, «Горкидагы йорт», «Егерме алты», «Магнит тавы», «Таня» исемле поэмалары һәм башка зур күләмле әсәрләре, нәфис юллардан торган тирән эчтәлекле, әдәби пафослы йөзләрчә шигырьләре чуваш әдәбиятын бизәп торалар. Алар аның алтын фондына кергән әсәрләр. Шулай ук алар гомуми совет әдәбиятының да мактаулы, күренекле әсәрләре булып саналалар.

П. Хузангайның әсәрләре Советлар Союзында һәм чит илләрдә кырыклап телгә тәрҗемә ителгән. Бу әсәрләр һәр җирдә үзенең укучыларын таба һәм аларны уңай юнәлештә тәрбиялиләр. Моның шулай икәнен раслау өчен П. Хузангайга ерак Австралиядән килгән бер хатның кайбер юлларын күчереп үтүне кирәк табам. Бу хатны аңа Виктория шәһәренең Антини Фексье исемле бер гади кешесе язган:

«Мин хәзер генә Сезнең шигырьләр китабын укып чыктым,— ди ул хатында.— Бу китап миңе тормыш сазлыгыннан аллалар тавына алып менде, рухландырды.

Шигырьләрегезне гади итеп, һәр кеше аңларлык итеп язгансыз. Ләкин бу — шигъриятле гадилек, кыр чәчәкләредәй хуш исле гадилек.

Мин Сезнең республикагызны белмим, игенчелек эшен дә белмим, ә инде колхозларыгыз турында бөтенләй белмим. Шулай да мин Сезнең шигырьләрне укыган колхозчы булсам, кулымнан килгәнгә караганда, икеләтә артыграк эшләргә тырышыр идем»,— ди.

Бу самими юллар П. Хузангай шигырьләренең эмоциональ көчен бик ачык, бик матур күрсәтеп торалар.

П. Хузангай, шуның белән бергә, зур һәм оста тәрҗемәче дә. Ул дөнья һәм совет әдәбияты классикларыннан В. Шекспир, А. Пушкин, М. Лермонтов, Г. Тукай, Х. Ботев, В. Маяковский, М. Җәлил һәм башкаларның иң яхшы әсәрләрен туган теленә тәрҗемә итте, халыклар дуслыгын ныгыту, чуваш халкын гомуми социалистик культурага якынлаштыру юлында бәя биреп бетермәслек зур эшләр башкарды.

П. Хузангай Г. Тукай әсәрләрен аеруча ярата, хәтта аның кайбер шигырьләрен күңеленнән белә иде.

Моннан ун ел элек, П. Хузангай Казанга килгәч, аның белән бергә Г. Тукай каберенә бардык. Кулларыбызда яңа гына өзеп алынган хуш исле чәчәкләр иде. Аларны кабер өстенә салдык. Аннары икебез дә, тынып, уйга калып, башларыбызны түбән игән хәлдә, кабер янында берничә минут басып тордык.

Җәй иде, кояшлы көн иде. Кояш нурлары, куе агачлар, ямь-яшел яфраклар арасыннан төшеп, шагыйрь кабере өстендә өзлексез уйныйлар, аны бизиләр иде.

Бу минутларда чуваш дустым нәрсә уйлагандыр,— белмим. Ул, беркадәр моңсу, сагышлы карасу күзләрен кабер өстенә текәп, тынып калган иде.

Бераздан без каберлектән чыгып киттек һәм берничә минут сөйләшмичә, бер-беребезгә эндәшмичә бардык. Тик Яңа Бистә урамына барып чыккач кына ул, тынлыкны бозып:

— Беләсеңме, мин нәрсә турында уйланып барам? — диде һәм, җавабымны көтмичә, сөйләвендә дәвам итте.— Тукай белән чуваш халык шагыйре Константин Ивановның язмышлары турында. Бу ике даһиның язмышлары шул кадәр уртак, хәтта хәйран калырлык бер төсле. Икесе дә кара реакция елларында, иң авыр шартларда яшәделәр. Икесе дә ялкынлы иҗат утында янып беттеләр. Икесе дә үпкә авыруыннан һәлак булдылар. Икесенең дә гомерләре бер үк яшьтә диярлек өзелде. Тукай егерме җидедә, Иванов егерме биштә генә иде. Икесе ике милләттән булуга карамастан, чордашлар, рухи дуслар алар. Иҗатларын чагыштырып караганың бармы синең? Иҗатлары белән дә бик аваздаш бит алар. Хәтта үзләренең әдәби-политик юнәлешләрен күрсәтеп торган шигырьләрен дә бер үк елны язганнар. Тукайның «Милләтчеләр», Ивановның «Безнең заман» исемле шигырьләре турында әйтәм мин. Икесе дә 1908 елда язылган. Гаҗәп түгелме? — диде ул, һәм, җавап көткәндәй, миңа борылып карады.



*Татар һәм чуваш язучылары. Сулдан А. Калган, Г. Әпсәләмов, А. Шамов, П. Хузангай, З. Нури, Х. Туфан.*

Мин тагын җавап бирер өлгермәдем, башымны иеп алып, ризалыгымны белдерү белән генә чикләндем, ә ул башлаган сүзен дәвам иттерде. Матур итеп, кешеләрнең күңеленә сеңеп калырлык итеп сөйли белә иде ул. Логикасы көчле иде, җөмләләр, үзләреннән-үзе оешып, төз, җыйнак булып агылып чыга, әйтәчәк фикере, тирәнәйгәннән тирәнәя бара һәм сине үзенә җәлеп итә иде. Син аны бирелеп тыңлыйсың, сүзен бүлмисең.

— Мин үзем Тукай шигырьләрен беренче тапкыр рус телендә, Павел Радимов тәрҗемәсендә укыдым,— диде ул.— Әмма миңа чуваш телендәге тәрҗемәләр ныграк тәэсир итте. Тукай моңы, Тукай аһәңе дөресрәк сакланган аларда. Бәлки, халыкларыбызның бер үк географик һәм политик-экономик шартларда яшәвеннән дә киләдер ул. Аннары телләребез дә бер-берләренә бик якын. Шулай түгелме? «Шагыйрь» исемле шигырен күңелемнән беләм. Беләм генә түгел, еш кабатлыйм мин аны. Гаҗәп көчле шигырь! Егерменче еллар башында аны безнең Семен Чегесь тәрҗемә иткән. Шундый шагыйребез бар иде безнең.

Яныбыздан кешеләрнең узып-китеп йөрүләренә карамастан, ул Тукайның «Шагыйрь» исемле шигырен чувашча кычкырып укый башлады. Урыны туры килгәннән файдаланып, әйтим: Педер Хузангай үз шигырьләрен генә түгел, башкаларның шигырьләрен дә гаҗәп оста, матур укый иде. Артистлык таланты бар иде анда.

— Бу шигырьнең соңгы юллары миңа бигрәк тә ошый,— диде ул. Мин чувашча җитәрлек белмәгәнгә, аларны татарча укып күрсәтте:

**Җырлый, җырлый үләрмен мин үлгәндә дә,**
**Дәшми калмам газраилне күргәндә дә;**
**«Без китәбез, сез каласыз» — дип җырлармын**
**Җәсәдемне туфрак белән күмгәндә дә.**

— Гаҗәп бит! — диде ул, беркадәр кычкырып җибәреп, һәм уң кулын һавада болгап алды.— Нинди зур оптимизм! Яшәүнең үлем өстеннән тантанасы! Моны, шундый көчле итеп, бары бөек шагыйрь генә әйтә ала!

Шул ук елларда, Чабаксарга баргач, ул мине чуваш халык шагыйре К. Иванов һәйкәле янына алып китте. Һәйкәл Идел буендагы паркка куелган.

Шул ук паркта, бераз читтәрәк, К. Иванов музее да бар. Анда аның очраклы рәвештә генә сакланып калган кульъязмалары, үзе исән чакта басылган шигырьләре, соңыннан чыккан китаплары һәм төрле телләрдәге тәрҗемәләре бик зур тырышлык белән тезелеп куелган. Кешеләр кереп-чыгып йөриләр: эшчеләр, колхозчылар, укучылар, хезмәткәрләр. Чувашлар, руслар, татарлар, марилар...

Ә шагыйрь үзе, онытылмас «Нарспи» авторы, скульптор кулы белән иҗат ителгән К. Иванов, өзлексез шаулап, дулкынланып торган Иделгә, аның аръягындагы урманнарга, болыннарга карап, мәңгегә тынып калган.

Октябрь ае иде. Күк йөзен тоташ каплаган соргылт болытлардан вак, ябышкак яңгыр өзлексез сибәләп тора. Парктагы агачлардан соңгы яфраклар коела. Аларның кайберләре, җил белән очып килеп, һәйкәл итәгенә килеп төшәләр дә, шунда, җиргә ябышып, тынып калалар.

Бу юлы да кулларыбызда чәчәкләр иде. Соңгы чәчәкләр, көзге чәчәкләр. Аларны без шагыйрь һәйкәле итәгенә, юеш, саргылт яфраклар өстенә салдык.

Һәйкәл янында, эшләпәләребезне салып, тын калып, басып торганда, башымда һаман бер уй булды: «Чордашлар, рухи дуслар... Гәрчә, Тукай белән Иванов берберләрен белмәгән, бер-берләре белән очрашмаган булсалар да, рухи дус булганнар, үз халыкларының бердәй язмышлары, бердәй кайгылары, хәсрәтләре, матур хыяллары, өметләре турында җырлаганнар, аларны бәхетле, азат һәм культуралы итеп күрергә теләгәннәр, көрәшкә өндәгәннәр... Дуслык... Халыклар дуслыгы... Борынгыдан, бик борынгыдан килә ул. Аның кайчан башлануын, бәлки, тарихчылар да белми торгандыр...»

Педер Хузангай кешеләргә бик игътибарлы, җылы мөнәсәбәтле, һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер торучы гүзәл бер зат иде. Шуның белән бергә ул бик күңелле мәҗлестәш тә иде.

Моннан биш-алты ел элек без, берничә татар язучысы, Мәскәүгә, РСФСР Язучылары союзының чираттагы пленумына бара идек. Юл чәйләре инде эчелгән, сөйләшәсе сүзләребез беткән, күзләребезгә йокы керә башлаган иде. Тыштагы һаваның начарлыгы, кыек бәреп яуган көзге яңгырдан тәрәзәбезнең туктаусыз җылавы да безне җылыга, одеялларыбыз астына тарта иде.

Шундый минутларда, Канашны узгач, күрше вагоннан, безне эзләп, Педер Хузангай килеп керде. Гадәтенчә, җылы итеп, якын итеп, дусларча күреште, арабызга кереп утырды, сөйләшергә кереште.

Ул да Мәскәүгә бара. Ул да РСФСР Язучылары союзы идарәсе члены.

Сүз әдәби яңалыкларга күчте. П. Хузангай, беренче чуваш совет шагыйре Михаил Сеспель (1899—1922) шигырьләрен рус теленә тәрҗемә итеп бетереп, үзе белән Мәскәүгә алып бара икән.

Ул безне бу үзенчәлекле һәм бик талантлы шагыйрьнең тормышы, революциянең беренче еллардагы зур иҗтимагый-сәяси эшләре, Совет властен ныгыту өчен алып барган каты көрәшләре һәм иҗаты белән таныштырды.

Гаҗәп язмыш! Егерме өч яшь тә тулып җитмәгән бу талант та туберкулездан үлгән. Үзенең туган җирендә, Чувашстанда түгел, ә еракта, Украинада, Старогородка дигән авылда. Сыйнфый дошманнарның эзәрлекләүләре аркасында еракка, читкә китәргә мәҗбүр булган. Анда үзенең дусларын, фикердәшләрен тапкан.

Украина халкы аның каберен дистәләрчә еллардан бирле кадерләп саклый, бәйрәмнәрдә чәчәкләр китерә, аларны кабер өстенә сала, шигырьләрен укый. Гомерен, талантын халыклар бәхетенә багышлаган көрәшче беркайчан да онытылмый!

Без М. Сеспельнең иҗаты белән бераз таныш идек. Шулай да, Педер Хузангайның җанланып, бик рухланып сөйләве белән мавыгып китеп, тәрҗемәләрен укуын үтендек. Дустыбыз кыстатып тормады, куен дәфтәрен чыгарды. Аның һәр битен, бик тырышып, вак, йөгерек хәрефләр белән язып тутырган иде. Укырга кереште.

Ул укымый, ә Сеспельнең ялкынлы шигырьләре белән бергә яна иде шикелле.

Күпме вакыт узгандыр,— белмим. Йокыларыбыз онытылды, сүрәнлегебез бетте, күңелләребез күтәрелеп китте, хәтта купэбез дә җылынып, киңәеп, матурланып китте сыман.

Дустыбызны озатырга чыкканда, коридорда инде беркем юк, юлчылар күптән йоклаган, тик дежурный проводник кына, башын кулларына салып, стенага беркетелгән кечкенә урындыкта утыра. Ул да йоклый иде. Хузангайның узып китүен, ишекнең теләр-теләмәс ачылуын да сизмәде.

Чуваш дустыбыз чәйсез мәҗлесне дә менә шулай рухландыра, күңелләндерә белә иде.

П. Хузангайның татар теленә тәрҗемә ителгән кечкенә бер җыентыгы бар. Кайчакларда мин аны кулыма алам. Битләрен актарам. Миңа шигырьләрнең берсе, «Буран» исемлесе аеруча ошый. Зур түгел. 42 юл гына. Ләкин аңа шул кадәр тирән мәгънә салынган,— ул шагыйрьнең тормыш юлын, иҗатын, көрәшен тулысынча ачып бирә кебек.

Төн. Тышта каты буран. Ул, ачуланып, тәрәзәләргә килеп бәрелә, салам түбәләрне кыштырдатып уза... Өйдә, сүрән лампа янында, теләк тели-тели, әни карчык орчык эрләп утыра: «Адашкан бәндәләреңне бураннан коткар, хода, юл күрсәт, раббем, аларга»,— ди.

Шагыйрь аңа җавап бирә:

**...Белмисең, синең улың да**
**Буранда йөри, әни;**
**Юл салып олаучыларга**
**Һәм сузып ярдәм кулын,**
**Җырлары белән җылытып,**

**Юлларда яши улың;**
**Белмисең, әни, бу юлда**
**Елдан-ел читен аңа:**
**Иленә җылы өләшә,**
**Ә үзе суына бара...**

Дустыбыз Педер Хузангай чыннан да шулай, бу шигырьдәге лирик образча, туган иленә, халыкларга дистәләрчә еллар буенча иҗаты белән җылы өләште, аларны рухландырды, тәрбияләде, изге максатлар өчен көрәшкә чакырды.

Бу кайгылы юлларны язганда, дустыбыз, инде тәмам суынган килеш, салкын җир кочагында ята. Әмма аның шигъри җылысы безнең арада, томнарында, төрле телләрдә, китап киштәләрендә, халык кулында. Ул халык белән бергә матур киләчәккә, бөек коммунистик җәмгыятькә бара.

**МАРТ, 1970 ЕЛ.**

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЙОМГАК СҮЗЕ

Язучыларның гомуми җыелышы 1969 елда иҗат ителгән әсәрләрне «Яхшы тормыш җирдә була алмый — була алмый яхшы китапсыз» дигән принциптан чыгып барлады һәм Габдулла Тукайның «Һич риза булмыйм үземнән язганымнан соңра мин» дигән законы буенча бәяләде. Йомгак, гыйбрәт, анализ һәм тәҗрибә сүзе әйтеләсе төп чыгышларны быел Аяз Гыйләҗев (проза турында), Сажидә Сөләйманова һәм Рәдиф Гатауллин (поэзия буенча), Азат Әхмәдуллин (драматургия) һәм Гали Халитов (тәнкыйть) иптәшләр бик зур тырышлык белән һәм төпченүле итеп әзерләгәннәр иде. Аларның шул ук фикерләре соңыннан радиодан да әйтелде, матбугатта да басылды. Фикер алышуларда катнашучы Бакый Урманче, Равил Фәйзуллин, Рафаэль Мостафин, Фатих Хөсни, Зәки Нури, Шамил Рәкыйпов, Гариф Ахунов, Мөдәррис Әгъләмов һәм Ибраһим Гази иптәшләр еллык эшчәнлегебез нәтиҗәсе, әлбәттә, теге яки бу дәрәҗәдә куанычлы, әмма аны юаныч итәргә кирәкмәс дигән сүзне бик урынлы кабатладылар. Чөнки хикәяләрнең әле һаман да аз язылуы, заман темасына проблемалы очеркларның житенкерәмәве, масштаблы, көчле, әйдәп баручы образларга мул повесть яки романнарның соңгы елларда шактый сирәк күренүе кебек фактларга күз йомып карарга һич мөмкин түгел. Чыга торган әдәби китаплар санының да елдан ел күзгә күренеп артмавы шулай ук борчулы күренеш булып кала бирә. Шуңа күрә дә җыелыш, яңа иҗади уңышлар биеклегенә сузыласы яңа юллар җебен әдипләр күңеленә йомгак итеп урап, һәр язучының зуррак активлык белән эшләвен, Язучылар союзы идарәсенең исә һәр язучының көндәлек эшенә игътибарлырак, кузәтүчәнрәк, ярдәмчелрәк булуын, иҗат секцияләренең эшен тиешенчә оештыруны һәм җитәкләүне таләп итте. «Аеруча зур киеренкелек һәм киң колач белән оператив эшләүне Язучылар союзы үзенең яшь көчләреннән, хәзерге өлкән буын әдипләрнең әдәби алмашыннан көтә»... диелде чыгышларда. Яшьләр өчен осталар үрнәге, өлкәннәр тәҗрибәсе бар. Алар яңа төзелешләрдә төпләнеп, колхозларга-совхозларга барып, ерак маршрутларда йөреп, язылася китапларының геройлары белән бергә яшәп һәм бергә эшләп, зур күләмле әсәрләр иҗат итәргә тиешләр.

## НӘНИЛӘРНЕ КАЙГЫРТЫП

Язучылар союзының балалар әдәбияты секциясе мәктәпкәчә яшьтәге балалар әдәбиятының уңышлары, кимчелекләре һәм бурычлары турында фикер алышу үткәрде. Бу сөйләшүдә язучылар, Татарстан китап нәшрияты һәм Татарстан Мәгариф министрлыгы хезмәткәрләре, Татарстанның төрле почмакларында татар балалар бакчаларында эшләүче тәрбиячеләр, нәниләр өчен чыгарыла торган китапларга рәсем ясаучы художниклар, нәниләр өчен музыка иҗат итүче композиторлар катнашты. Анда филология фәннәре кандидаты Ф. Ибраһимованың мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен чыгарылган әдәбият турында, балалар әдәбияты секциясе җитәкчесе Мәрзия Фәйзуллинаның нәниләр өчен чыгарылган шигъри әсәрләр турында докладлары тыңланды. Фикер алышуларда композитор Б. Мулюков, язучы Р. Батуллин, Апас районыннан балалар бакчасы мөдире Г. Гомәрова, нәшрият редакторы — язучы Гәрәй Рәхим, Актаныштан балалар бакчасы мөдире Ф. Камалова, шагыйрә Зәкия Туфайлова, Татарстан АССР мәгариф министры урынбасары Н. А. Хамматова һ. б. иптәшләр катнашты.

## КОНКУРСТА КАТНАШТЫЛАР

1970 елда Габдулла Тукай исемендәге ике премия конкурсында Тукай исемендәге республика премияләре комитеты түбәндәге кандидатуралар катнашканын белдерде:

**Атилла Расих** — «Ике буйдак» романы өчен (1968 елда рус телендә «Когда расходятся пути» дигән исем белән чыккан вариант).

**Александр Сергеевич Ключарев** — «Канатлы яшьлек» исемле җырлар җыентыгы һәм татар халык музыкасын җыю, аны актив пропагандалау буенча зур эшчәнлеге өчен.

**Илһам Шакиров** — 1968—1969 еллардагы яңа концерт программалары өчен («Татар халык җырлары», «Җырларым сиңа, Октябрь»).

**Азат Габбасов** — «Җәлил», «Катерина Измайлова», «Оптимистик трагедия» операларында баш рольләр һәм Тукай сүзләренә язылган вокаль әсәрләр башкарганы өчен.

**Марсель Сәлимҗанов** — Татар дәүләт академия театрында «Американ», «Кыю кызлар», «Миркәй белән Айсылу», «Шамил Усманов» спектакльләрен куйган өчен.

**Николай Кузнецов** — «Татарстанның зур нефте һәм химиясе», «Мәскәүнең яңа силуэт-

лары» исемле индустриаль пейзаж күренешләре өчен.

**Алексей Спориус, Николай Артамонов, Валерий Охотин, Владислав Володин, Эдуард Волков** — Татар кулинария йортының декоратив-художестволы оформлениесе өчен.

## РЕЦЕНЗИЯ АВТОРЫ: «КРОКОДИЛ»

Хәзерге татар әдәбиятының юмористик һәм сатирик әсәрләреннән иң яхшы үрнәкләрне үткен шагыйрь һәм оста тәрҗемәче Иван Законовтан рус теленә тәрҗемә иттереп, Татарстан китап нәшрияты «Татар елмаюлары» («Татарские улыбки») исемле китап чыгарды. Китапка елмаюлы һәм җылы рецензияне биш миллион җиде йөз кырык мең тиражлы «Крокодил» журналы (№ 4, 1970 ел) язды. Анда: «Татар сатириклары коллективы күп санлы аудитория алдында зур әдәби концерт белән чыгыш ясый... ул концерт номерлары китабын өй өчен, гаилә өчен алырга мөмкин», диелә.

## ЯҢА ҖЫРЛАР

В. И. Ленинның тууына 100 ел, Татарстан АССР төзелүгә 50 ел тулу уңае белән иң яхшы җырга Татарстан профсоюзлар өлкә советы, Культура министрлыгы, Хор җәмгыяте, Язучылар һәм Композиторлар союзлары игълан иткән конкурс тәмамланды. Конкурска барлыгы 61 яңа җыр килгән иде. Беренче бүләккә лаеклы әсәр булмады. Икенче бүләк Рөстәм Яхинның «Туган ягым» исемле (Р. Байтимеров сүзләре), өченче ике бүләк Марс Макаровның «Татарстан таңнары» (Г. Афзал сүзләре) һәм Аллаһияр Вәлиуллинның «Байсар егете» (М. Ногман сүзләре) дигән җырларына бирелде.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР БИРЕЛДЕ

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының баш режиссеры **Марсель Хәким улы Сәлимҗановка** — театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем;

Җырчы **Абдулла Мөхәммәтгалим улы Рәхимкуловка** — татар музыка сәнгатен үстерүдәге һәм пропагандалаудагы хезмәтләре һәм югары башкару осталыгы өчен Татарстан АССРның атказанган артисты дигән мактаулы исем;

Минзәлә драма театры артисты **Җиһангир Җиһанша улы Җиһаншинга** — театр сәнгатен үстерүдәге уңышлары өчен Татарстан АССРның атказанган артисты дигән мактаулы исем бирелде.

## ЧИЛӘБЕДӘ ОТЧЕТ

Менә 60 ел инде Чиләбе шәһәрендә татар-башкорт китапханәсе эшләп килә. 1905 нче елда, ул заманның әдәбият сөюче шәкертләре, татар мәгърифәтчеләре куллары булган китапларны җыеп, кечкенә генә китапханә ачып җибәргән булганнар. Китапханәне яктырту, җылыту, өстәл-шкаф шикелле әйберләр булдыру өчен кирәкле акчаны да алар үзара җыешканнар.

Хәзер бу китапханәгә хөкүмәтебез ел саен меңнәрчә сум акча тота. Аның фондында инде 87 меңнән артык китап бар. Китапханәгә 6 мең китап укучы йөри.

Китапханә каршында егерме яшь язучыны берләштергән әдәбият түгәрәге эшли. Алар Чиләбе язучылар союзы бүлеге белән, Татарстан, Башкортстан язучылар союзы белән тыгыз элемтәдә торалар. 1970 елда Көньяк Урал китап нәшриятында чыккан «Уч төбендә кояш» исемле китапка түгәрәк әгъзаларыннан Салисә Гәрәева, Рамазан Шагалиев, Булат Батталовларның да шигырьләре кергән.

Китапханәдә татар, башкорт язучылары да еш була. Әле соңгы елларда гына да биредә шагыйрьләрдән Нәби Дәүли һәм Мөхәммәт Садри килеп киткән иде. Шушы елның март башында язучы Ләбибә Ихсанова һәм библиограф Асия Гыйниятуллина да Чиләбе китап сөючеләре белән очраштылар.

«Казан утлары» журналы буенча үткәрелгән укучылар конференциясендә журналның эше, алда басылачак әсәрләр, язучылар һәм Язучылар союзы эше турында бик күп сөйләнде. Кунаклар китапханәгә татар язучыларының автографлар белән биреп җибәргән китапларын һәм альбом төзү өчен язучыларның фоторәсемнәрен бүләк иттеләр. Күп санлы сорауларга җавап бирделәр.

Кичәнең соңында әдәбият түгәрәге әгъзалары үзләренең шигырьләрен укыдылар.

## ТАШКЕНТТА ҖӘЛИЛ КИЧӘСЕ

Герой шагыйребез Муса Җәлилгә һәм аның патриотик иҗатына багышланган бу кичә Үзбәкстанның Белемнәр йортында шагыйрьнең туган көнендә — 15 февральдә үткәрелде. Муса Җәлилнең тормышы, иҗаты һәм батырлыгы турында докладны кичәдә Җәлил һәм җәлилчеләр темасына диссертация якларга әзерләнүче Исхак Зәбиров сөйләде. Муса турында истәлекләр белән җәлилчеләрдән Г. Фәхретдинов һәм М. Мохсинов иптәшләр чыкты. Кичәдә Үзбәкстан ССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, драматург Зиннәт Фәтхуллин, күренекле шагыйрь һәм прозаик Әсгать Мохтар, Азиз Абдразак һәм Ташкент театрлары артистлары катнаштылар.

## ЯЗУЧЫЛАР БУА ҺӘМ САБА РАЙОННАРЫНДА

Язучы Хәсән Сарьян, шагыйрьләр Рәшит Гәрәй һәм Мөдәррис Әгъләмов, район газетасы хезмәткәре, башлап язучы шагыйрь Данис Хәбибуллин Буа районының Черкен-Килдураз, Бик-Үти, Толымбай, Исәк, Түбән Наратбаш, Кайбыч, Иске Тинчәле, Яңа Тинчәле авыллары мәктәпләрендә һәм клубларында укучылар белән очраштылар. Әдәби кичәләрдә һәм очрашуларда татар совет әдәбияты 50 елда ирешкән уңышлар

турында чыгышлар булды, яңа әсәрләр укылды.

Шундый ук очрашуларны Хәсән Сарьян, Галимҗан Латыйп һәм Мөдәррис Әгъләмов Саба районының 1 Май, Ленин, Муса Җәлил, Куйбышев, Карл Маркс, Фрунзе исемендәге, «Уныш» һәм «Алга» колхозларында үткәрделәр. Йомгак кичәсендә Сабада торучы шагыйребез Газиз Нәбиуллин да катнашты.

## МУЗЫКА МӘКТӘБЕНДӘ ҺӘМ ЭШЧЕЛӘР ТОРАГЫНДА

Совет Армиясе көне һәм Ватан сугышында бөек җиңүебез бәйрәме уңае белән Ватан сугышында партизан булып Константин Заслонов берләшмәсендә сугышкан шагыйрь Зәки Нури, сугышта дошманны бомбага тоткан очучы Юрий Белостоцкий Казан консерваториясенең махсус музыка мәктәбендә һәм «Спартак» аяк киемнәре фабрикасының эшчеләр торагы Кызыл почмагында укучылар белән очрашты.

## ӘСӘРЛӘР УКЫЛДЫ, ҖЫРЛАР ҖЫРЛАНДЫ

Лениногорск шәһәрендәге әдәби берләшмә Зәй-Каратай, Юлтимер авылларында, Лениногорск музыка-художество училищесында һәм 14 номерлы техник училищеда очрашулар уздырды.

Очрашуларда Шамил Бикчурин, яшьләрдән Альберт Хәсәнов, Җәмит Рәхимов, Разим Вәлиуллин, үзешчән композитор Фәйзи Хөснуллин, яшь җырчы Фәнис Йосыпов һәм музыка училищесы студентлары катнашты.

Яңа язылган әдәби әсәрләр укылды, Лениногорск шагыйрьләре сүзләренә яшь композиторлар язган җырлар башкарылды.

## УКУЧЫЛАРГА — ЛЕКЦИЯ, ШИГЫРЬ ҺӘМ ҖЫР

Шагыйрь, филология фәннәре кандидаты, Казан дәүләт университеты укытучысы Мостафа Ногман Арча районының Олы Мәнгәр урта мәктәбендә, Казанның 76, 80 номерлы һәм Галимҗан Ибраһимов исемендәге мәктәпләрендә, Әгерҗе районының тимер юлчылар клубында, милиция хезмәткәрләре клубында, Салагыш авылы 8 еллык мәктәбендә һәм культура йортында, Исәнбәт авылы урта мәктәбендә һәм культура йортында, Кадыбаш авылы урта мәктәбендә һәм культура йортында укучылар белән очрашты. Ул «Ульяновлар семьясы Казанда» һәм «Володя Ульянов Кокушкинода» дигән темаларга лекцияләр сөйләде, үзенең «Кокушкино таңнары» исемле һәм Советлар Союзы Герое Казанбаев турындагы поэмаларыннан өзекләр укыды, Ленинга, партиягә, туган илгә багышланган җырларын магнитофон язмасында яңгыратып, шуларның текстларын ничек иҗат итүе практикасын аңлатты.

## «ТАТАР АШЛАРЫ» КИТАБЫ РУС ТЕЛЕНДӘ

Күренекле пешекче һәм аш-су остасы Юныс Әхмәтҗановның «Татар ашлары» дигән китабын, күбрәк санлы укучыларга житкерү өчен, Татарстан китап нәшрияты быел 140 меңле тираж белән рус телендә бастырып чыгарды.

## ӘДӘБИЯТ-СӘНГАТЬ КИЧӘЛӘРЕ

Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге Язучылар союзы, Композиторлар союзы белән берсәләп Актерлар йортында күңелле бер эш башлап җибәрде: әдәби-музыкаль кичәләр оештыра башлады. «Муса Җәлил һәм музыка» дигән кичәдә Г. Кашшаф, Р. Мостафин, Ә. Исхак катнаштылар.

* * *

Г. Зәйнашева, Татарстанның халык артисткасы В. Шарипова һәм үзешчән композитор З. Гыйбадуллин Минзәлә районында җыр кичәләре үткәрделәр. Алар колхоз клубларында һәм урта мәктәпләрдә 20 гә якын чыгыш ясады.

* * *

Ю. Белостоцкий, В. Байдерин, В. Синев Биектау районының Чернышевский исемендәге совхозда һәм «Россия» колхозында әдәби очрашулар үткәрделәр.

* * *

В. Байдерин Казан гарнизоны хәрби хезмәткәрләре белән очрашты. Укучыларны В. И. Ленинның Казандагы, Кокушкинодагы тормышына багышлап язган хикәяләре белән таныштырды.

* * *

«Спартак» аяк киемнәре берләшмәсенең Культура сараенда шигырь һәм музыка кичәсе үткәрелде. Бу кичәдә Г. Рәхим, З. Маликов, композитор С. Садыйкова катнаштылар.

* * *

Политмәгариф йортында авыл советы председательләре белән язучыларның очрашуы булды. Ю. Белостоцкий, Г. Рәхим, М. Әгъләмов яңа әсәрләрен укыдылар.

* * *

Казан электр конструкцияләре заводы тулай торагында Н. Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында», «Җимерелгән бастион» романнарына багышлап укучылар конференциясе үткәрелде.

* * *

Р. Батуллин, З. Маликов, Г. Саттаров Казанның 97 нче мәктәбендә укучылар белән очраштылар.

* * *

В. И. Ленин исемендәге житен комбинатында «Совет әдәбиятында Ленин образы» дигән темага кичә үткәрелде. Кичәдә Ю. Белостоцкий, В. Байдерин, Е. Сойкин катнашты. Шундый ук кичә Казанның Суворов училищесында да булды. Анда Г. Паушкин, Ю. Белостоцкий, В. Синев катнаштылар.

* * *

А. Гыйләжев Казанның 94 мәктәбендә укучылар белән очрашты. Бүгенге татар әдәбияты торышы һәм үзенең хәзер нинди яңа әсәр язуы турында сөйләде.

* * *

5 мартта Дербышки поселогының культура сараенда Г. Минский, Г. Ахунов, Г. Рәхим матур әдәбият укучылар белән очраштылар. Поселок эшчеләре Г. Ахуновның «Яшьлек яме» повесте, «Хәзинә» һәм «Хуҗалар» романнары, «Канатлар кая илтә» исемле документаль хикәяләре турында җентекләп сөйләделәр. Шагыйрь Г. Рәхим яңа шигырьләрен укыды. Кичәне Г. Минский алып барды, ул татар әдәбиятының бүгенге уңышлары турында сөйләде.

* * *

Казанның 109 мәктәбендә Гариф Ахуновның «Канатлар кая илтә» исемле документаль хикәяләренә багышланган укучылар конференциясе үткәрелде. 6 нчы класс укучылары бу китапка бәйле рәвештә Татарстан турында бик күп материал өйрәнгәннәр. Конференция республикабызның катлаулы бай тормышы: аның тарихи үткәне, бүгенгесе, эшчеләр һәм колхозчылар тормышы, әдәбияты-сәнгате турында зур сөйләшүгә әйләнде. Конференциядә автор үзе дә катнашты, балаларның күп кенә сорауларына җавап бирде. РСФСР Язучылар союзының III нче съездына бару алдыннан Татарстан язучыларының эшләгән эшләре турында сөйләде.

## ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ АРХИТЕКТУРА ҺӘМ МУЗЫКА СӘНГАТЕ

Бу кичә Г. Тукай клубында үткәрелде. Татар халкының архитектура сәнгате турында тарих фәннәре кандидаты Фуат Вәлиев сөйләде. Татар халкының музыкасы турында музыка белгече Мәхмүт Нигъмәтҗанов чыгыш ясады. Кичәне язучы А. Шамов алып барды.

## АРХЕОЛОГЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУ

Татар халкының килеп чыгуы, аның Болгар чорындагы тарихы белән бик күп кеше кызыксына. Шуны искә алып Г. Тукай клубында язучылар белән археологларның очрашулары үткәрелде. Кичәдә тарих фәннәре кандидаты Равил Фәхретдинов иске Казан һәм борынгы Биләр шәһәрләре турында, анда алып барыла торган археологик эшләр хакында сөйләде.

*Хөрмәтле иптәш!*

«Казан утлары» журналына язылу дәвам итә.

Һәр айның 20 сенә кадәр сез алдагы айлар өчен журналга языла аласыз.

Журналга Советлар Союзының барлык почта бүлекләрендә язылырга мөмкин.

Аның өчен, журналның 73210 номерлы индексын әйтеп, аена 50 тиен исәбеннән акча түләү җитә.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ